# казан утлары

10
ОКТЯБРЬ-1971

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

10

ОКТЯБРЬ
1971

## Бу санда:

### РОМАН, ПОВЕСТЬ, ХИКӘЯ, ШИГЫРЬЛӘР

И. ЮЗЕЕВ. Маневрда шагыйрь бара... Һәр нәрсәгә карыйм... Шагыйрьләр нигә картаймый! Дуска. Шушы урамнардан атлап... Бер сүз. Хыяллар. Иптәшләре җәза бирделәр дә... Шигырьләр . 3

Г. АХУНОВ. Чикләвек төше. Повесть . . . . . 7

Р. ГӘРӘЙ. Гөрләп кабыныр төсле. Исемеңне язсын бүтәннәр. Тик шулай да... Карлыганнар каралган. Кем уйлаган... Ут йотып кайтып киләм. Олы һөҗүм шулай башланды. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . 46

Ә. БАЯНОВ. Ут һәм Су. Роман . . . . . . 48

З. НАСЫЙБУЛЛИН. Булды еллар... Һәйкәл янында. Безнең көнгә карый Спартак. Үлем түшәгендә... Кара аккош. Шулай булды... Шигырьләр . 95

Ф. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. Сайлаган юлымнан... Гомерләр бар... Туган көнемдә. Шигырьләр . . 99

Р. МИҢНУЛЛИН. Үзгәрешләр. Шамун Фиданга. Татар хатыннары. Шәһре Болгарда. Сагындыра. Элегия. Пират исемле эткә. Шигырьләр . . 100

Д. ЗӨБӘЕРОВА. Куш өянке шаһит. Хикәя . . . 103

### ДӨНЬЯ ӘДӘБИЯТЫННАН СӘХИФӘЛӘР

Р. БЕРНС. Тауларда минем йөрәгем. Сәфәрче төн кунган йорт. Финдлей. Син мине ташладың... Кырларның яңгыр, карларын... Җыр. Җыр. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 122

### ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

Р. МАКСУДОВ. Шәйморза кешеләре. Очерк . . 128

### ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Р. МОСТАФИН. Традицияләрне үстерик, тирәнәйтик . . . . . . . . . . . . . . . 139

Ф. МИҢНУЛЛИН. Үсеш баскычлары . . . . . 148

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

## ХАЛЫК ИҖАТЫ

Ә. ГАЛИЕВ. Керәшен татарлары җыры . . . . 153

## СӘНГАТЬ

И. ИЛЯЛОВА. Актерның иҗат юлы . . . . . 160

## ЯКТАШЛАРЫБЫЗ СӘЯХӘТТӘ

А. СКРЫПНИК. Могҗизаның кире ягы . . . . . 169

## ИСТӘЛЕКЛӘР, ЯЗМАЛАР

Л. ХӘМИДИ. Шагыйрьнең беренче бюсты . . . 177

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Б. КАМАЛОВ. Драматургиябез горурлыгы . . 179
Г. КАШШАФ. Фәхри Әсгат . . . . . . . . 182
А. ӘХМӘТ. Хөрмәтле язучыбыз . . . . . . 182

## ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

Г. МӨХӘММӘТШИН. Җыелыш. Хикәя . . . . . 185
Дусларча шаярулар . . . . . . . . . . . 186
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*
Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар. Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.

Баш редактор: **Гариф Ахунов.**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова,** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рафыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

---

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина.*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева.*

---

Производствога бирелде 1/VII-1971 ел. Басарга кул куелды 25/VIII-1971 ел. ПФ 09071. Кәгазь форматы 70×108[1]/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 79.346 экз. Заказ И-466. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1971 ел.

## Илдар Юзеев

# Маневрда шагыйрь бара...

«Туган илнең өч елгасын кичтем,
Һәр елгада тамды минем кан»...

«Фронт сәхифәсен актарганда
Соңгы сугыш диеп язарсыз»...

ДЕМЬЯН ФӘТХИ

Мина шартлый.
Шагыйрь ава.
Шагыйрь ята:
Соңгы сулыш.
Иреннәре
Тәкрар итә:
«Соңгы сугыш,
Соңгы сугыш».
Шагыйрь тына.
Өч елгага
Тамып алсу
Каны кала.
Җырларында
Тыпырчынып
Алсу-ярсу
Җаны кала.
Ракет. Бомба.
Күкләр тетри.
Җир күчәре
Сынар кебек.
Фашист уза,
Өч елгага,
Бар дөньяга
Кулын суза:
Туфрак шагыйрь
Кузгалырлык,
Сүз алырлык:
«Мин уйладым,
Мин ышандым,
Дөньяда дип
Соңгы сугыш.
Юк, мин түзеп
Ята алмыйм,
Алдым диеп
Соңгы сулыш»...
...Өч елганың
Ярын кагып,
Йөрәкләрдә
Дулкынланып,
Алсу-зәңгәр
Каны бара,
Маневрда,
Яшь солдатлар
Арасында
Шагыйрь җыры —
Җаны бара.

1971

●

Һәр нәрсәгә карыйм исем китеп:
Алтын көзгә,
Ачык йөзгә,
Бөдрә тупылга,
Уйчан Айга,
Шаян тайга,
Йөгерек дулкынга,—
Һәр нәрсәгә карыйм исем китеп,
Тәүге тапкыр күргәндәй итеп.

Һәр нәрсәгә карыйм исем китеп:
Сулган гөлгә,
Сүнгән көлгә,
Янган таңнарга,
Үкси-үкси,
Яулык селки
Калган ярларга,—
Һәр нәрсәгә карыйм исем китеп,
Соңгы тапкыр күргәндәй итеп.

Җиргә яңа туган сабый мин
Һәм сугышта үлгән абый мин.

1971

## Шагыйрьләр нигә картаймый?

Шагыйрьләр нигә картаймый?
Дөнья уе — башында.
Асыл кошлар затыннан ул,
Сандугачлар яшендә.

Болай да кыска гомерне
Мәгънәле итәсе бар,
Юлчы булып, дөнья буйлап
Сәфәрләр китәсе бар.
Тормыш дигән әкиятнең
Йомгагын сүтәсе бар,
Фатир сорап күңелләргә
Тәрәзә чиертәсе бар.
Картаеп сүнгән йөрәкнең
Бозларын эретәсе бар,
Үксезләрнең күзләреннән
Яшьләрен сөртәсе бар.
Гашыйкларны кавыштырып
Туенда биисе бар,
Сабыйларның бишекләрен
Тирбәтеп йөрисе бар.
Сандугач киткән күңелгә
Кунаклап сайрыйсы бар,
Дошман йөрәген тишәрлек
Хәнҗәр-сүз сайлыйсы бар.
Юлда адашып калганга
Маяклар тезәсе бар,
Үзеңне адаштырсалар,
Бирешми түзәсе бар,
Халык кайгырганда — елап,
Көлгәндә — көләсе бар,
Ил булып утка керәсе,
Ир булып үләсе бар.
Оясы юк, мөлкәте юк,
Каләме, биштәре бар,
Бар дөньяны тетрәтерлек
Җырлары-хисләре бар.

1971

## Дуска

Әгәр дә мин синең белән бергә
Эссе чүлгә китсәм,
Зар-интизар булып, комлы җиргә
Ятып сусыз кипсәм?

Әгәр дә мин синең белән бергә
Разведкага барсам,
Дошман угы күкрәгемә тиеп,
Яраланып калсам?

Әгәр дошман алга ялган өеп,
Хәйлә, мәкер корса,
Яки дустың, яки үзең диеп,
Мылтык төбәп торса?

Мине Сак итсәләр, безне аерып,
Сине Сок итсәләр?
Мине генә ирекгә калдырып,
Сине юк итсәләр?..

Туры җавап катгый сорауларга —
Тоям, дустым, иңдә.
Җәлил, Алиш түзгән сынауларга
Әзерме син? Мин дә!..

1971

●

Шушы урамнардан атлап киттем,
Шушы урманнарда атлар көттем,—
Юк, онытмадым.
Сине ташламаска антлар иттем,
Ә бер көнне ерак чыгып киттем,—
Юк, онытмадым.
Хәзер җырчы булып кайтып киләм,
Танымас дип, уйга батып киләм,—
Юк, онытмаган,
Җырым миннән алда кайтып кергән,
Авылдашка сердәш булып йөргән,—
Юк, онытмаган.

1960

## Бер сүз

Уйламыйча дустым бер сүз әйтте;
Йөрәгемә ул сүз кадалды.
Үзе берни белми, китеп барды.
Ә сүз калды.
Ул сүз тора минем йөрәгемдә,
(Аннан авыр яра юк сыман.)
Җәясеннән ялгыш атылып киткән
Һәм дустына тигән ук сыман.

1966

## Хыяллар

Хыяллар, хыяллар, хыяллар...
Күңелем еракка тартыла.
Китикме ал-зәңгәр үзәннәр,
Сахралар, дәрьялар артына?
Хыяллар, хыяллар, хыяллар...
Күңелем очардай талпына.
Меникме күп серләр яшеренгән
Һаваның җиденче катына?
Хыяллар, хыяллар, хыяллар...
Китерде җиде юл чатына.
Җиде төн уртасын балкытып,
Алдымда йолдызлар атыла.
Еракта таңнарым яктыра,
Хыялым тормышка чакыра.

●

Иптәшләре җәза бирделәр дә
Оныттылар.
Ә ул...
Түзсәң түз.
Эштә,
Өндә,
Төштә
Вөждан белән калды күзгә-күз.
Дус-ишләр дә аны аңладылар,
Кызгандылар,
Ә ул...
Әллә ни
Булды йөрәгенә,
Үз хуҗасын үзе җәлләми.
Акылы да шелтәләүдән тынды.
Бәхилләде, искә төшерми.
Тиле яшьлек кылган бер хатаны
Тик йөрәге,
Тик йөрәге мәңге кичерми.
Төзәтер өчен кире китәр иде...
Яшьлегенә кем соң кайтала?!
...Ул бары тик улына васыять итеп
«Кабатлама!» диеп әйтала.

1971

**Гариф Ахунов**

# ЧИКЛӘВЕК ТӨШЕ

ПОВЕСТЬ

## 1



Мин аңардан гел аерылам дип яшәдем.

Ул хакта беркайчан да, бер генә кешегә дә сөйләмәм дигән идем. Ләкин еллар үтеп, тормыш тәҗрибәм арткач, сөйләргә булдым.

Чөнки ул — кешеләргә кирәк.

Мин Казанның Яңа бистәсендә туып үстем. Безнең алты почмаклап салынган зур өебез, бистәгә дан тоткан алма бакчабыз бар иде. Сугыш елларында да мин әллә ни авырлык күрмәдем. Өстем бөтен, тамагым тук булды. Әтием меховойда тире иләүче булып эшли, әнием фабрика ашханәсендә аш өләшеп тора иде. Әни кичләрен ашханәдән, түбәләмә ике чиләк төяп, бәрәңге кабыгы, кәбестә калдыклары алып кайтып, сыер асрый, әти меховойдан яшереп кенә алып чыккан тире корамаларыннан пальто якасы, бүрек ише әйберләр тегеп, аларны таныш-белешләре аркылы талчукта саттыра иде. Ипи кытлыгы күрмәдек. Ситсы-мазарны чират торып алган булмады. Үзебез кайчандыр авылдан килгән булсак та, әти авылларны бик өнәп бетерми, фатирга кертми, ипинең һәр телеме үлчәүле чакта аның «авыл өерен» туйдырып ятарга бер дә исәбе юк иде. Аның дуслары булмады диярлек. Мин аларның берданбер баласы булып, күрше кызларыннан матуррак киенеп, ачлыкның ни икәнен дә белми үстем.

Халикъ белән танышкан чакта миңа унтугызынчы яшь иде. Кайвакыт кичләрен, чәй янында үзләре генә калгач, әтинең әнигә: «Кулдан озатырга кирәк. Бозыла торган товарның үз юлында булуы яхшы»,— дигән сүзләрен ишетә башладым. Алар мине әти кул астында эшләүче Гапсамат исемле төпле акыллы, тапканын әрәм-шәрәм итми торган, өстәвенә, читтән бер сандык мал да төяп кайткан бистә егетенә кияүгә бирмәкче булдылар. Егет безгә килеп утырды. Әти белән әни аның әле артына, әле алдына төшеп, өрмәгән җиргә генә утыртмадылар. Табынга мине дә чакырдылар. Әлеге Гапсамат буйга тәбәнәк булса да, гәүдәгә нык иде, ул миңа кыска бармаклы каты кулын биреп

күреште, ара-тирә генә сүз башлаштырып, гел этигә төбәлеп утырды. Мин чәй ясап тордым. Ул миңа ошамады дип кенә әйтсәм, дөрес булмас, Гапсамат минем күңелемә шом салды.

Кыска бармаклары белән чәй тәлинкәсен нык кына эләктереп, шопырдатып чәй эчкән чагында:

— Алай диген. Тә-әк. Тормышны таза көйләгән син, Гыйбау абзый,— дип, бер-ике сүз әйтеп куйгач, өйгә авыр тынлык иңә иде.

Әти кунак-мазар килгән чакта сандык төбеннән алып кия торган укалы кара түбәтәен арткарак чигереп, тегәрҗеп юанлыгы гына калдырып кырган кара мыегын, очлы кара сакалын бирчәйгән бармаклары белән сыпыргалап сүз башлады:

— Халыкның хикмәтле сүзен беләсең инде син, Гапсамат. Салам ялгыз казыкка түгел, парлы казыкка әләгеп кала, ди халык. Әдәм баласының үз вакытында казыгын какканы, үз куышын корганы мәслихәт.

Мин шунда кинәт эшләрнең кая барганын төшенеп алдым. Юкса, моңарчы Гапсамат өйгә кереп тормый, куенына тыгып килгән тирерярыны этигә өй алдында гына биреп китә, алар анда шыпырт кына сатулаша торганнар иде.

— Казыкны нык итеп кагарга ният бар, Гыйбау абзый, син тәҗрибәле кеше, дөньяның җаен беләсең, кулдан килгәнне булышкалап торсаң...— диде Гапсамат һәм чынаягын каплап куйды.

Әни бик өтәләнеп кыстаса да, ул бүтән чәй эчмәде, зур кара күзләрен тутырып миңа бер карады да, аннан күзен кыса төшебрәк, сөзеп кенә тагын бер карап алгач, китәргә ашыга башлады. Чоланга чыккач, мин аның эти белән кызу-кызу сөйләшкәнен ишетеп тордым, күңелемдәге шом тагын да артты. Әтинең сүзне өзеп сөйләшә торган гадәтен белгәнгә күрә, бүген, бүген булмаса иртәгә, парлы казык турында янәдан сүз кузгатачагын көтеп йөри башладым.

Минем күңелемдә икенче бер егет, безнең күршебездә фатир торучы Халикъ урын алганын алар белми иде әле. Халикъ Гапсаматның капма-каршысы: озын буйлы, җете зәңгәр күзле; гәүдәсенә сыланып, аны аеруча зифа итеп күрсәткән яшькелт френч киеп, лейтенант погоннары тагып йөрүче офицер. Яшькә дә ул Гапсаматтан күпкә яшь: күрше Хәерниса түтәйләрнең урыс капкасыннан ялт итеп килеп чыга да, минем дә көянтә-чиләк күтәреп капкадан килеп чыкканымны үтә сокланып каршы ала:

— Исәнме, күрше, суга барасыңмыни?! — дип, бик тә үз иткән ягымлы тавыш белән дәшеп кала.

— Суга барам шул...— дим мин дулкынланып. Аның белән якын булуымнан каушап һәм шул ук вакытта җанымда әйтеп бетергесез рәхәт бер тынычлык тоеп, үз юлыма китеп барам. Җилкәм белән тоям: ул мине чаттан борылганчы озатып кала...

Безнең әле ялгыз калып сөйләшкәнебез дә юк, аның мине якын күрүен күңелем белән сизсәм дә, «Кем соң моның сөйгәне булыр икән?» — дип уйлыйм, шул билгесез кыздан хәтта көнләшә үк башлый идем.

Гапсамат безгә килеп киткән көнне мин күкрәк турымда нәрсәнеңдер бик авырттырып сыкрап торуын сиздем. Зарыгып, тилмереп кич җиткәнне көттем. Чоландагы кисмәккә дә, бакчадагы кисмәккә дә тутырып су китердем, ләкин ул көнне миңа Халикъ очрамады, мин көне буе пошыргаланып, әледән-әле ян тәрәзәгә килеп, аның эштән кайтканын көтеп йөрдем.

Ул кайтмады.

Өстен иске чүпрәк белән кысып бәйләгән зур гына ике чиләк күтәреп әни кайтты. Кухня ягында бәрәңге кабыкларын юып пешерергә куйды. Аның көн саен гадәтләнгән бу эшенә мин булыша торган идем. Бүген

никтер булышасым килмәде. Кухня ягына күңел болгаткыч әчкелтем бәрәңге кабыгы исе таралгач, кәефем бөтенләй кырылды.

Әти эштән кайтып, такта сарайда эш киемнәрен салып керде, гөлбәчтә озаклап юынды. Кичкырын булса да сакал-мыегын кырып кайнашты. Сандыктан укалы кара түбәтәен эзли башлагач, мин: «Тагын Гапсамат килә микәнни?» — дип борчылып, почмак якта утырдым. Юк, бәхетем, килмәде Гапсамат. Ләкин әни табынны кунак килгәндәге төсле итеп әзерләде. Бер йомарлам базар мае, бавырсак, кәрәзле бал куйды.

Мине бик яктырып чәй янына чакырдылар.

Чыктым.

Сүзсез генә чәй эчтек. Әти сакалын чеметкәләп, тамак кыргалап утырды. Мин аның миңа әйтер сүзе барлыгына төшендем. Бераздан ул өй алдына чыгып китеп, бер төенчек күтәреп керде. Аны ашыкмый гына чиште. Биек итеп күпертеп җыйган тимер караватка — минем урынҗирләрем өстенә — елкылдап торган чытыр ак атлас чыгарып салды.

— Кызым, Рокыя, кил әле монда, ошыймы бу сиңа? — диде.

— Ошый,— дидем, хәтерләрен калдырмас өчен әйттем. Атласта кайгым юк иде.

— Бигрәк тә матур инде. Каян алдың бу хәтле затлы әйберне? — диде әни, әтигә куштанланып.

— Гапсамат табып китерде. Ике бәясен бирсәм бирдем, ди, әмма ләкин малны кулдан ычкындырмадым, ди.

Әти атласны озынчага сузып, минем буема салып карады. «Әлләлә!» — дип тел шартлатты. Тик минем сөмсерләрем коела башлаганны күреп, яңадан челтәр япма өстенә илтеп куйды.

Нәкъ шул мәлне ишек шакыдылар, әтиләр аны-моны әйтергә өлгергәнче, ишек ачылып китте дә, безгә... милиция киеменнән Халикъ килеп керде. Әнинең йөзе көл кебек агарды, әти, ашыгып, атласны яшерергә маташа башлады.

Мин кулларымны кушырып, караваг буенда басып калдым.

— Гафу итегез,— диде Халикъ, тотлыгыбрак сүз башлады.— Унайсыз булса да керергә туры килде. Хәерниса карчыкның капка-курасы аварга житкән. Тол карчык үзе бер ни дә булдыра алмый, шуларны турылап куярмын диган идем. Гыйбадулла абзыйның кораллары булмый калмас, дидем. Балта белән тигезләгеч кенә биреп торыгызчы...

Әтинең каушавы йөзенә үк чыккан иде. Ул беркавым зиһенен җыя алмый торгач:

— Хәзер табабыз аны...— диде.— Балтасы лапаста инде аның... Тигезләгечен кая куйган нем соң әле? Менә син тамаша, кара инде... хәтер диген инде шуны да... Миңкамал, әй кем, кызым Рокыя, син белмисеңме? Табып кына бирче булмаса. Әй, туктале, кем, чибәр егет, исемеңне белмим. Табынга рәхим итәр иең...

Халикъ йомшак кына рәхмәт әйтеп, борчуы өчен тагын бер мәртәбә гафу үтенеп, ишектән чыкты. Мин дә, тигезләгечне табу сылтавы белән, аның артыннан чыктым.

Такта сарайдан, әтинең эш кораллары яткан шкафтан тигезләгечне эзләп таптык. Халикъ, каушый төшеп, кулымнан җиңелчә генә тотты да:

— Рокыя, мин синең белән очрашыр идем,— диде.

— Кайда? — дидем, ашыгып.

— Милиция идарәсендә.

— Син ни сөйлисең?.. Нишләп мин анда барып йөрим? Минем хакта ни уйламаслар.

— Кайда соң, алайса?

— «Тукай» киносы янында

— Кайчан?

— Иртәгә. Көндезге уникедә.

— Ярый.

Ул, иелә төшеп, сарайның тәбәнәк капкасыннан чыгып китте. Мин, тәнем буйлап йөгергән калтырауны басар өчен, беркавым сарай буенда торырга мәҗбүр булдым.

— Рокыя, кайда син? — дип, әни ишектән башын тыгып дәшкәч кенә өйгә кердем.

Әтинең миңа ак атлас күрсәткәндәге дәрте сүнгән иде инде. Миңа таба бер генә күтәрелеп карады да:

— Сиңа алай бик чәчрәп чыгарга кирәкмәс ие... Яратмыйм шул милиция халкын. Балта дигән була, берәрсе чагып, иснәнеп йөрүе түгел микән? — диде.

Минем бу сүзләргә хәтерем калды — дәшмәдем.

Икенче көнне сәгать уникегә житкәнне көч-хәл белән көтеп алдым да «свиданиегә» киттем. Әти белән әни эштә иде әле.

Халикъ анда иде инде, кинотеатр янына жыелган халык арасында, сәгатенә караштыргалап, арлы-бирле йөреп тора иде.

Мине күрүгә ашыгып кына яныма килде, рөхсәт сорап култыклады, без каршыдагы бакчага кереп утырдык.

— Я, ярар, мин бу сүзне кайчан да булса әйтергә тиеш инде,— дип, йомшак кына итеп кулларымнан алды.— Мин яшь кеше түгел. Сугышта йөреп кайттым. Ике мәртәбә яраландым. Акны ак дип, караны кара дип таный беләм. Сугышка кадәр елгачылар техникумына кергән идем. Соңгы курсыннан китеп бардым. Артиллерист. Менә Казанга кайттым. Әти үлде. Әни исән, сеңелем бар, укый, минем белән яшиләр.

— Сез миңа боларны нигә сөйлисез? — дидем аптырап.

Ул гаҗәпләнде. Борын очы тирләп чыкты. Кулларымны кинәт җибәрде дә моңсуланып калды. Аннары әкрен генә, гафу үтенгән тавыш белән әйтте:

— Синнән башка көн юк миңа, Рокыя... Мин сиңа гашыйкмын,— диде.

Гүя өстеннән тау төшкәндәй, көрсенеп куйды.

Аның шундый гадилеге, мин газапланып йөргән тойгыны туп-туры әйтеп бирә алуы мине таң калдырды, хәтта каушатып җибәрде. Әле күпмедер бергә йөргәч, бер-беребезне ныклап белгәч, ягъни мине зур хискә әзерләгәч әйткән булса, мин дә бәлки аңа инде ул безнең күршегә килеп тора башлагач ук күзем төшкәнне, аны күрү үзем өчен бәхет икәнлеген әйтеп бирә алыр идем. Бигрәк кисәк булды шул бу. Мин аңа:

— Ә сез нигә... милициягә кердегез? — дип кенә әйтә алдым.

— Тәртип урнаштырыр өчен...— диде ул, өзеп кенә.

«Тәртип урнаштыру» минем әтиләрем көткән дөньяга да бәйле иде. Ул дөнья мине бәхетле итә, гамьсез итә иде. Кинәт мин Халикъның әтиләрне кулга алуын, жавапка тарттыруын күз алдыма китердем. Күземне камаштырып ак атлас чагылып китте. Минем өчен изаланып йөргән әтием кызганыч булып тоелды. Иркә бала булып үсүем, сугыш чорында да авырлык күрмәвем, алты почмаклы таза йортта, мул тормышта яшәвебез өскә калыкты:

— Юк, мин милициягә кияүгә чыкмыйм,— дидем.

Халикъ күзгә күренеп үзгәрде, аның озынча ак йөзенә, очкын чәчеп торган зәңгәр күзләренә рәнҗү бәреп чыкты. Ул хәрбиләрчә төгәл, нык хәрәкәт белән урыныннан торды да ике генә сүз әйтте:

— Гафу итегез. Ялгышканмын.

Саубуллашмыйча да китеп барды.

Горур кеше иде ул Халикъ. Мин моны ул чакта бөтен асылы белән аңлап житкермәгәнмен, аның шулай кискен кылануына аптырап, «свиданиегә» чыгуыма гарьләнеп, кайтып киттем.

Әтиләр өчен бу бик тә кулай булып чыкты. Милиционер Халикъ безгә керүдән туктады, мин аны суга барган чакларымда да очратмас

булдым, минем бәхеткә Гапсамат торып калды. Шулай булмыйча соң — үз бәхетемне үзем җимердем бит.

Эшләр чынга китте. Гапсамат безгә көн аралаш килә. Этиләр хәзер мине Гапсаматка кияүгә бирергә әзерлиләр. Әни ашханәдән көн саен алып кайткан бәрәнге кабыгын пешереп, минем туема тана симертә. Эти бирнәгә дип затлы мехтан тун тектерергә бирде.

Гапсаматның күңелендә тирән тойгы булуына шикләнә идем мин. Аңар, мөгаен, каеныта буласы кешеләренең таза хәлле булуы гына ошыйдыр, дип уйлый идем. Чөнки ул безгә килгән саен гел дөнья көтү турында сөйләшә. Этинең авызына кереп, үзенә кирәкле акыллы сүзне генә йотып утыра иде.

Гапсамат аракы эчми. Минем эти дә шешә белән дус түгел. Мин тик бер генә мәртәбә аларның мәҗлес корып утырганнарын күрдем. Эчми эчкәнгәме, Гапсамат кызган иде.

— Их, бабай...— дип, этигә тарсынмый-нитми кияү булып дәшеп, мине бал-май эчендә генә йөздерәчәген әйтте. Әшнәләре аны хуплап тордылар. Утыра торгач, Гапсамат:

Казгансаң маллар табыла,
Йөрәккә кан савыла,—

дип җырлап та җибәрде. Тавышы аның куе, матур тавыш, тик ул җырның тәмен дә, моңын да аңламый иде бугай. Бистә егетләре кебек, тавышын чамадан тыш калтыратып җырлый иде.

Әшнәләреннән берсе Гапсаматтан да уздырып җибәрде.

— Ну, ахири, чикләвекле имән ава инде өстеңә, бәхетле йолдыз астында тугансың икән, чукынмыш! — дип, йодрыгы белән тегенең күкрәгенә төртеп алды.

Мин мондый ачыктан-ачык әрсезлектән йөземне чытып чыгып киттем. Егетләрнең арттырып җибәрүләрен эти дә сизде бугай, ул мәҗлес халкын алма бакчасын карап керергә чакырды.

Минем дәшми-тынмый йөрүемне этиләр ризалык билгесе дип аңладылар, ахрысы. Минем белән шул хакта бер көнне кичен, чәй эчеп утырганда, чынлап торып сөйләштеләр.

— Кызым,— диде эти,— яшең дә җиткән, кием-салымың да житәрлек, үзебез исән чакта әйбәт урынга биреп калырга ниятләп торабыз. Кыз бала гомер буе ата-ана йортын саклап утырмас. Әмма ләкин синең ризалыгыңнан башка ул дәү эшне эшләп булмый.

— Кемгә? — дидем. Халикъ кебек, сүзне өзеп сөйләшәсем килде.

— Күзең сукыр түгел, күреп торасың, Сәмигулла абзый малае Гапсамат синең өчен җан атып йөри. Нәсел-нәсәпләре дә ил-көн алдында хур итә торганнардан түгел. Эчеп-исереп кеше көлдергәннәре юк. Нәселләрендә катын белән шаяручылар да күренми, аллага шөкер. Әллә, мәйтәм, озын-озакка сузмыйча, тәвәккәлләп, туеңны итеп алабызмы?

Мин байтак вакыт дәшми утырдым. Этигә кушылып, әни дә Гапсаматны мактады. Мал таба торган җегет, малның кадерен белә торган җегет, тәкми-чәчми, әрәм-шәрәм итми, кулында менә дигән һөнәре дә бар, диде.

Күңелемдә котырынып кире тойгы уянды.

Халикъка өзеп әйткәнне, нигә дип әле мин Гапсаматка да өзеп әйтмәскә тиеш? Өзеп әйтсәм, этиләр бердәнбер кызларын теләмәгән кешегә биреп, гомер буе аның каргышын алып яшәргә теләрмени?

— Юк, эти, көчләмәгез мине, яратмыйм мин Гапсаматны,— дидем.

— Әй-йәй-йәй! Менәтерәк, әйтте бу! — диде эти.— Йә, кем генә соң яраткан кешесенә кияүгә чыга? Тора-тора яратасың аны... ийе, һм... Моңарчы, кызым, алланың биргәненә шөкер, безнең сүздән чыкканың юк иде, анысына рәхмәттән башка сүзебез юк, әмма ләкин соңгы сүзең

белән рәнҗетәсең син безне... Иә, кай төше кемнән ким Гапсаматның? Буе-сыны бар, нәсел айгырларын егып салырлык тазалыгы бар. Ай һай, балам, бу заманда, сугыштан соң өшәнеп беткән бер вакытта Гапсамат кебек алтын җегетне кулдан ычкындыру, мин сиңайтим, исәрлек! Заманасы да бит аның сайлана торган замана түгел. Сугыштан кайтканы гарип-гораба, сугыш вакытында буй җиткәне — чирлечирләшкә...

Әтинең кычкырмый-бакырмый гына аңлатырга теләве күңелемне йомшартып җибәрде. Каты бәреләсем килмәде:

— Юк, әти, ирексезләмәгез. Мин әле укырга телим,— дидем.

— Кайда, кем булырга? — диде әти.

Ул минем дәшми торуымны күреп, бик тә үз иткән, кечелекле тавыш белән үгетләргә кереште:

— Без сиңа, балам, изгелектән бүтән бер ни дә теләмибез. Әмма ликин кисәтеп куям, кара аны, суңыннан үкенерлек булмасын. Сәмигулла абзый малаена кызның менә дигәннәре табылыр...

Әтиләр мине бүтән кыстамады. Тик аларның дөньяда гамьнәре дә калмагандай булды. Әни өйне гөл кебек итеп тоту гадәтен ташлады, әти бер-ике тапкыр кызмача кайтты. Безнең җитешле түгәрәк тормышның гүя бер ягы кителеп төште. Әтиләр әллә ничек кызганыч. Әллә Гапсаматка кияүгә чыгаргамы? Ялгыз өйдә, япа-ялгызым үскәнгә, әлегә бер җирдә дә төпләнеп эшләмәгәнгә, минем таныш егетләрем юк, укуны да мин сылтау итеп кенә әйттем. Укымаган кеше дә үлми. Әнә бит әни укымышлы кеше сайлап тормаган, тоткан да дүрт класс белемле әтигә кияүгә чыккан. Нәрсәсе начар? Әшен дә эшли әти, тормышын да алып бара. Кеше арасында хур булып торганы юк. Халикъ, мин кырт кисеп сөйләшкәннән соң, безнең күршедән күчеп үк китте. Ул миңа бүтән әйләнеп тә карамаячак.

Бер көнне өйләрне җыештырып, урын-җирләремне тагын бер мәртәбә кабартып җыйгач, шул уйларым белән миңгерәүләнеп, путаллы зур көзге алдына килеп бастым. Миңа хәзер егерме тулып килә. Яшьлегем үтеп бара түгелме? Минем әле йөзләрем алсу, күзләрем сөрмәле, буйсынымның тал чыбыгыдай зифа чагы, нигә миңа Гапсаматның иркә хатыны булып, йорт биләүче акыллы хуҗа бикәсе булып яшәмәскә? Тагын дүрт-биш ел торсам, яшьтәш егетләрем өйләнеп бетәчәк, мин сазаган кыз булып утырып калачакмын.

Миңа үзем, үземнән дә бигрәк, минем кайгымнан бетерешеп, гомер буена рәнҗеп яшәячәк әтиләрем кызганыч тоелды. Чыннан да, Гапсаматның кай төше кемнән ким? Кулында һөнәре бар, мал кадерен белә торган холкы бар. Ярый, дорфарак та булсын ди, юнылмаган бүкән булсын ди. Аннан кемгә зыян? «Ир — баш, хатын — муен» дигән сүз дә бар бит әле. Муен борылмаса, баш борыла алмый. Мин, ун класс укыган кыз, Гапсаматны тәрбияли алмаммыни? Аны дорфа кыланышларыннан арындыра алмаммыни?

Гапсаматта булмаганны бар итеп күрергә, аны матур һәм нечкә күңеллерәк итеп күз алдына китерергә тырышып яши башладым. Хыялым эшкә җигелде.

Уйларымны әти-әнигә әйтмәдем әле. Шулай да бер көнне әти Гапсаматларга өй туена барырга кирәклекне әйткәч, карышмадым.

Матуррак күлмәгемне, бәйрәмдә генә кия торган кытай туфлиемне сандыктан алгач, әтинең чырае яктырды, ул ничектер сүзчәнләнеп китеп, кием-салымыңны кызганма, бетсә тагын алырбыз, дип әйтеп куйды.

Өчебез дә, өф итеп кенә киенеп, өй котларга барып кайттык.

Бу бару минем күңелемне тагын да Гапсамат ягына аудара төшкәндәй булды. Ул өстенә буйлы ак күлмәк, кара бостон костюм, аягына ул чорда бистә егетләре өчен бик модалы булган, балтырлары кайтары-

лып куелган күн аслы ак фетр кигән иде. Аның чукечтәй нык гәүдәсе, ташып торган кара тутлы алсу йөзе бу юлы миңа хәтта чибәр дә булып күренде.

Рокыя туташ дип, Гыйбау абзый, Минкамал түти дип, аяк өсте торып безне сыйлаулары, аракы-мазарны да эти белән икесе безгә күрсәтми, почмак якта гына төшереп керүләре минем күңелемә гел менә хуш килде.

Мин дә тырыштым.

Дәшкән чакта ягымлы итеп, бераз гына назланып, үз кадеремне үзем белеп дәштем. Тойгыларым кузгалганга алсуланып киткән йөзем (зур путаллы көзге минем каршымда иде) мәҗлес халкына бик тә ошап куйды булса кирәк, ул көнне мин мәҗлеснең күз өстендәге кашы булдым. Бу минем тәкәббер горурлыгымны, үз-үземне яратуымны арттырды. Һәм шул кич минем язмышымның борылып китәчәгенә сәбәпче дә булды.

Әтиләр Гапсамат турында кабат сүз кузгаткач, әллә ни назланды-рып тормадым. Ике өйдә дә туй әзерлеге башланды. Бәйрәмчә аш-су: табак-табак бавырсак, чәкчәк, кош теле әзерләдек. Әллә ничә төрле паштет пешердек. Идәннәрне кырып юдык. Келәмнәрне кагып элдек. Синькаланган челтәрләр тәрәзәләргә ямь биреп, өйгә бәйрәм төсе кертте. Ишек алларын кат-кат себердек. Кунакларның караватта гына сыймаганын йоклатырга дип, эти тапчаннар ясады, юрган-матрасларны март кояшында җилләтеп, тузаннарын кагып керттек.

Булачак туй мәшәкате әни белән икебезгә бер атнага житте. Әтигә дә отпускысын шушы вакытка туры китереп алырга туры килде. Мин моңарчы күреп карамаган өр-яңа тормышка әзерләнеп, төннәрен хәвефләнеп яшәдем. Йокым качты. Моны әни бик тиз сизеп алды. Ул төнге сәгать икеләр тирәсендә минем яныма чыга, ак мендәргә сибелеп киткән чәчләремне сыйпап, беркавым янымда утырып тора, тик сүз катмый, сүз катудан ул ничектер уңайсызлана һәм, мин тагын да күбрәк борчуга төшмәсен дип, аналарга гына хас булган бер сизгерлек белән минем алгы көнемне кайгырта иде.

Мин йоклый алмый ятам.

Тәрәзәдән бәс сарган алмагач ботаклары күренә. Ә күк йөзендә, бәсле ботаклар арасыннан, зәңгәрсу йолдызлар тетрәнеп яна, алар бер кабынып, бер сүнеп торалар, я бик якын, я хыял житмәс ерак булып тоелалар...

Туйга ике-өч көн генә калгач, кодалар килеп, туй хәстәренең ничек барганын белешеп киттеләр. Күп сөйләшмәделәр. Гапсаматның әнисе минем әни кебек йомшак күңелле, йомыкый гына бер карчык икән, алар әни белән яшереп кенә бер елашып та алдылар.

Мин инде беркемнән дә бәйсез кыз чакларымның үтеп барганын, тиздән миңа килен булып кеше йортында хезмәт итәргә туры киләчәген аңлап, яшьлегем белән аерылышу тойгысыннан күңелем тулып, төнне елап үткәрдем. Әни ике мәртәбә яныма килеп, башымнан, ак мендәргә таралган кара чәчләремнән сыйпап китте.

Ләкин көтмәгәндә безнең гаилә өчен бик күңелсез хәбәр килеп әйттеләр.

Иртәгә туй дигән көнне Гапсаматның әнисе килде. Самавырга барып тотынган әнине туктатып, шыпырт кына әйтте:

— Ашыкмый тор әле, Миңкамал, чәй куярга. Өйдәгеләргә әйтмичәнче генә киткәнием. Эшләрнең көе китеп тора бит әле...— диде, яулык чите белән күзләрен сөрткәләп алды.

— Ай аллам, ни булды тагын? — дип, әни булачак кодагые өчен хафалана башлады.

— Гаптелсаматымны алып киттеләр.

— Китсәнә! Кая?!

— Милициягә алып киттеләр. Кичәгенәк төннә ике милиция килде. Ак өебезнең ишегенә йозак салдылар. Өй янына берәүне бер китермәскә куштылар. И кодагый, ниләр генә булыр икән ул балакаема?..

— Әллә михавайдан берәр нәрсә алып чыкканыемы?

— И-и-и әйтмә инде, Миңкамал, нәфсе дигәннәре шайтан бит. Туй расхутларына булыр дип, бер каракүл тире алган. Аны күлмәк эченнән урап кигән. Вахтачы карт — яңа себерке — тентегән булып кыланып милиция чакырткан, тиресе-ние белән алып киткәннәр. Бүген пүнәтәйләр белән килмәкчеләр. Ай! Килгәннәрдер дә инде. Йөгерим. Ул-бу нәрсәгез булса, зинһар, яшерегез. Күрше-коланга ышаныч юк, бер-берсен сатарга гына тора, сезне дә харап итеп куймасыннар.

Әнинең кулыннан самавыр капкачы төшеп китте. Яңа хәбәрне әйтергә дип, ул әти янына сарайга йөгерде. Сандыкта тире кисәкләреннән җыеп теккән ике бүрек бар иде, аларны кая куярга белми чабышып йөри башладылар.

Гапсаматның әнисе Гөлниса җиңги ни төсле өтәләнеп килеп кергән булса, шундый ук кызулык белән бәреләсугыла чыгып та китте.

— Бәхетләрең юк икән, балакаем, и-и-и, юк икән бәхетләрең! — дип, әни миңа карап елап җибәрде.

Әти аңа бер генә кычкырды:

— Җитте сиңа! Яп авызыңны! Тапкан монда эт кебек улап утырыр вакыт. Килеп җиткәннәрен көтәсеңме? Ач сандыкларыңны, тиешлетиешсез әйберең булса, чыгар... Әгәренки мин югында Гапсаматны сорап килсәләр, белмим диген. Төшендеңме?

— Туктале, әтисе, ничек инде олы башым белән алдашып утырыйм? Гапсамат кияү буласы кешебез ләбаса...

— Кияү буласы! Бирерләр сиңа киявеңне! Мине төрмәдә череткәннәрен телисеңме? Булыр сездән. Ни чыкмаса катын-кыздан чыга. Тарчалатып, жыландай телемне чыгарып әйтәм, ишетсен колагың: белмим диген. Белмим! Белмим! Белмәгән дә күрмәгән — мең бәладән котылган. Гапсамат безнең өчен юк хәзер, юк! Рокыя, ишеттеңме?

Гапсамат хәлләрен Гөлниса җиңги безгә көн саен җиткезеп тора. Аларны тентегәннәр. Ун каракүл бүрек, җиде баш тире, алты кисәк бостон отрезы алып чыкканнар.

— Ниләр күреп җыйдыгыз шул тамашаны? — диде әни, Гөлниса җиңгигә шелтә белән карады.

— И-ии әйтмә инде, Миңкамал, күрәчәк күмер ашата, ди. Нәфсе бит, нәфсе, күрәчәгебез булгандыр инде...

Әти дөрес сизенгән икән.

Гапсаматның җиле безгә дә килеп кагылды. Егетне кулга алганнан соң бер атна чамасы узгач, шөкер, килүче-китүче юк дип тынычланып кына утырганда, мине машина белән килеп милиция идарәсенә алып киттеләр.

Әни хәтта сау бул дип тә әйтә алмады. Телдән язып, күгәрде дә катты.

Мин, милиционер ишетсен дип, әнинең иңбашларыннан сыйпап әйттем:

— Борчылма, әни, мин бик тиз әйләнеп кайтырмын, безнең бер гаебебез дә юк бит,— дидем.

Яңа бистәнең Аскы урамындагы, тәрәзәләре тимер рәшәткәле зур гына агач йортның коридорына килеп кергәч, күңелемне курку басты. Иске телогрейка, дәү кирза итек кигән бер кешене мылтыклы милиционер миңа каршы коридор буйлап алып килә иде. Моның Гапсамат булып чыгуыннан йөрәкләрем алынып, бер читкә тайпылдым. Уф! Гапсамат түгел икән. Бәлагә эләккән бер Гапсамат кына димени дөньяда!

Мине алып килгән милиционер коридордагы бик күп ишекләрнең берсен ачып җибәрде. Караңгы гына коридордан соң яп-якты кабинетка

тордым.

Боларны мин нигә бик төпченеп сөйлим? Бу — минем тормышымда гаять мөһим момент, бәлки шуңа күрәдер, ул минем күңелемә бик тирән уелып калды. Күзләрем камашып, бер ни күрми торган арада мине алып килгән милиционер:

— Иптәш өлкән лейтенант, гражданка Гыйбадуллина сезнең карамакка китерелде,— дип чатнатып әйтеп честь бирде.

— Китәргә мөмкин,— диде аңар өлкән лейтенант дигәннәре.

Һәм мин, өстәл янында каккан казыктай басып торган чибәр лейтенантның Халикъ Саматов икәнен күреп, артыма егылып китә яздым.

— Утырыгыз, гражданка Гыйбадуллина,— диде миңа үтә дә таныш һәм үтә дә чит рәсми-коры тавыш.

«Менә нинди хәлләрдә очрашасым бар икән минем аның белән! — дигән уй миемне яндырып узды.— Беләсе иде, мине ул эш белән чакыртканмы, әллә минем теге көнге отказым өчен үч алырга җыенамы? Әгәр үч алырга чакырткан булса, ул бик әшәке кеше булып чыга, мин аңа бер сүз дә әйтмәячәкмен».

— Сез мине гафу итегез, Рокыя туташ,— диде ул, милиционер чыгып киткәч.— Мин сезнең белән башка урында очрашуны кулайрак күрер идем, ләкин нихәл итмәк кирәк, хезмәтем миннән рәсмилекне таләп итә.

Мин әнә шунда, беренче мәртәбә, аның үз эшенә фанатикларча бирелгәнен күрдем. Мин бит аның мине яратканын белә идем, хәзер дә ул вакыт-вакыт миңа төбәлеп, онытылып кала, тик хисләренә ташып китәргә ирек бирми, шундук рәсми-житди тонга күчә.

Мин аңар әтием-әнием турында, аларның нинди карашлы кешеләр булуы, мине ничек тәрбияләүләре турында яшерми сөйләп бирдем. Минем хәйләләмәвемне, гадел сөйләвемне ул аңлады, баштагы мөнәсәбәтен үзгәртеп, дустанә сөйләшүгә күчте. Дөресен генә әйткәндә, без берберебезне сыный идек. Юк, ул миннән үч алмый, аның хәле минекеннән авыррак: ул, мине яратканы хәлдә, мине авыр тойгыларга салырга һәм мин бигүк өнәп бетермәгән интим мәсьәләләргә дә кагылырга мәҗбүр иде.

Өч сәгатькә сузылган сөйләшү вакытында ул бик нык арыды, арыганын миннән яшерергә дә теләмәде. Яшерим дисә, ул мине кайтарып кына җибәрә ала. Иртәгә тагын көн бар, берсекөнгә дә көн бар. Көн саен аз-азлап, итагатьле генә сөйләшеп, ул үзенә кирәкне җыеп бетерә ала иде. Тик ул алай теләми, намусына каршы бара алмый, икебезгә дә авыр, бик авыр булган эшен — миннән допрос алуын дәвам иттерә.

— Гражданин Сәмигуллин Габделсамат сезнең белән нинди мөнәсәбәттә иде? — ди милиция өлкән лейтенанты Саматов.

Мин көрсенеп әйтәм:

— Мин аның ярәшелгән кызы идем.

Ул кәгазь өстенә иелеп, шатыр-шотыр яза башлый, озаклап, ярсынып яза, каләм сабы тоткан бармаклары, артык кысудан, агарып киталәр.

— Сезгә гражданин Сәмигуллин каракүл тире яки тегелгән бүрек китермәдеме?

— Беләсезме, иптәш өлкән лейтенант, мин бу сорауны тактсызлык дип саныйм. Нишләп әле мин сезгә булачак ирем өстеннән сөйләп утырыйм?

— Ләкин бит, Рокыя туташ, миңа сезнең әти-әниегезне чакырып сөйләшергә туры киләчәк. Ничек уйлыйсыз, аларны алҗытып йөртү кирәкме, әллә үзегез генә сөйләп бирәсезме?

Минем ачуым кабара башлый:

— Сез нәрсә, миңа әтием-әнием өстеннән әләк сөйләргә кушасызмы?

— Тынычланыгыз, зинһар. Кабат сорыйм: гражданин Сәмигуллин сезгә каракүл бүрек китермәдеме?
— Китермәде.
— Тире китергәнен дә күргәнегез булмадымы?
— Булмады. Әгәр андый эшләр хатын-кызга күрсәтеп эшләнелә дип уйласагыз, бик ялгышасыз.
Ул миңа сүзсез озак итеп карап торды, аннары ниндидер звонокка басты, ашыгып килеп кергән милиционерга:
— Иптәш сержант, гражданка Гыйбадуллинаны машина белән өенә илтеп куегыз,— диде.
Мин мыскыллы елмаеп:
— Рәхмәт кайгыртуыгызга, аяк-кулым исән, җәяү дә кайта алам,— дидем.
Милиция идарәсенә мине тагын өч тапкыр чакырттылар. Машина белән алып китәләр, җәяүләп кайтам. Өйдә мине дүрт күз белән этиләр көтә, энәсеннән җебенә хәтле сорашалар, ах-ух киләләр, мин сөйләгәндә әни, тыела алмыйча, елап та җибәрә, әти аны шундук тыя, эшләрнең ни белән бетәсен белмәгәнгә, алар төннәрен керфек какмый үткәрәләр, аларның ябыгып, агарып калган йөзләренә карау минем өчен ифрат авыр.
Кайчандыр Халикъ Саматовка булган нәфис тойгыларым, аның өчен янып-көеп йөрүләрем соңгы көннәрдә икенче бер хис — бу кешене күралмас дәрәҗәсенә җиткән нәфрәт белән алышынды. Нигә дип азаплый ул безнең гаиләне? Ябасы икән, тотсын даябып куйсын.
Ләкин тора-бара, үзем дә сизмәстән, тойгыларым үзгәрә, янә элекке хәленә кайта башлады. Саматов чын дөреслекне белергә тели, аның өчен дөреслек бар нәрсәдән өстен. Мин моның шулай икәненә ышана барам. Аны иң авыр чакларда да сыенып булырдай олы итеп таныйсым килә. Минем хәтта ул кадәрле олы тойгыны этигә карата да тойганым юк бит әле. Саматовка барысын да сөйләп була, ул барысын да дөрес аңлый дигән уйга килгәнлектән, мин аңа этинең меховойдан тире кыйпылчыклары алып чыгуын, шуннан төннәр буена әни белән икәүләп, күз бетәштереп, бүрек тегүләрен әйтеп бирергә телим, ләкин икеләнәм. Әйтсәм, эшләр тирәнгә китмәсме? Әйтми калдырсам, мин Халикъны белеп бетерә алмыйм, аның закон колымы, чын кешеме икәнен бик тә беләсем килә. Бу миңа бик кирәк, чөнки бу минем язмышымны хәл итәчәк. Әгәр мин аларны әйтеп, Халикъның гадел кеше икәнен белә алсам, ике дә уйламый аңа язмышымны бәйләр идем. Ә ул закон колы булып чыкса? Минем сабыйларча ышанып әйткән сүзем аркасында, юк кына нәрсә өчен этине утыртып куйса? Бу миңа гомерлек яра булачак. Кешеләргә булган ышанычымны мәңгегә югалтачак.
Шулай да мин тәвәккәлләдем. Тик әйтер сүземне Халикъка аның кабинетында түгел, беркем дә тыңлап тора алмастай аулак урында әйтергә булдым. Мин аның белән Идел буена барып сөйләшергә сүз куештым. Ул моның белән килеште һәм без, кояшлы бер көнне, елга трамваена утырып, Услон тауларына чыгып киттек.
Мәңге онытасым юк ул көнне.
Май урталары иде. Агачлар яфрак ярган. Җир өсте үлән белән түшәлгән. Юк, бу җәй урталарындагы инде күз күреп туйган, өстен тузан басып, җилләр ундырып бетергән яшеллек түгел. Агач яфракларының сыткый сагызы да бетмәгән әле, аларны берәмтекләп санап чыгарга була, алардан баш әйләндергеч хуш ис, яз исе аңкый әле. Дөньяга килүләренә атна-ун көн дә узмаган сыек яшел яфраклар талгын җилдән әкрен генә җилфердәшә; яңа күлмәкләрен күрсәтергә чыккан күбәләкләр пыр да пыр килә; каяндыр моң гына булып гармун тавышы ишетелә, яшьләр көлә, яшьләр сөенә...

Мин бәхетемне сыныйм. Халикъка мин этиләр турындагы чын дөреслекне сөйләргә килдем. Ул бүген милиция өлкән лейтенанты киемендә түгел, мин погонлы Саматов белән Идел буена чыкмаган да булыр идем. Халикъ бүген аксыл-күрән костюмнан, изүләрен чишеп җибәргән ак күлмәктән. Ул, тезен тезгә куеп, агач төбендә утыра, беткәннән-беткәнгә ялгап, тәмәке тарта, дулкынлана. Күрәсең, ул минем нинди уй белән килүемне сизенә.

Мин, аның күзенә туры карап, сүз башлыйм:

— Минем этием Гыйбадулла — вак сәүдәгәр. НЭП заманында үз йортында кибет тоткан. Сәүдәгәрлек аның канына сеңгән. Меховойдан ул тире кыйпылчыклары алып кайта.

— Нишләтә ул аларны?

— Әни белән икәү бүрек тегәләр.

— Бер айга ничә бүрек тегә алар?

— Бер, я икене.

— Кайда сата?

— Талчукта.

— Ала-а-ай...— диде Саматов һәм кинәт тынып калды. Папиросын бармак арасында йомарлап, читкә атты. Мин аның озак кына сүздән язып торуыннан куркып:

— Я, нигә дәшмисез? — дидем.

— Әтиең мин сездән допрос алганны беләме?

— Белә.

— Борчыламы?

— Әгәр сез мине тагын бер атна йөртсәгез, аның кайгыдан урын өстенә егылуы, яки акылдан язуы ихтимал.

— Ничек уйлыйсыз, Рокыя туташ, Сәмигуллинның төрмәгә утыртылуы әтиегез холкына да борылыш ясармы?

— Әти әйтә, әгәр бу эштән исән-сау гына котылсам, бүрек игәннәренә әйләнеп тә карамас идем, ди.

— Тукран тәүбәсе булмасмы?

— Минем әти сүзен җилгә очыра торган кеше түгел.

Саматов кискен итеп башын чайкады, миңа өздереп кенә карады да:

— Минемчә, шул җиткән! — диде.

— Аңламадым. Нәрсә җиткән?

— Куркып яшәве — аның өчен җитәрлек җәза.

Мин утырган җиремнән сикереп тордым да Саматовны кочаклап алдым. Аклады бит ул, аклады минем әметемне!

Мин Халикъ Саматовны элеккесеннән дә битәр бер ярату белән, олы итеп, зур итеп, сыеныр кешем итеп ярата башладым, миннән допрос алу бәрабәренә үзе турында да сөйләттем.

Әтисе Габдрахман, әнисе Маһибәдәр икән, башкорт ягында туып үскән, «кыдыл бодау» дип сөйләшә, ди. Халикъ ачлык елны туган, шуңа күрә озын булып үскән, имеш. Нигә аксыл йөзле дә зәңгәр күзлеме? Өченче буын бабасы латыш, әбисе сөргендәге латышка кияүгә чыккан. Карчыга борын, озын буй, җете зәңгәр күз — латыш бабасы бүләге. Дүрт бала булганнар. Берсе суга батып үлгән, берсе кызамык чиреннән вафат. Төпчек кыз Сания дә баш бала Халикъ торып калганнар.

Утыз биненче елны әтисе аларны Казанга алып килә. Үзе ТЭЦта бетонщик булып эшли. Тик бәхете булмый картның. Ашханәдә агулы колбаса ашап үлә. Бәлки ул үлмәгән дә булыр иде, колбасаның агулы икәнен сизеп алуга конторага йөгерә. Башкаларны — илле дүрт кешене — коткарып калалар, ашыгу сәбәпле, моны онытталар. Урындыкка утырган килеш бөгәрләнеп үлгән.

«Минем әти шул эшне эшли алыр идеме? Башкаларны коткарыр өчен үзен корбан итәр идеме?» Бу фикергә мин җавап таба алмыйм.

Халикъ әкрен генә сөйләп утыра. Үзләре турында ул үзе бик яхшы белгән чит кешене, инде туйдырып бетергән хәлләрне сөйләгән сыман, тоныk тавыш белән сөйли. Миннән допрос алгандагы активлыгы, кызыксынуы беткән. Тик ара-тирә ул үз хәленә гүя гаҗәпләнеп карый, аның җете зәңгәр күзләре караеп, тирәнәеп китә төсле, аларда уңайсызлану галәмәте булып, елмаю барлыкка килә. Игътибар иткәнегез бармы? Уңайсызланган чакта гөнаһсыз сабыйлар әнә шулай елмаеп торалар.

Мин аның зирәк акылын, кешеләрнең үтә дә үз итүен, мохтаҗларга ярдәм итәргә бик теләп һәм ашкынып торуын белдем инде. Җиденчене бетергәч, ул Володя Сомов исемле иптәше белән авиация техникумына кермәкче булган. Халикъ имтихансыз, ул отличник, Сомов имтихан тотарга тиеш. Уза алмый Сомов, елгачылар техникумына күчә. Иптәшлек йөзеннән Халикъ та елгачылар техникумына күчеп килә. Әтисеннән күчкән сантыйлык Халикъта шул чагында ук була. Кирәк бит, иптәшем белән бергә булам дип, инде кереп урнашкан техникумынны ташлап чык әле! Исәр баш! Андый кешенең урыны кайда икәне билгеле: бер елдан моны комсомол секретаре итеп сайлыйлар. Унсигез яшь тулуга — партиягә кандидат. Беренче курс кызларын өлкән курслар аулап бетерә икән. Халикъ үз группасыннан Мәликә исемле кызны эләктерә. Комсомол секретаре бит — өлкән курска торырлык!

— Чибәр идеме? — дидем мин, әллә кайлардагы әнә шул кыздан ничектер көнләшеп куйдым.

— Казанда ике чибәр кыз булса, берсе — Сәхибҗамал Волжская, икенчесе — Мәликә.

— Хәзер кайда соң ул?

— Ашыкма, Рокыя туташ, тәртибе белән житәрбез,— диде ул елмаеп һәм шундук күзләренә монсулык кунды: — Әти үлгәч, тормышлар авыраеп китте. Әнинең әллә ни һөнәре юк. Кара эшче. Миңа хәзер семьяны да кайгыртырга туры килә. Укыган чакта ук эшләргә булдым. Җәй көннәрен Иделдә пароход йөртәм. Айлыгы житмеш биш сум. Минем эше буй житкән егеткә, йөргән кызы да булган егеткә, күп акча түгел бу. Әниләргә Әстерханнан кипкән балык, ак балык, селедка алып менәм. Укуым өчен дә файдалы — практика. Казаннан башлап Әстерханга тикле һәрбер култык, һәрбер тугай таныш булып бетте. Бервакыт шулай Әстерханнан Горькийга барабыз, радиодан Молотов сөйләгәнне тапшыралар: сугыш башланган! Миңа егерме бер яшь ул чакта. Капитаннан өйгә генә кереп чыгыйм дип сорадым да элдердем военкоматка. Үз иркем белән китәм. Әниләргә ул хакта ләм-мим — мобилизация белән алалар, дидем.

Киев хәрби округына килеп эләктем.

Немец Киевка якынлаша.

— Урта һәм югары белемлеләр, ике адым алга!

Бер мең дә ике йөз кеше чыктык. Мин дә чыктым — техникумның дүртенче курсы урта белем була бит инде. Безне Киевның артиллерия училищесы карамагына тапшырдылар. Немец якынлашу сәбәпле училище Саратовка күчте. Шәһәрдән дүрт километрлар читтә хәрби училище бар иде — шунда китереп аудардылар безне. Өчьеллык училище. Көненә унике сәгать укыйбыз. Бер ай укыйсың да бер ел өчен имтихан тапшырасың. Бер ел өчен тапшыра алсаң, тагын укыйсың, тапшыра алмасаң, сержант исеме бирәләр дә орудие командиры итеп частька озаталар. Калган белемне шунда аласың — фронтта. Өч имтиханны да үтеп чыктым мин. Бер мең ике йөздән — житмеш алты кеше чыктык. Лейтенант исеме бирделәр дә декабрьның егермесендә Мәскәү хәрби округына озаттылар. Сугыш вакытында нәрсәнең кайда икәнен һич белерлек түгел, Мәскәү хәрби округы Горькийда булып чыкты. Килдек.

Идел буе хәрби округына беркетмәсеннәрме! Мин — яңа пешеп кенә чыккан лейтенант — гәүдәмә сыланып торган өр-яңа хәрби киемнән, елгачылар техникумына йөгерәм. Дәрескә алып керделәр — кая ул дәрес кайгысы! — Парта астыннан язу йөртәбез. Мәликә дә шунда утыра бит инде...

Кичен Мәликә белән Академия театрына барып кайттык. Иптәшләрнең берсендә озату кичәсе әзерләде кызым. Студентларча гына.

Китәргә ике-өч кенә көн калгач, бөтен частька вахта тора идем, берәү доложить итә:

— Иптәш дежурный, часть карамагына бер төркем сугышчы килде! Старший Сомов!

Таныш фамилия. Ут яндырып карасам — Володя Сомов. Курсанташларымны рядовой итеп минем карамакка алып килгән. Соңыннан алар бөтен дивизиягә таралдылар.

Озакламый фронтка киттек. Китәсе көнне әни килде. Ана ияреп Мәликә килгән. Юлда танышканнар. Чәй куеп эчерергә генә өлгердем. Тимер юл буена китеп, беренче мәртәбә үбештек...

Ул туктап, тынып калды. Папирос алып, кулында әвәләде, шырпы тартмасыннан шырпы ала алмыйча аптырап бетте.

— Соң шуннан? — дидем мин.

— Шуннан шул. Запфронт. Мосальский район. Куян тавы. Поезддан төшүгә дивизия сугышка керде. 1942 нче ел. Мин — артиллерист. Взвод командиры. Батарея командиры. Смоленск юнәлешендә бер мәртәбә жинелчә яраландым. Орша янында каты яраландым. Үпкәгә осколка эләккән иде. Сигез ай госпитальдә ятарга туры килде.

— Кайсы елны?

— Кырык дүртенче елның июне.

— Сугыш бетәргә күп тә калмаган икән.

— Әйе шул. Госпитальдән өйгә кайтармакчылар иде. Риза булмадым. Сорагач, артиллеристлар әзерләргә жибәрделәр. Житомирда эшләдем. Костромада булдым. Өченче Ленинградскийда. Рус, поляк, югославларны укыттым. Житомирда артиллерия полкының штаб начальнигы урынбасары булдым. Кырык сигезенче елны демобилизацияләнеп Казанга кайттым. Менә, бөтен булганы шул. Милициядә эшлим. Укуны дәвам итәргә исәп бар.

— Ә Мәликә?

— Мәликә... кияүгә чыккан.

— Кемгә?

— Бишбалтаның магазин директорына. Ике-өч көн ник кына артыннан йөри егет — шул житә. Горький пьесаларын укыганың бармы? Әнә шул Горький пьесаларындагы мещанка.

Бу сүзләрне Халикъ миңа карата сөйли кебек. Мин дә шулай була яздым ич. Мин уңайсызланып кызарам, тиктомалдан борчыла башлыйм. Борчылуымны сиздермәс өчен, ашыгып:

— Ә нигә сез милициягә кердегез? — дим.

— Казанга кайткач, партия учетына басарга кирәк. Райкомга кердем. Секретарь әйтә, иптәш Саматов, МВД органнарын ныгытырга кирәк, ди. Партия сүзе минем өчен закон. Өстәвенә, звание саклана, беренче дәрәжә карточка бирәләр. Минем өчен ул да бик мөһим: сеңелне укытып чыгарасы бар, әнигә дә ярдәм итәргә кирәк.

Ул сүзеннән туктап, тагын бер мәртәбә тынып торды, бүтән тәмәке тартмады, урыныннан торып, мине култыклады да урман сукмагыннан алып китте.

Мин аның белән янәшә атлыйм. Аның таза беләкләренең җылысын тоеп, кулын күкрәгемә кысып барам. Безгә хәзер сүз сөйләү кирәкми, ул минем өчен ачык, мин аны үтәдән-үтә күрәм шикелле.

Көн кичкә авышып килә. Күләгәләр озая башлаган, көндезге кайнарлык та кими төшкән, ял итеп йөрүче яшьләр кайту ягына борылганнар.

Урманда озак кына йөреп, яр буена төштек.

Халикъ мине көймәләр биреп тора торган лабаз янына алып китте, паспортын бирде, ун сум акча калдырды да, миннән рөхсәт тә сорап тормастан, ныклы ихтыяр белән мине көймәгә кертеп утыртты, кулына ишкәк алды, моңсулана төшкән зәңгәр күзләрен балкытып:

— Ә хәзер кич безнеке...— диде.

Мин аның ихтыярына буйсындым.

## II

Кемгә ничектер, минем үземә бик тә аңлаешлы бер хакыйкать бар: егет чакта еллар буе белмәгәнне ирең булгач бер айда белергә була икән. Бер күреп сөйләшергә әллә ни бирердәй булып йөргән кыз чагымда Халикъ Саматов минем өчен озын буйлы чибәр офицер иде. Мин аның белән икәү култыклашып урамнардан узып китәчәк көннәремне күз алдыма китерәм, көнчелектән нишләргә белмәгән бистә кызлары безгә кызыгып карап калырлар инде, дип уйлый идем. Өйләнешкәнебезгә ел ярым булды инде, минем әле Халикъ белән урамда йөргәнем юк.

Туй узу белән ул мине укырга кыстый башлады. Син укырсың, мин эшләрмен, диде. Ул заманда хатын-кызлардан укырга бик атлыгып торучы юк иде, абитуриентларның күбесе фронттан кайтып төшкән шинельле солдат иде. Мин әллә ни авырлык күрмичә пединститутка барып кердем. Тик уку дигән нәрсә үзе бик авыр булып чыкты. Дәрестән кайткан саен Халикътан үземне кызгандыра торгач, ярты ел дигәндә институтны ташладым. Аннары безнең улыбыз туды. Халикъ аңа француз революциясе хөрмәтенә Марат дип исем куштырды, һәм мин көннәремне «француз революциясе» янында үткәрә башладым. Тагын бер елдан мин Халикъка икенче малай табып бирдем. Халикъ анысына Максим Горький хөрмәтенә Максим дип исем куштырды һәм шул көнне үк гомеренең бушка узып барганын, инде үзенең укырга керергә тиешлеген әйтте. Әгәр мин укуны ташламасам, икебезнең берьюлы укый алмаячагыбызны әйтер идем, ләкин үзем укымагач, өстәвенә, ике ел эчендә ике улым туып, кул-аягымны да бәйләп куйгач, аңар каршы килә алмадым.

Халикъның ун класс белеме юк, фронтка ул елгачылар техникумының дүртенче курсыннан киткән — унынчы класс өчен экстренно имтихан бирәм дип атлыга. Право алу өчен ике йөз сум акча түләргә кирәк иде, түләде, тик инша язган чакта артыграк тырышып җибәргән: унике биткә унике хата ясаган. Экстренно имтихан тапшырудан Халикъны төшереп калдырдылар, ләкин ике йөз сум акчасын кайтарып бирмәделәр. Әнә шул ике йөз сум минем өчен Халикъ тарафыннан эшләнгән беренче сантыйлык булып күренде. Я, кем инде тик торганнан ике йөз сумны суга сала? Минем сантый Халигым үтә дә үзсүзле булып чыкты. Икенче елны кичке мәктәпкә барып керде. Хәзер генә ул яшьләрне көчләп укыталар, ул чакта уку түгел, эш таләп итәләр иде. Халикъ кичке мәктәпкә түрәләреннән яшереп керде: аның милиция идарәсендәге эше кичке сәгатьләргә дә бәйле иде шул!

Әй, авырга да туры килде соң аңа уку! Безгә бернинди уңайлыгы да булмаган иске йорттан болын чаклы зур бер бүлмә биргәннәр иде,

ул бүлмәдә Халикъның әнисе, бер туган сеңелесе Сания, Халикъ үзе һәм ике бала белән мин торам. Халикъка дәрес хәзерләргә урын да, шарты да юк, шунлыктан ул күбрәк вакытын милиция идарәсендә үткәрә, хәтта куныл та кала торган иде. Мин аны кызганып, нигә азаплана бу сантый, званиесе бар, хезмәт хакы әйбәт, казна киеме киеп йөри, тагы ни кирәк, ди идем. Үз кадерен үзе белеп, рәхәтләнеп кенә яшәр чакта... кирәк бит, әй! Йокысызлык, каты диванда черем итеп кенә алулар аны бик тә арытты бугай, ул миннән мендәр белән ак җәймә сорап алып, аларны шунда эш бүлмәсендә тумбочкага бикләп тота торган булды. Минем күңелемдә вәсвәсә уянды. Әгәр ул анда хатыннар белән буталса? Власть үз кулында. Урын-җире, диваны бар. Ә мин монда өй саклап ят! Гомерем заяга уза түгелме? Әллә Халикъ миннән Гапсамат үчен аламы? Мин бит аңа түгел, Гапсаматка чыкмакчы идем. Мин Халикъка эштән соң өйдә торырга, милиция идарәсендә кунып-төнеп ятмаска дигән таләп куйдым. Тешен кысып булса да, ул моның белән килеште. Кич кайтып, башын салкын су белән юа да, колакларын сөлге белән урап укырга утыра. Минем тагын ачуым килә. Табыйм дисә таба бит җаен кеше, башын да күтәрми укый. Укый да укый, укый да укый, урам йөрергә чыгып керә дә тагын укый. Я төнге дежурга китеп бара. Мин тагын җаным әрнеп, мыскылланып, өй тулы халык белән утырып калам.

«Юк, кадерле ирем, син миннән алай тиз генә котыла алмассың,— дип уйлыйм усалланып.— Кара син аны, акыллы баш, ул укып түрә булмакчы, мин монда бер бүлмәле фатирда аның нәселе, балалары белән хәсрәт чигеп ят». Бәйләнәм дисәң, сәбәп табыла бит ул. Бер көнне бу сеңелесе Саниягә, унынчы классны бетергән көнгә дип, биек үкчәле туфли алып кайткан. Миннән сорау юк, киңәш юк, туганнарына яхшы булып күренмәкче. Юк, дидем, күренми тор әле! Каенанам да өйдә чак иде. Халикъның эштән кайтып керүе булды, күтәрелеп бәрелүем булды:

— Бәлки син мине бала чүпрәге юучы асрау хатын итеп тотмакчы була торгансыңдыр? Мине тау чаклы вәгъдәләр биреп өйдән алып киттең дә, ат абзары чаклы бүлмәгә бикләп куйдың, инде минем белән киңәш итүне дә үзеңә хурлык саный башладыңмыни?

— Ни сөйлисең син, Рокыя? Саниягә үз гомерендә беренче мәртәбә туфли алып бирәбез, шундый сөенечле көнне кара кайгыга әйләндермә, зинһар,— ди бу.

Аның шулай үтә дә белдекле, тыйнак тавыш белән, суфиларча сөйләнеп торуына җен ачуларым чыгып, авызымны гына ачкан идем, каенанам сүзгә кушылды:

— Улым Халикъ, безнең өчен катының белән тәмсезләнмә. Табып бир безгә берәр җирдән фатир, үзебезчә иплә кенә яшәрбез, җан биргәнгә җүн бирер әле,— диде.

Ләкин Халикъ әнисе белән Саниягә фатир табып биргәннән соң да мин аңа тынгы бирмәдем. Минем белән киңәш итми-нитми укырга барып кергән. Милиция идарәсенә икееллык Югары хуҗалык мәктәбенә разнарядка килә. Әйтә бу начальникларына: «Мине җибәрегез, хатын белән конфликт та бар, качып-посып уку да туйдырды»,— ди. Укулары Куйбышевта буласы икән, китте-барды Халигым мине ике бала белән калдырып. Әтиләргә барып киңәш иттем, мин әйтәм, менә шулай, шулай, киявегез мине ташлап укырга китте, нишлибез? — дим.

Әти аптырап, башын кашып тора.

— Ни дип кенә әйтим соң, кызым? Сиңа сүз әйтсәм, син җәлке, киявгә тел тидерсәм, үземә бәк тә зур яхшылык эшләгән кеше. Балаказадан саклап калды бит. Акылсыз кеше дип әйтеп булмый, шешәмазар белән шаярганы да күренми, эш урынында да яраталар. Тагын ни әйтим сиңа? Ир белән катын арасына кысылу җүнлелеккә илткәне

юк. Үз башың үзеңдә, мине бутама, күңелең ничек куша, шулай эшлә, кызым...

— Ә ул хатыннар белән чуалса, мине ике балам белән ташлап китсә?

— Анысын дөрес әйтәсең. Хәзергесе заманда катын-кызга бер дә генә ышаныч юк. Сугыштан соң бәк усалланды катын-кыз, карт дими, яшь дими, аксак дими, бөкре дими — ир аулый. Баладән башаяк, саклаганны алла саклармын дигән, барып кайт булмаса янына, үз күзең белән күреп кайт. Калганын кайткачыннан сөйләшербез.

— Ә балалар?

— Нәрсә булсын балаларыңа! Миңкамал янында уйнап торырлар, сабакка йөриселәре юк бит әле.

Миңа төенчекләремне төйнәп Халикъ янына Куйбышевка юл тотудан башка әмәл калмады.

Бу бару минем өчен бик тә гыйбрәтле булды: Халикъның мин тагын бер сантыйлыгын белдем. Кияү балакай миңа әйтми-нитми генә берьюлы ике җирдә укып ята, Югары хуҗалык мәктәбендә бер имтиханын биреп чыга да юридик институтка йөгерә икән. Килеп төшсәм — ябыккан, чыкмаган җаны да, ишелмәгән сөяге генә бар.

— Син нәрсә, миннән качып китеп хатыннар белән буталып ятасыңмы монда? — дип ябырылдым тегеңә.

Ике урында берьюлы укуын әйтеп бирергә мәҗбүр булды. Моны шундук Югары хуҗалык мәктәбе директорына җиткердем. Теге бөреп алган Халикъны.

— Син нәрсә, Саматов, бездән яшереп йөрисең? Ике җирдә укыйсың икән бит...

Укымыйм дияр иде, ялган була, укыйм шул дияр иде, хуҗалык мәктәбеннән куып чыгарырлар, дип курка. Дәшми. «Иелгән башны кылыч кисми» принцибы белән эш итмәкче. Хәзер эттән алып эткә салып тирги башлый дип торганда гына, директор Семашкин әйтә моңа: «Без бер путевка алдык, егерме дүрт көнлек, мин аны сиңа бирергә булдым»,— ди. Менә бит ул ничек! Ир-атның барысы бер чыбыктан сөрелгән. Мин аңа Халикъ Саматовның берьюлы ике җирдә укуын, алдашып йөрүен барып әйтәм, ә ул аңа путевка тәкъдим итә. Ул гынамы! Саматовның акчасы юклыгын белеп, путевканы бушлай бирдертә, аэропортка барырга машинасын бирә. Ләкин аэропортка кадәр әле Халикъның бер имтихан тапшырасы бар. Әзерләнеп житмәгән. Керә бу тәвәккәлләп, билет ала. Тәвәккәллекне әҗәткә сорап тормый инде ул! Шул тәвәккәллеге аңа күпме күңелсезлек китерде. Барыбер эшли. Керә бу, ала билет. «Суд процессында гражданлык эше белән дәгъвачының катнашу очрагы». Практикадан белә ул аны, теориясен укырга вакыт тимәгән. Ә күршесендә утырган кызга сорауның нәкъ киресе эләккән: «Суд процессында гражданлык эше белән дәгъвачының катнашмау очрагы». «Беләсеңме?» — «Беләм».— «Син чык әле»,— ди Халикъ, аның сөйләгәнен тыңлап торып, киресен сөйләргә уйлый. Дөрес түгел, ниндидер көлке бер нәрсә килеп чыга. Баштагы ике сорауга яхшы гына җавап биргән булгач, профессор сорау бирә дә бирә. Ә Халикъның самолетка өлгерәсе бар. «Ник ашыгасыз, егет?» — ди профессор. Халикъ дөресен әйтеп бирергә мәҗбүр. «Өчле»гә килешәләр. Халикъның шул «өчле»се хәтта дәүләт имтиханнарында да килеп чыкты. Бер мәртәбә алдашты, анда да тоттылар үзен. Ләкин ул «өчле»нең актыктан аңа кирәге чыкты. Анысын да сөйләрмен.

Халикъ мине юатып, гафу үтенеп, самолетка утырды да ял йортына очты. Мин, япа-ялгызым, Куйбышевта калдым. Ир-ат халкына үләр чиккә җитеп ачуым чыкты: бер-берсен яклыйбыз дисәләр, табалар бит җаен. Институтына бардым, Югары хуҗалык мәктәбенең директорына тагын кердем. Иплән кенә, йомшак кына итеп, юмалап чыгардылар.

Куйбышевка килүемнең берәүгә дә әйтмәгән тагын бер сәбәбе бар иде. Халикъның койрыгын бозга катырып куймакчы идем. Янәсе, моңа малайларга өстәп бер тәти кыз табып бирәм. Халигым маңгаемнан үпте дә аркамнан сыйпады, мин шул сыйпауга җылынып бер ай әтиләр янында торырга тиешмени инде хәзер?

Бик гарьләнеп йөри идем, ял йортыннан хат язгач, шул азрак юаныч булды. Уникe көнгә җиде кило да ике йөз грамм арттым, диген. Чистый чучка икән. Ашау әйбәт, ябык типтагы МВД ял йорты. Аңа нәрсә — ашый да йоклый, ашый да йоклый — рәхәткә чыккан! Үлчәп карасалар, житмеш биш килограмм булган. Житте, чаңгыга бас, дигәннәр. Күңелем тагын вәсвәсәләнә, тагын әрнешә: «Чаңгыга бас!» — дип кенә калсалар бик хуп та, аннан зуррагы булып куймасын. Халикъ кебек ашый да йоклый, ашый да йоклый торган икенче бер зат юктыр дисеңмени анда!

Югары хуҗалык мәктәбендә укуның файдасы шул булды: укуын бетерүгә моны Идел — Балтик каналына билгеләп куйдылар. Элекке Мариинский системасы. Вычегда белән Шексна калалары арасында. Онега күленнән Рыбинск сусаклагычына кадәр ара. Халикъ Саматовның дәрәҗә зур: төзелештә кадрлар бүлеге начальнигы.

Бу юлы минем үз акылым үзем белән иде инде. Егетем, башта үзем барып урнашыйм, теге дә бу дип, койрыкны тайдырмакчы иде, чатырдап ябыштым тегенең итәгенә. Ни күрсәк тә бергә күрербез, мин синнән калмыйм, дидем. Балаларны да үзебез белән алып киттем. Вычегдада тордык. Гомеремдә күрмәгән каналлар күрдем. Петр патша заманында ул бәләкәй генә канал булган, хәзер кырык метр киңлеге итеп казыдылар. Элек утыз җиде шлюз булган, хәзер тугыз-ун шлюз калдырып, калганын су белән күмделәр. Илле өченче елның маена тикле яшәдек. Халикъ-сантый анда да укуын ташламады. Шушы көнгә тикле миңе гаҗәпкә калдырган бер нәрсә бар. Халикъ кебек кешеләргә шул кадәр дә тырыш, шул кадәр дә ихлас, беркатлы сантыйлык каян килә икән? Эшеннән эт кебек арып, телләрен салындырып кайтып керә, инде бу тамагына да ашый алмас, өстен чишенер дә авар, дип уйлыйсың, юк, башын салкын су белән юып ала да, сөлге белән колакларын урап укырга утыра. Куйбышевтан ерагайдык, Ленинград юридик институтына күчте. Имтиханнарны шунда барып тапшыра. Таныш начальник хатыннары гаҗәпләнеп: «Халикъ Абдрахманович ничек барысына да өлгерә ул?» — дип сорыйлар. Нәрсә дип җавап бирергә белмәгәч, мин аның үзеннән сорадым.

— Берәүләр гайбәт сөйли, икенчеләре жалоба яза, өченчеләре зәмзәм суыннан рәхәт таба. Мин аларның берсенә дә күңел бирмәгәч, вакытым укырга кала,— диде Халикъ.

Идел — Балтик каналында эш беткәч, безне Мәскәүгә кайтардылар. Дөрес, без туп-туры өйгә, Казаныбызга да кайтып китә алган булыр идек, әмма Халикъның көзгедәй чиста биографиясе, сугыш юлын узган булуы, канал төзелешендә үзен яхшы яктан танытып өлгерүе Главканың симпатиясен уяткан. Мәскәүдә эшләп, вакансия көтәргә куштылар. Безгә Тундрадан, Тувадан, тагын әллә кайлардан урын тәкъдим иттеләр. Мин риза булмадым. Тел-теш тидерер хәлем юк, ул чагында Халикъ минем белән бик тә исәпләште. Исәпләшмәслек тә түгел: мин өченче баламны табарга йөри идем инде ул чакта. Күрәсең, Халикъ безнең хәлләрне ачыктан-ачык сөйләп биргән, безне Казан карамагына җибәрделәр. Ә Казанда Халикъ Саматов кебек эш атларын көтеп кенә торалар. Безне тоттылар да Әлмәткә җибәрделәр. Киләчәге зур шәһәр. Илнең күз өстендәге кашы булачак. Нефть осталары җыелачак. Дөнья күләмендәге конгрессләр шунда узачак, Татарстан җиренә менә шундый кала салып бирергә кирәк, диләр. Халикъны Әлмәттә һөнәр мәктәпләре башлыгы итеп куйдылар.

Әлмәттә минем өченче улым туды. Халикъ анысына, бирәүгә дә ирмичә, бирәүнең дә хөрмәтен хөрмәтләп тормыйча, Җәүдәт дип исем куштырды. Өч бала белән кеше өстендә торып булмый. Килүгә квартир алдык. Времянкалар күп төзелә иде. Бик матур коттедж эләкте. Үзебезнең тормыш көйләнде, ләкин һөнәр мәктәпләрендә эш бик көйсез. Сугыш вакытында ата-анасын, туганын югалткан үсмерләр килеп тулган. Торак тәрәзәләренең пыяласы ватык. Җил сызгырып утыра. Зоналарда өере белән кәгазь чүпләре очып йөри.

Гөнаһысына керер хәлем юк — Халикъ бар җирдә тәртип бар. Беренче мәртәбә свиданиегә килгән чакта аның миңа әйткән сүзләре исемә төште. «Нигә милициягә кердең?» — дигәч, «Тәртип урнаштырырга кирәк»,— дигән иде бит. Ул моны, күрәсең, ил күләмендә алып әйткән. Ә мин, унынчыны гына бетергән яшел кыз, ул чакта аны аңлап җиткермәгәнмен.

Халикъ «тәртип урнаштырырга» кереште. Бажановтан өч көнгә эшкә чыкмый торырга рөхсәт алды. Бажанов дигәннәре «Татнефтестрой» комбинатының начальнигы, отставкадагы генерал. Һөнәр мәктәпләре аңа эшче көче бирә икән: үсмерләр дүрт сәгать укыйлар, дүрт сәгать эшлиләр, ягъни балта остасы, буяучы, штукатурчы булып практика узалар. Халикъ складтан ак җәймәләр яздырып алды, армейский заправка ясыйбыз дип, ду килеп йөри. Кузгалды тегенең фанатик сыйфатлары. Бригадирларны җыеп сөйләшә. Педагогларга тынгы бирми. Мине торакларның берсенә тәрбияче итеп куйды, үзе белән ияртеп йөри.

Мунча яктыртып халыкны тазарттык, чистарттык.

— Ошыймы бу тәртип? — ди, һөнәрчеләрне җыеп.

— Ошый,— диләр.

— Яхшы эшләсәгез, тагын да яхшырак булыр.

Һөнәрчеләр арасыннан һәвәскәр ике художник табып алды, плакатлар яздырды, стендлар эшләтте, стена журналы «Чаян» чыгара башладык. «Чаян»ны бөтен зонага күренеп торырлык зур итеп эшләтте. Художниклар кайгыга калдылар. Атнасына ике мәртәбә чыгарыла торган сатирик журналга — егерме квадрат метр зурлыгындагы фанер тактага буяу каян табып бетерергә? Карикатураларны төсле итеп ясарга кирәк. Монда да җаен тапты Саматов, фанерны известь белән буята, иске галошларны яндырып корым әзерләтә, төсле буяуга үлән суы кулланалар. Үләндә, үзегез беләсез,— яшеле дә, сарысы да, алы да — күңелең ни тели, шул төс бар. Гаҗәп матур карикатуралар килеп чыга. Әллә кайлардан күренеп тора.

— Иблистер бу Саматов! — диләр педагоглар.

Китте һөнәрчеләр арасында ярыш. Художниклар алдынгыларның да, ялкау-саботажникларның да фамилияләрен язып, сурәтләрен төшереп торалар. Ялкаулардан һөнәрчеләр эче катып көлә.

Бу минем өчен бик тә күңелле бер хәл иде. Тик мин «тәртип урнаштыруның» шома гына узмаганын аңлап алдым. Минем намуслы сантыем Саматов һөнәрче үсмерләр арасында гына түгел, бригадирлар арасында да тәртип урнаштырырга кереште. Аның өчен син булачак балта остасы, ятим үсмерме, әллә тәҗрибәле бригадирмы, барыбер — син кеше булып калырга тиеш. Саматов килгәнче бригадирлар, ятим балаларны кешегә санамыйча, кимсетеп караганнар. Эшкә чыгарган чакта ремесленникларның хәтта аякларыннан сөйрәп төшерү кебек нәрсәләр булган.

Саматов андый бригадирларны рәхимсез рәвештә эштән куды. Сәбәбен — социалистик законны бозган өчен дип аңлатты. Тегеләрнең килешәсе килми, өйрәнгәннәр җәзасыз башбаштакланырга. Саматов өстеннән Казанга, хезмәт резервлары идарәсенә жалоба язалар. Янәсе, Саматов, һөнәрчеләр белән сүз берләшеп, җимерү эше алып бара.

Уйламаган-көтмәгән җирдән комиссия килеп төште. Комиссия башында хезмәт резервлары идарәсе начальнигы.

Кизүдәге егет чатнатып җавап бирә:

— Иптәш идарә башлыгы, егерме җиденче торактан егерме кеше эштә, берәү авыру. Дежурный Касыймов.

Комиссия карап чыга торакларны — армиядәге төсле тәртип. Икешәр кат ак җәймә, яшел одеял, чытыр ак мендәр. Идәннәр ялт итеп юылган. Стеналарда — плакат, картина.

— Барысы да шулаймы, иптәш Саматов?

— Барысы да шулай, иптәш идарә башлыгы.

Ашханәгә киләләр. Дежурный чатнатып рапорт бирә. Ашап карыйлар — аш тәмле.

Киңәшмә җыя идарә башлыгы, тәрбиячеләрне, педагогларны, бригадирларны чакыра, кыска гына итеп әйтә: Саматов дөрес эшли. Уңыш телим сезгә, ди.

Ләкин моның белән генә бетмәде эле. Бер тынгысыз әллә ничә кешегә җан борчуы таба ала. Комиссия китеп, озак та үтмәде, Халикъ «Татнефтестрой» начальнигы Бажанов белән низагка керде. Халикъ инкасса аша «Татнефтестрой» начальнигына биш йөз мең сумга счет китереп куйды. Шул суммага комбинат безгә җиһаз бирергә тиеш булган, бирмәгән, һөнәрчеләр эшләгәнгә акча да түләмәгәннәр. Счет куюга гаепле кеше өч көн эчендә «дөрес түгел» дигән отказ язарга тиеш, отказ язмаса, акча дәгъва кылучы кассасына күчә. Менә шунда килеп чыкты да инде Халикъның теге чактагы «өчле»се. Дәгъвачы нишләргә тиешлеген Саматов имтиханнан соң кат-кат укый. Үзәк бәгыренә үткән әлеге сорау аның хәтеренә мәңгегә сеңеп кала. Ләкин генерал моны белми бит, минем тынгысыз Халигымны үзенә чакырып ала да өстәл сугып кычкыра:

— Нефтьчеләр акчасына баш булмакчы булдыңмы?

— Сез счет куйганны көтеп ятарга тиеш түгел идегез.

— Урыныңнан алдырам. Судка бирәм,— ди генерал.

— Бирегез, тик мина кычкырмагыз,— ди Саматов, кызмыйча гына.— Совет законы кемнең хаклы, кемнең хаксыз икәнен үзе ачыклап бирер.

Халикъ миңа шуны соңыннан бик ачынып сөйләде.

— Нигә бәйләнәсең? Генерал син белгәнне генә белмимени? — дидем.

— Сугыш күргән солдат ике һөҗүмне берьюлы ота,— диде Халикъ.

Миңа ул үз-үзенә артык ышана кебек тоелды.

— Икегез дә дәүләт эше белән йөрисез, дәүләт акчасын тотасыз, тыныч кына килешер идегез,— дидем.

— Юк, килешеп булмый,— диде Халикъ.— Бажанов кебекләр һөнәрчеләрне икенче сорт халыкка санарга гадәтләнгән. Менә мин алардан шул акчаны закон нигезендә каерып алсам, алар безгә бер чакрымнан бүрек салып йөри башлаячаклар.

Халикъның әйткән сүзен җилгә очырмавын белсәм дә, генерал хәтле генералны җиңеп чыгачагына барыбер ышанмадым. Монда, бәлки, генералларны илаһи итеп карау да үзенекен иткәндер, мин Халигымның эше барып чыкмас дип борчыла башладым.

Ләкин ул үз эшен бик белеп, нык кул белән эшләде.

Халикъ үзләренең бухгалтерына әйткән, әгәр Бажанов безнең банктагы счетка арест салдырса, шундук баш тарт, отказ язып бир, дигән. Өч көн саен отказ язып тора болар. Бажанов тиресеннән чыгардай булып талпына, алай да барып чыкмагач, эшне Мәскәүгә, РСФСР арбитражына бирә. Ни хикмәттер, Саматов файдасына әйләнеп кайтты. Генерал Бажановка җиде процент госпошлина түләргә туры килде. Биш йөз мең сумның җиде проценты ничә сум була? Бер проценты —

биш мең, җиде проценты — утыз биш мең сум. Дәүләт файдасына генерал Бажанов утыз биш мең сум акча түләде. Нефтьчеләр кесәсеннән алып түләде. Генералның аңардан башка да акылсыз эшләре булган икән. Шәһәргә ул утыз метр биеклегендәге фонтан салдырырга уйлаган. Янәсе, киләчәк буыннарга һәйкәл калдыра.

Аны эшеннән алдылар.

Эшне тикшерә килгән обком секретаре әйткән:

— Шәһәрне пычракка батыргансың, оятыңны фонтан белән юмакчы булдыңмы? — дигән.

Минем Халигым җиңүче булып чыкты. Минемчә, ул хаклык эзләп йөргәнгә генә түгел, эшне җиренә җиткезеп, барлык законнарын белеп эшләгәнгә җиңде. Шулай да мин аның генерал хәтле генерал белән тартышуын хупламадым. Әгәр шунда генерал җиңеп чыккан булса? Мин өч балам белән өелеп калсам? Сантыйлык бу. Акыллы адәм эше түгел.

### III

1954 нче елны Әлмәттәге һөнәр мәктәпләре махсус училищеларга әйләнде. Саматовны Казанга МВД системасына чакырып алдылар.

Халикъ белән без, мал-мөлкәтне җыештырып, дөресрәге, юк-бар бәягә сатып, Казанга кайтып төштек. Бу миңа сөенеч кенә булды. Ел саен диярлек урын алмаштырып, адәм рәтле оя кора алмыйча, кагылып-сугылып йөргәнче, Казанда ныклап кына бер төпләнеп алсак, әйбәт кенә яшәп китәрбез. Балаларыбыз бер мәктәпкә йөреп, бер укытучыга ияләнер. Маратның быел сабакка барасы елы. Әти белән әни дә безне яктырып каршы алдылар. Күз генә тимәсен, өрмәгән җиргә дә утыртмыйлар. Әни көндезләрен бакчада мәш килә, төпчек улым Җәүдәтне коляска белән алма күләгәсендә йоклата, олыракларына иртә өлгерә торган алмалар җыеп, карлыганнан, кура җиләгеннән авыз иттерә.

Мин үзем кайткач та әтигә әйтеп куйдым:

— Йөрмәдек түгел, күп йөрдек, әти. Инде төпләнәсе килә. Киявенә мамыклырак эш белешә тор әле,— дидем. Юкса, Халикъның холык бик чуар, эшсез торса, эче поша башлый, син аңа эш кенә téткәзеп тор. Дәгъвалырагын бир. Көрәшсез үткән көн көнмени, янәсе! Тагын бер баш чыкмастай эшкә кереп куйса, артта калган берәр предприятиене өстерәргә тотынса, күр дә тор, ярты картаясың инде. Ул чагында минем кайгым түтүт! Гадәт-холкын белгәнгә, тегенең гел җаеннан гына торам. Хәйлә белән алдырырга исәп.

Әтинең таныш-белешләре аркылы Казанның Бауман урамындагы универмагына коммерческий директор кирәклеген белеп алдым. Менә дигән хезмәт хакы, почеты-даны, менә дигән «ЗИМ»ы булачак. Безгә генә Петр патша заманнарыннан калган каналларны киңәйтеп, бөтен илдән җыелган ятим сукбайны һөнәргә өйрәтеп, тәрбияләп, үзсүзле генераллар белән дәгъвалашып яшәргә димәгәндер! Гыйбадулла кызы Рокыя да бер лимузинга утырып йөреп карасын әле! Йортсыз йомран кебек илнең бер башыннан бер башына йөрүдән бик тә туйган идем, көн дә үгетлим Халикъны, төн дә үгетлим. Дәшми. Иртән чыгып китә, кич кайта. Дүртме-бишме көн йөрде бу шулай. Бер көнне бите-башы яктырып, зәңгәр күзләрен күк ачуташ кебек балкытып кайтып керде:

— Эш таптым, энисе!

— Нинди эш?

Плэтән төрмәсендә политик-тәрбия эше начальнигы итеп куялар.

— Бар икән күрәселәрем, никләр чыктым мин сиңа кияүгә? Никләр генә Гапсамат теге чакта бәлагә эләкте икән? — дип елап җибәрдем.— Кеше эшләгән җирдә эш беткәндер шул, адәм каргышы яуган җирне эзләп йөрмәсәң, күңелең булмый инде синең! Мине кабергә керткәнче

тырышасың. Беләм мин. Бу кайгыга сабышып үлсен, я тиләләр йортына барып керсен, дип үчегәсең...

Күңелемдә җыелып килгән барлык-барлык үпкәмне берьюлы чыгарып аудардым да:

— Мин синең белән тормыйм. Тормыйм! Чыгып кит бездән! — дидем.

Нишләгәнемне, ни әйткәнемне белештермәдем. Ярсып, дулап, рәнҗеп әйттем.

Саматовны андый рәнҗүләр белән генә хатын-кыз итәгенә тагып буламы соң! Китте бу чыгып, ай буе бездән аерым яшәде, бер генә мәртәбә дә мине үгетләргә килмәде. Латышлар ягыннан кушылган канмы, газаплы сугыш юлын узып җыйган ныклыкмы — аны хатынкыз тирәсендә чебер-чебер китереп йөртми иде.

Яңа эшендә бер ай чамасы эшләгәч, урамда очраттым.

Майор погоннары таккан яңа френчтан, күз явынны алырдай чиста хром итектән, озын буйлы, төз гәүдәле офицер. Аерым яшәү дә аның мәһабәт горурлыгын киметмәгән, ул әүвәлгечә үк ачык, ягымлы, житди. Хәрәкәт-гамәле төгәл, олысымак. Мин аның бер генә мәртәбә дә вакланганын, түбәнсенгәнен күрмәдем.

Аңардан аерым үткәргән бер ай гомеремне кызганып, үләр чиккә җиттем. Аның мине бер генә сүз белән дә гаепләмәве, ихлас бер гадилек белән хәлемне, әти-әниләрнең хәлен, балаларның хәлен сорашуы күңелемдә үкенү сыман бер нәрсә уятты. Тик мин ана үкенүемне сиздермәдем, үземне горур һәм бәйсез тотып, аны гаепләрдәй берничә төртмәле сүз дә әйтеп, мәгънәсез генә китеп бардым. Әтәч тә кук, мин дә кук!

Ләкин минем тәкәбберлегемне җимерә торган бер хәл булды. Очрашканга атна-ун көн уздымы-юкмы, газеталар утызмеңчеләр дип шаулый башлады. Завод-фабрикаларда, институтларда җыелышлар уза. Радиодан көн саен карар укыйлар. «Төпсез кое» колхозларны күтәрергә Халикъ кебек беркатлы адәмнәрне җыялар. Бавырым белән сизеп йөрим — Халикъ миңа үч итеп китеп барыр. Ә авылда берәр тылакые аның башын әйләндереп куйса? Калырсың, Рокыя, атаң йортын саклап. Я Халикъ белән китәм, я гомерлеккә әти йортын саклап калам...

Юраганым юш килде. Халикъны авыл хуҗалыгы институтында бер ай чамасы укыттылар да Кама буендагы иң артта калган бер колхозга председатель итеп озатып та куйдылар.

Бу юлы әти түзмәде:

— Бу ниткән әкәмәт бу, ә? — диде.— Эчеңдә җаның бармы синең, юкмы? — диде.— Ирең әнә кая китеп барды, ә син, берни булмаган төсле, үзеңне үзең кочаклап утырасың. Бәк тә шәп инде, бәк тә мөрәвәт эш! Киләчәк көнеңне уйлыйсыңмы син, юкмы? Өч бала белән кемгә хаҗәтең бар синең? Әллә булмаса, син картаймыш көнемдә дә әти карап-багып асрар, дип ышанасыңмы?

— Нишли алам соң мин, әти?

— Бәк күп нәрсә эшли аласың син. Бәк күп нәрсә! Закун да, хокук та хәзергесе көнне катын-кыз ягында, әллә онытгыңмы шуны? Онытмаган булсаң, менә вәйт: ирең синең партиунный, бала-чагасыннан аерып, хатыныннан аерып җибәрергә хаклары юк. Андый права бирәүгә бирелмәгән.

— Нишлим дим бит мин сиңа?

— Бар обкомына, Беренченең үзе янына кер. Сөйләп бир хәлләреңне, менә шулай-шулай диген, ничәмә-ничә еллар ирем Саматов Халикъ иң әтбитствинный, иң җаваплы эштә эшләде, диген, башта Балтик каналын салдырды, аннары нефтьчеләр каласы Әлмәтне төзеде, и шулай ук алын-ялын онытып эшләде, диген, кайда җимерек, кайда тишек,

бер Саматовка гына ямап йөрергә димәгәндер бит, диген. Кем өйрәтте, дисәләр, мин өйрәтте, димә, үзем беләм, диген. Ун классны бетергән кыз, син аларны гына белергә тиешле. Бар-бар, монда ике кулыңны кушырып, үзеңне үзең кочаклап утырсаң, он да чыкмас, тоз да чыкмас, гомер буена тол катын булып утырып та калырсың. Ничу катын-кызны мыскыл итеп, иреннән аерым яшәтергә!

Мине обкомга озата чыкканда ул каушый төшеп әйтте:

— Бәк әллә ни чәпчемә, чи-чи килмә, ипләп кенә, җаен җайга китереп кенә сөйлә, галимнәр утыра анда, башлы халык, синең белән мин белгәнне киртәгә чыгарып элгән...— диде. Мине Беренче янына кертмәделәр. Өстәвенә, секретарь янына кергәч, мин югалдым да калдым. Кая ул әти сүзе! Үз сүземне дә онытып бетердем.

Ишектән түргә чаклы сузылган озын келәм. Ай, аннан атлаулары! Теге башта сине көтеп, секретарь басып тора. Гыйбадулла кызын гына күргән дисеңмени аны!

Түгәрәк шома бит, тап-такыр баш, ялт иткән костюм. Үтәли тишеп чыгардай үткен караш. Сөйләргә кушты. Сөйләдем. Дөресрәге, мин ике авыз сүз әйтү белән үк ул минем Саматовны Казанда алып калырга теләвемне аңлады.

— Әйбәт яшисезме? — диде.

Нәрсә әйтим?

— Әйбәт,— дидем, сүзне Саматовка бормакчы идем, ул мине тагын бүлдерде:

— Авылда да әйбәт яшәүләрен телисезме?

— Телим.

— Бик яхшы. Сез шунда барыгыз да, ирегез Саматов белән кулга-кул тотынып, колхозчыларның тормышын көйләгез. Мин Саматовның әтисен беләм. Ул минем авылдашым иде. Колхоз оештырды. Әгәр Халикъ Габдрахман абзыйга охшаса, булдырыр. Без аңа ышанабыз.

Обкомнан мин әллә ничек юашланып кайттым. Кайтып керүемә әти ишектән башын тыкты — аңар да кул гына селтәдем. Көне буе әзерләнеп, бала-чагамның керен юып, ямавын ямап, ике көн тула дигәндә, Кама буена, ирем кабул итеп алачак колхозга, китеп бардым. Нәкъ көненә туры килдем. Борынгы мәчетләрне бергә җыеп салган шыксыз иске клубка халык кереп тулган — председатель сайлыйлар.

Минем беркайчан да колхоз җыелышында булганым юк иде. Коридор кебек озын һәм тар клубка дыңгычланып тулган халыкны күргәч, йөрәгем наразыйлык белдереп каты-каты тибеп куйды. Юк, Халикъның моңарчы эшләгән җирләре алтын булган икән. Монда бернинди тәртип тә юк, булачагы да юк, мин монда калсам, бетәм, үләм, хур булам. Хәзер үк борылып чыгып китәргә кирәк, бөркүлектән йөрәгем кысыла, тыным бетә, ләкин мине чыгармыйлар, әвәреп уртага алып баралар иде.

Бер-берсен бүлдереп шаулаган төрле тавышлардан мин бер нәрсәне аңладым: соңгы ике ел эчендә биредә колхоз председателе булып райбашкарма председателе эшләгән, аны прокурор алыштырган, ниһаять, МВД киеме киеп, укалы погон таккан Халикъ Саматов килеп төште!

Шуңа гөрле халык, себер китәсе көннәр алда икән, ди.

Сугыш медальләрен тагып килгән парторг Хисами, утызмеңчеләр турындагы хөкүмәт карарын бик озаклап, буталчык итеп аңлатканнан соң:

— Алыштырабызмы председательне? — диде.

Битен кап-кара сакал баскан бер адәм, урыныннан чәчрәп торып:

— Алыштырабыз! — дип ачы тавыш белән кычкырды.— Прокурор председатель булып торды. Арба майларга май юк. Май бир, дидек. Сыер тизәге белән майлагыз, диде. Кирәкми безгә колхозны мыскыл итүчеләр.

Анардан соң тагын кемнәрдер торып сөйләде, кемдер ата-анасы белән сүгенде, ахыры ничек беткәнен хәтерләмим, кысан һәм бөркү коридордан мин башым авыртып, күңелем болганып чыгып киттем. Нигә Халикъны эзләп килүемә коточкыч үкенү тойгысы гына хәтеремдә торып калган.

Иртәгесен идарә җыйдылар — Саматовка печать тапшыралар. Үз ирке белән эзләп килде бит сантый. Аңа гына күп кирәк.

— Колхоз председателе кайда?

— Районга кайтып киткән.

— Райком секретаре кайда?

— Районга кайтып киткән.

— Председатель урынбасары кем?

— Шәриф Искәндәрев.

— Шәриф ага,— диде Халикъ җәй көне бүрек киеп йөрүче бераүгә,— мин хуҗалык белән танышканчы идарә итә торырсың. Ялгышсаң, үзем киңәш бирермен.

Көлке! Кайда ялгышканың беләсе бар бит әле. Колхозда әйле-шәйле бер полуторка, ике «газик» бар икән. Сәләхи исемле егет бер күзен кысып, бер кашын югары чөеп, минем идән тулы балаларыма карап елмайды да Халикъны кырга алып чыгып китте. Әйләнеп кайтканда Халикъның баш түбәсе тавык күкәе чаклы булып күбеп чыккан иде. Шофер бик әйбәт иткән: машинаны канау аркылы алып чыгып, Халикъның башын кабина түбәсенә бәргән. Йөрмәсен булдыра алмастай эшкә тыгылып! Мин бит аңар Казанда коммерческий директор урыны табып бирдем. Лимузинга утырып, асфальт юлдан гына йөрер иде. Башына тай типмәсә — шунда калыр иде.

Монысы әле башы гына булган икән. Икенче көнне Халикъ ат абзарына килә.

— Атлар бармы?

— Бар. Ел буе җигелмәгән айгыр бар.

— Ияре дә бармы?

Дүрт кеше ярсып торган кара айгырны абзардан алып чыгалар да иярләп Халикъны атландыралар. Капканы төбенә кадәр ачып җибәрәләр. Янәсе, яле, җилле егет, кайда егылып муеныңны сындырырсың икән? Шуны ишеткәч, йөрәгем өзелеп төшеп киткәндәй булды, түзмәдем, урамга чыктым. Ни дисәң дә ирең — кызганыч. Имгәнгән хәбәрен кайчан килеп әйтерләр, дип көтәм. Безнең өй турысыннан бер көтү малай чабып узды:

— Кара айгыр Саматовны кырга апчыгып китте!

— Кара айгыр кырга чапты!

Бер сәгать чамасы узгач, ак күбеккә баткан айгырын җитәкләп Халикъ кайтып килә.

— Көлмәкче булалар, имансызлар. Ләкин кешесе ул түгел. Минем артиллерист икәнне оныткannар. Бар курыкканым урамда егылып калу иде. Түздем. Кырга чыккач, туйганчы чаптырдым, район үзәгенә барып житә яздым. Кайтышлый арыды. Бер чокыр буена туктады. Карап торам, ишләр икән дим, галифедән тартып төшерде. Атландырмый, хәерсез. Ярый, илтеп тапшырырга кирәк. Атыгыз ничава, кертеп ябыгыз, диярмен...

Ул тәмам арыган, төсе качкан иде. Шулай да атын илтә китте. Артыннан карап калдым — шундый якын, шундый якын, кызганудан елап җибәрә яздым. Бигрәк беркатлы, бигрәк ихлас күңелле сантый шул!

Төш вакытлары житте. Урынбасары Искәндәрев килгән. Сирәк сары сакалын сыпырып тора:

— Иптәш председатель, механизаторларга аш кирәк.

— Пешерегез,— ди Халикъ,— миннән сорап тора торган нәрсәмени инде ул, Шәриф агай?
— Юк бит...
— Нәрсә юк?
— Он юк.
— Сельподан сорагыз.
— Бирмиләр.
— Яңаны сугу белән икеләтә кайтарып бирербез, диегез. Басу тулы икмәк ич.
— Күпме сорыйм соң?
— Көненә ничә пот он китә?
— Биш поттан да ким китмәс.
— Сорагыз ике тонна.
Тагын ике көннән дәүләткә беренче ашлыкны озатырга җыендылар. Безнең өйгә бухгалтер Сәлимә килеп керде.
— Саматов иптәш, капчыклар юк.
— Кая киткән алар?
— Шоферлар белән грузчиклар урлап бетергән.
— Яла! — диде Халикъ, тавышына борыч өстәп.
Бухгалтер хатын каушап төшмәде. Халикъка якынрак килеп, шыпырт тавышка күчте:
— Саматов иптәш, мин сезгә изгелек телим. Эшләргә дип килгәнегез күренеп тора. Шуңар күрә кайбер хәлләрне әйтеп бирергә тиешмен. Тазабайлар — гомер-гомергә карак авыл. Сыерны монда чабата кидереп урлаганнар. Кемнең кем икәнен белеп тотынмасагыз, алар сезне бик тиз төп башына утыртачаклар.
— Яхшы. Тикшерермен. Капчык алырга күпме кирәк?
— Дүрт йөз сум.
— Рокыя, санап бир. Банкта эшләр җайлангач, кайтарып алырбыз.
Халикъ белән без башта, колхозның акчасы бар, теге көнне алырга җай гына юк, дип уйлаган идек. Бактың исә колхозның миллион ярым бурычы бар икән.
Халикъ төннәр буе экономика өйрәнә. Башына берәр уй килгәндә, мине уятып, фикер уртаклаша. Минем йокым килә, аның тиешле-тиешсезгә уятуына кәефем кырыла.
— Биш мең ике йөз илле гектар сөрү җире бар. Бу — күп. Бүгенге шартлар өчен ифрат күп,— ди Халикъ, ишекле-түрле йөренеп.— Биш йөз хуҗалык. Барысы бер авылда, анысы яхшы. Культура йорты салсаң да, җыелыш җыйсаң да — барысын берьюлы күтәрергә була. Бер йөз дә туксан өч баш сыер малы. Бозаулары-ниләре белән. Тфү! Адәм тәганәсе — шул да булдымы ферма! Нәрсә карап ятканнар, кем үстерер дип ышанганнар? Иген уңышы — гектарыннан биш центнер ярым. Тфү! Көлке! Чәчү орлыгы белән фуражга да җитми! Ә колхозчыга нәрсә? Ашлама чыгару юк, тирес чыгару юк. Хезмәт көненә ике йөз грамм. Акчалата бер тиен юк. Тазабайлар — карак авыл. Гомер-гомергә карак. Урлашалар. Майларына чыдаша алмаганнармы? Һич. Ашарга юк — урлыйлар, мал-туарга юк — урлыйлар. Җан асрыйсылары килә.
Халикъ төннең яртысын марш атлап чыга. Үз-үзе белән сөйләшә. Мин инде куркуга кала башладым. Бу, мин әйтәм, үзе белән үзе сөйләшә торгач, исәргә сабышып китмәгәе. Башы сау чакта моннан алып китү ягын карарга кирәк. Ләкин хәзергә Халикъны мин түгел, Тазабайлар борчуга сала. Төн уртасында ул мине тәмле йокымнан уятып, хуҗалык эшләрен сөйләргә тотына:
— Ишетәсеңме, Рокыя? Ә бит бухгалтер Сәлимәнең әйткәне дөреска чыга. Районда да кисәттеләр мине: Тазабайларның һәрбер йорты — кече карак, йорт аралаш — олы карак, диделәр. Син шуны яхшы бел. Каракларны җиңәрлек тәҗрибәң бар, сиңа закон өйрәтеп торасы юк,

диделәр. Райком секретаре Байназаров вәгъдә биргән «Газ-69» килеп житте бит Сәләхине кудым. Яңа шофер алдым. Фәйзи исемле. Шаян егет. Оптимист. Солдат хезмәтендә булган, кайсы йортның холкы нинди, кайсы агайның бармагы үзенә кәкре — биш бармагы кебек белә. Әйттем үзенә, әгәр син булышсаң, колхозда тәртип урнаштырабыз, дидем. Басу юлыннан атлы килә. «Кем бу?» — «Садри абзый». «Холкы ничек?» — «Бармагы үзенә кәкре». Туктатабыз. Арбага салам салган.

— Председатель иптәш,— ди,— абзарның бер кырые тәмам тишек,— ди,— шушы саламны алып кайтырга гына, зинһар, рөхсәт ит инде, бардан түгел бит, юктан алу,— ди.

— Ярый,— дидек.— Салам астында нәрсә?

— Юк, билләһи, юк,— ди, үзе тотлыга.

Ачып карадык, ике капчык арыш. Амбарга илт, квитанциясен бухгалтерга тапшыр, дидек.

Халикъ бер атна эчендә бишме-алтымы кешене тотты. Ярулла Заһирыннан бер тонна бодай алып чыкканнар. Авыл халкы моны Халикъның заманында милиция эшендә эшләвеннән күрде, ул гына булдыра алган эш итеп сөйләде. Сөйли торгач, ул хәл бик нык күпереп, әкияткә әйләнә язды.

Имеш, райком бүләк иткән машинага утырып, Саматов басудан кайтып төшә. Күрә, чирәмдә арба эзләре бер капкага кереп киткән. Стоп. Фәйзи, бу йортка бур кергән. Туктата бу машинаны, Фәйзине үзе белән алып керә. Каршыга егетнең әнисе өтәләнеп чыга. «Әйдүк, ди, бик вакытлы йөрисез, ди, бәрәңгем пешеп кенә чыкты, күршедән әжәткә ипи сорап торыйм да тозга ярып пешергән бәрәңге белән сыйлап җибәрермен, ди. Бер дә генә борчылмагыз, күршебез Гатият мытысыда эшли, бура тутырып бодай ала, аларда ипи булмый калмас».

Башка председатель булса, рәхмәтен әйтеп китеп барыр иде. Саматовны алай гына алдый алмассың! Бик рәхмәт, апа, тамаклар бик тә ачып тора иде, керәбез, тозга ярып пешергән бәрәңгедән дә яраткан ризыгым юк минем, ди. Шофер Фәйзине ияртеп, туп-туры лапаска барып керә. Лапаста камыл астын чабып аударган печән.

— Гаеп итмә инде, персидәтел, улым Гарапша бер дә генә эштән бушамый, кышка сыерыбыз ач калмасын дип урак белән урып апкайтканыем.

— Бик әйбәт, апа, камыл астын урганга сүз юк,— ди Халикъ. Үзе кулына тоткан таягы белән тирә-ягына төрткәләп, тикшеренеп йөри. Әйдә кыртлап утырган тавык бар икән, боларны күреп, дөньялар бетереп кытаклый башлый.

Гарапшаның әнисенә шул гына кирәк тә.

— Бу ниткән көпә-көндез тавык куркытып йөрү, тол катын дигәченнән дә мыскыл итәргә уйладыгызмыни? — дип разбой сала башлый. Кеше жыймакчы! Халикъны андый провокация белән генә куркыта алмассың! Андыйны ул милиция эшендә кырык күргән.

— Гафу итегез, апа, гаеп бездә,— ди Халикъ Саматов.— Без үзебез туздырганны төзәтә дә беләбез, дип, тавык оясына барып керә дә оя астыннан капчыгы белән бодайны тартып та чыгара.

«Саматов ул, овчарка эте кебек, кайда чит нәрсә ятканны исеннән сизеп таба»,— дип сөйли башлады халык. «Мескен тол катын» йортына Халикъ понятойлар чакыра, өй астыннан, чормадан, чоланнан ун капчык ашлык табып алалар.

Шундый халык авылда биш-алтыга жыелды. Иң азау теше ярган икесен утырттылар. Авыл кинәт тынып калды. Кичен чыгып йөрү, басу юлларында урлашу бетте. Әмма мин бу тынлыкның юньле тынлык түгел икәнен күреп тордым. Монын ахыры ничек тә бер Халикъка барып тоташырга тиеш. Төрмәгә эләккән кешеләрнең туганнары Халикътан үч алачак әле!

Беркөнне кичен Халикъ кайтканчы дип аш-су әзерләп йөри идем, баскыч төбендә әзек-әзек итеп бик кискен сөйләшкән тавыш ишеттем. Чыксам, тәрмәгә утыртылган Гарапшаның абыйсы Мөбәрәкша тавыш куптара. Исереп килгән.

— Барыгыз, кайтып йоклагыз,— ди Халикъ.

— Кайтмый торсын! Сөйләшәсе сүз бар.

— Сүзне идарәдә сөйләшербез, кайтыгыз,— дип Халикъ чоланга минә башлады, мине күреп, бар кер, дип, кул селтәде. Андый чакта китеп буламы соң! Карыйм, Мөбәрәкшаның танавы кыегайган, Халикъ өстенә килә.

— Кара аны, тәти егет, үкенергә туры килмәсен. Синең ише закун капчыкларының ике аягын бер кунычка тыккан бар безнең.

Халикъ сүз көрәштермәде, эшнең юньлелек белән бетмәслеген аңлап, арты белән чигенә-чигенә, баскыч күтәрмәсенә менде. Мин читкә тайпылып калырга гына өлгердем, ишеккә арканы терәп алды да, шундый итеп тибеп җибәрде, әле генә акаеп килгән Мөбәрәкша баскычтан очып җиргә капланды. Куенынннан шалтырап арба кендеге төшеп калды. Тынсыз ята. Котым чыкты, җан җиренә тибеп, үтереп үк куймадымы, ходаем? Барып карадым: сулу ала, исән. Ул арада Халикъ та килеп җитте. Тегене якасыннан урап алып күтәрде, чигендереп капкага тикле алып барды да урам якка селтәп атты.

Мин паника куптарып: районга барып әйтсә, жалу итсә дип, аны аптыратып бетердем.

— Итмәс. Керосином пахнет! — диде Халикъ, бүтән сүз дәшмәде.

Иртәгесен Мөбәрәкша идарәгә килгән, бригадирлар алдында Халикътан гафу үтенә икән. Янәсе, син минем башымны тиштең, дөрес тиштең, миңа шул кирәк тә фәлән-фәсмәтән.

— Син кем? — дигән Халикъ. Минем сине күргәнем дә, белгәнем дә юк.

Идарәгә җыелган халыкның шаркылдап көлүенә түзә алмыйча, Мөбәрәкша өенә кайтып киткән. Мине очраткан чакларда да ай буе дәшми кара коелып йөрде, аннары ничектер яктырып исәнләшә башлады. Мин моның нигә шулай икәнен белергә теләп, Халикътан сорадым.

— Кеше бит хайван түгел. Гаделлекне кайчан да булса бер аңлый,— диде Халикъ.— Минем үземә генә килеп, идарәдә тәүбә итте. «Мин авылның ата карагы. Председательләрне без капчык киертеп дөмбәсли идек. Син сабак укыттың миңа. Әйткән сүз менә шул: синең иң беренче памушнигың булам, урлауны ташлыйм»,— ди.

Урлавын ташлагандырмы-юкмы, әмма ул тиздән Халикъның уң канаты булып китте. Бактың исә ул беренче кул балта остасы, беренче кул тугымчы икән. Шулар өстәвенә, тимер-томырны да белә. Мал-туар үрчетәм дисә дә, төшеп калганнардан түгел. Халикъ моны ферма мөдире итеп куйды. Ну, тынгысыз да адәм булып чыкты соң! Ике көннең берендә таң сызылуга тәрәзә төбендә кем диген — әлеге дә баягы Мөбәрәкша. Фермалар янына коры чакта салам кайтартып калдыру, печән ташып кую, сарыклар фермасының түбәсен яптыру — Халикъның өстеннән төшми — камчылап куа! «Әллә бу теге чактагының юри үчен ала микән?» — дип тә уйлап куям. Халикътан сорыйм, юк, ди. Намусы уянды, әнә шул намус куа, ди.

Халикъның чын ярдәмчеләре икәү булып чыкты. Берсе — крестьянча нык акыллы, «практичный» Мөбәрәкша булса, икенчесе — парторг Тәлгатев. Ул да юрист, дүртенче курс студенты. Өчәү җыелып алалар да, ун ел буена председательдән председательгә күчеп йөргән котсыз йортның кара ягын тәмәке төтене белән төтәтеп, киләчәк көнгә колхозны зур юлга алып чыгачак эшләр белән хыялланалар. Кычкырып-кычкырып сөйлиләр. Тавышлары колагымны тондырып бетерә. Баштә

«практичный» Мөбәракшаның карлыккан тавышы гөбе төбеннән чыккан сыман ишетелә. Кыска гына, кадак суккандай саран гына итеп әйтә:

— Житен чәчәргә кирәк. Удмуртлар житеннән унды. Пилга персидәтеле Гаврила нәрсә ди: «Где лён — там мильон!» Бар Гаврила янына, нинди китаптан укып үстергәнен бел, хәзергесе көндә китап — ин беренче акыл!

Парторг Тәлгатевнең кызу-кызу сөйләгән ачы тавышы янгырап китә:

— Мөбәракша абый дөрес әйтә: житен синең экономикаңны ныгытачак. Иген уңышын тиз генә яхшыртып булмый, ашлама юк, техника юк. Колхозчының күңелен нәрсә беләндер үстереп жибәрергә, эшләгәне бушка китмәячәгенә ышандырырга кирәк. Житен орлыгына үзем барам. Гавриланың улы Леша минем белән бергә укый, этисенә шуның аркылы сүз әйттереп куярмын. Юк ашламаны көтеп ятма, жирне ныгыта торырга кирәк. Бердәнбер котылу юлы — күпьеллык үлән чәчү.

— Симәнәсе юк бит.

— «Сабанчы»дан биш-алты центнер клевер орлыгы сорарбыз. Өч елдан биш-алты йөз гектарга житәрлек симәнә бирә. Әле бер көн генә председателе, банктагы счетыма арест салдылар, син юрист кеше, өйрәт әле, дип килгән иде. Юлын өйрәтеп жибәрдем, гел безнең жайдан торып эшләргә булды.

Алар шулай хыялланып төн үткәрәләр. Мин урам яктан ишетелгән шыпырт тавышларны тыңлап ятам. Өй буендагы өянке иртәнге жиләс жилдән әкрен генә гөжли. Бер агачта өздереп сандугач сайрый, сандугачның кайгысы юк, аңа тирәк булсын да сайрарга таң булсын. Монда кешеләр хыяллана, ә иртәгесен иртүк идарәдә, кырда, басу станнарында кешеләр иртәгәге көннәрен кайгыртырга тотынып, бригадирлар белән, председательләр белән яңа дау, яңа низаглар кубар. Дөнья шулай икән ул: гаугасыз бер генә көн дә узмый.

Тормышта тыныч кына, гамьсез-рәхәт кенә яшәүчеләр дә бар. Минем белән Яңа бистә мәктәбен бетергән Мөхлисә Ташкентка китеп, үзбәк егетенә кияүгә чыкты. «Ярты гектарлы жимеш бакчабыз бар, үзебез кызыл аракы кайнатабыз, үз машинабыз белән йөрибез, ике катлы агач йортта торабыз»,— дип язган. Кешеләргә кияүнең дә рәтлесе, дөньяда тора белгәне табыла. Булмады инде минем бәхетем! Колхоз дип, кеше бәхете дип авыз суларын корыта торган шыр тиле Халикъка чыгып әрәм булды яшь гомерем. Ни үзенә, ни кешегә дигәндәй, көн тудымы — хәсрәт, кич життеме — сагыш. Өздереп-өздереп сандугач сайрый. Мөхлисә, мөгаен, сандугач сайрауларын рәхәтләнеп тыңлый торгандыр. Мин аны чуар парчалы үзбәк халаты кигән итеп, бергә китереп кушкан шомырт кара кашлы, кояшка янган каратут йөзле, таза һәм шат күңелле итеп күз алдыма китерәм. Янында бер кәтү баласы; ул аларга, тез башына утыртып, хөрмә ашатадыр. Мин аның бәхетеннән үләр чиккә житеп көнләшәм һәм әллә ни гомер йокы га китә алмый ятам...

Гаделлек итәм, авыл халкында ышаныч тудырам дип, сантый Саматов бәлагә тарыды. Дәүләткә тапшырганның уңбиш процентын колхозчыларга бирә бару хокукы бар икән. Ни өчендер Халикъ нәкъ әнә шул хокуктан файдалануны үзе өчен аеруча кирәкле чара дип уйлый, чөнки ул шуның белән колхозчының ышанычын казанырга итә иде. Шул процентлар белән саташып йөри торгач, моның акылы ба[illegible] шына дәүләткә биргән ашлыкның уңбиш процентын түгел, ә [illegible]рда утырганның, ягъни әле жыеп алынасы игеннең уңбиш процентын бирергә диган уй килә. Колхозчыга бүләргә өч мең биш йөз центнер икмәк исәпләп чыгара. Ут чыккандай чаптырып ведомость төзетте[illegible]

хезмәт көненә бер килодан иген өләшеп ташлый, ә калган ашлыкка бер йөз баш сыер контрактовать итә.

Мин бу вакытта МТСка кадрлар бүлегенә эшкә кергән идем. Халикъның ярамаган эш эшләвен иң элек МТСта белеп алдылар. Директорыбыз Хәмзә Сафич мине үз итә иде, иремнең тиешсез эш эшләвен сер итеп кенә ул миңа әйтте. Әгәр Халикъ ялгышканын райкомга үз теле белән барып әйтмәсә, утызменче дип тормаслар, ике дә уйламый төрмәгә ябып куярлар, диде.

Кулымнан эш төште. Күнелемә хәвеф тулды. МТС ихатасы бездән әллә ни ерак түгел иде, төшке аш вакытында өйгә чаптым. Халикъ өйгә кайтып кына тора иде, елар чиккә житеп, аның ялгышканын сөйләп бирдем.

Халикъ мине, кашларын жыергалап, өнәр-өнәмәс кенә тыңлады. Мин шундук аңлап алдым: колхозчыга бер кило икмәкне белеп өләшкән ул сантый, белмәмешкә салынган гына!

Тагын ике көннән Халикъны жилтерәтеп районга алып киттеләр. Ул елларны үзбаш кыланганнарның чәченнән сыйпамыйлар иде. Миңа ни өчендер Халикъны өйгә дә кайтарып тормаслар, шуннан гына утыртып куярлар кебек тоела башлады. Халикътан бигрәк үзем кызганыч булып киттем. Аңа нәрсә! Төрмәнең ни икәнен белә. Ике дә уйламый керер утырыр, срогын да тутырып чыгар, чыккач та әле, мин хаклы идем дип күкрәк сугып йөрер. Өч балам белән мин нишләрмен?

Шуларны күз алдыма китергәч, тәннәрем эсселе-суыклы булып китте, үтереп башым авырта, сулыгып-сулыгып күз кабагым тарта башлады. Ниләр дип кенә газаплый бу мине, үзен уйламаса, мине, балаларын уйласын иде.

Төн урталары житкәндә капка төбенә машина килеп туктаганы ишетелде. Атылып урамга чыктым. Машина кабинасыннан ишелеп Халикъ килеп төште. Иңнәренә барып сарылдым:

— Ниләр эшләдең син, жүләркәем? Кайчан утырталар?

— Зинһар, урам уртасында паника куптарма,— диде ул. Гадәтенчә, өзеп, кыска итеп әйтте. Тик шунда гына эчемә бераз жылы керде.

— Я, турама бәгъремне, әйт, ни булды? — дидем, аш жылытып китерергә дә онытып, төпчәнә башладым.

— Колхозчы икмәкле, мин «строгачлы» булдым,— диде тыныч тавыш белән, һәм әз генә елмаеп та куйды, әйтерсең, аңа яхшы эшләгәне өчен бүләк биргәннәр.

Халикъның моннан соң да чәчемне агартырдай эшләре аз булмады. Озакламый ул МТС белән дау куптарды. Хәмзә Сафич аппаратында эшләгәнлектән, таякның дәү башы минем өскә төште. Директор белән председатель принцип өчен ут уйната, аларның утлы күмерләре минем өскә коела. Натуралата түләү ул заманда гектар башыннан иде. Кулында вымпел тоткан алдынгы комбайнчы Сабир утыз ике гектар арыш урган, Халикъ аңа гектар башыннан исәпләгәндә 32 центнер натуралата түләргә тиеш, ә тегенең ни бары бер бункер икмәге бар. Халикъ әйтә, гектар башыннан түләмим, центнер башыннан түлим, ди, гектар башыннан түләү ул колхозчыны егып талау, ди. Хәмзә Сафич әйтә, синең өчен генә аерым закон юк, түләмәсәң — судка бирәм, ди. Ул заманда шулай иде бит: бармы синең икмәгең, юкмы — түлә! Түлә! Түлә! Хет бөтен ашлыгыңны, орлыкка дигәнеңне, фуражыңны биреп бетер — МТСның анда эше юк.

Халикъ иртән тора да Пәнжәргә чаба, госпоставка алуларын үтенә, госпоставкадан ни дисәң дә центнерына биш сум акча керә, азмы колхозның чыгымы! Колхозга акча кирә генә башлый — Хәмзә Сафич: нишләп Тазабайлардан ашлык керми дип, мине ирем Саматов янына жибәрә.

— Халикъ,— дим мин, елар дәрәҗәгә житеп,— сиңа гына бик күп кирәкме соң? Нишләп син мине кара кайгыларга саласың? Закон бит бер синең өчен генә чыгарылмаган. Әйләнә-тирә барысы гектар башыннан тулы. Табылган акыллы баш — законны әйләнеп үтмәкче! Үлсәң дә сиңа законны әйләнеп үтәргә ирек бирмиләр, син юри, миңа үч итеп эшлисең моны! Чыдамасын, китсен, директор Хәмзә Сафич миңа кырын карасын, мине эшемнән куып чыгарсын, дип кыланасың!

Сүзләремнең хаклы түгеллеген дә беләм. Халикъның юри эшләмәгәнен дә белеп торам, әмма йөрәгем чуарланган, гарьлегем ташып чыккан, нәрсә әйткәнемә исәп биреп тормастан, жанымда җыелганны Халикъ башына аударам. Ул мине кашларын җыергалап тыңлый, озынча чибәр йөзеннән күләгәләр уза, карчыга борынының канатлары сизелер-сизелмәс тетрәнеп куя. Ахырда ул түзми, тыенкы итеп:

— Ярар, бүгенгә җитеп торыр, калганын иртәгә әйтерсең,— ди.

Вакыт-вакыт, күңелем җибәргән чакларда, мин Халикъ ягына авыш бетәм, ул булып борчылам, Казаннан алып килгән балаларымны ул булып үгетлим. «Бигрәкләр дә күп шул әтиегезнең эше, бигрәкләр дә көйрәк жан шул сезнең әтиегез»,— дип сөйләнәм. Халикъны гел дөресен генә эшли торган, утә дә чыккан акыллы, зирәк кеше итеп күрсәтәсем килә. Балаларыма гына түгел, авыл халкына шуларны кычкырып-кычкырып әйтәсем килә. Хәер, алар моны миннән башка да беләләр бугай, эшкә теләбрәк йөри башладылар. Саматов хезмәт көненең кадерен арттырды, дип сөйләнәләр.

Пилга председателе Гавриладан алып кайтып чәчкән уникe гектар житен икенче елны житмеш биш гектар чәчәрлек уңыш бирде. Ә житмеш биш гектар житен уңышы ике йөз дә илле мең сум саф табыш китерде. Практичный Мөбәракша, парторг Тәлгатев белән бик һәйбәтләп киңәшеп, ул акчаны спецсчет дигән статьяга кертеп җибәрделәр, алай итсәң, имеш, хезмәт көненә түләүне яхшыртырга була. Файдасы аның белән генә бетмәде, колхозга радио керттеләр, нәрәтне радио белән бирә, ашыгыч карарларны радиодан әйтә торган булдылар. Житен дигән хикмәтле нәрсә мал-туар караучыларга да акча бүлеп бирә башлады.

Мин күңелемнән генә сөенеп йөрим. Җайлана бит иремнең эшләре. Берүк күз генә тия күрмәсен. Ләкин ул заманда яңа бер нәрсә уйлап чыгармаган көн аз иде. Инде барысы көйләнеп бетте, инде эшләр жайга салынды дип кенә торганда, куян асрау, каз-үрдәк үрчетү дигән яңа бер нәрсә уйлап чыгардылар. Бөтен дөнья шул турыда шаулый. Безнекеләр дә жиң сызганып эшкә тотындылар. Алагаемга ду китереп, колхозчылардан контрактация белән куян җыеп алдылар. Бу эшнең энтузиасты итеп практичный Мөбәракшаның мал-туарны бик тә ярата торган олы улы Сөләйманны куйдылар. Элекке бер бригада өен куян торагына әйләндерделәр, илле баш куяннан район күләмендә үрнәк ферма оештырылды. Китте, мин сиңайтим, кар йомгагы тәгәрәп! Шушы базада район куст семинары җыйдылар. Энтузиаст Сөләйман белән куян караучы Вагыйз ничәмә-ничә колхоздан килгән председательләргә, ферма мөдирләренә тәжрибәләрен сөйлиләр. Район газетасы «Кызыл таң» колхозын мактап зур гына бер полоса чыгарды.

Халикъның нигәдер сөмсерләре коелып йөри. Дәшми. Юньле-рәтле сөйләшми. Ни булды икән тагын моңа? — дип баш ватам.

Беркөнне каз үрчетүче Мөбинә белән сөйләшкән чакларына туры килдем.

— Халикъ абый, сез үзегез акыллы гына кеше, ниткән эш инде бу? — ди Мөбинә.— Тавык йомыркасыннан без табыш алабыз, ә казлар шул табышны ашап, йотып баралар. Колхозчыдан илле баш каз җыйдык, жиде бәбкә чыкты, адәм мәсхәрәсе!

— Шаулама, Мөбинә, алар безнең данны күтәрде, «Кызыл таң»ны республикага ишеттерде, галстук тагарга кирәк аларга,— ди Халикъ. Әллә чынлап, әллә шаяртып әйтә.

Инкубатордан ике мең чамасы үрдәк баласы алганнар иде, күзгә таба Иж елгасы култыклары ап-ак булды. Казаннан килеп, фотографлар шарт та шорт рәсемгә төшереп йөрделәр. Илле баш куян күзгә таба йөз илле башка житте. Кая карама Халикъны мактыйлар: район газетасында да Саматов, өлкә газетасында да Саматов! Тик Саматов үзе генә әвене янган кеше төсле йөри. Идарәдә исәпләп чыгарганнар: йөз илле баш куян дүрт йөз баш сарыкка исәпләнелгән клеверны ашап бетергән, үрдәк-казның ашаганы итеннән өч мәртәбә кыйбатка килеп төшкән.

Алай да Халикъ бу юлы дау күтәрмәде, колхоз активын җыеп, кайсыдыр бер академикның китабын кат-кат укыдылар да, махсус фермалар булмау сәбәпле дигән үтә дә акыллы бер сылтау табып, бик әллә ни кысмыйча гына, алтын бәясенә төшкән куяннарны, Иж суларын балкыткан үрдәкләрне әкрен генә бетерә башладылар. Радиолар да тынды, газеталар да Саматов исемен тәсбих урынына тартмас булдылар. Аның каравы, озак та үтмәде, өлкә газетасында председатель Саматовка багышлап «Травопольный король» дигән мәкалә бастырып чыгардылар. Район вәкилләре чатыр чабышып килде, карап торып клевер жирләрен сөрдерттеләр. Шулай да вәкилләрне борыннарыннан сөйрәп йөртә торгач, Җайлангар урманы артындагы аулак бер почмакта ике йөз житмеш гектар клеверны яшереп алып калдылар.

Үлән басуларын бетерүнең «файдасы» күзгә бик тиз күренә башлады. Сөт тапшыруда районда беренче урынга чыгып килгән колхоз, яшен сугып сындырган агач төсле, кинәт артка авып төште. Күрше «Фрунзе» колхозыннан бер көтү халык килеп Халикъның Байрагын алып киттеләр.

Бу хәлләргә күнегеп кенә килгәндә, ящур өянәге башланды. Халикъ көн дә фермада, төн дә фермада. Коммунистларны чиратлап дежурга куйды. Мең газапка төшкән бер ай йокысыз төннән соң өянәк узды. Район комиссиясе бер йөз дә алтмыш жиде дуңгыз баласына акт язып кайтып китте. Артыграк та ычкына иде, әлеге дә баягы Халикъның булсынга йөрүе жинде.

## IV

Ни булды минем бу Халигыма? Колхозның мал-туарын үләнсез калдырдылар, партбилетында каты шелтә асылынып тора, ә ул һаман черәшә, һаман черәшә. Газеталардан укып, Белоруссиядә атаклы «Рассвет» колхозы барлыгын белеп алды, башта парторг Тәлгатевне жибәрде, аннары үзе барып кайтты. Житенне «Рассвет»тагы кебек кул белән түгел, машина белән үстермәкчеләр. Хезмәт көненә акча түләү ясады. Анысы да жиңел булмады — авантюра дип жанына тиделәр. МТС базасының Тазабайларда булуыннан файдаланып, авылны электрлаштыра башлады. Ел саен утыз-кырык йортка ут кертәләр, үен эш түгел бит — баганасы, чыбыгы юк, монтерларын табарга кирәк. Сугыш елларында бик беткән, бик өшәнгән хуҗалыкларга өмәләр ясап, йортлар салдыра бу. Хуҗалар өй туе ясый. Халикъның түбәсе күккә тигән — үзенә йорт салып кергәнмени!

Килгән көннәрдәге тиле гадәте тагын әйләнеп кайтты. Төннәрен ишекле-түрле йөреп, марш атлап үткәрә, үзе белән үзе сөйләшә:

— Колхозга акыллы житәкчелек итү — кадрлар булдыру дигән сүз. Яхшы бригадирларың булмаса — нуль син, Саматов. Ялгыз нуль. Завхозсыз кая барасың, бухгалтерсыз? Бик шәп экономист кирәк. Парторг Тәлгатевтән ундым, хыялга бай, ышандыра белә, ләкин бит ул гомергә

безгә тормаячак, институт бетерүгә юрист булып китәчәк. Аның киләчәге — юриспруденция. Югары партия мәктәбендә укучы Әнвәр Тавилов бар, әллә шуны үзебезгә кайтарыргамы? Башлы егеткә охшый. Кәжүнни булып чыкмаса? Колхозның үз инженеры, үз механигы булырга тиеш. Хезмәт көненә бер кило ашлык түләү ясадык — анысы яхшы. Сакларга шуны, сакларга! Бурычның бер миллионын түләдек. Калганын списать итсеннәр. Итсеннәр!

Минем сантыемның төннәр йокламый уйлап йөргәннәре дөрескә чыга бара. Ул, үзе дә сизмәстән, МТС техникасын алуга әзерләнгән булып чыкты. Хөкүмәт карары чыгуга район җитәкчеләре «Кызыл таң»га ябырылдылар:

— Халикъ Габдрахманович, синдә акча бар, давай үрнәк күрсәт!

Каты шелтә бирсәләр дә Халикъ, үрнәк күрсәтәсе булса да Халикъ! Ярый әле, Саматов бар. МТС техникасын, МТС мастерскоен алырга йөри бу. Белгечләр чакыртып бәя куйдылар, түләп бетерү срогын билгеләделәр. Механизаторлар колхозга элеккечә гектар башыннан түләү белән күчәргә тиеш. Саматов тагын үз туксанын тукылдата башлады. Юк, ул гектар башыннан түләүгә риза түгел, ана совхоз нормасы булсын — центнердан! Бу, имеш, югары уңышка стимул!

Табылып тора бит моның тегермәненә су коючы. Механизаторлар бригадиры Габдулла Маликов әйтә, мин риза, ди, колхозчыдан безнең кай җиребез артык, доходыбыз хәзер кимесә, соңыннан артыр, ди. Идарә җыйдылар, колхозның гомуми җыелышында сөйләштеләр. Саматов шул хәтле тырышты, тәки совхоз нормасын үткәрттерде. Менә китте низаг: элек икешәр-өчәр машина бодай алып кайткан комбайнчылар бер машина белән кала, тегеләрнең хезмәт көне ике ярым мәртәбә кимеде. Районнан килеп бер кысалар, механизатор халкы бер тирги! Алай да чыдаса чыдый икән кеше. Ике ел уздымы-юкмы, Габдулла Маликов белән моның әйткәннәре тагын дөрескә чыга башлады. Механизаторларның уңышны әйбәтрәк аласылары килә: тракторчысы да җирне әйбәтрәк сөрә, комбайнчысы да сирәк басу сайлап йөрми. Кышын басуга тирес чыгарыйк, ашлама ташыйк, дип өйгә килеп йөдәтәләр. Стимул! Кайткан ашламаны да Әгерҗе станциясенә аударып калдырулар бетте. Гектардан уңышны ничек тә күбрәк алырга кирәк. Колхоз тауга менә бара. Авыр йөккә җигелгән ат кебек гыжлый, туктап-туктап тора, ләкин менә. Черәшә-черәшә менә, Халикъның үзе кебек. Иген уңышы да үсә, акча өләшү дә арта, ике-өч ел бик ныгытып билләрне буып тартканнар иде, «Кызыл таң» белән «Фрунзе» колхозы миллионерга чыкты куйды. Менә кайчан минем сантыемның сөенер көннәре житте. Тик Халикъның алама бер гадәте бар: сөенечен дә адәм рәтле сөенә белми, кайгыга да башын салып йөргәне юк. Гаделсезлек булса гына тиресеннән чыгардай булып шашына, ул якка кан бик кызу!

Миллионер булдык дип бәйрәм итәргә чамалап килгән Мөбәракша абзыйны жайлап кына үгетләп чыгарды. Сарыклар фермасын салып бетерәсе бар, Культура сараена фундамент сала башларга кирәк — бәйрәм кайгысы түгел, янәсе!

Халикъның сөенече белән кайгысы янәшә йөргәнгә мин күнеккән идем инде. Миллионер булганның икенче көнендә үк күкрәп-яшенләп хәсрәте дә килеп җитәр әле дип көтә башладым.

Андый хәсрәт озак көттермәде.

Алтмыш икенче елны яз бик матур килде. Игеннәр күкрәп үсте. Авыл картлары елның килешенә эчтән генә сөенеп, берүк күз генә тия күрмәсен, дип йөриләр. Халикъ эшне каты кул белән алып бара. Арыш басулары дугалы ат күмелерлек. Такыр елны тырышканнан икеләтәнык тырышырга кирәк. Механизаторлар центнер башыннан булганга ашлыкны көрәп алачак. Төнне көнгә, шәфәкъны таңга ялгап эшлиләр.

Колхоз кәнсәләрендә кеше калмады, яшелчәдән, жимеш бакчасыннан кырга күчтеләр. Халикъның йоклаганы да юк. Аяк өсте яки утырган җиреннән генә черем итеп ала да кырга чаба. Тугыз көн тула дигәндә арышны урып бетерделәр. Бодай урырга керешкәннәр иде — китте янгыр, китте яңгыр! Ярты көн ява, ярты көн аяз. Комбайнчылар, летчиклар кебек, көн аязганны каравыллый. Машиналар Пәнҗәр юлыннан кайта алмый интегә. Халикъның теге чакта, ике институтта берьюлы укыган заманындагы кебек, чыкмаган җаны да, таралмаган сөяге генә торып калды. Көннәр буе юеш кием белән йөргәнгә, Халикъ, бик хәтәр салкын тидереп, больницага керде. Анда да әле карышып маташкан була. Яңа сайланган парторг, Югары партия мәктәбен бетереп кайткан Әнвәр Тавилов, районнан врач чакыртып, ай-ваена карамый, сәгате-минуты белән илтеп салды. Больница әле дә ярый үзебездә — Тазабайларда. Балаларым янында күрше хатынын калдырдым да үзем дә кердем Халикъ янына. Көйрәк җан, мин әйтәм, юньле-рәтле дәваланмас, я качып чыгып китәр, дим. Үзем карап, үзем терелтергә исәплим, көне буе янында утырам. Тизрәк терелтәсе булгач, Халикъ та каршы килми.

Хәл белергә райком секретаре Байназаров килде. Үз гомеремдә бер мәртәбә Халикъның да сөенгәнен күрдем. Сүнеп барган күзләренә нур керде, кайнар кулы белән беләгемнән тотып әйтә:

— Хәл белергә Галим Саттарович үзе килгән. Ә син әйтәсең, минем берәүгә дә кирәгем юк, дисең. Менә бит, килгән.

Райком секретаре баш врачны чакыртып алды да:

— Терелтегез безнең председательне, чыксын тизрәк! Монда аунарга ярамый аңа,— диде. Халикъка карап иптәшләрчә елмайды: — Борчылма, Саматов, ныгытып терел, колхозыңа вәкил калдырам, эшләрең артка китмәс...

Әнә шул сүз ошамады Халикъка. Ни пычагыма кирәк ул вәкил, ди. Парторг бар, бригадирлар бар, идарә бар. Телефоннан колхоз хәлләрен сораша башлады. Хәлләрне парторг Тавилов хәбәр итә. Ул яшь кеше, алдаша белми, юатып та маташмый, туп-туры әйтә.

Секретарь килеп киткәнгә ике көн үткән иде, шулай телефоннан сөйләшә минем Халигым, күрәм, телефон трубкасын тоткан кулы дерелди, йөзе көл кебек агара бара.

— Ни булды? — дим, әйләнеп тә карамый.

— Сез нәрсә, кем кушты? Башың бармы синең — юкмы? Мин синнән сорыйм, кем кушты? Үтердегез, пычаксыз суйдыгыз!!

Күзләре урыныннан чыгар дәрәҗәгә житеп шашына башлагач, телефон трубкасын йолкып алдым. Врачны чакырдым. Көч-хәл белән урынына яткырдылар. Баксаң-күрсәң, орлыкка дип әзерләнгән сигез йөз центнер бодайны дәүләткә озатканнар икән. Кем кушканмы? Уполномоченный. Имеш, тагын җыярсыз! Җыярсың, бар, яңгыр астында яткан бодайдан орлык җыеп кара.

Халикъ ярсына, үзен-үзе белештермәс дәрәҗәгә җитеп дулый. Мине дә, сестраларны да, врачны да тыңламый, киемнәрен эзләп коридордан чаба. Ниһаять, мин аның сабырлыгы беткәнен, үләр чиккә җитеп ярсынганын күрдем. Аны больницада алып калу мөмкин түгел иде.

Кайту белән вәкилне идарәгә чакыртып китерде. Бер генә кычкырды:

— Бүген үк китегез! Вон! Юкса, эт өстереп куармын!

Шул ук көнне кайтып китте вәкил. Шул ук көнне райбашкарма председателе Фәхриев килеп җитте. Анысы да Халикъ кебек кайнар адәм. Ләкин башта Халикъның ачуын кабартыр өчен сабыр тавыш белән сөйләшеп маташты:

— Партия карарларын үтәмәскә булдыңмы, Саматов? Власть вәкилен куып җибәрәсең! Бик шәп...— Кинәт өстәлгә йодрык белән китереп

орды: — Саботажник! Райком күрсәтмәсе сиңа бер тиен дә тормый! Менә сиңа мең ярым центнер өстәмә задание — үтәмәсәң — үзеңә үпкәлә!

— Өстәмә планны күптән үтәдек.

— Тагын үтәрсез. Үзеңдә глубинка ачасың. Тирә-як колхозлардан икмәк кабул итә башла.

Халикъ та курка торганнардан түгел.

— Син үз кабинетыңда түгел, Фәхриев. Йодрык төймә миңа. Әгәр колхозга килеп командовать итәргә телисең икән, мә — ачкыч, мә — печать, итә бир.

Әнә нинди хәлгә китереп житкерделәр авыру Халикъны.

Фәхриев сүрелә төште. Саматовның тирләп чыккан битенә карап:

— Кызынма, Саматов. Киттек амбарга,— ди.

Киттеләр. Мин дә ияреп бардым. Халикъ бит чыгырыннан чыгып бара, алла сакласын, һуштан язып егылуы бар. Юк, мин инде аны миһербансыз адәмнәр кулына бүтән калдырасым юк. Шушы бәлаләрдән исән-аман алып чыксам, алып китәм Казанга. Житәр, күп мыскыл иттеләр, элекке заман түгел.

Амбарга керәбез. Дүрт мең центнер ашлык амбар алдында ята. Таутау көшел.

— Икмәгең күп бит,— ди Фәхриев.

— Аз түгел.

— Ә нигә карышасың?

— Дәүләткә бармый ул, фуражга гына яраклы.

— Ник?

— Кызган.

— Карарбыз. Барырмы, юкмы?

Фәхриев бездән туп-туры Пәнжәргә киткән. Заготзернодан лаборатория килеп төште: бер автомашина, өч лаборант кыз.

Халикъ начаррак төшләрен күрсәтә. Аңар фураж кирәк. Ашлыкны яраксыз тапсалар, фуражлы була, янәсе. Беркатлы сабый. Үзе чиста күңелле булгач, бүтәннәр дә шулай дип уйлый. Нәтиҗәсе нәрсә? «Кызыл таң»да икмәк чери. Саматов дүрт мең центнер икмәкне бозган. Менә кайчан район аппараты хәрәкәткә килде. Биш көннән бюро. Халикъ аңлап алды: икмәк черетте дип төрмәгә тыгачаклар. Фәхриев тә, вәкил дә Халикъны гафу итмәячәк. Ләкин Халикъның анда эше юк. Икмәкне сакларга. Икмәкне сакларга!!

Биш көн Халикъ кебек тиз уйлый белә торган кешегә бик озак гомер ул. Кырдан дүрт комбайн-самоходканы кайтартты, бер-бер артлы тезеп куйды да, комбайннар аша үткәреп тора. Өч сортировка белән җилләтәбез. Ир бирмәк — җан бирмәк, ди, мин дә җиң сызганып тотындым, кипшергән ашлыкны чутлап кабул итәм. Ашлык кипшереп кенә калмый, чистара да. Колхозчылар да дәртләнеп тотынды. Бердән, икмәкле булалар, икенчедән, Саматовны кулдан ычкындырасылары килми. Азмы булышты ул аларга, азмы алар өчен хәсрәт чикте? Аларның тырышканнарын күреп минем күңелләрем нечкәрә. Сортировкадан чыккан ашлыкны ябык ындырга кертеп, зернопульттан үткәрәбез. Аннан сушилкага озатасы. Тәүлек буе, өч смена эшли сушилка. Өч көн тулды дигәндә, бер мең җиде йөз центнерны киптереп бетерә яздык. Тагын өч көн тырышсак, дүрт мең центнер икмәкне коткарып калабыз.

Фәхриевкә кемдер житкергән: Саматов икмәкне киптереп бетерә!

Халикъны биш көннән түгел, иртәгесен үк чакырталар бюрога. Парторг Тавилов белән икесе иртә таңнан машина куып Пәнжәргә киттеләр. Халикъ бюродан курыкмый, аның бар борчылганы — икмәк! Китәр алдыннан ул колхозның механигын чакыртып алды. Мөбәрәкша абзыйны чакыртты, сушилкага эшкә күчкән Мөбинәне чакыртты:

— Туганнар, бер генә минутка да эшне туктатмагыз. Бу — минем приказым да, үтенечем дә. Миннән башка бер кешене дә тыңларга хакыгыз юк,— диде.

Пәнҗәр бездән егерме чакрым. Юллар бозык. Кайчан барып җитәләр дә кайчан кайтып җитәләр. Күңелемдә ут, сулыгып-сулыгып күз кабагым тарта. Юк, мин Халикъны эшеннән алырлар дип курыкмыйм, алсыннар, мин хәтта шуны телим, ичмасам, адәм рәтле тыныч эшкә күчәр иде. Тырышып ярамый кеше, койрык болгап ярый. Халикъта аларның берсе дә юк. Аның үзе ышанган иманы бар, ул — дөреслек. Ул — намус. Ул — булсынга эшләү. Аны аңламадылар, аны көчләргә, ирексезләргә теләделәр, аның сырт йоннары кабарды. Бәлки ул үзенең үлеменә киткәндер. Ходаем, бик артык тискәреләнмичә, дуламыйча, ипләбрәк сөйләшсә, ичмасам, эшеннән алу белән туктарлар иде, күрәгең таза булса, эш беткәнмени! Мин аңар Казанда йөз эш табып бирәм. Бу юлы инде ул бәлки карышып та тормас. Җитәрлек сабак укыттылар аңа. Шыр тиле булмаса, аңларга тиеш. Төрмәгә генә башын тыга күрмәсеннәр, эшеннән алу берни түгел, эшеннән алганга сөенәм генә. Күңелемнән мин кырыкмаса кырык тапкыр шул уйны уйладым. Халикъны үзем белән Казанга алып китәр өчен әллә ниләр эшләргә әзер идем мин.

Кич җиткәнче ике-өч тапкыр идарәгә барып кайттым, парторг Тавилов хатыны Хәдичәдән белештем. Хәдичә — яшь хатын, дөньяның ачысын-төчесен татымаган, мондый тәшвишне беренче тапкыр күрүе булганлыктан, кайгыра да белми. Нәрсә булсын аларга, юри эшләмәделәр бит, ди, мине юатып маташа.

Авыл өйләрендә утлар кабынып, берничә көн яумый торган яңгыр тагын сибәли башлагач, балчыкка, ләмгә батып, машиналарын Җайлангар урманында калдырып, Халикъ белән Әнвәр кайттылар.

Мин хәл сорашырга ташландым.

Халикъ теләр-теләмәс кенә әйтте. Бюро булган. Аны председательлектән алалар икән. Бар сөйләгәне шул булды. Мин бик ялынгач, тагын ике сүз өстәде: дөбердәтеп алырбыз! дигәннәр.

Тагын бер сәгатьтән Халикъны партактивка чакырып алдылар. Активны Халикълар белән килгән прокурор ярдәмчесе Хәмзин үткәрә. Карар чыгаралар: райком бюросы карарын дөрес дип табарга, шул хакта парторг Тавилов иртәгә гомуми җыелышка хәбәр итә. Биш колхозчы-коммунист райком карарын яклап чыга.

Җыелышны иртән сәгать унга билгеләделәр. Сәгать сигезләр тирәсендә райком секретаре Байназаров килеп төште. Үзе белән яңа председатель дә алып килгән.

Унга чакырган халык тугызда ук килеп тулды. «Саматовны төшерәләр!» дигән хәбәр олысын-кечесен урыныннан кузгаткан. Тик амбар янында, ашлык җилләткән төштә генә, Мөбинә, Мөбәракша абзый, механик Нурмөхәммәт торып калган. Халикъ аларга, ни ялынсалар да, җыелышка килергә рөхсәт итмәгән.

Ул җыелыш гомердә онытылмаслык булып хәтеремдә калды. Бүген, ничәмә еллар узганнан соң да, мин аны яттан сөйләп бирә алам.

Райком секретаре Байназаров яшел япмалы өстәл янына чыгып баскач, клубка күз төшерде. Биек. Якты. Сулышларың иркенәеп китәрлек. «Кара, кара,— дидем күңелемнән үчегеп.— Саматов салдырган клуб. Культура сарае. Бүген син аны алып ташларга тиеш. Эшләгән ярамый сезгә, ялагай ярый».

Секретарь үзен олы итеп тота. Унлап кеше президиум өстәле янына чыгып утырганчы, залдагыларга сүз катмады. Клубны күзәтә, йөзендә елмаю. Менә прокурор ярдәмчесе Хәмзин чыгып утырды, парторг Тавилов чыкты, алдынгы колхозчылар чыктылар. Миңа таныш түгел, кара костюмлы яшь кенә бер егет, тубал чаклы чәчен куллары белән баскалап, өстәл янында күренүгә, минем арттан хатыннар:

— Котдусов. Яңа персидәтел,— дип пышылдашып алдылар.

Халигым никтер кызганыч булып китте. Эшлә, эшлә дә ватык арба кебек чүплеккә атсыннар, имеш. Әллә, югыйсә, президиумга да утыртмаскамы исәпләре? Юк, утырттылар. Байназаров үз янына чакырып алды. Халикъның утырып житүе булды, парторг Тавилов шундук залга төбәлеп:

— Иптәшләр,— диде.

Рәттән рәткә кыштырдау, чыш-пыш килүләр шуылдап узды. Биш йөз кеше сыешлы зал тын калды. Мин чигә тамырымның сулкылдап тибүен ишетә башладым.

— Иптәшләр! Гомуми җыелышны ачык дип белдерәм. Көн тәртибендә председатель мәсьәләсен карау. Каршылар юкмы?

Тынлык.

— Алайса башлыйбыз. Мин сезне мәсьәлә белән таныштырып узыйм.

Әнвәр бик тырышып кырынган. Өстенә зәңгәр костюм, ак күлмәк кигән, галстук таккан. Кәгазь тоткан кулы сизелерлек дерелди. Ул тотлыгыбрак чыккан кыюсыз тавыш белән, сүзләрне азапланып эзлиэзли, председатель Саматов турындагы райком бюросы карарын аңлатып бирде, аннары партоешма карарын сөйләргә тотынды. Аның хәле авыр, ул Халикъны да екмаска, райком каршында да начар булып күренмәскә тырыша. Яшь шул әле, тәҗрибәсез. Тормышта алай булмаганын белми. Әлек кенә ул берьюлы ике байга хезмәт иткәннәр.

«Тәлгатев булса алай эшләмәс иде»,— дип уйлыйм.

Яшь парторгның үзен тотуы халыкка ошамады. Моңарчы тыныч кына утырган зал умарта күче кебек гөжли башлады.

Байназаров сулы графинның бөкесен алып, аңар карандаш белән озак кына кагып торырга мәҗбүр булды. Алай да халык тынычланмагач:

— Иптәшләр, вакытны әрәм итәбез, шауламыйк,— диде.— Минемчә, мәсьәлә ачык: дүрт мең центнер икмәкне бозганы, бер йөз дә алтмыш жиде дуңгыз баласын һәлак иткәне өчен председатель Саматовны эшеннән алырга. Райком бюросының карары шундый. Кемдә нинди сорау бар? Кем чыгып сөйләргә тели?

Арткы рәтләрдән кемдер:

— Мәсьәлә ачык түгел! — дип кычкырды.

Халык дөбердәшеп шул якка таба башын борды. Практичный Мөбәрәкшаның олы улы Сөләйман басып тора.

— Сезгә нәрсә аңлашылмый, иптәш... фамилиягезне белмим.

— Миңа, Галим Саттарович, менә нәрсә ачык түгел,— диде Сөләйман һәм, кулына тоткан кепкасын йомарлаштыргалап, беркавым дәшми торгач, сүзен ялгап алып китте: — Ягъни быел кыш көне, мал кырыла башлагач, безгә районнан биш кешелек комиссия килде. Бер йөз дә алтмыш жиде дуңгыз баласының ящурдан үлгәнлегенә акт язып, кул куеп, печәт басып киттеләр. Монда Саматовның ни гаебе бар? Мин һич кенә дә аңламыйм, сез нигә председательне ул эшкә китереп кыстырасыз?

— Чистый! Тапканнар апалнай кеше!

— Саматов тырышмаса, ярты ферма кырылып бетә иде. Әнә күршеләргә карагыз, өч йөз илле баш дуңгыз малы аягын сузды.

— Әлбәттә, шулай. Дөресен сөйләргә кирәк, ничу!

Кызыша барган залны тынычландыру өчен тагын байтак көч түгәргә туры килде. Шуннан соң бер-бер артлы чыгып кыска-кыска гына итеп биш кеше сөйләде. Күрәсең, кичә партҗыелышта билгеләп куелган кешеләр булгандыр. Саматовның эшләгән эше дә бар, радиодан да күп аңлатты, өйләребезгә кереп хәлебезне белде, дип, бигүк әһәмиятле булмаган якларын санап киттеләр. Аннары райком бюросының карарын

дөрес дип тапканнарын әйтеп, Саматовны эшеннән азат итәргә, яңа килгән яшь кешегә эшне тапшырырга кирәк, дип нәтиҗә ясадылар.

Инде барысы да көйләнгән кебек иде. Парторг Тавилов мәсьәләне тавышка куйды. Саматовны председательлектән алырга дип алты кеше кул күтәрде. Биш йөздән артык кеше Саматов ягында торып калды.

Китте бәхәс, китте сүз көрәштерү. Авыл советы председателе Исмәгыйлев Даут күтәрелде. Озак еллар шушы эштә эшләп, халык акылын үзенә туплый барган, соңгы елларда корсак үстереп җибәреп, тынычрак, гамьсезрәк тормышка күчкән бу абзый сөйләсә сөйли дә, ышандыра да белә иде. Сүзен ул өлкәннәрдән башлады:

— Җәмәгать, ил картлары! Нишләп без болай үзебезне үзебез азаплыйбыз? Саматов Халикъка начарлык телибезмени? Ул егылып үлсен, тарта-тарта сеңгере өзелсен дип әйтәбезмени? Саматов Халикъ эшләде үзенә тиешлесен. Рәхмәт. Инде калганын булдыра алмый икән — бигайбә. Көчәндермик. Үзебез дә гаепле, вакытында ярдәм итә алмадык, булышмадык, аның эшләгән эшенә контроль дә ясап бетерә алмадык. Озын сүзнең кыскасы, Саматов Халикъны без кулдан ычкындырдык, алга таба житәкли алырдай олы житәкче итеп тәрбияли алмадык. Менә шуңар күрә, гаепне үзебезгә дә алып, бушатыйк эшеннән, куйыйк яңа иптәшне, яшь иптәшне, көчле иптәшне...

Авыл советы башлыгы никадәр оста сөйләмәсен, күпме генә хәйләләмәсен, азаккы нәтиҗәсе белән эшне бозып ташлады.

Ул сүзен сөйләп бетереп, урынына да утырып житмәгән иде әле, балта остасы Ахунжан сикереп торды, агач ботакларын балта белән чапкандай селтәнеп, сүзне вак йомычка кебек чәчә башлады:

— Туктап тор, туктап тор син, энем Даут! Авыл советы булсаң да, кулыңда пичәт тотып утырсаң да, мин барысын да дөрес сөйлим, дип ялгыша күрмә, и шулай ук безне, авыл картларын, үз арбаңа жигеп куярга да ашыкма. Кем безгә авыз тутырып ипи ашатты — Саматов. Кем безгә йорт салып бирде — Саматов. Саматов безгә килгән чагында без кем иек? Авызыбызны ачсак, үпкә-бавырыбыз күренеп торган хәерче идек. Эш көнебезгә безнең кайчан да булса бер акча алганыбыз барыемы? Яле, күзгә карап әйтегез, барыемы?

— Юууук,— дип гү килде зал.

— Дөрес әйтәсегез, юк ие. Хәзер безгә Саматов кирәк булмый башладымыни? Без аны бер селтәнүдә, агачыннан кисеп төшергән ботак кебек, алып ыргытмакчы булабызмыни? Шаярмыйк, җәмәгать. Ничу! Амбар алдында арыш кызып ята икән, бер Саматов кына гаепле түгел, ул гупчи дә гаепле түгел, әгәр беләсегез килсә. Саматов Гаптелхаликъ, булсынга йөреп, аяктан егылды, бульнискә кереп ятты, аны аннан адәм рәтле дәваланырга да ирек бирмичә, атылып-бәрелеп чыгарга мәжбүр иттеләр. Кем дип сорыйсызмы? Районнан китерттергән упалнамучынный. Аның райком алдында бик тәти егет булып күренәсе килә, и шулай ук мидал аласы килә, и тота да бу безнең күз карабыз кебек итеп әзерләгән сигез йөз центнир бодаебызны задание өчен дип жиңел кулдан гына жипнәртереп тә куя. Әл-лә-лә-лә, акыллы баш! Син әле аны башта чәч, аннары үр, аннары өч трит сартировкадан үткәр, амбарга, яңгырларга чылатмыйчан, салып куй, менә шуннан ары күрербез, син ул симәнә бодаен жиңел кулдан гына өстәмә план исәбенә жибәрергә праван бармы-юкмы? Менә шул, җәмәгать, минем кара акыл белән уйлый торган фикерем шундый. Байназаров иптәш, син миңа кырын карама, и шулай ук бу алама карт сүз урынына йомычка чәчте дип, кашыңны да жыерып утырма, дөресен дөрес итеп сөйләргә кирәк. Мин персидәтелебез Гаптелхаликъ эшеннән бик тә канәгать, ул эшләсә әле үзем дә кулга балта тотып, сарык бәрәннәренә абзар салып бирергә ниятләп йөрим, и шулай ук яңа мәктәп салынасы дип ишетеп торам, ходай гомеремне биреп, аңар да катыша алсам, гупчи дә начар буласы түгел. Инде килеп

аңлатып бирә алмаган булсам, әйтим: мин, «Кызыл таң» колхозының балта остасы, житмеш яшьлек Ахунжан, персидәтелебез Саматов Гаптелхаликъны эшеннән алуга гүпчи дә каршы.

Балта остасы Ахунжаннан соң халыкның ярсынуы шул дәрәҗәгә житте, Байназаров тагын сөйләми булдыра алмады.

— Бирсдә кайбер иптәшләр Саматовны яклау юлына бастылар,— дип тыныч һәм сабыр булырга тырышып сүз башлады ул.— Әйтерсең, райком Халикъ Габдрахмановичның эшләгән эшен күрми, аның эшенә, әйтерсең, без күз йомабыз. Юк, иптәшләр, эшләгән эш югалмый. Саматов жиде ел эчендә бик күп эш эшләде. Фермаларны яңартты, уңыш алуны яхшыртты, колхозны кадрлар белән ныгытты һәм башкалар, һәм башкалар. Ләкин без, барысын да Саматов кына эшләде дип, сәяси хата ясыйбыз түгелме? Күзләрегезне киереп ачып, тирә-юньгә игътибар беләнрәк карагыз әле: кругом күтәрелеш, кругом үсеш! Юк, хөрмәтле иптәшләр, колхозлар Саматов ихтыяры белән түгел, партия һәм хөкүмәт ихтыяры белән, әгәр беләсегез килсә, колхозчылар, эшчеләр, бөтен халык ихтыяры белән үсәләр. Әлбәттә, Саматовның да оештыручы буларак бу эштә катнашы бар, тик аны күпертеп, әллә ниләр ясап күрсәтмәскә кирәк. Ирешелгәннәр белән канәгать булып яшәү коммунист өчен, партия члены өчен ят бер нәрсә. Райком әйтә, Саматов тынычланды, ди. Саматов таләпчәнлеген югалтты, ди, андый сыйфатлар белән хәзерге этапта зур бер производствоның, алты мең гектар жире булган колхоз производствосының командиры булып эшләп булмый, ди.

Логикасы начар эшләми Байназаровның. Ораторлык куәсе дә ходайга шөкер. Ләкин нигә соң әле ул ялыныр дәрәҗәгә житеп әгъвәли колхозчыларны? Ул бит бюрода Саматовка: «Дөбердәтеп алырбыз!» — дигән. Әгәр залда Саматовның эшен үз күзе белән күргән кешеләр утырмаса, бер хәер иде, Байназаров аларны кайнар сүзе белән ышандырып та куйган булыр иде. Мисал таләп итә залдагылар, ярты сүздә бүлеп кычкыра. Мисал ягына киткәч, эшләр саега. Язгы отчет чорыннан бирле текә күтәрелеш булмады, ди Байназаров. Биш-алты ай эчендә текә күтәрелешне ничек булдырасың? Әнә бит колхозларны илле өченче елдан бирле текә күтәрү бара. Ләкин бик текәләнеп китмиләр бит, текәләнеп китсәләр, үзәк Комитет ел саен авыл турында сөйләп, ике пленумның берсен авыл хужалыгына багышламас иде. Урып-жыю күрсәтелгән срокта үтәлсә дә, югалту бар, ди Байназаров. Кемдә юк ул югалту? — дип карыша зал. Атналар буе баш өстендә явып торсын да — югалту да булмасын. Ашлык кыза, ди Байназаров. Кызмый хәле юк. Басудан коры килеш кермәде бит, тизрәк кайтару, дымлы булса да, ындыр табагына аудару ягын карадык. Үз жае белән барса, Саматов авырмаса, өстәмә ашлык түләтергә дип вәкил маталап йөрмәсә, жилләтеп тә, киптереп тә бетергән булыр идек.

Барлык тавышларны ярып, зал өстенә практичный Мөбәрәкша күтәрелде:

— Әгәренки, Байназаров иптәш, Саматовны урыныннан алырга дип каныккансыгыз икән, сез аны алмыенча туктамассыгыз инде. Аңысын гына беләбез. Илла дә мәгәр бу эшне безнең «Кызыл таң» колхозчыларының ихтыярыннан башка эшлисез икән, райком әле соңгы чик түгел, дәрәслекне таба торган бүтән төрле юл да бар. Безнең ише буразнага бил бөккән кешенең дә сүзен бик һәйбәтләп тыңлый белә партия.

Моңысы Ахунжан карт сөйләгәннән дә кайнаррак булып чыкты. Иңрәк түреннән чыккан сүзгә халык гөр китереп кул чапты.

Аннан соң Тавилов торып аңлатып маташты, Байназаров тагын үзенең ораторлык куәсен эшкә жикте, берсе дә ярдәм итә алмады. Кул күтәрткәннәр иде — алты уңай, биш йөз каршы.

Миңа шунда мине Байназаровның мәсьәләне бөтенләй көтелмәгән яктан китереп куярга маташуы сагайтты. Ул халык гөжләгән арада

Халикъка таба иелеп, аның белән озак кына сөйләште, тегесе башын чайкаштыргалап торды, нигә чайкый — аңламадым.

Халикъ аягүрә басты. Үтә дә якын итеп, үзен эштән азат итүләрен, бик тә арыган булуын, сәламәтлеге житмәвен, райком карарына буйсынырга кирәклеген әйтте. Тик шунда гына аңлап алдым. Байназаров тәмам хурлыкка кала башлагач, Халикъны әгъвәләгән, башлаган эше барып чыкмаса, авторитеты бетүдән куркып, хәтта ялынудан да тайчанмаган.

Саматовның колхозчыларга сүз кушуы янә аптырау тудырды. Халык икеләнә. Җибәрер иде — Саматов кирәк, җибәрмәс иде — каныгалар Саматовка.

Ир-ат арасыннан сөйләрдәй кеше калмагач, хатын-кыз сүз алды. Монда инде акыл түгел, йөрәк сөйли.

Карасам, теге заманда каз-үрдәге белән иза чиккән тол хатын Мөбинә кулларын бутый.

— Зерә дә кирәкмәс эш белән вакыт уздырабыз. Амбар янында ашлык кыза! Кем җавап бирә? Клевер басуларын сөрдереп бетердегез. Кем җавап бирә? Мал-туар курмысыз калды, кем җавап бирә? Чыдаган Саматовка рәхмәт. Мин булсам, күптән тиләләр йортына керер идем. Я асылынып үлгән булыр идем.

Зал тып-тын булды.

— Нинди тәкъдим әйтәсез? — диде Тавилов.

— Азапламагыз Саматовны, ике айга ял бирегез. Эшләмәде түгел, эшләде. Үзе әйтеп тора, авырыйм, ди, дөрес бит инде авыруы, персидәтел башы белән уборка өстендә больниска кереп ятмас иде авырмаса. Барсын Кавказга, я Кырымга, ял итеп кайтсын да тагын эшләсен. Саматовның бездән артканы юк.

Бу тәкъдим халыкка бик тә хуш килде. Ул тик ике кешегә генә хуш килмәде. Берсе — Байназаровка. Байназаров үтенүе белән — Халикъка.

Байназаров халыкны үгетли-үгетли хәлдән тайды. Тавилов халыкка аңлата-аңлата арып бетте. Ә халык үзе акны кара дип аңлатуларыннан гаҗиз иде. Һәр ике як инде хәлдән тайган, кичке җиделәр булып килә иде инде, минем сантый Халигым тагын үзе торып басты:

— Иптәшләр, минем сезгә бер генә үтенечем бар. Азат итегез мине. Иптәшләрчә әйтәм: сугышны буеннан-буена йөреп чыктым. Сугыш беткәнгә унҗиде ел, бер көн дә ял иткәнем юк. Менә авыл хуҗалыгы институтын бетергән яшь-яшь иптәш килгән, энергиясе бар, белеме бар, аңар мин килгәндәге төсле өшәнгән колхоз калмый, бергә-бергә алып барырсыз. Булмый миннән, коткарыгыз.

Заманында Халикъка бик нык ярдәм иткән кеше, механизаторларга ашлыкны гектардан түгел, центнердан түләүгә риза булган комбайнчы Габдулла Маликов торды.

— Чыннан да, алҗытмыйк, иптәшләр, Саматовны. Арыса да арыгандыр, машина түгел бит, адәм баласы. Бушатыйк эшеннән. Тик минем сүзем шул: рәхмәтле булыйк. Хезмәт кенәгәсенә рәхмәт язып җибәрик. Райком аның кызыл билетын пычратып җибәрмәсен, әгәр шунар риза икән, райком секретаре Галим Саттарыч җыелыш алдында сүз бирсен.

Бирми кая бара ала? Иплән кенә әйтергә мәҗбүр булды секретарь:

— Моңарчы райкомга бар җирдә дә буйсыналар иде. Бар җирдә дә партия җитәкчелек итә. Әгәр без Саматовның партия билетына тап төшерергә уйласак, бюрода ук партиядән чыгарган булыр идек. Борчылмагыз, ул эш булмас. Инде яңа председатель мәсьәләсенә килгәндә, без сезгә начар кеше тәкъдим итмибез,— дип булачак председательнең биографиясен сөйләп чыкты. Аннары колхозның төзелеш эшләренә ярдәм итәргә, нәрәттән тыш материал табып бирергә вәгъдә итте.

Ниһаять, кичке ун тулганда, председатель Саматовны эшеннән азат итеп, аның урынына Котдусовны сайлап, сүлпән генә таралыштылар.

Башка чакта булса, мин бу хәлгә сөенер генә идем. Иремнең председатель газаплары мәңгегә бетте! Безгә генә тишек-тошыкны томалап, ала канат булып йөрергә димәгән, үз кайгыбызны кайгыртырга да вакыт. Ийе, башка вакытта булса мин нәкъ шулай уйлаган, шулай фикер йөрткән булыр идем. Бүген мин алыштырып куйгандай үзгәргәнмен. Күңелемдә кем беләндер ут ягып кычкырышасы килү уе яши. Халикъны рәнжеттеләр. Гадел кыланмадылар. Ул гомерендә беренче мәртәбә йомшаклык күрсәтте. Мин моңа каршы. Каршы мин! Һәм мин моны болай гына калдырмаячакмын. Шөкер, миңа хәзер обком юлы таныш. Халикъны яклап мин Беренченең үзенә барырмын. Бу юлы инде мине ансат кына борып җибәрә алмаслар. Мин үз кайгымны кайгыртып йөрмим...

Халикъка белдерми генә юлга җыена башладым.

Тик миннән дә өлгеррәкләр бар булып чыкты. Колхозчылар җыелыш беркетмәсен туп-туры обкомга җибәргәннәр. Шау-шулы көннән соң атна-ун көн дә узмады, Халикъны Казанга чакырып алдылар. Халикъ авыл хуҗалыгы секретаре янына барып керә. Караса — Байназаров та шунда.

Секретарь нык итеп әйтә боларга:

— Икегез дә дөрес эшләмәгәнсез. Сез, Байназаров иптәш, колхоз җитәкчесен иң кирәк чагында эшеннән аергансыз, халык җыеп шаулагансыз — персональ җавап бирергә туры килер. Ә сез, Халикъ Габдрахманович, номенклатурадагы работник. Сезне халык ихтирам иткән, урыныгызда калырга иде, колхозчыларны кыен хәлгә китереп куймаска иде. Конфликтны без хәл иткән булыр идек. Ярый, эшләнәсе хата эшләнгән, аны хәзер кире кайтарып булмый. Сезгә тагын Кама буендагы бер колхозны тапшырабыз. Тәҗрибәгез бар. Чыныгу алдыгыз. Бер ай ял итегез дә яңа коллективны кабул итәргә әзерләнегез. «Кызыл таң»га булышу шулай ук сезнең өстә кала.

Шулай итеп, Саматов тагын колхозга башын китереп тыкты. Мин бу юлы гаҗәпләнмәдем, тик тагын авыр көннәр кичерәсебезне күз алдына китереп, аңардан сорадым:

— Әйт әле, Халикъ, шул хәтле мыскыл иткәннән соң да ничек синең колхоздан җаның бизмәде?

Ул миңа бик тә үз итеп карады, беркавым дәшми торгач әйтте:

— Беләсеңме, Рокыя,— диде,— тормышта төрле хәл булуы мөмкин. Әгәр кешенең үзәге чын булса, ягъни чикләвекнең төшенә зыян килмәсә, ул тагын тернәкләнә, тагын яңа үсенте бирә. Син минем иң якын кешем, минем белән бергә күп җәфалар чиккән хатыным. Яшермим синнән, әйтәм: үзәгемне саклыйм мин, төшемне. Мине туктаусыз дөмбәсләп чыныктыралар. Мин бит егерме яшьтән партиядә. Һәм гел сынап киләм. Халык партия дип карый. Югарыда кем генә утырмасын, хикмәт утыручыда түгел, фундаментта. Безнең партиянең фундаменты нык, әгәр шушы фундаментка ялгышып кына ватык кирпеч яки черек агач эләксә, ул барыбер фундаментны үзгәртә алмый, чөнки аны алып ташлыйлар...

Халикъ Саматов турындагы чын хакыйкать менә шушы. Мин беренче елларны аңа кияүгә чыгуыма үкенеп, гел аерылу уе белән яшәдем. Ләкин булдыра алмадым. Мин аны түгел, ул мине үз юлы белән алып китте. Мин ул хакта беркайчан да, берәүгә дә сөйләмәм диган идем. Еллар үтеп, Халикъ сүзләре дөрескә чыккач, өстәвенә, өч улымның өчесе дә әтисе юлы белән китеп баргач, сөйләргә булдым.

Ул хакыйкать кешеләргә кирәк.

*Әгерже — Казан.*
*1970—1971.*

## Рәшит Гәрәй

### Гөрләп кабынып төсле

Язны сагынып көткән үзәннәрдә
Тракторлар бердәм кабына.
Ә мин килдем авыл музеенда
Ялда яткан «Фордзон» янына.

Ул хәзер дә гөрләп кабынып төсле
Безнең чорның кайнар сулышыннан...
Үзе сызган тәүге буразнага
Карап тора гүя шушыннан.

### Исемеңне язсын бүтәннәр

Бер уйласаң, кызык: кемгә инде
Кирәк булган минем исемем.
Үткен пәкем бар дип мактангандай,
Сырла, имеш, мәктәп ишеген.

Икенчедә уйган хәрефләрем
Сакланганнар шушы көнгәчә.
Бусагадан атлап кергән чакта
Малай чагым миңа эндәшә:

— Яңа мәктәп салыныр... Бу искесен
Ишегеннән башлап сүтәрләр.
Ә саклансын дисәң, исемеңне
Үзең түгел, язсын бүтәннәр.

### Тик шулай да...

Без үлсәк тә, дөнья җимерелмәс,
Аның бездә артык эше юк.
Тормыш һаман шулай дәвам итәр,
Мәңгелеккә килгән кеше юк.

Тик шулай да каушап гомер итәм
Гүргә иртә ятып калудан:
Эшләнмәгән эшләр, арттан килеп,
Чытырдатып тоткан чабудан.

### Карлыганнар каралган

Карлыганнар, карлыганнар,
Карлыганнар каралган.
Син карлыганнар җыйганда,
Яннарыңа баралмам.

Саубуллашып китә торган
Көннәрем житә инде.
Илемнең ерак чигендә
Дусларым көтә мине.

Тагын аерылышабыз, дип
Моңаю ярамый ла.
Карлыгандай күзләреңне
Тутырып кара миңа

## Кем уйлаган...

Яшьлегебез төсе булып калган
Истәлекләр сиңа якынмы?..
Сүткән чакта сезнең йортыгызны
Хат тапканнар... Минем хатымны.

Озак еллар буе сакланган ул
Син яшереп куйган урында.
Үз хатымны бүген үзем укыйм,
Сиңа булган гыйшкым турында.

Кем уйлаган насыйп буласыңны
Синең ул чак жиде ятларга...
Каршысына җавап язылмаса,
Саргаялар икән хатлар да.

## Ут йотып кайтып киләм

Кая гына барып чыкма,
Һәйкәлләр дә һәйкәлләр.
Алар яуда үлгәннәрнең
Исемнәрен әйтәләр.

Туган елларын әйтәләр...
Күбесенә егерме.
Тирән кайгым йөрәгемдә
Гомер буе йөрерме?..

Сукмаклар-юллар буйлап мин
Уйларга батып киләм.
Яуда үлгәннәр эзеннән
Ут йотып кайтып киләм.

## Олы һөҗүм шулай башланды

Тынычлыгын жуйган игенчене
Кырлар көтә шулай зарыгып.
Комбаенын соң кат тикшерде ул
Һәм карады аны кабызып.

— Барысы да бик шәп! — дигән төсле
Яңгырап китте мотор тавышы.
...Штурвалга баскан яшь егетнең
Җәйге төне таңга авышты.

Сизеп торам: кырлар бушаганчы
Онытылыр ялы, ашлары...
Тик жиңүгә генә илтә торган
Олы һөҗүм шулай башланды.

Әхсән Баянов

# УТ ҺӘМ СУ

РОМАН [1]

## ИКЕНЧЕ БҮЛЕК



Дөрес эшлисеңме, юкмы — Табигатьтән сора.
Дөрес яшисеңме, юкмы — тирә-якка күз ат.

Шәһәр үзен генә түгел, әйләнәсен дә үзгәртә. Вакыт әкрен-әкрен урман эченә алтын төсләр кертә-кән кебек, авылларга да яңа төсмерләр бирә. Шул төсләр исә кайчак кызык, ә кайчак гыйбрәтле сурәтләр булып күңелгә керәләр.

Иске Чурай — шәһәргә якын авылларның берсе. Бүген Фәез шул авылда, бүген ул да кунак. Аның идарәсе колхозга терлек абзары салып бирергә вәгъдә иткән иде. Ниндирәк абзар кирәклеген белер өчен башка инженер җибәрергә мөмкин булса да, тагын үзе килде.

Колхоз председателе өйдә туры килмәгәнлектән, фермаларны партком секретаре белән карадылар. Терлекләр әле дә җәйләүдә. Сыер абзарлары өр-яңа һәм чиста. Түбәләре шифер белән ябылган.

— Барысы да типовой проект белән салынды,— диде секретарь бераз гына мактана да төшеп.

«Председатель исә шефлык итүчеләр алдында зарланырга тырышыр иде», дип уйлап алды Фәез.

Аннары сарык абзарларын карадылар. Монда да шул ук хәл — керсәң чыгасың килмәс. Бозаулар янына баргач та шулай. Бернинди начар ис юк. Киресенчә, шәһәрдә булмый торган дымлы әчелек — күңелне күтәрә торган ис. «Сухое вино» исе. Башына кинәт килгән шул мәзәк уйдан Фәез үзе дә көлеп куйды.

Атлар абзарына машина белән бардылар — анысы бөтенләй бүтән якта икән. Утарда җан әсәре юк. Атлар эштә, эштән бушаганы — яланда. Абзарга кергәч, җиләс әчелек борынны тагын да рәхәтрәк итеп кытыклый.

Идәннәрдә су җыелып тора. Югарыдагы ачык-тишекләрнең санына чыгарлык түгел.

— Ник түбәне адәм рәтле итеп япмыйсыз? — диде Фәез, йөзенә беренче тапкыр ризасызлык билгесе чыгарып.

---

[1] Дәвамы. Башы 9 санда.

— Атларга почет ул хәтле түгел бит хәзер, үзең беләсең,— диде юлдаш агай ваемсыз диярлек тавыш белән.— Аннан соң алар түземлерәк тә. Сөт кимисе юк. Менә шуңа күрә килеп чыга инде ул тишекләр.

Абзарларны карагач, тагын елга буена төштеләр — үзәнлекләр буйлап уздылар, үр өстендәге каенлыкка керделәр.

— Бу агачлык дәүләт җиреме?

— Колхозныкы.

— Әйбәт. Менә шушында яңа абзар салырга булыр.

— Бик тә мөмкин.

Бераз йөргәч, уйлангач һәм машинага утырып, агай правление өенә житәрәк туктатуны сорагач кына, Фәез аңа:

— Председательгә минем тәкъдимемне җиткерегез,— дип куйды.

— Ярый, житкерербез. Нинди тәкъдим?

— Алар бездән тагын бер сыер абзары салуны сораганнар иде. Ә без ат абзары салып бирәчәкбез. Сыерлар хакында үзләре дә шәп кайгырталар икән.

— Төзүчеләргә сөт кирәкмимени? Ат сөте эчәләрме? — дип чәпчергә тырышты партком секретаре.

— Сөт тә эчәбез, әлбәттә. Ләкин ашказаны хакында уйлап, күңел мәнфәгатен дә онытырга ярамый. Менә шул, без сезгә ат абзары салырбыз.

— Ярый соң, уйлашырбыз.

Урам буйлап күпмедер баргач, машина туктады. Соргылт чирәмдә язгы үлән төсле яшел чебиләр йөри иде. Сентябрь аенда, сентябрьнең егерме бишендә аларны күрү могжиза белән очрашу кебек тоелды Фәезгә.

Чебешләр чирәм өстеннән нәрсәдер чүпләгән булып йөриләр. Әнкәләре, артларыннан калмыйча, үз телендәниләрдер сөйләнә, үгет бирә.

Фәез берсен тотарга да чамалаган иде, тавык кыр-кыр килеп өскә ташланды. Тавык чыр-чуын ишетеп, ахрысы, капкадан әби күренде — беренче карашка ул шушы ак тавыкның икенче данәсе сыманрак тоелды. Фәез үзен ничектер гаепле хис итеп, аңа таба атлап китте:

— Исәнме, әбекәй?

Карчык эндәшмәгәч, Фәез: «Әби тәкәбберрәк, ахрысы», дип уйлап, тынып калды. Әби исә чебешләрне өй янынарак куа башлады:

— Көш, көш. Өй тирәсендәрәк тибенегез, дип күпме әйттем инде сезгә. Ашарга җитмиме? Аллага шөкер, үзем биргәне дә бетмәгән ләбаса.

Фәез, сихерләнгән шикелле, әбидән һәм чебешләрдән калмыйча, капка төбенә тикле озата килгәч кенә әби игътибарына лаек булды.

— Кем дип әйтим соң, улым, сине? Зәйнетдин малае дисәм... пөхтәрәк...

— Мин бу авылныкы түгел, әби, белми торгансың.

— Кайсы авылныкы соң?

— Мин Чаллыдан, әби.

— Алай икән.

Әбинең белергә теләү хисе шуның белән чикләнде, ә Фәез, чебешләр сихереннән ычкына алмыйча, капкадан ихатага үк узарга тиеш тапты. Ихата ватык-җимереклеге белән башкаларныкыннан шактый аерылып тора икән. Ләкин Фәезнең игътибарын монысы озак җәлеп итә алмады. Аның күзләре һаман чебиләрдә иде.

— Әйт әле, әби, тавыгыгыз качып чыгарганмы бу чебиләрне? — Авыл малае буларак, Фәезнең мондый хәлләрне күп күргәне бар иде.

— Качып түгел, үзем чыгарганыем шул, балакаем, үзем.

— Чебешне, болай, яз көне чыгаралар түгелме соң?

— Һәй, сөйләмә инде, балам, буталганмын. Көзге матур көннәрне язга исәплэп, тавык утыртканмын, балакаем. Менә шушы юньсез бутады. Көз көне кыртлап йөрмәсә, адәм таганасе, чеп-чеп-чеп-чеп!

Әби агач тагаракка су салды.

— Яз белән көзне бутагансыңмыни, әби?

— Бутаганмын шул, балам, бутаганмын.

— Көннәр җылы булгач, көз белән яз бер инде ул, әби.

— Шулай дип белгәнмен шул, гөнаһ шомлыгы, шулай дип уйлаганмын.

— Әби, сиңа ничә яшь инде?

— Әлла, сиксән тула бугай.

Фәезне юксыныпмы, машина янындагылар да ихатага кереп, алар да әбидән шул ук чебешләр хакында сорашкач, өйдән яшьрәк бер апа чыкты.

— Бездәме соң, мин әйтәм, бу тавышлар. Машинагыз да ят тоелгач, аптыраган идем. Әйдәгез, өйгә кергез,— дип ана каз төсле пайпылдый апа.— Өйгә кереп батарлык та... курыкмагыз. Мин әле фермадан яңа гына кайткан идем — җыештырып өлгермәдем. Әйдәгез, әйдә,— дип сөйләнә-сөйләнә ишек ачты.

— Иминлек телибез бу йортка,— диде Фәез бусаганы узганчы ук.

Авыл өе ачык күңелле, үзенең иң якты серләрен түргә, күргәзмәгә куя. Зур рамнарга куелган фоторәсемнәр, мендәрләр, чигешләр һәм башкалар, һәм башкалар.

Фәез апалардан сораша-сораша карточкалар карагач, гаилә биографиясе күз алдына тиз арада килде дә басты. Биография гап-гади — халык, ил биографиясе: колхоз оешкан елларда яшь игенче наданлык белән көрәшкән, иртә таңнан торып караңгы капканга кадәр басуда йөргән, трактор йөрткән, басуның аркылысын-буен меңнәрчә кабат исәпләп-үлчәп чыккан. Фотокарточкадан үзенең бернинди хәйләсез туры карашы белән яшь игенче карап тора.

— Өйләнешкән елны төшкән иде, миңа хәтле,— дип аңлатты хуҗа бикә.— Ә менә монда без икәү, аның белән.

Мондый пар рәсемнәрне дә күп күргән Фәез һәм күпме күрсә дә күңелдә әллә нинди авыртуга охшашлы соклану белән карый ул аларга. Толымнарын күкрәгенә салган, тулган ай төсле түгәрәк йөзле, оялчанлыгы хәтта рәсемгә күчкән чибәр кыз һәм баягы туры карашлы шат егет... Көр күңеллелекнең мәңгелек рәсеме калган шулай һәм тагын күпме торыр — ә кешесе... кешеләре...

— Ул сугыштан кайтмадымы? — дип сорады Фәез, күңелдә җавап әзер булса да.

— Кайтмады шул, кайтмады...

Апаның сүзендә артык әченү юк, шулай да фаҗиганең кимегәнлеге һич сизелми, дөресрәге, эчкә яшерелгән булуы аны тагын да көчәйтә генә.

— Ә бу яшь солдат кем?

— Улым.

— Хәзер кайда?

— Чаллыда.

— Чаллыда? Анда нишли?

— Бульдозер дигән трактор белән җир актара.

— Шәп! Әтисе юлыннан киткән икән.

— Бераз гына тайпылды шул. Шулкадәр әйттем, шулкадәр пайпылдадым — китте дә барды. Җыен карт-коры рәтеннән нишләп ятыйм сезнең авылыгызда, ди.

— Шаярта торгандыр.

— И, уены-чыны бергә инде аның,— дип, апа кулын селтәде.

— Исеме ничек?

— Рәшит.

— Фамилиясе?

— Миңлекәев фамилиясе.

— Минлекәев! Ишеткәндәй булам.
— Бергә үк эшлисездер әле.
— Бергә үк түгел, югыйсә белер идем.
— Ә, пәрәмәч... Сезнең белән үзем дә мавыгып киткәнмен ләбаса. Әйдәгез, өстәл янына. Шулар хакында сөйләшә башласаң, дөнья оныдыла.
«Шулар» дигәне — улы һәм ире... Икесе дә йөрәк түрендә — икесе ике төрле газаплый...
Ниһаять, өстәл өсте сый-хөрмәт белән тулды. Самовар ачылып, аннан йомыркалар алынгач һәм алары да табынга куелгач, апа сөтле чәй ясады. Чынаякны аның кулыннан алганда Фәез апаның исемен сораган иде, тегесе гадәтенчә тезә китте:
— Мин шул һаман да Гөлниса апаң булам инде. Шакирҗаным Ниса ди торган иде. Хәзер Гөлнисаттәй диләр. Әйдәгез, барыннан ризык итегез, кабып кына утырыгыз әле. Юл кешеләре бит сез. Юлда ашасы килә ул.
Тавышсыз-тынсыз гына утырганда, өйгә әби керде. Ул беркемгә дә артык илтифат итмәстән:
— Аллага шөкер, җир йөзендә йөрибез әле,— дип сөйләнә-сөйләнә казан ягы бүлмәсенә узды.
— Бу — минем бианам була инде,— диде Гөлнисаттәй.— Колаклары бераз гына сагайды шул, гаепләмәссез инде.
— Ничә яшьтә әби?
— Туксән икесе тулды.
— Яше бар икән шул.
Чәй эчкән арада гаилә биографиясе тулылана торды. Рәшит шәһәргә киткәч, болар икәү генә калганнар икән. Болай яшәү шактый кыен һәм күңелсез тоелып, Фәез аларны торган саен ныграк кызгана барды һәм, ничектер, ярдәм итәсе килде. Гөлнисаттәй исә, аның нәрсә уйлавын белмәстән, һаман авырткан җиргә кагыла:
— Шакирҗан үлгәннән бирле шушылай инде. Кыен булса да ямьсезләнешмәдек. Бергә, аллага шөкер. Кайбер адәмнәр үзләренең туган аналары белән дә болай тату тора алмый. Әйтмәгәнем булсын — бик матур гомер кичердек.
— Ике хатын-кыз. Йорт-кураны карарга гына кешеләре юк, шул яклап кына кыен,— диде сүзгә сирәгрәк катнашкан Әхмәтхан агай.— Малайны җибәрү дөрес булмады.
— Ә үзегез малай янына барсагыз? — Фәезнең баядан бирле тел очында бөтерелгән һәм әйтергә җай тапмый торган соравы булды бу.
Гөлнисаттәй көлеп үк җибәрде:
— Һи! Безнең кебек карт-коры нигә кирәк инде ул шәһәр җирендә. Әнә улымны, көчле-куәтле булгач, аркан белән дә бәйләп тота алмадык.
— Сезгә дә эш табылыр иде, Гөлнисаттәй. Өегез дә шактый тузган... Казна квартиры булса, караучы кешеләре дә була, хуҗалык дип аһ орасы юк,— дип, Фәез чынаягын самовар борыны астына куйды.
— Казна квартиры! Безне генә көтеп торалардыр инде анда, кемгә бирергә аптырашта калганнардыр. Бик кызык кеше икәнсең, энем.
— Әйе шул, бик кызык кеше мин, апа. Мин сиңа үз идарәмдә менә дигән эш табам. Я маляр, я штукатурчы буласың. Өйрәтербез — икеч айда менә дигән тәзүче буласың.
— Һе-һе-һе, әбиегезне дә өйрәтерсезме?
— Аны ук өйрәтеп булмас... Ә сезне өйрәтербез.
— Булды алайса, киттек,— диде Гөлнисаттәй шаяртып,— фатир бирерсез, улым белән бергә торырбыз.
— Әйе шул — өч таган таймас.
Шуннан соң Гөлнисаттәй шаярудан туктады.
— Рәшит белән киңәшеп карарга ярый шул.

— Бик ярый, Гөлнисаттәй.
Тагын күпмедер утыргач, Фәез кузгалды:
— Бик зур рәхмәт сезгә, авыл чәе шул хәтле тәмле булды.
— Үзең авыл чәен яратсаң да, апаларыңны калага чакырасың әле. Алар китсә, болай тәмле итеп кем әзерләр сиңа чәйне? — дип, секретарь агай рәхәтләнеп бер елмайды.
Фәез саубуллашты:
— Ярый, хәбәрләшербез әле, Гөлнисаттәй.
— Килгәндә, туп-туры үзебезгә керегез. Ачык чырай, такта чәй һәрвакыт булыр.
— Рәхмәт, керербез. Бер иялэшкәч.
Тәрәзәдән карап калган Рәбига әбигә һәм урамга чаклы озата чыккан Гөлнисаттәйгә Фәез машинадан кул болгады.
Ярым шаяртыбрак әйткән булса да, Фәез сүзен үтәргә бик тиз җай тапты. Иң башта, кирәклеге шактый шикле булса да, Гөлниса апаны идарәнең авылдагы материалларын саклаучы итеп эшкә алды һәм правление аркылы рәсмиләштереп тә куйды. Шул рәвешле Гөлнисаттәгез җинел генә кала эшчесенә әверелде һәм паспорт алды. Ай чамасы вакыт үткәч, бүтән эшкә күчерелүе сәбәпле, ул автобус белән көн саен Чаллыга йөри торган булды. Рәшит тулай торакта семьялы кешеләр белән тора иде. Аларга иркенрәк квартира бирелгәч, Рәшит әниләрен үз янына алды. Чуртан кушуы буенчарак килеп чыкты бу хәл. Ләкин чуртанның Фәез икәнен Гөлнисаттәй бик яхшы белә, аның яхшы кеше икәнен дә сизә, тик мондый да зур изгелекне ни өчен эшләгәнен, ни өчен нәкъ менә аларга эшләгәнен генә чамалый алмый интегә. Гидрострой поселогында бөтен шартлары килгән өр-яңа квартирга кереп утыр әле! «Йа ходай, бар бит шушындый да яхшы бәндәләрен!» дип Фәезгә бианасы белән икәүләп догалар кыла-кыла, намазлар багышлый-багышлый яшәп китмәсеннәрме!
...Без, бу җәһәттән, чак кына алгарак чаптык, ярый, дәвамын үз вакытына калдырыйк та яңадан бераз гына артка чигеник.
Төсмерләр дигәннән китте бит сүз. Шулай көннәр үтә торгач, ап-ак декабрь җитте.
Ауга чыгарга нияте һәм мөмкинлеге булса да (якшәмбе көн), Фәез чаңгы һәм мылтыксыз гына чыгып китте. Исәбе — төзелеш барган һәм барачак мәйданнарны карау иде.
Беренче булып, су астында калачак авылларга бардылар. Күчәргә тиешлекләре ауган капка һәм коймалар белән язылган. Өйләр, ихаталар — сырынты астында. Бигрәк тә шундый сурәт күңелдән китмәс — ярым җимереклек арасыннан мүкләк сыер башын сузган:
— Мму-у! — дип мөграп тора. Адәм теленә күчерсәң, «ярдәм ит» дигән сүзме икән инде бу.
«Ничек ярдәм итик соң сиңа, хуҗаң карамагач...»
Хуҗа, үз адресына тигән сүзне сизгәндәй, каралтының икенче ягыннан башын сузды да, кешеләр барын күргәч, киез итекләре белән лаплоп атлап якынрак килде, йөзендә — эчкерсез елмаю.
— Исәнмесез, әйдәгез, өйгә узыгыз.
Таныш түгел кешене бары тик авылда гына өйгә чакырулары ихтимал. Күңел сәламәтлеге, ышанучанлык билгесе бу. Рәхмәт абзыйга. Тик Фәез баягы шелтәсен хәтергә төшерде.
— Ник ныгытмыйсың бу абзарны?
— Китәсе бит.
— Терлек беләме шуны?
Абзый җавап урынына кулбашларын җыерды.
— Ә кая китәсез?
— Калага. Төзелешкә.
— Гаилә зурмы соң?

— Сигез бала.
— Сиңа, иптәш, үзеңә бер детсад кирәк булачак.
— Әһе,— дип кенә самими елмайды хуҗа.
— Ә нишләп өй тирәсендә агачлар юк синең?
— Салкын тигәч, кисеп аттык.
— Ник яңаны утыртмадыгыз?
— Балыклар алма ашамый бит.— Абзый тагы елмайды.
— Начар, бик начар.
— Ә нишләргә тиеш соң без?

Фәез үзе дә киңәш бирә алмый икән шул. Аптырагач, сүзне шаянга борды:

— Тик абзарны нygытырга кирәк. Югыйсә, сыерың жалоба бирде.

«Урамга машина күреп чыккан картлар, олтанлы киез итек кигән, шәл бөркәнгән апалар, әбиләр! Ничек ярдәм итәргә соң сезгә? Бер генә юл кала — төзергә, күбрәк төзергә кирәк».

Шактый ара узгач, юл урман эченә алып керде.

Үз гомерендә Фәез урманнарны күп күргән, хәтта тайга төпсезлеген тойган кеше — ап-ак кар белән төренгән ылыслар тынлыгын, сирәк ишетелеп киткән кыштырдауларның татлы мәгънәләрен яхшы аңлый ул. Кара урманнарда куна калганы, аюлар белән күзгә-күз очрашканы, мөнәсәбәтләрне «сөйләшүләр юлы» белән хәл иткәне бар. Аучы булса да, тынычлыкны сөя Фәез.

Хәзергә андый тынлыкны табу җиңел түгел, әлбәттә. Таныш кыштырдаулар бүген ишетелми, кар өстендә җәнлекләр калдырган күңелле язулар күренми. Фәез, сунарчы буларак түгел, табигать баласы буларак шуларны юксына. Җәнлек, мылтыктан бигрәк, балтадан курка бит...

Калку җирдән озак кына баргач, яңа күренеш ачылды: кем ничек теләсә шулай кисеп аударылган чыршы, наратлар. Аяк астында тыпырчынып, сулкылдап, соңгы сулышын алып ята урман. Чибәр кызның кабарып торган чәчләрен кисеп, аяк астында аунаткан шикелле... Ләкин күз яшьләре — урынсыз, кызгануны да җиңәргә кирәк!

Фәез, машинасын калдырып, эчкәрәк узды. Агач башларында йөргән җил белән бәхәсләшеп күпме торгандыр, бервакыт яр буеннан ике-өч йөз метр чамасы ераклыкта ниндидер кыштырдаган тавыш ишетелде. Караса, әллә эт, әллә бүре... Кыяфәтенә караганда — бүре, ялгыз бүре. Әллә Фәезнең аучы икәнен һәм бүген мылтыксыз икәнен белеп, аның чак кына элегрәк кылган гөнаһлары өчен үч алырга килгәнме ул? Сагалап торганмы? Үз биләмәсенә кергән кешеләрнең һич югында берсеннән үч алмакчымы? Менә ул карап тора. Килеш-килбәте һич тә яхшылык вәгъдә итми. Кеше һәм бүре... Гаҗәп тә түгел — ике дошман. Алар арасында игълан ителмәгән сугыш бара...

Ләкин бүген кеше сөйләшү башларга җыена. Ул аңа эндәшә:

— Сиңа миннән ни кирәк?

— Синнән миңа берни дә кирәк түгел! — Бүренең кыяфәте шулай дип әйтә кебек. Фәез күптәнге аучы, бүреләр телен аңлый ул.

Бүре әйтә:

— Син, нәкъ минем кебек үк, бүтән җан ияләре исәбенә яшисең. Шуңа күрә мине үзеңнең көндәшең дип исәплисең. Син үзең ашарга ниятләнгән сарыкны ашаганга күрә миңа каршы сугышасың. Ләкин минем үз хокукларым бар — мин дә дөньяга табигать тарафыннан китерелгән, нәкъ синең кебек үк.

Кеше:

— Бүтән җан ияләре исәбенә яшәүне мин уйлап чыгармадым. Бу тарих логикасы белән, биологик һәм социаль тарих логикасы белән аңлатыла — бүтән ысул хәзергә минем кулда юк.

Бүре:

— Туклы булыр өчен син сарык үтерәсең.

Кеше:

— Иртәгә аны үтерү мәҗбүри булмаячак. Иртәгә миңа табигать бирә торган тире, мех, ефәкне, җитен һәм киндерне, каучук һәм мамыкны, агачны һәм металлны, табигый буяуларны химия дигән тылсымлы көч бирәчәк. Хайванның тиресен тунау кирәк булмаган кебек, иртәгә миңа аның тәнен кимерүнең дә кирәге булмаячак. Минем табынымда үз кулым белән ясаган аксым, үз кулым белән ясаган май, үз кулым белән ясаган шикәр һәм башка әйберләр булачак.

Бүре:

— Мин синең белән тик шул чакта гына дуслашырмын. Тик шул чакта гына син үзеңне чын Кеше дип атарга хаклы булырсың... Барлык үткән заман кешеләреннән принципиаль аермаң шунда гына барлыкка килер. Тик шул чакта гына син үзеңне чын мәгънәсендә ихтирам итә алырсың, үзеңне безнең өлкән дустыбыз дип исәпләргә лаек булырсың. Ә хәзер — син безнең дошман.

Кеше:

— Барыгызга булмаса да, кайберләрегез белән бүген үк дус.

Бүре:

— Син аларны да бит матурлык ләззәте алу өчен түгел, ә кирәк өчен генә үстерәсең. Ә мәҗбүрият бетсә, син аларны үрчетерсеңме? Шулай хәтта йорт хайваннары да юкка чыкмасмы? Атлар әнә бетеп бара...

Кеше:

— Әйе, миңа уйларга кирәк.

Бүре:

— Син уйланып торган арада күп җәнлекләр үлеп бара. Элек заманнарда бу урманнарда аю йөргән. Хәзер ул кайда? Мин дә аның эзләре белән барам... Мин дә үлсәм, синең бит ярты дөньяң юкка чыгачак. Ярты дөньяң — синең җаның, күңелең. Синең әкиятләрең бетәчәк, могҗизаларың юкка чыгачак. Бала чактан укып үскән барлык әкиятләрең минем белән, аю белән, төлке һәм куян белән бергә китсә, нинди ямь калыр синең бу дөньяңда?

Кеше:

— Әйе, калмас.

Бүре:

— Син мине яратырга тиеш!

Кеше җавап эзләгән арада бүре куак арасына кереп китте. Янадан күренмәсме дип көтсә дә, күренмәде. Әллә бөтенләй бернәрсә дә юк иде инде анда? Ләкин барыбер — Кеше аңа үзе бүген төзи торган киләчәк көннәрне һәм тормышны тасвирлап күрсәтмәкче иде...

Җир шарының барлык кыйтгалары чиксез урманнар, болыннар һәм бакчаларга күмелеп, өйләр һәм промышленность биналары шул яшеллек эчендә утырачак. Дөнья — яшел, дөнья — сәламәт, куәтле, шаулы дөнья! Кама буенда шундый матурлык иҗат итә Кеше! Яңа Җир, яңа Тормыш, яңа Мәхәббәт!

Дөрес, моның өчен барлык кешеләр бер төрле көрәшми. Булдыксыз промышленниклар дистәләрчә мең кеше психологиясенә яман тәэсир ясыйлар, елгаларны, күлләрне генә түгел, күңелләрне-җаннарны пычраталар. Алар өчен табигать — хуҗасыз, беркемнеке дә түгел. Аккошларны атарга мөмкин, буаларда пиратлык итәргә мөмкин...

Шулай, Бүре белән ахыргача ук килешеп булмас бәлки, әмма әкиятләрне сакларга кирәк.

Антик традиция беренче аллаларны курку тудырган дип исәпли. Ә соңгыларын бәлки мәхәббәт тудырыр... Тудыручы анага — Табигатькә булган мәхәббәтнең изгегә әверелүе бик ихтимал бит. Беренче әкиятләр

шулай ук көчсезлектән, тылсымлы кодрәт эзләүдән килеп чыккандыр. Ә хәзергеләре — гүзәллектән, мәхәббәттән.

Шәһәргә житкәнче, Фәез шул хакта уйланып кайтты.

Яна больница яныннан узганда гына, кинәт сискәнеп, машинасын туктатырга мәжбүр булды: әлеге дә баягы — урман... Бу юлы бигрәк тә — кеше кулы белән утыртылган яшь наратлар, яшь чыршылар. Ин ачысы — аларны харап итү монда бөтенләй мәжбүри түгел. Йортларны биш-алты метр гына читкәрәк салсаң, шул житәсе. Ә шуна күңел жылылыгы табылмаганга, хәзер буйдан-буйга күпме урман кырылачак!

Пычкыны да кирәк санамаганнар, бульдозер белән аударалар. Агачлар шытырдый, тарткалаша, ыңгыраша, ә корыч вал — рәхимсез. Артта ямь-яшел агачлар урынында тун балчык кантарлары гына тырпаеп кала. Бомбага тоткан шикелле, кабер шикелле — базлар, чокырлар.

Килеп туктау белән Фәез бульдозер каршына ыргылды:

— Хәзер үк туктат, ишетәсеңме?

Бульдозер чынлап та туктады һәм, кабинадан яшь кенә егет башын сузды:

— Нәрсә бар?

Татар егете икән үзе — беренче сүзеннән үк сизелә. Таныш та кебек. Кайда һәм ничек күргәнен генә хәтерли алмый Фәез.

— Ничек кулың бара? Ничек? — диде ул.

— Нәрсәгә? Ничек «кулың бара?»

Егет, үртәлеп, кабинасын япты һәм жайлап утырды да бульдозерны кузгатты. Тагын бер агачка таба шатырдап барган арада, Фәез жан ачуы белән аның кабинасына ыргылды һәм тегесе машинасын туктатырга мәжбүр булды:

— Син нәрсә...— егет сүгенә-сүгенә Фәезне этеп төшерде,— син нәрсә, табигатне үзгәртергә көчең житсә, үзгәрт, яңа эш бир — мина барыбер. Әтәрмен. Ә болай тиле кеше төсле буталма. Синнән башка да күп эшкә зыян китерүчеләр. Бар, юлыңда бул.

— Егет, мин сиңа чынлап әйтәм, кеше бул, давай.

— Мин болай да кеше. Мина кушылган и...

— Ә мин сиңа туктарга кушам.

— Син кем?

— Мин Насыйбуллин... дүртенче идарә начальнигы.

— Булсаң соң! — диде егет, ихлас көлеп,— сезнең кушу безгә эшпочем!

Фәезнең бөтен тәне ут кебек яна, ачудан калтырый ук башлады. Уйланмаган сүз ычкынганын сизми дә калды:

— Дурак!

Бульдозер, котырынкы тавыш чыгарып, алга ыргылды. Фәез аның каршысына атылды һәм... Ярый әле — егет өлгер булып чыкты, күз ачып йомган мизгелдә машинасын читкә каерып, ары ташланды. Фәез тун кир кантары белән бергә аунап калды. Сикереп торып, тагын бульдозер кабинасына ташланган иде, арттан көчле куллар эләктереп алуын сизде. Борылып караса, шофер икән — начальнигының жайсыз хәлдә калуын күреп, монда йөгергән һәм бик вакытлы килеп житкән. Чөнки бу вакытта Фәездән теләсә нинди юләрлек көтәргә мөмкин иде.

— Жибәр! — диде Фәез аңа жикереп.— Жанын алам!

— Юк, жибәрмим! Акылыңа кил! Идарә начальнигы бит син!

Сүзләр шактый үтемле янгырады — Фәез кинәт тынды да, күзләрен елт-чылт йомгалагач, кемнәндер чиркангандай жирга төкерде.

«Каһәр төшкере, малайлыктан картайганчы чыгып булмас микәнни иде?!»

* * *

Икенче көнне, вакытыннан да иртәрәк торып, Фәез управляющий кабинетына ашыкты. Тиз генә икенче катка дип йөгерсә, почмактан Лазарев үзе килеп чыкты — чак бәрелешмәделәр. Аптырап калмады Фәез, арткарак чигенде дә сүзгә керешге:

— Ә минем сезнең янга килүем иде.

— Мин силикатныйга ашыгам.

— Минем дә ашыгыч иде шул.

— Нәрсә бар анда синең?

— Жилстрой сала торган өйләр...— дип башлаган иде, управляющий кырт кисте:

— Ярый, әллә ни зур кайгын юк икән. Бар, үз эшләреңне кара.

— Минем житди йомыш... Анатолий Самойлович. Сөйләшмичә ярамый.

— Ярый, алайса, кич минем өйгә кил.— Шулай дип, управляющий машинасына утырып китеп тә барды.

...Кичке сигез туларга биш минут калганда, Фәез Лазаревлар ишеге янында иде инде. Икенче катка караса, анда ут юк... Димәк, управляющий кайтмаган әле. Менеп, звонок биреп тормады, якын тирәдә генә йөренергә керешге. Егерме минутлап көтте, юк. Ярты сәгать көтте — юк. «Соңлады, берәр эш чыккандыр инде»,— дип, Фәез ераграк китеп йөрөнә башлады һәм шунда үзләре яшәгән гидрострой поселогы белән моңарчы хәтта аз гына да таныш түгел икәнлеген аңлады.

Баш идарә бинасыннан үргә таба бер-бер артлы бишәр катлы өйләр салынган — бернинди плансыз, тәртипсез. Теләсә ничек, теләсә кайда бастырганнар да куйганнар йортларны. Бер рәтен табарга, урамга, хәтта тыкрыкка гына булса да охшаган ачыклык табарга тырышты Фәез. Ләкин андый нәрсә күзгә чалынмады. Хәзер монда ким дигәндә йөзәр квартирлы йөз йорт бар. Бер-берсен асфальт сукмаклар гына тоташтыра. Ә кайберләре арасында ул да юк... Туганын, яисә бүтән бер якын кешесен эзләп килгән ят кеше кирәк йортны ничек таба икән? Таба алмыйча киткән чаклары күбрәктер, валлаһи. Адрес: «Гидрострой поселогы, фәлән йорт...» Ә урам юк. Йорт номерының куелу принцибын да тиз генә төшенә алмассың. Чаллы белән ГЭСны тоташтырган төп трассаны урам дип атасак та — бөтен поселокны шул урам исеме белән атарга туры килер һәм аңа карап кына барыбер урам барлыкка килмәс. Номерлар саны әле түбән яктан үргә таба, әле шәһәр ягы юлыннан аркылыга таба китә. Өстәвенә кайбер өйләргә фәлән саннан соң «А», «Б», «В» хәрефләре дә өстәлгән.

Ярый, бу саннарда буталмадың, баш катыргыч лабиринтлардан исән чыктың ди. Ләкин тапкан адресың тагы синеке булып чыкмавы мөмкин. Чөнки Кама ягыннан килгәндә уң кулдагы икешәр катлы особнякларның үз автономияләре бар — аларның исәбе тагын берле саннан башлана һәм мөстәкыйль рәвештә алга таба китә. Биш катлы йорт урынына ике катлы йорт тапкан булуың да бик ихтимал.

Кыскасы, Керосинниковның үз өен таба алмый интегүе бик табигый икән һәм мондый поселок дөньяда бердәнбер булырга тиеш. Шушындый да ахмаклыкны ничек эшләдек икән без? Поселокны плансыз салырга кем рөхсәт итте икән? Шәһәрдә әллә архитектор штаты юкмы? Әгәр булмаса, проектчылар үзләре нәрсә караган? Ниһаять, алар да карамаса, йортларны салучылар? Ягъни без? Кайда булган безнең күзләр?

Шул уй белән янадан Лазарев өенә килсә, тәрәзәләре тагын каплкараңгы. Сәгать тугыз тулып егерме минут киткән инде. Баш идарәдә исә, тәрәзәләрдән бүлмәгә сыеша алмагандай, утлар агыла... Һәм күк күкрәгәндәй тавыш ишетелә — управляющий телефоннан сөйләшә.

Фәез инде кайтыр якка борылды. Күпмедер баргач, күзгә таныш шәүлә чалынды. Борис икән. Нииндидер ят кыз белән. Фәезгә игътибар итәргә вакыты юк иде бугай. Фәез аның көлә-көлә кызга нәрсәдер сөйләвен, ахырда кабинаны ачып кызны алгы урындыкка утыртуын, машинаның гөрләп китеп баруын аермачык күреп торды һәм, ник икәнен дә белмәстән, көлемсерәп куйды.

Хатынын кайтарып куйгач та Гета белән йөри башлап, аның өстеннән тагы бер кыз тапты Борис. Ничә катлы хыянәт була икән инде бу? Ә Фәез бер генә кешене дә таба алмый. Исемен генә белгән, ике-өч кабат кына күргән сихерле бер кызны эзләп һәм көтеп каңгыра. Ул аны Бориска үлчәшебрәк, күк зәңгәрлеге төсле чиста мәхәббәт тә бар дип раслар өчен дә эзли бугай. Бәлки таба да алмас. Ничек? Таба алмас? Юк, табачак, моңарчы бер хыялының да җиргә төшмичә калганы юк әле. Күк зәңгәрлеге дә төшәчәк. Мәхәббәт башта һәрвакыт йолдыз янында була, ә соңыннан барыбер җиргә төшә ул. Шуңарчы җирдәге кайбер җайсызлыкларны бетерә тору фарыз. Кунак белән бәйрәмне йорт-кура җыештырмыйча, бизәмичә каршыламыйлар бит.

* * *

Силикат заводын тизләтүгә багышланган чираттагы сөйләшүгә, Харламов һаман терелеп җитмәгәнлектән, тагын Фәез чакырылды. Озын өстәл. Фәезнең урыны горком секретаре Шакировның каршысына ук туры килде. Шакировка янәшә кырык яшьләр тирәсендәге, мәһабәт һәм мөлаем бер кеше утыра. Анысы — өлкә комитеты секретаре икән. Мондый дәрәҗәле кәңәшкә Фәезнең беренче катнашуы диярлек. Шуңа күрә үзен ничек тотарга кирәклеген бик үк чамалап бетерми иде булса кирәк. Силикат заводына кирпеч кайдан алырга дип баш ватканда: «Кирпеч заводы үзе суксын кирпечне», дип куйды. Елмаючы гына булмады...

Әңгәмә азакка якынлашканда, сүз сорарга да батырчылык итте. Фәезне оратор дип әйтүе кыен, шулай да аның үзенең сизүенчә дә, бүтәннәрнең соңыннан килеп әйтүләренчә дә, тотлыга-тотлыгарак сөйләгән сүзләре ничектер тыңлаган кешене тыныч калдырмый. Мөгаен, моның сере, сүз сөйләү өчен яки үзеңне күрсәтү өчен генә нотыклар белән мавыкмыйча, чынлап борчылудадыр.

Фәез Кама буйлап сәяхәт иткәннәрен сөйли башлаган иде, иптәш Шакиров:

— Без бүген бүтән хакта сөйләшәбез, иптәш Насыйбуллин, эшкә якынрак, пожалуйста,— дип борчып куйды.

— Минемчә, мин нәкъ эш хакында сөйлим. Әгәр без үзебез суккан кирпечләрне Кама битенә ыргытабыз икән, чыккан һәм чыгачак барлык кирпечләр генә түгел, хәтта заводның үзе дә безгә сукыр бер тиенгә дә кирәкми.

— Бүгенге киңәшмәнең бурычы ул түгел, кирпеч заводына ничек ярдәм итәргә җыенасыз? Шул хакта әйтегез.

— Кирпеч заводына? Кирпеч заводын безнең идарә тәземи. Әгәр катнашуыбыз кирәк икән...

— Кирәк...

— Нәрсә кирәк соң? Без тырышырбыз...

— Сез тынлап утырыгыз. Үз мөмкинчелекләрегезне беләсез...

— Минемчә, төзү эшенә өйрәтә торган курсларны турыдан-туры шушы кирпеч заводын салуга күчерергә кирәк. Тәҗрибәле осталар кул астында эшләсәләр, өйрәнгәндә үк файда китерәчәкләр.

— Сез һаман башкалар хакында, ә үзегез нишли аласыз?

— Без тәҗрибәле ташчылар һәм бетончылар бирә алабыз, ләкин тулы бригадалар түгел...

— Мөмкин, минемчә,— диде Фәездән ике-өч кеше кырыйдарак утыручы чандыр озын агай. Аның силикат заводының директоры икәнен Фәез соңыннан сорап белде.

— Без үзебезгә кагылганны эшләрбез — бездән калмас. Ләкин без үз эшебезнең кая, нәрсәгә китергәнен дә белеп торырга тиеш. Минемчә, хәзер без ничек тә задание үтәү өчен генә тырышабыз. Мин мондый югары даирәдә сирәк булам, шуна күрә күңелдәген әйтеп каласым килә. Бездә бик ямьсез практика урнашып бара — тик завод булсын, тик ГЭС булсын, салкыннан, янгырдан яшеренер өчен түбә булсын, ә матурлык һәм табигать хакында кайгыртмыйбыз диярлек. Сүздә кешеләр хакында кайгырткан булып, эштә аларга зыян эшлибез.

Фәез күптән түгел бульдозерчы егет белән булган хәлне сөйләп бирде һәм шәһәр төзелеше хакында болай дип өстәде:

— Безгә нәрсә кушылса, без аны үтәргә тырышабыз, әлбәттә. Безгә төзергә кушылган. Һәм без төзибез. Ничек төзибез, анысы икенче нәрсә, чөнки ул хакта уйларга кушылмаган, бездән моның өчен отчет сорамыйлар һәм без уйламыйбыз. Без шәһәр салмыйбыз, иптәшләр, теләсә кайда, теләсә ничек өйләр генә салабыз... Без бу бару белән барсак, киләчәктә шәһәр зурлыгы хаос төзеп куячакбыз. Без салган кала, без төзегән тормыш бүгенгедән чагыштыргысыз матур һәм саф булырга, якты булырга тиеш. Әгәр без аның йөзен каралтсак, гарип бала тудырсак, халык безне гафу итмәячәк. Безнең кала — сөекле Кама калфагына куелган бизәк, ай булырга тиеш. «Тиеш» дигән сүз — әле бу шулай бар дигән сүз түгел. Моның өчен шәһәрнең хуҗасы булырга тиеш, архитекторы, тәртип һәм матурлык хуҗасы. Кайда ул? Кайда бу шәһәрнең хуҗалары! Мин аларны, кызганычка каршы, күрмим.

Кем әйткәндәй, томшыгындагы сарысы да бетмәгән «кошчык»ның шушы хәтле солидный кешеләргә акыл бирүе кемнәрнедер үрти, билгеле. Почмактан бер усалы чәнчеп куйды:

— Син, егет, хуҗа дисең. Менә син бар бит.

— Шулай шул, мин хуҗа буларак сөйләдем дә. Кунак булсам, мактар идем.

Почмактагы әлеге усал ялагай:

— Иптәшләр, без төп мәсьәләдән читләштек,— дип, нотык сөйләргә керешмәкче иде, өлкә комитеты секретаре горком секретарена сүз кушты:

— Насыйбуллин фикерләренә сез ничек карыйсыз? — Фәезнен фамилиясен дә белә икән!

Шакиров:

— Мәсьәлә бик житди. Аның белән без дә кызыксынабыз. Ул өйрәнү стадиясендә,— дип башлаган иде, Фәез (менә оятсыз!) бүлдерергә батырчылык итте:

— Сез өйрәнгән арада без шәһәрне салып бетерсәк, йортларны күчереп утыртырсызмы?

— Шулай ук тизләрсез микәнни? — дип кенә куярга мәҗбүр булды Шакиров.

Фәезгә исә шундый форсат кына кирәк тә.

— Ә шәһәрнең гомуми планы юкмыни? — диде ул.— Кайда генплан? Агач кала төземибез дип, таш кала төзибез дип, күпме бәхәсләштек, күпме ямьсезләнештек. Иптәш Лазарев белән иптәш Лебедев күпме кылыч сындырдылар. Ә ни өчен? Шушы рәтсез поселок өченме?

Тынлык. Иптәш Шакиров бармакларын өстәлгә бәргәли. Кәефе китте, димәк. Аңлашыла.

— Ярый,— диде ул, ниһаять, бүтән сөйләүче күренмәгәч,— бу мәсьәлә белән эш тәртибендә кызыксынырбыз. Проблема хәл ителү стадиясендә. Гидростанция әле башлана гына. Шулай бит?

Өлкә комитеты секретаре бәхәскә катнашмыйча гына Кама буендагы төзелешләрнең республика һәм ил тормышындагы урыны хакында сөйләде. Якын киләчәк — гигантлар төзелеше. Масштаблар — баш әйләндергеч. Нишләтәсең, ул Фәез теләгәнне сөйли. Һәм кайбер нәрсәләрне ачып, әйтеп тә бетерми бугай... Фәез аңардан генплан хакында сүз көткән иде.

Фәез, башкисәр, үзен юкка гына җайсыз хәлгә куйды микәнни?

* * *

Горком секретарена катырак сугылганын тойган хәлдә, үзенә карата ниндирәк нәтиҗә ясалыр дип йөргән көннәрнең берсендә, телефоннан Лазаревның кискен тавышы ишетелде:

— Хәзер миңа сугыл әле... Китмәгән булса, Филиновны да ал.

— Ярый...

— Хәзер үк,— диде дә трубканы куйды.

«Башланды. Минем урынга Борисны куялар икән!» Филинов үзе дә шуны сизгән төсле тоелды Фәезгә. Ләкин ялгышты.

Управляющий коры тотты:

— Сезнең идарә начальниксыз.

— Терелә инде, шушы арада эшкә чыга,— диде Фәез шундый ук кырыслык белән.

— Мин дә сөйләштем. Ләкин аңа авыр булачак. Хәзергә бүтән эш бирербез. Монда бүтән кеше кирәк.— Шулай дигәч, тыйлыгыбрак торды, әйтерсең, янда утыручыларны сынный иде ул. Фәез, нindidер бүтән сүз көтеп, Лазаревка карады, аннан Бориска күз салды... Борис ни өчендер кызарыбрак куйды. Ул Лазарев авызыннан хәзер үз фамилиясе ычкынуын көтә, билгеле. Аның моңа шундый нигезләре бар: Куйбышев ГЭСында, аннары Тольяттида СМУ начальнигы булып эшләгән һәм Иранга барып, совет инженеры дәрәҗәсенә тап төшерми кайткан... Әлбәттә, Лазаревның чакыруы шуның өчен булырга тиеш.

Борис та Фәезгә нindidер өмет белән карады — дусты, аның исемен атарга, тәкъдим итәргә тиеш хәзер... Чөнки Фәез аннан бераз яшьрәк һәм тәҗрибәсе дә азрак. Ләкин аның ишетергә теләвенә каршы, Фәез бер сүз дә әйтмәде, ә Лазарев исә бөтенләй көтелмәгән исемне атап аны гаҗәпкә калдырды... Икесенең дә моңа ышанасы килми торды: «Мөмкин түгел, мөмкин түгел! Колаклары ялгыш ишетәме әллә?!»

— Мин сине болай күзәтеп йөрим...— диде Лазарев Фәезгә карамыйча һәм шул ук вакытта сүзләренең кемгә адресланганын ничектер нык сизелерлек итеп,— син болай тырыш күренәсең... Чын күңелдән эшлисең... тәҗрибә җитеп бетмәү, төрле яккарак ташлану сизелә, билгеле, бераз ашыгу бар... Ләкин монысы — вакыт эше булса кирәк. Сине мин СМУга законлы начальник итеп куймакчы булам... Ничек карыйсың?

— Белмим шул,— диде Фәез һәм, бүтән сүз тапмыйча, аптырабрак калды.

Хәзер инде киңәш көтеп Бориска ул карады. Ә дусты башын игән дә тик тора. Актан да, карадан да — ләм-мим. Димәк, Фәезне лаек түгел дип саный — һәм шуңа күрә Фәез үртәлеп тә куйды, тик сиздермәскә тырышты.

Бәхәсне куертудан файда көтмәгән управляющий:

— Ә баш инженер итеп үз урыныңа кемне тәкъдим итәсең?

Конкрет сорауга конкрет җавап кирәк иде дә, тик Фәез тагын уңайсызланыбрак калды. Лазарев Борисны чакырган икән, димәк, баш инженер итеп аны куярга чамалаган. Ләкин Фәез аның белән әйбәт эшләвенә ышана алмый... Шулай да, баягы үпкәсен җиңеп, ул дустын кызганып:

— Филиновны сез шуның өчен чакыргансыздыр бит инде. Кандидатура ярый торгандыр,— диде.

— Бу — җитди түгел,— диде кырт кисеп Лазарев,— тагын кемне тәкъдим итә аласың?

— Өченче участок начальнигы... Копылов... Яхшы егет, тырыш.

— Риза, мә, таныш.

Фәез үзенә сузылган кәгазьгә текәлсә — приказ язып ук куелган! — Фәез Насыйбуллин идарә начальнигы итеп куела, ә Игорь Копылов — баш инженер. Насыйбуллинның укып чыгуын сизеп, Лазарев сүзне түгәрәкләргә ашыкты:

— Бетте — эшкә тотынығыз.

Фәез торды. Икеләнеп кенә Борис та кузгалды:

— Миңа да китәргә мөмкинме?

— Мөмкин.

Управляющий сүзен әйтеп бетергәнче телефонына сузылды. Чара юк, аңлашылып җитмәсә дә — аудиенция тәмам.

Кыска вакыт эчендә килеп чыккан бу үзгәреш икесен дә аптырашта калдырды. Борисны бигрәк тә.

— Ә мине ник чакырган икән инде ул?

— Һич әйтә алмыйм, Боря.

Сорау ачык калды һәм, ашханәгә борылганчы бергә килсәләр дә, әңгәмә башланмады. Ничектер хәзер Борис яңа эшкә күчүе белән Фәезне котларга тиеш иде кебек, ә тегесе, авызына су капкандай, башын иеп тик бара.

Юк, ул тәбрик итмәде Фәезне. Булдыра алмады. Шактый йөргәч кенә, әллә үзенә, әллә Фәезгә әйтте:

— Макаренко! Юри, мыскыллар өчен чакырган ул: «Синең дә шулай үсүең мөмкин иде», янәсе. Стерва.

Мыскыллы сүзләр Лазаревка адресланган иде.

— Ярый, Боря... Уйлашырбыз.

— Нәрсәсен уйларга?

— Киләсе ялга ауга чыгабызмы?

— Мылтыгым юк.

— Мин табармын.

— Ярый, хәзергә, Фәез.

* * *

Икесе ике якка берничә генә адым атлап өлгергәч тә, аларны урамның икенче ягыннан көлгән, кычкырган тавышлар туктатты. Борылып карасалар, ашханә төбендәге яшь-җилкенчәк «күңел ача» икән. Ишек янындагы баскычта Фәездән чак кына өлкәнрәк — утыз-кырык яшьләр чамасындагы ике кеше исерек тавыш белән ниндидер көй чыгарырга азаплана. Ә ике егет ашханәгә таба килә — берсе гражданский купшы киемнән, икенчесе әле армиядән күптән түгел генә кайткан, ахрысы — хәрби киемнән. Көй чыгара торганнарына якынлашкач, купшы киенгән егет әлеге шул солдат киемлесенең каешын сорап алды:

— Бир әле, бер генә минутка.

— Нәрсәгә?

— Соңыннан күрерсең.

Каешны алгач та әлеге исерекләрнең берсе янына килеп, тегенә каеш белән сыптыра да башлады. Көй кайгысы очты хәзер — бәндән кәҗә тавышы белән бакыра, ә тегесе һаман саен каеш белән чыжылдата. Яндагылар: «Рәшит, җитәр, Рәшит!» дип сабыр гына эндәшеп тик торалар.

— Боря, әйдә,— дип, Фәез алар янына ташланды.

Борис нәрсәдер мыгырданып калды. Фәез анын: «Хулиганнар белән сугышып йөрергә генә калды инде»,— дигән сүзләрен генә ишетте. Пөгереп барып та житте, тегесе абайлап өлгергәнче каешны тартып алып, егетнең үз аркасына саллы гына тамызды да.

— Авыртамы? Авыртамы? — диде.

Тегесе эндәшми торгач, тагын берне өстәде:

— Әйт, авыртамы?

— Авырта,— диде егет, ниһаять, артык сызланмыйча гына.

— Ә ник бу кешенеке авыртмаска тиеш дип уйлыйсың? Аныкы нишләп авыртмаска тиеш?

— Авырта, шуңа күрә сугам да.

— Ә ник сугасың?

— Анын танавы ошамады миңа.

— Нишләп?

— Каян белим мин аны? Ошамады и все.

— Ничек? Ничек әйттең, яле, кабатла.

Фәез егеткә текәлебрәк караган иде, танигандай тоелды һәм гажәпләнеп тагын сорады:

— Без синең белән таныш бит, дустым?

— Ихтимал.

— Ихтимал түгел, ә тәгаен. Син бит теге яшь наратларны бульдозер белән актарып ташлаган егет.

— Ну, шулай булса?

— Шул булса шул — аркаңа ике рәт эләккәч житәр дип, мин сине жибәрмәкче идем. Ә хәзер әйдә.

— Кая?

— Баргач белерсең?

— Әйтмичә бармыйм? Кая?

— Милициягә.— Фәез урам аръягында торучы Бориска кычкырды:— Боря, милициягә шалтырат әле, тиз бул!

Дусты кул гына селтәде:

— Жибәр, пычранма чүп-чар белән.

— Син дә пычранма, мин дә... Кем арындырыр безне бу пычрактан?

Борис, бәхәсләшмичә, китеп кенә барды. «Кирәк чакта милиционеры да юк бит. Нишләргә соң?» Шулай уйланып торганнан соң Фәез егеткә әйтте:

— Мин синең өченче идарәдә эшләвеңне беләм, исемеңне дә беләм — Рәшит, син Гөлнисаттәй малае, Иске Чурайдан. Качсаң, барыбер эләгәчәксең. Ике-өч минут мине шушында көтсәң, хәерлерәк булыр. Әниеңә әйтмәм...

Шулай диде дә ашханәгә кереп китте һәм аннан милициягә шалтыратты. Урамга чыкса, хикмәт, егет китмәгән. Мондый «анлы» хулиганны Фәезнең беренче тапкыр очратуы иде.

Милиционер килгәнче шундый сөйләшү булып алды:

— Син минем әнине каян беләсең? — дип сорады Рәшит.

— Без анын белән якын дуслар.

— Син безнең бүлмәгә әнине кертергә булыштыңмы?

— Әйе.

— Ул сине гел сөйләп кенә тора. Әби дә.

— Бая мин сине танып өлгермәдем, таныган булсам, тагын да жиллерәк кундырган булыр идем.

— Болай да ярыйсы эләкте.

— Күңелең булдымы?

— Булды. Үчеңне кайтардың, молодец.

— Тагын сугышасыңмы?

— Бәйләнсәләр.

— Ә бәйләнмәсәләр? Сугышмассыңмы?

— Тырышырмын.
— Сүз бирәсеңме?
— Ярый, бирәм.
— Бар, сыпырт.
— Ә милиция?
— Качкан диярмен. Исемеңне әйтмәм.
Ә дигәнче егеттән җилләр исте.

* * *

Ауга чыгу турында Борис белән алданрак килешенмәгән булса, әлеге кечке вакыйгадан соң Фәез аңа мондый тәкъдимне ясамаган булыр иде. Соңгы вакытта болай да өнәп бетерми иде, хәзер әллә ничек, дустының дәрәҗәсе аның күз каршында кинәт төшеп китте. Халыкта ышанмаган кешең белән сәфәр чыгарга киңәш итмиләр. Ауга инде — бигрәк тә. Беркөнне сине хулиганга ташлап калдырса, икенче көнне бүреләргә ташлап качмас дип әйтүе кыендыр. Тик вәгъдә биргәч кире кайтуны да холык әшәкелеге дип исәпли Фәез. Кеше начар дип, син дә начар булырга тиеш түгел.

Сәгать иртәнге бишләрдә ул Борис ишеген какты. Бер тапкыр дөбердәтте — эндәшүче юк, ике, өч тапкыр... Ниһаять, йокылы тавыш ишетелде:

— Кем анда?
— Боря, ач, мин.

Борис трусик һәм майкадан гына иде.

— Әйдә, уз. Мин хәзер киенәм.

Шулай диде дә туалетка кереп китте — озак кына торып, юынып чыккач, шулай ук ашыкмыйча гына киенде:

— Син ашадыңмы?
— Капкаладым.
— Мин дә капкалыйм инде алайса.

Кухняга кереп, янадан чыкты:

— Минем аз гына калган икән — баш төзәтмибезме?
— Юк, мин кичә эчмәдем.
— Ә... гафу...

Ул кухня ишеген япкач, Фәез өйдәге кайбер нәрсәгә игътибар итте. Беркөн ничектер күрелмәгән, әллә яңа гына куйган, тумбочка өстендә — рамлы рәсем — Борисның хатыны елмаеп утыра, бәхетле, яшь хатын! «Әллә егет гаиләсен сагына башладымы икән?»

Ләкин шуннан ерак та түгел, караваt янында, ниндидер хатын-кыз киеме аунап ята... Онытып калдырганнардыр инде. Кайсы икән? Гетамы, сатучы хатынмы? Тагын да яңарагымы?

Борис белән бу хакта, гомумән, аның яшәве хакында беренче җай чыккач та сөйләшергә кирәк булыр.

Борис кухнядан чыкты.

— Тегендә капкаларга туры килерме икән?
— Белмим шул, килер дә бәлки.
— Мин бутерброд кына алыйм инде.

Тагын кухняга кереп чыккач, ниһаять, киттеләр. Алар Камага төшеп җиткәндә, сәгать алты тулган иде.

— Соңгарак калдык,— диде Фәез.
— Безгә дигәне калыр әле,— диде Борис ваемсыз гына.

Кама аръягына чыктылар һәм яр буйлап сузылган калкулык итәгеннән кышкы лагерьга таба бардылар. Лагерьга чаклы юл ярыйсы иде. Аннан соң кар шактый тирәнәйде һәм акрынрак барырга туры килде. Икенче бер калкулыкка җитеп, урман эченә кергәч, Фәез туктады.

— Машинаны калдырыйк шушында.

— Ярый.

— Синең аяк кая таба тарта?

— Кая таба булса да барыбер.

— Алайса, менә мин уң яклап йөреп килим, син сулга кит. Дүрт-биш сәгатьтән шушында очрашырбыз.

— Сәгать унберләр тирәсендә буламы инде ул?

— Әйе.— Фәез машинадан мылтыкларны алып, берсен Бориска тоттырды:

— Ни пуха, ни пера!..

Чаңгы киделәр дә, яңа, йомшак карга бата-бата, икесе ике якка юл тоттылар.

Көн чак кына болытлы һәм тын. Салкынлык зыянлы түгел. Кышкы урман үзенең барлык гүзәллеге белән синең иркеңә бирелгән — кадерен бел һәм ләззәтен күр.

Кышкы урманның үз өстенлеге бар — беренчедән, җәйге хатирәләрне яңартып, күңелне шулар белән кытыклаcа, аннары — кышка калган җимешләре белән кадерле ул. Чаңгыда уйсу җиргә шуып төшкәч тә, Фәез өзелми калган балан тәлгәшләре тапты. Кып-кызыл тәлгәшләр — дөньядагы барлык җәйге чәчәкләрдән дә матурдыр болар. Бөртекләп өзеп, тәмен таты. Менә шулай. Искиткеч бер терелек тәме... Шундый үзенә бертөрле әчелек тагын кайда бар икән? Мондый тәмне бары тик бер карауда күңел яраткан һәм сөю вәгъдә иткән, ләкин шуннан артыкка якын җибәрмәгән җитди һәм мөлаем караш белән генә чагыштырырга мөмкиндер.

Тәлгәшне чүпләп бетергәч, күңеленең тагын да яктыруын һәм сафлануын тоеп, таякларга каты-каты басып, тизләбрәк шуып китте Фәез. Икенче бер урында камырлыкка туры килде. Анысының тагы үз тәме, сизелер-сизелмәс тыйнак тәм... Һәм төшләре дә каты — тиз генә ватам, ашыйм димә,— үкенүең ихтимал. Тәме белән канәгать бул да шул җитәр.

Күпмедер баргач, миләш очратты. Монысы тагын балан төслерәк, тик аермасы да бар кебек — үзе татлы, үзе ачы... Бу инде беренче караш түгел, бу инде тирәнрәк киткән хисләр — борчулары, хәсрәтләре, көнләшүләре һәм, ихтимал, үкенечле аерылышулары яки ялгышулары белән... Бәлки, Фәезне дә шундый мәхәббәт көтәдер.

Кышкы урман! Никадәр тәмле, никадәр дәртле һәм ямансу! Ярый әле, кая карама, шунда — аклык. Ә аклык күңелгә ниндидер өметләр бүлеп керә, күзләрне камаштыра, рәхәтләндерә, кытыклый, шаярта. Ах, бу кышкы урман!

Тукта, агачлар белән, кар белән мавыгу монда китергән максатны оныттырган лабаса. Әнә эзләр, эзләр... Төнлә бераз кар яуганга, иске эзләр чак кына күмелгән, яңалары аермачык беленеп тора. Бу эзләр бүгенге. Алар артыннан, менә шушы сукмактан барырга ярый.

Кама урманнары киртләч-киртләч таулы ярлар арасында. Фәез шул таулардан шуды, үзәннәрдә йөрде, сазлыклар аша узды. Ә җан иясе юк та юк. Сәгатьләр үтте, ләкин күңеле төшмәде. Табыш белән генәмени — шушы урманнарда йөрү, яшь кар исен тою, балан һәм миләш сафлыгын хис итү — моннан артык рәхәтлекне каян табарга мөмкин?! Куе агачлар артында, наратлар башында җил җуылдый. Әллә җил йөри, әллә бүтән кодрәт... Әллә инде шулай моңаеп, аның ямансу хыялы сулый? Шул үгай, әйтерсең, кайдадыр якында, шушы тирәдә генә аның мәхәббәте яшеренгән дә аны күзәтә, ләкин үзе күренми.

Шушы тирәдә генә — бүген булмаса иртәгә киләчәк мәхәббәт.

Аның исеме — Кама.

Тукта, куак артында кемдер селкенде! Әллә Кама... Юк, куян бу...

Әйтерсең, шуны күрер өчен махсус килмәгән, кул янындагы ак җан иясенең куян булып чыгуы, әйтерсең, ул көткән нәрсә түгел — әйтерсең, аны күрүдә бернинди сөенеч юк.

Шулай да, туры килгән икән, атарга кирәк... Һәм Фәез, куянны күздән ычкындырмаган хәлдә, җайлырак урын алырга тырышып, тагын да аскарак шуып төште. Төште дә, куянга чак кына якынрак барыйм дип, өч-дүрт адым ара үрмәләде һәм менә гаҗәп — борын төбендә генә дигәндәй, икенче куян атылып чыкты. Тиз генә чакмага басты... Гөрселдәп мылтык атылды... Карасa — якында куян тәгәрәп йөри. Ә тегесе ерактагы тау битендә ята...

Борисның буш кул белән чыгачагын хәтерләп, Фәез анысын да калдырмаска кирәк тапты...

Үзе аткан куяннарны үзе кызгана торган гадәте бар Фәезнең. Ләкин ауга йөрү — ата-бабадан калган гадәт. Ул Фәездән генә калмаган һәм калмас... Ә бүгенге табыш — бик күп аучылар арасыннан да иң бәхетлеләренә генә туры килерлек. Менә шундый бәхетле кеше нишләп Фәез икән? Әллә ул бәхетле йолдыз астында туганмы? Әйе, аның бер йолдызы бар, ул аны бер дә ташламый — тылсымлы талисман кебек хәерле юл теләп озата йөри...

Менә кичәге хәлне әйт инде син, Борис белән чагыштыр. Борис инде кайчаннан бирле участок начальнигы гына. Кайчаннан бирле идарәнең баш инженеры һәм начальнигы постын үзенең иң якын, табигый урыны дип исәпли һәм аның моңа законлы нигезләре дә бар. Яшь ягыннан ул Фәездән ундүрт яшькә зур — аңа хәзер кырык яшь. Яшьтән бигрәк, тәҗрибәсе, иң кирәклесе — сәләте бар, гади генә сәләт түгел, иҗади сәләт. Эш процессларын рационаллаштыру буенча инженерлар арасында аңардан җиңел һәм күп эшли ала торган кеше, ихтимал, юктыр. Дөресен генә әйткәндә, аның бу ягына хәтта Фәез дә көнләшеп, сокланып карый. Кыскасы, Фәезгә хәтле ул баш инженер булырга тиеш иде. Кичә чакырып алгач, управляющий идарә начальнигы итеп аны куярга тиеш иде. Юк, аны түгел, Фәезне куйды. Ник? Әлеге дә баягы — бәхет... Шуның өчен дә кичә Фәезгә ничектер уңайсыз да булды. Ник шулчаклы фартлы егет икән соң ул, аны бүтәннәрдән, әйтик, Бористан, өстен итәрлек нәрсә бар икән?

Бер карасаң, күңелле, бер карасаң, Борис кызганыч. Ул бөтенләй чырайдан язды. Рәтләп сөйләшми.

Менә, җитмәсә, ул иңенә ике куян асып кайта. Ничектер күңеленең иң тирән төше белән тоя Фәез, сизә — мөгаен, Борис аны буш кул белән көтәдер... Фәезнең юравы дөрескә чыкты. Бориска тагын бер җәрәхәт... Ярдәм итәр, хәлен җиңеләйтергә тырышыр идең, ләкин ничек ярдәм итәсең?

Борис машина янында Фәезне көтеп тора иде. Күзләре пар куянга төшкәч, катты да калды. «Ба!» — дип кенә куйды. Күзләрендәге ачынуны, сызлануны күрсәң!

— Нишләп син мине шундый зур табыш белән тәбрик итмисең әле?

— Ә... синеме?..

— Тагын кемне булсын?

Борис бу минутта елап ук җибәрер төсле иде. Җитмәсә, Фәез куяннарны ничек атып алуы турында аучыларча арттырып сөйләргә тотынды: имеш, бер куянга атарга җыенганда, икенчесе каршыга үзе чабып чыккан да карап тик тора, имеш. Фәез, берничә адым гына читкәрәк шуышып, икесен бер сызыкка туры китереп чакмага баса да, алда ике куян да шар-шор килеп кычкырып ята, имеш. Бер атуда ике куянга тидергәнгә ышаныр дип түгел, болай кызык өчен генә сөйләгән иде дә, нишләптер, ышанды Борис. Бүтән чакта гел җай гына килеп торгангамы, бу юлы фарт килүе дә табигый тоелгандыр инде. Борисның чырае көл төсле булды.

Фаез сәгатенә карады — ике тулган. Кара син, вакытның үткәне сизелми дә! Күп булса, ун-унбер тирәседер дип уйлаган иде Фаез. Сәгатьләр, бәхетле сәгатьләр һәм көннәр. Бәлки еллардыр...

— Нишлибез? Киттекме? — диде ул машинага сөялеп торган Борискә карап.— Да... син йөрәгеңә якын алма — сунарда шулай инде ул: бүген синә эләгә, иртәгә — миңа.

— Син нәрсә, әллә мине шуның өчен кәефсез дип уйлыйсыңмы? — Ләкин үзенең күзләре һаман куяннарда... Сиздермәскә тырышса да, булдыра алмый...

— Ә нәрсә өчен соң?

— Бернәрсә өчен дә түгел, болай гына.

— Алайса, яхшы, киттек.

— Коньякны тәгәлләп куймыйбызмы?

— Син баш төзәтәм дигән идең ич.

— Берүзем... минем андый гадәт юк.

— Давай алайса...

Борис машинадан сумкасын алды, ә Фаез толып чыгарып, шуны карга йонлы ягы белән җәйде дә ятып тәгәрәргә керешге:

— Сахра монда! У-у! Яшәп тә карыйбыз синен белән без, ә?

— Искитәрлек нәрсә юк.

Боряның кыяфәте һаман да төксе. Фаез исә шатлыктан исергән, аның кәефен тик берәр алама сүз белән генә бозарга мөмкин. Борис, шуны сизеп, әзерләнә дә иде бугай... Ә Фаез моны уйламый һәм уйлый да алмый. Урман үзенең сихерле һавасы, тылсымлы матурлыгы белән аның күңелен тәмам тутырган иде.

— Синең, Боря, дөресен генә әйткәндә, кәеф китте. Ләкин юкка. Рас миңа эләккән, синеке дә бит инде ул. Без бергә булгач, табыш та уртак. Бер куян синеке, вәссәлам. Мин аны махсус синең өчен аттым.

— Мине син шуңа мохтаҗ дип беләсеңме?

— Менә инде...

— Синнән сәдака өмет итә дип уйлыйсыңмы?

— Тфү, чорт, нинди бәндә син, сиңа ничек тә ярамый. Ну, давай сал, алайса.

Кичәгедән калган дигәне ярты шешәдән кимрәк икән. Хуҗа кеше кавырсын бөкене ачты да фарфор рюмкаларга салды. Борис аныскын да кайгырткан!

— Киттек! — дип, чәкештермичә генә эчеп тә җибәрде.

Фаез үзе өчен үзе тост әйтергә мәҗбүр:

— Уңышлы сунар белән!

Борис тагын тынды — күзләре тагын куяннарга төште. Ах, бу чаклы да көнчел кеше булыр икән!

Өйдән алып килгән салкын ит һәм кара икмәк капкалагач, тагын берәр рюмка тоттылар. Монысы бөтенләй сүзсез булды. Бүтән чакта шешәләп сала белгән Борисның бүген ике рюмкадан ук чырае карангылана башлады. Шуңа күрә калган ярты рюмканы күтәргәндә, Фаез аны туктатмакчы иде, тегесе гаҗәпләнеп:

— Ник? — дип сорады.

— Сизәм, житте.

— Ике кешегә чалыш чирек нәрсә ул?

Борис шулай дип эчеп җибәргәч, Фаез хәлне төзәтмәк өчен дусларча тавышка күчте:

— Син, Боря, юкка үпкәлисең. Миңа бер атуда ике куян эләккән икән, мин гаепләме инде шуңа?

— Мин аның өчен түгел,— дип ычкындырды Борис. (Үзеңә зыян китерә торган сүзләр күпме ычкына бездән. Ә соңыннан үкенсәң дә тота алмыйсың — һавадагы торна кебек!)

— Ә нәрсә өчен?

— Да, болай, кайбер нәрсәләр...

— Шуннан, шуннан, нинди кайбер нәрсәләр? — диде Фәез төпченеп,— ачыкларга кирәк, эчтә кер йөртү егетлек түгел.

— Да, син миңа өстән карама, иптәш, СМУ начальнигы булдым дигәч тә...

— Атакаем! Ну, шулмы минем гаеп?

— Түгел.

— Ә нәрсә?

— Ярар, утыр син, әтәчләнмә бик.

Фәез сабырлыгын җуеп тезләнгән иде — яңадан утырды да, җай табалмыйча, күкрәгенә ятты һәм дустының күзләренә текәлде:

— Я, мин тыңлыйм сине. Минем сиңа нинди зыяным тигән, әйт.

— Тигән шул.

— Нинди зыян?

— Син үзең миннән яхшырак беләсең.

— Белми белмим. Син нәрсәне күздә тотасың?

— Үзең үк ошаткан дүрт тәкъдим... Акчасы һаман юк.

— Алай икән! Без бит синең белән ничә тапкыр сөйләштек инде — тәкъдим эшкә ашырылгач дип. Аванс алдың — кот бераз, шушы арада тегесен дә...

— Шушы арада! — диде Борис, мыскыллап,— әүзеңнеке булса, теге арада үк алган булыр идең.

— Үземнең дә шундый хәл — тикшер.

— Синең... андый тәкъдимнәргә...

— Нинди тәкъдимнәр? — әкренләп Фәез дә үртәлә башлады.— Синекеннән начарракмы?

— Тәкъдимнең начары булмый. Синең — болай, кечкенәрәк үзгәрешләр һәм аз эффект...

— Шуңа күрә минем аларга күп акча сораганым да юк.

— Шулай да сине начальство ярата.

Бу сүзгә Фәез тагын сәерсенебрәк калды һәм җавап урынына «һы!» дип кенә куйды. Беразга бәхәс тынып торды, ләкин бу тынлык давыл алды тынлыгы иде. Борис шактый ачулы кыяфәткә кергән, тиз генә тынычланырдай күренми иде:

— Мин синең ни өчен түләргә ашыкмавыңны беләм, билгеле. Бүтән кешегә булса, әллә кайчан түләгән булыр идең...

— Бүтәннәр өчен дә бер үк тәртип.

— Анысы да минем аркада, миңа түләмәс өчен уйлап чыгардың син аны.

— Боря, нәрсә сөйлисең син!

— Син миңа, дус буларак, этлекне бик матур эшли белдең, әлбәттә... Ни өчен икәнен дә беләм.

Борисның ачуы шактый зур икәнен сизеп, Фәез сүз көрәштермәс булды. Башын толыпка куеп, тыңламаган кыяфәттә ятты. Хәзер ул чынлыкта бөтен көчен җыеп түзә генә, ләкин түзеп булмаслык сүзләр ишетә:

— Ни өчен дисең, син үзең кешечә яши белмисең. Асылда сиңа акча кирәкми. Үзең яшәмәгәч, мине дә үз калыбыңа сыйдырырга тырышасың.

— Көнләшәм! — диде Фәез мыскыллап. Түземлеге җитмәде. Түзәргә тырышкан саен ачуы ныграк җыела барды.

— Нәкъ дөресе шул! Чөнки син... Сиңа нәрсәгә кирәк акча? Хатынкызга файда тия торган кеше түгел бит син... авыру...

— Подлец!

Фәез сикереп торды да Борисның якасыннан эләктереп алды. Ә тегесе һаман зәһәрләнә бирде:

— Өстенә бастыммы? Дөресме? Дөреслек шулай ачы була ул...

Фәез лач иттереп дустының битенә төкерде, толыбын күтәрергә иелгәч, тегесе аягы белән анын тез астына төртте:

— Мин сиңа теге хулиган түгел, мин синең нечкә төшләреңне шактый беләм.

— Мин синең пычрак кеше икәнеңне белә идем, ләкин мондый ук түбән егылырсың дип башыма да килми иде. Хәзер мин сине аңладым.

— Алайса, аңлаштык. Минем алда синең дәрәҗәң күптән югары тормый инде — кызганыч бер адәм син...— Борис тагын да усалрак сүз табалмыйча тынып калды һәм сумкасына вак-төяк әйберләрен тутырырга кереште.

Фәез дә, толыбын алып машина эченә куйгач, Бориска таба борылмыйча гына:

— Иртәгә бик нык үкенерсең, дустым, соң булыр,— диде.

— Янәма, синең кебек коры аракыларны күп күргән мин.

— Ә мин әйтәм, үкенәчәксең.

— Көтеп тор! — дип, Борис, кырт борылып, кайтыр якка китте.

Фәез, килеп чыккан хәлне аңларга, төшенергә тырышып, машинага сөялеп калды... Бераздан куяннарга күзе төште... «Хәерсез куяннар, сезнең аркада булды бит бу... Киткән чакта да сезгә карап куйды Борис дус... Гаеп бары сездә...»

Башында шул уй белән буталганда, еректан ниндидер хихылдап килгән шикелле тавыш ишетелде. Нәрсә бу? Кем?

— Хи-ха-ха! — Бөтен урман кычкырып көлә.

«Беләм, беләм мин моның кем көлүе икәнен! Ике дусны кычкырыштырыр өчен икесенә дә тиешле куяннарны бер генә кеше каршысына чыгарды да хәзер үз шуклыгыннан үзе көлә, ике дусны кычкырыштыра алуыннан рәхәтләнеп көлә».

— Ха-ха-ха!

«Бу көлү бүген артык матур яңгырамый, хәйләле көлү! Менә син нинди дә була аласың икән! Әйе, кош авазы түгел, әйе, бу син, син! Ике дусны кычкырыштырган зат — син, Кама! Син миңа үпкәләгән идең шул — үч кайтара башладың. Миңа синең белән ничек тә якын арада күреп сөйләшергә, килешергә кирәк. Болай ярамый».

— Ха-ха-ха!

Фәез машинасын борып юлга ашыкты һәм тиз арада Борисны куып җитте:

— Әйдә, утыр.

— Юлыңда бул! — дип, дусты кул гына селтәде.

— Ара ерак, ким дигәндә — ун чакрым.

— Бар, бар!

Борис үзен шактый горур тотып атлый бирде. Фәез ни уйларга да белмичә, дустын ялгызы калдырып, выжлап узып китте.

Җәяүле юлчы калды — хәерле булсын.

Урман ягыннан һаман әлеге тавыш ишетелә:

— Хи-хи-хи-хи...

Әйтерсең Кама аларның икесен дә усал мыскыллап озата барды...

* * *

Яңа көннәр, көндәлек шөгыльләр башланды.

Фәез барлык объектларны карап чыкса да, нефтебазага бармады, чөнки Борис шунда. Ләкин бергә эшләгән кеше белән тел яшереп яшәү мөмкин булмаячагы билгеле. Я килешергә, я бөтенләй аерылышырга кирәк — икенең берсе.

Фәез төшкелеккә китешли үз бүлмәсенә сугылган иде, секретарь кыз аны эзләп ике тапкыр Борис кергәнен әйтте.

«Килгән шулай да... Ник? Начар уен башладың, дустым, бернинди отыш вәгъдә итә алмыйм мин сиңа».

Фәез ашханәдән кайтып кергәндә, секретарь кыз янында Борис үзе утыра иде. Өченче тапкыр килгән. Димәк, шактый борчыла кешең. Фәез кул бирмичә генә исәнләште һәм бүлмәсенә узышлый артыннан Борисның да иярүен сизде. Тик борылып күз салмады, юри карамады. Үзен беренче тапкыр начальникларча шактый кырыс тотканын сизеп, елмайгандай итте.

Каршыда йончыган кыяфәтле Борис утыра. Ул да сүзсез, Фәез дә. Шактый кыен минутлар... Секретарь кыз кул куярга папка кертте — Фәез шуларны ачмакчы иде... Юк, янында кеше утырганда җайсызрак. Шуңа күрә ул Бориска: «Я, ни йомыш?» дигән сораулы караш ташлады. Тегесе тагын башын иде дә, урыныннан торып, Фәезгә якынрак атлады:

— Син мине гафу ит... Урмандагы өчен.— Фәез эндәшмәгәч, Борис сүзен дәвам иттерде:— Кызмачалык белән... Үземне тота алмаганмын.

— Синең алай гына бүтән чакта да эчкәнең бар.

— Монысында ничектер кәеф юк иде. Ачуланма.— Сүзнең нигездә әйтелеп беткәнлеген сизеп, Борис баштагы урынына барып утырды.— Синең үзеңнең дә ычкынып киткән чакларың булгалый бит.

— Болай ук түгел... болай ук булганы юк.

— Ул хәтле, онытылмаслык бернәрсә дә эшләмәдем бугай мин сиңа.

— Эшләмәсәң, әйттең... Бәлки онытып та булмас.

— Үч алырсыңмы?

Тагын күпмедер сөйләшә алмый утыргач, ничектер Борисның кыяфәте кызганыч тоелып, Фәез аны тынычландыру уе белән:

— Ярый, Боря, шушының белән бетсен,— диде.

— Бик дөрес. Кичә сунар булмады...

— Булды, нишләп булмасын. Син минем ике куянны кая куясың? Ике куян — сирәк бәхет... Алардан баш тартмыйм мин.

— Кычкырыш булмады.

— Анысы булмады. Ярый.

Икесе дә сак кына елмаештылар. Борис, озакка аерылышкан кебек, кул биреп саубуллашты.

Тагын берни булмагандай сөйләшә, аралаша башладылар. Тик шуннан соң бер-берсенең өйләренә керешмәделәр — күңелләрендә эреп бетмәгән боз кисәге һаман калды булса кирәк. Араны бозу гына җиңел, яңадан төзәтүе — ай-һай!

Әйе, эшләр тиз генә төзәлүгә таба китмәде. Борисның кәефе бер дә рәтләнер төсле түгел. Иң үкенечлесе — эшенә суына бара. Иртәнге сигездән төп-төгәл кичке дүрткә хәтле эшли дә, эш бетүгә якынлашкач, сәгатенә карап кына тора — эшчеләрен калдырып үз юлы белән китә дә бара. Шактый кыен хәлләр дә килеп чыккалый. Үзе белән ул хакта сөйләшә башласаң, ачу куа, үч ала диячәк. Ләкин бер заман барыбер тагын нык кына аңлашырга туры киләчәк...

Телефон шалтырады, хатын-кыз тавышы ишетелде:

— Миңа Фәез Насыйбуллин кирәк иде.

— Мин тыңлыйм.

— Исәнмесез, Фәез. Бу — Гета. Сезнең белән сөйләшәсе сүзем бар иде.

— Минем белән? Нәрсә хакында?

— Телефоннан сөйләшә торган сүз түгел, күрешеп сөйләшергә кирәк.

— Белмим шул, кайчан күрешеп булыр икән?..

— Сез эштән кайчан бушыйсыз?

— Кичке сәгать тугызларда.

— Мин сезгә килер идем... әгәр рөхсәт итсәгез.

— Пожалуйста — нинди рөхсәт кирәк аңа.

— Сез өйдә булыгыз инде алайса, мин килермен.
— Ярый, сәгать тугызда.
Гетаның тавышында моңарчы ишетелмәгән курку, каушау билгеләрен ишетү кыен түгел иде... Мөгаен, Борис тагын берәр яманлык эшләгәндер. Сөйләшкәндә аның да кирәк булуы ихтимал. Бәлки болай үпкәләшкәннәр генәдер. Андый чакта ике якны да тыңлау фарыз. Шуңа күрә Фәез Борисны телефон аша — Гета килергә тиешлеген әйтмичә генә — кичен үзенә чакырды.
Ә эштән кайтуына — тышкы ишек төбендә йөренеп, аны Гета көтеп тора иде инде. Дусларча кул биреп күрештеләр, өйгә керделәр. Стенадагы ут кабызгыч төймәне капшаган арада, караңгыда Гетаның авыр сулышы ишетелде. Ут кабызгач, кыз көчәнеп кенә елмайгандай итте. Ямансу һәм кызганыч елмаю...
Өс киемнәрен салдылар.
— Рәхим ит, Гета, түргә уз. Хәзер без синең белән кичке аш рәтләргә тиеш. Булышасыңмы?
— Бик рәхәтләнеп.
Кухняга кергәнче, Фәездән рөхсәт сорап, Гета квартирның бүтән бүлмәләренә дә кереп чыкты да күзләрен чет-чет йомгалап:
— Берүзеңә ике бүлмә! — дип куйды.
Фәез исә, көлемсерәп, кызның гаҗәпләнүен арттырды гына:
— Залны онытасың, өч бүлмә.
Гетаның йомшак күз карашы залдагы телевизорны, холодильникны, диванны, аннары зур трюмо алдындагы телефонны сак кына сыйпагандай тоелды.
— Атакаем, түрәләр яши белә! — диде ул, саф зәңгәр күзләрен тәмам түгәрәкләндереп.
Егет житди кыяфәт белән аңлатырга тиеш булды:
— Борчылма, Гета, гостиница бу. Теге якта мөсафирлар тора.
— Ә-ә-ә,— диде Гета, чыннан да тынычланып,— жәлсыз икән. Нишләп квартир бирмиләр?
— Сораганым юк.
— Ә ник сорамыйсың?
— Кирәк булсам, үзләре бирерләр әле. Әйдә, күп белмә, тиз картаерсың.
Шуннан соң икәү бергә бәрәңге әрчеп пешерергә куйдылар... Кибеттән Фәез алып кайткан тавык итен жылыткач, чәй кайнаттылар. Юкныбарны сөйләшә торгач, кичке аш әзер дә булды.
Күңел чынлыгы өчен генә Фәез Гетага тамак чылатып алырга тәкъдим иткән иде, кыз шундук риза булды.
«Күнегелгән хәл»,— дип уйлады Фәез. Коньякны алып та чыкты һәм, Гета алдында ук ачып, рюмкаларга салды. Өстәлгә өч рюмка куелган иде.
— Сезнең әллә тагы киләсе кешегез бармы? — дип сорады Гета.
— Юк.
— Өч рюмка булганга әйтәм.
— Ә! Ялгыш... Димәк, кем дә булса килергә тиеш — шуның билгесе бу.
— Безгә бүген беркем дә кирәкми.
— Нәрсә өчен эчәбез? Яки кем өчен? Борис өченме?
— Борис өчен?.. Бераз үсә төшсен әле.— Фәезнең сәерсенүен сиздекыз.— Әйдәгез, үзебез өчен эчик әле. Югыйсә, син дә ялгыз, мин дә...
Кинәт Борисның урманда әйткән әшәке сүзе хәтергә килде дә Фәез йөзләрен жыерды. Шулай да хрусталь чыңы күңелгә әйбәт тәэсир итте. Гета да елмаеп куйды һәм Фәезгә жор гына күз кыскан булып рюмкасы күтәрде. Аз-маз ризык капкалагач, телгә килделәр.

— Карале, Гета... Ялгыз дигәннән... Сер булмаса, әйт әле, әллә сез Борис белән...— Фәез җеп очын ычкындырды, тотлыгып калды.

— Сер дип... Кем өчен сер. Кем өчен түгел. Мин сездән яшермәскә булдым.

— Бик әйбәт.

— Минем хыял шундый — туачак баласын атасы белән бергә тәрбияләп кеше итү. Шуның өчен эчтем.

Фәез аңа тиз генә җавап бирә алмады. Дөньяның астын өскә китереп яшәгән кыздан кинәт бала хакында сүз ишетү гаҗәбрәк, көтелмәгән нәрсә сыман тоелды. «Хатын-кызлык инстинкты шулай үзе дә сиздермәстән тавыш сала. Ләкин эчкәч нинди бала инде?»

— Дөрес, кешелекле максат инде бу... Һәр хатын-кызның күңелендә йөргән нәрсә.

«Бөтенләй үк бозылып бетмәгәнсең икән әле». Тел очына килеп житкәч, Фәез дорфа фикерен туктата алды.

— Алай ук түгелдер дә... Хатын-кыз баланы теләмичә таба... Сәламәт булса. Авыру булса, таба алмый торса гына максатка әйләнә ул.

— Ә сезнең? Шуңа әйләндемени?

— Мин — икенче исәп...— Кыз башын иде.— Мин атасыз балаларны кызганам.

— Алай икән!

Әллә ничек, томанлы сөйли Гета, аның үзе дә сизми ычкындырган сүзләреннән шактый күңелсез мәгънә баш сузгандай тоела. «Юк, юк, мөмкин түгел». Фәез житди сөйләшергә базмыйча, чынаякларга кофе койганда, Гета аңа күзләрен тутырып карап торды.

— Нинди әйбәт, чибәр егет... Нишләп сез беркемне дә яратмыйсыз, ә?

Көтелмәгән сүздән Фәез каушый калды.

— Ничек яратмыйм? Мин бөтен дөньяны яратам.

— Сөйгән кызың юк.

— Ә Кама?

— Кама? Нинди Кама ул? Елгамы?

— Елга да, кеше дә — минем өчен икесе дә бер алар.

— Бернәрсә дә аңламыйм. Камиләме әллә?

— Мин үзем дә аңлап бетермәгәч, сез нишләп аңларга тиеш?!

— Сез фантазер... Җир кешесе түгел. Боря хаклы.

— Ул нәрсә ди?

— Тормыштан ваз кичкән фанатик, ди.

— Алай икән!

— Ну, ул сезгә ачуланып түгел, чынлап әйтә, гаҗәпләнеп.

— Ышанам. Димәк, аңламый, күпме бергә йөреп, кем белән йөргәнен тәки төшенмәгән.

— Ә кем соң сез?

Фәез нәрсәдер әйтергә җыенды, ык-мык итте, ләкин туры сорауга туры җавап бирә алмады. «Кара, ул үзенең кем икәнен үзе дә белми икән ләбаса? Шулай булгач, бүтәннәр ничек белсен? Ә бүтәннәр беләләрме икән үзләренең кем икәнлекләрен? Кинәт шундый сорау бирсәң, җавап таба алырлармы икән? Әлбәттә, дөрес һәм төгәл җавап. Гетаны ризалаштыру өчен генә теләсә ни әйтеп булыр иде. Ләкин Гетадан бигрәк аның үзенә җавап кирәк. Кем соң ул? Төзүчеме? Төзүче — профессия, шәхес билгесе түгел... Идарә начальнигымы? Монысы — эштәге урының гына... Тукта, кем соң ул Фәез? Бары тик төзүче, идарә начальнигы гынамыни? Казна кешесе? Ә шәхесе, кешелеге белән кем соң ул?

Бу хакта Фәезгә моңарчы бер дә уйланырга туры килмәгән икән... Ә юкка — уйланырга һәм җавап табарга тиеш булган Фәез. Ничек итсә дә итәргә, үзенең кешелек асылын, төп сыйфатын ачыкларга, эзләргә, эзләргә, ниһаять, табарга тиеш иде.

— Сезнең нәрсәгәдер кәефегез китте, Фәез.

— Юк, болай гына.

Ярый әле, шул вакыт ишектә звонок шалтырады — Фәез ишек ачарга чыгып китте, һәм залга анын белән бергә Борис керде:

— Гета? Моны ничек аңларга? — диде ул, ишек төбендә тукталып.

— Очраклы рәвештә,— диде Фәез, сүзне тизрәк элэктереп алырга тырышып.— Ул кайтып килә иде... безнең трест ягыннан... Бергәләп кайта торгач, башка уй килде — давай, мин әйтәм, күптән сөйләшкән дә юк.

— Ул юри генә әйткән иде, кермәс дип, мин чынлап кердем. Хәзер үзе дә үкенә,— дип елмайган булды кыз.

— Да, мин анда магазинга кергән идем... «Культтовары»га. Шунда канцелярия әйберләре сатучы кыз белән сөйләшеп, мавыгып киткәнмен.

— Нәрсә?

Борис тагын нидер әйтмәкче иде, тотлыкты — ниндидер ярамаган сүз ычкындыра язды бугай... «Ничек инде ул сөйләштегез? Ул бит минем белән иде» дия алмый бит инде, шуңа күрә кул юарга дип, тиз генә туалетка кереп китте. Ләкин чыккач та Гета бәйләнә бирде:

— Я, ничек? Сәлам әйттеме ул миңа?

— Әйтте, бик күп итеп әйтте.

— Ышанам.

— Ярый, иптәшләр, минем өйгә килеп әрепләшмәгез. Кычкырышасыгыз килсә, үз өегезгә чакырышып кычкырышыгыз,— дип ярым шаярып, ярым чынлап әйтте Фәез.

Тегеләр икесе ике якка карап тындылар. Фәез уңайлы форсаттан файдаланырга чамалады:

— Без монда, сүз белән игълан итмичә генә, һәр икебез хыял өчен бераз тамак чылаттык. Сиңа да шуны тәкъдим итәбез. Боря, әйдә.

— Минем хыялым юк,— диде Боря,— мин жир кешесе.

Гета һаман усаллашуында булды:

— Димәк, син эчмәскә дә тиеш.

Фәез дә анын яклы:

— Ә нәрсә өчен яшәргә кирәк алайса?

— Нәрсә өчен? Ул хакта без синең белән төн буе бәхәсләштек бит, Фәез. Хыялым юк, эшләрем, кешеләрем, шатлыкларым, кайгыларым гына бар. Старт һәм финиш, ә арада — төрле озынлыктагы чакрымнар... Ахыр чиктә ераклыкның әһәмияте юк. Ике ара — яшәү формасы...

— Эчтәлектән тыш форма үзе генә була алмый дип өйрәтә фән, иптәш.

— Эчтәлеге шул: һәр тере әйбер үзенең тереклек рәхәтен, яшәү ләззәтен тоярга тиеш — тән рәхәтен белеп яшәргә тиеш. Ә безнең очрашулар, көрәшүләр, эш хакы алу һәм башка атрибутлар — яшәү рәвеше. Мена шулар инде форма — классик философиягә каршы килмим мин.

— Ләкин ярыйсы ук үзеңчә аңлатасың.

— Мин шуны гына беләм, һәр тере әйбер яшәргә тиеш. Ул беренче чиратта — тән... Ул үзенә бирелгән барлык мөмкинлекләр белән яшәргә тиеш — тормыш, дөнья биргәннәрне ахыр чиккә хәтле татып белергә тиеш. Бүтән кешеләр белән дә ул шунын өчен аралаша, беренче чиратта үзе өчен яши. Үзе өчен дигәнем, әлбәттә, үзе генә дигән сүз түгел — кешеләр мөнәсәбәтендә туа ул матурлык, тәм, гомумән яшәү. Табигый закон. Ә менә син ничек яшисең?

— Син уйлаганча. Гета миңа әйтте инде синең фикерне, рәхмәт.

— Сүз шуннан киткән икән инде, үз авызымнан ишет — кеше аркылы ишетелгәне гайбәт була аның. Тик син тагын берәр рюмка сал әле миңа.

Фәез сүзсез генә коньяк салды һәм чәкәштермичә иреннәрен рюмканың кырыена гына тидереп куйды.

— Тыңлыйм, дустым, тартынма, әйт.

— Тартынмыйм, бүтән әллә сөйләшеп була, әллә юк.— Каршы сүз әйттермәс өчен, Борис кулын күтәрде.— Анысы зыянсыз. Менә шул... Кеше — терлек түгел, ул иҗат итәргә тиеш — бәхәссез. Син мине иҗат итми дия алмыйсың, әгәр синнән артыграк булмаса.

— Ихтимал, артыграктыр...

— Ну вот, молодец. Ләкин минем иҗат — шулай ук яшәү формасы.

— Һәркем өчен шулай.

— Ә синең өчен алай түгел шул. Синең өчен ул — максат, беренче чиратта... баягыча әйтсәк.

— Шулай шул — иң зур бәхет... Кешенең төп асылы, мәгънәсе, бурычы шул.

— Менә аңлаштык та. Шуннан башлана да инде безнең аерма. Син — герой, көн-төн эштә, бөтен тормышың җәмгыятькә бирелгән. Ә үзең яшәмисең...

— Яшим.

— Ничек? Кем белән? Кама беләнме?

— Әйтик... Кама белән.

— Хыял белән. Сакаллы сабый! Олы бала! Менә кем син!..

Ничек диде? Бая күпме баш ватып таба алмаган сүзне чак кына уйлап тормастан әйтте дә бирде! Олы бала! Менә кем икән ул Фәез! Олы бала! — Бик үк матур яңгырамаса да, дөрестер ул, төп мәгънәсе белән дөрестер. Бүтәнчә әйтсәң дә мәгънәсе шул каладыр... Дөреслек, кырыс дөреслек.

— Югыйсә, Чаллыда ни гомер яшәп, берәр кешегә күзең төшмәс идеме? Ялгыш күреп калган кызны эзләп җүләргә сабышыр идеңме? Син бит аны чибәр булганы өчен түгел, Кама исемле булганы өчен яратасың. Кешене түгел, ә аның исемен яратасың. Шушы буламы яшәү?

— Бу рухи яшәү дип атала бугай, ялгышмасам. Тән генә түгел бит...

— Эх, дустым, эх, дустым! — Борис чын күңелдән көлеп җибәрде.— Ярый, болар барысы да ерунда... Шекспирча әйтсәк, үз-үзең белән мавыгу — табигатькә, яшәүгә җинаять ул. Ярый, бетсен шушында — безнеке генә түгел, мең еллык бәхәс, без генә хәл итә алмабыз аны. Исәнлек өчен — әйдәгез.

Шактый вакытка сузылган сүзсезлектән соң, Борис радио тоташтырмакчы иде, Гета каршы килде:

— Зинһар... туйдым тавыштан!..

Шулай диде дә Фәезнең йокы бүлмәсен ачты:

— Мөмкинме, Фәез?

— Әлбәттә, әлбәттә, Гета.

Фәез бераздан «Гетаның сүзе бар» дигән мәгънә белән Бориска күз кысты. Үзе диванда утырып калды.

Сөйләшүләре бүлмә аркылы аермачык ишетелеп тора, пышылдап түгел, ичмасам, әкренрәк тә сөйләшмиләр. Ирексездән шаһит булырга туры килә Фәезгә. Шактый күңелсез нәрсәләр шаһиты...

— Сатучы кыз ничек яшәп ята?

— Тәрбиячеләр кебек үк, күңелле.

— Күңеллерәктер дә әле. Югыйсә, миннән ана күчмәгән булыр иден.

— Нәрсә, көнләшәсеңме әллә?

— Көнләшмим. Алла сакласын. Теләсәгез, хет Себергә олагыгыз.

— Безгә Чаллы да бик ошый. Нишләргә икән?

Гета моңа җавап тапмады бугай — сүз беразга өзелде. Аннары гына ачусыз шелтәсе ишетелде:

— Бая мин бала өчен эчтем. Аны әтисе белән бергәләп тәрбияләү өчен...

— Нәрсә? — Борисның тавышында гаҗәпләнүдән бигрәк курку, куркудан бигрәк — ачу ишетелде.— Нәрсә лепелдисең син? Шаярма син минем белән.

— Ә мин шаярмыйм.

— Шаярасың! Мине эләктерер өчен эшлисең син бу эшне. Ләкин әйтеп куям: хәйләгә каба торган сандугач түгел мин.

— Сандугач! Каян килгән! Трелле-ли! Бик ачуландырсаңмы? Бик алай ачуга китсәме — мин үзеңә дә, сатучыңа да Чаллыны харам итә алам. Ачуымны бик китерергә генә тырышыгыз.

— Син аны эшли алмаячаксың.

— Ә ник эшләмәскә?

— Чөнки син андый явыз кыз түгел. Мин бит сине беләм. Юкка яратканмы дисеңмени?

— Менә молодец! Монысы бөтенләй әйбәт. Шулай юхалансаң, хәерлерәк булыр.

— Тик мин синең баягы сүзеңә ышанмыйм. Юри генә әйтәсең син аны. Юри бит?

Катгый тавыш:

— Юри түгел, чынлап!

«Гета, мескен Гета! Шундый чакта да ничек тыныч сөйләшә ала ул! Гаҗәп кыз, чынлап та гаҗәп кыз! Әнә бит, Борис нәрсә ди, ә ул ничек тыныч кына җавап бирә.

— Гета, мин сине бик яратсам да...

— Әйтмә ул сүзне, пычратма.

— Ләкин син минем хатынлы кеше икәнне беләсең.

— Хатынлы! Беләм мин сине. Сатучы кызны әйтсәң, акыллырак булыр иде. Хатының аркасында бизденме соң син миннән?!

— Мин үземнең нинди уйлар, нинди принциплар белән яшәгәнемне башта ук әйттем. Минем максатым ул түгел, үзең беләсең... Максатым бала тудыру гына булса, мин хатыным белән генә яшәгән булыр идем.

— Әйе шул, дөрес әйтәсең.

— Ә моны нишләтәсең инде?

— Нишләтергә мөмкин соң?

— Син үзең белергә тиеш...

Борисның куркуы тавышыннан ыграк сизелә хәзер. Чөнки Гета ул ишетергә теләгәнне шактый озак көттереп кенә әйтте.

— Син курыкма. Без сиңа тагылмабыз. Үзең кара, әйдә. Ә мин аны барыбер табам, чөнки мин сине яратам, син юньсезне яратам мин. Чөнки дөньяда бер тиле мин...

Бориска бүтән нәрсә кирәкми дә, билгеле. Мөгаен, хәзер ул аны кочаклый, үбә, яратадыр, ләкин берниндн вәгъдә бирмидер һәм бирмәячәк тә. Чөнки ул аңа башта ук әйткән, Борисның кем икәнен Гета башта ук белеп торган... Үзе гаепле, бары тик үзе генә...

— Синең кебек итеп беркемне дә яратмыйм мин, Боря. Ятратканым да юк һәм булмас та.

— Ах, Гета, Гета, җүләрем, җүләрем! Син беркемгә дә ошамаган, беркемгә дә. Син үзеңчә саф, үзеңчә акыллы. Мин сине онытмам, мин сине һич тә оныта алмам.

— Рәхмәт, шуның өчен дә рәхмәт сиңа, ярый.

Фәез ул хәтле тәҗрибәле кеше түгел, ләкин ул да сизә: Борис үзен бәхетле итеп исәпләргә тиеш. Нинди йомшак һәм романтик күңелле кызга туры килгән бит! Икегә түгел, өч куянга берьюлы тидерде Борис — хатыны, Гета һәм сатучы кыз...

Шәп сунарчы син, Борис, шәп. Моннан соң мин аткан куяннарга көнләшеп карама!

* * *

— Фәез, миңа гариза язарга булышмассыңмы? — Зәңгәр күзләрен тутырып, Кәрам карап тора икән. Ирләр бер-берсенә, гадәттә, туры карамыйлар — Фәез тиз генә күзләрен кәгазьләргә күчерде.

— Нинди гариза тагы?

— Нинди дип... Гариза инде... общежитиедән урын сорап,— диде Кәрам, уңайсызланып кына.

— Общежитиедән өйләнешмәгән кешеләргә генә урын бирелә.

— Мин дә өйләнмәгән.

— Нәрсә? — диде Фәез, гаҗәпләнүе катыш үртәлеп.— Кайчаннан башлап?

— Бер атна инде... Мин буйдак.

— Карале, дус, минем бүтән мәшәкатьләрем дә житәрлек — тын алырга да вакыт юк. Син дә мәтәштереп йөрмә инде, яме. Бар, эшеңдә бул.

— Мин чынлап әйтәм, Фәез, без аерылыштык.

— Ничек — аерылыштыгыз? Ташлап чыктыңмы?

— Киресенчә, ул куып чыгарды.

— Гөнаһың булгандыр.

— Бернинди гөнаһ юк.

Шул вакыт, гаҗәпкә каршы, ишектән Гета килеп керде. Аның бу бүлмәдә беренче күренүе иде. Тәрбияче буларак, ул бронвахта белән дә бәйле. Ул Кәрам вакыйгасын ишеткән дә аның монда икәнен белеп кергән икән.

— Нинди бәхетле семья дип көнләшеп йөрсәм,— диде ул, Кәрамның колагын борган булып,— син дә юньсез малай булып чыктыңмыни инде?

Фәез дә мөмкин кадәр борычлырак сүз табарга тырышты:

— Бәхетле малай ирек сорый, егет буласым килә, ди.

— Гаризаны кемгә язарга икәнен белмим,— диде Кәрам, яман беркатлыланып.

Гета үртәлә үк башлады:

— Аерылырга башың житкән бит, нишләп гариза язарга башың житми?

— Ул мине үзе куды.

— Ник?

— Бер көн өйдә кунмаган өчен.

— Нишләп өенә кайтмыйсың? Иван чире йоктымы? — Ниһаять, Фәез максатына иреште, Кәрам чак кына ояла башлады.

— Ялга каршы көнне малай белән мунчага барган идем,— диде ул акланып,— соңга калынды. Көн дә бик салкын булгач, бабайга гына кереп йокладык. Ә ул ышанмый, азып йөрисең, ди.

— Нишләп әтисенә барып сорамый соң?

— Ике бала белән ул хәзер беркая да чыгып йөри алмый.

— Бабаңнан үтен, ул килеп аңлатсын.

— Анысы, эшем күп, ди.

Фәез аптырагач көлеп җибәрде:

— Кара нинди шәп конфликт, аерылышырга артыгы белән житкән!

— Мәхәббәт бетсә, сәбәп табыла,— диде Кәрам, чак кына уфтанып.

— Ә мәхәббәт кая киткән? — диде Гета.

— Анысын үзегез беләсез, үзегез гаепле.

— Ничек без?

— Күпме сорадым мин сездән квартир — бирмәдегез. Өемдә кеше саен бер бүлмә булса, мин дә, борынгы дворяннар шикелле, хатыныма мәхәббәт җырлары җырлап кына яшәр идем.

— Менә шулай, безнең кесә тулы ордер, теләсә кемгә өләшеп йөрибез, ә сина бирмибез, чөнки синең күзләрең зәңгәр.
— Сәбәбен мин белмим анысы, Фәез дус.
Фәез, елмаюын яшерергә тырышып, Гетага карады:
— Нишлибез?
— Хатыны янына барып сөйләшергә туры килер. Бергәләп барсак, шәп булыр иде.
— Ярый, бүген кичке якта карарбыз.
— Ә гаризаны кемгә язарга?
Фәез, тагын елмаймаска тырышып:
— Бүген кичке сигездә өендә бул, шунда хәл итәрбез.— диде.
Һәм ул сүзендә торды.
Бронвахтаны ап-ак кар күмгән. Ап-ак киңлек — чиксезлек иллюзиясе, иркенлек рәхәте. Ләкин, иркенлек белән бергә, кешегә җылылык та кирәк шул. Баржаларның яме киткән — аларда бөтенләй тормыш юк кебек. Әле кайчан гына җәйге яшел сахраларда балаларның чыр-чуы ишетелеп тора, палубалардан тирә-якка җил тизлеге белән җыр, бию, көлү-шаяру — күтәренке хисләр тарала торган иде.
Яр буенда таныш баржа. Күпчелек бүлмәләр буш — ишеген ачыпачып карадылар. Кәрамнарга житкәндә Фәезнең дә, Гетаның да кәефе кырылган иде. Өйгә кергәч, күңелдәге авыр хис тагын да көчәя төште.
Каршыда ике кеше сыешлы таныш карават. Кеше саны артса да, бердәнбер кечкенә өстәл янында артсыз ике урындык. Шуның берсенә Кәрамның малае Фәрит аягын бөкләп утырган да пластилиннан танклар, солдатлар ясап азаплана, әзерләре икенче урындыкка тезелгән. Аның да җәйге шуклыгы җилгә очкан. Кәрам үзе ишек катындагы стенага сөялгән, хатыны караватта бала тотып утыра. Фәезләр күренгәч, хуҗа елмайгандай итсә дә, күңелсезлек тиз генә таралмады — хатыны исә баласын тоткан килеш торып баскан булды:
— Әйдәгез, түрдән узыгыз, утырыгыз.— Ә утырыр урын юк.
Фәез дә, Гета да яшәү шартлары хакында сорашмадылар — бөтенесе күз алдында. Гета, хатын-кыз буларак, сүзне үзе башлады:
— Сезнең исемегез ничек әле, гафу итегез?
— Рәисә минем исемем.
— Без Кәрам белән сөйләшкән идек инде. Ул әйтеп бетермәде бугай. Нәрсә килеп чыкты соң сезнең?
— Ул мине алдый башлады.
— Әнә бит...— дип Кәрам каршы килмәкче иде, Фәез аны сүзеннән туктатты:
— Башта аның белән аңлашыйк, комачауламa. Синең белән без көн саен сөйләшә алабыз, аллага шөкер.
— Күзгә карап ялганламасын.
Рәисә кызып китте:
— Нәрсәсе ялган? Ошамыймыни? Ошамаса, койрыгыңны кысып өйдә генә яталар аны. Атналар буе гулять итмиләр.
— Нинди атна? Анысы без авылда концерт белән йөргәндә...
— Концерт! Кем җибәрсен сине көчләп — үзең йөрисең. Кама исемле кыз артыннан.
— Кама исемле? — Фәез кызарып китте.
— Әйе шул, Кама исемле. Ә бу ат азгыны. Шуңа азаланып, акылдан язды. Сандугач кебек сайрый башлады. Авылга да шуңа иярен китте, беркем көчләп җибәрмәде. Минем бүген-иртәгә больницага китәсен белгән килеш китте.
— Ни өчен больницага?
— Шушы баланы табарга инде.— Рәисә, оялыбрак, баласын күкрәгенә тагы да кыса төште.— Бала белән берүзем яттым, берүзем кайттым — каршыларга да килмәде.

— Кәрам, син шундый да алама кеше булып чыктыңмыни әле? — диде Гета.

— Әйтәм бит, авылда калдык, концерт белән.

— Кызлар белән! Нинди концерт! Ә мин берүзем кибеткә дә атналык баланы күтәреп йөрим, монысын өйдә бикләп.

— Менә сиңа Кәрам. Карап торсаң, бик тыйнак, бик әйбәт кеше төсле үзең.

— Йоклаганда тыйнак.

— Өйдә булмагач, мин нишлим инде?

— Сине беркем көчләп җибәрмәде.

— Көчләп җибәрде, концерт өзелә дип.

— Әгәр Рәисәнең хәлен әйбәтләп аңлаткан булсаң, беркем дә җибәрмәс иде сине. Ахыр чиктә, инде бик өзелә торган булса, өзелер иде, бөтенләй китмәгән булыр идегез. Син аларга әйттеңме соң?

Кәрам ык-мык итә:

— Белгән булсам...

— Белгән булса!.. Үзем дә әйттем, хәлемнең авыр икәнен үзең дә күреп тордың. Сиңа сөйләшү кирәк түгел иде, ат азгыны, яшь кыз артыннан ияреп йөрү кирәк иде. Ичмасам, тегесеннән берәр рәтле сүз ишетсә икән — йөрсен иде. Ә бит Кама моңа әйләнеп кенә дә карамый, үз егете бар ди.

— Нинди егет? — Кәрам бу сорауны бирмәскә тиешлеген аңласа да, соң иде инде.

— Синең кебек җилкуар түгел, ди, идарә начальнигы, ди.

— Идарә начальнигы? — Кәрам аптырап Фәезгә карады. Аныcы да уңайсызлана калды. Менә егетләр! Бар икән күрәселәр!

Шулай да, бераз фикер йөрткәч, Фәезгә җан керде. Ничек кенә кыен булса да, хәл матур булмаса да, әйтик, ике-өч кенә минут элек: «Кәрам белән буталырлык кыз нишләп миңа шул чаклы матур күренде икән соң әле?» дип уйлана башлаган иде ул. Әйтерсең үзе әллә кем. Юк, алай масаю килешмәс. Беренчедән, ул монда бүтән эш, бүтән йомыш белән килде. Икенчедән, тәкәбберлек, үзеңне үзең зурга кую — белеме, эше белән үзеңнән астарак кешене түбәнрәк дип фикер йөртү — алама һәм иске чир, «ул синдә дә бар икән, Фәез иптәш! Бар икән, бар, яшермә!»

Фәезнең кәефе ник җимерелгәнне Кәрам сизә. Ә Гета моны гаилә бозылу аркасында дип уйлый иде бугай. Әйтүе шуңа күрә булгандыр:

— Нишләтәбез бу кешене, бу бит чыгырыннан чыккан?

— Нәрсә булса да эшләргә туры килер, әйдәгез, уйлашыйк,— диде Фәез шактый кырыс тавыш белән. Ә үзенең башында бөтенләй бүтән нәрсәләр...

— Хәзер дә теләсә кайда кунып йөри. Концерт сылтау гына ул аңа, сылтау гына.

Җитмәсә, кулдагы баласы елый башлады.

Баланы һәм ананы кызганудан Фәезнең йөрәге чәнчеп куйды һәм ул, уйларыннан арынып, кискен карап әйтте:

— Минемчә, Кәрам, син ирләрчә эш итмәгәнсең. Хатыныңа иң авыр чакта, больницага кергәч, бәби алып кайткач һәм шул авыруыннан терелеп тә җитмәс борын чыгып киткәнсең. Минемчә, бу — хыянәт.

Гета да куәтләде:

— Әлбәттә, хыянәт.

Әгәр бала үзәге өзелеп еламый торган булса, дөньяда була торган иң киеренке минутларның, коточкыч авыр тынлыкларның берсе булыр иде бу. Үзенә текәлгән көйдергеч күзләрдән котылу өчен, Кәрам, бер сүз әйтмичә, башын иеп тик тора бирде. Шактый вакыттан соң, баягы кискенлеген саклаган хәлдә, Фәез әйтте:

— Менә нәрсә, Кәрам, әгәр безнең, бергә эшләгән барлык иптәшләрнең үзенә карата элекке ихтирамын саклыйсың килсә, син бүген үк хатының алдында гафу үтенеп, аңа кирәкне күз карашыннан аңлап алып үти башла. Шушы минуттан кереш. Югыйсә, безнең юллар аерыла, белеп тор. Өеңдә яшә.

— Кайда соң минем өем?

— Әгәр кертсәләр, гафу итсәләр,— диде Гета, сүзне икенчегә бору өчен, ахрысы.

— Анысы Рәисәнең үз эше — без катнаша алмыйбыз.

— Шулай.

Ире дә, хатыны да сүзсез калгач (әйбәт билге!), Фәез Кәрамга мөрәҗәгать итте:

— Я, Кәрам, ничек хәл итәбез?

Шуны гына көткәндәй, Кәрам кабынып китте:

— Сезгә ансат, үзегез ванналы-кухнялы өр-яңа квартирда торгач... Сезгә нәрсә! Менә минем өйдә йоклап карагыз сез — өч кеше бер караватта. Такта өйдә, кышкы челләдә. Минем монда кулымны сузарга да мәйдан җитми — аяк басарга да урын эзләп кенә басам.

Баласын юата алмыйча, әнисе дә елап җибәрде:

— Өйләнгән чагында әллә ниләр вәгъдә итте, оҗмахлар! Ник өйләндең, карый алмаслык булгач! Ник өйләндең, семья карарлык рәтең булмагач? Көчләп тагылдыммы әллә?

— Күрәләтә ник чыктың шундый булдыксыз кешегә? Мин сине куркытып алдыммы? Үз теләгең белән, бөтенесен белеп чыктың бит!

Алар кычкырышкан арада Гета Фәездән:

— Чиратта торалармы? — дип сорады.

— Торалар.

— Чиратлары җитәргә ничә кеше бар?

— Безнең идарә буенча уналты.

— Ким дигәндә тагын бер ел көтәргә икән.

— Цехком җыелышында тикшерергә, хәлне аңлатырга кирәк. Бәлки чиратсыз бирергә ризалашырлар.

Фәез, бераз уйлабрак торгач, Рәисәгә карады:

— Сез ул хәтле борчылмагыз, тынычланырга тырышыгыз.

— Мондый хәлдә ничек тыныч яшисең инде? Җүләр булырга кирәк.

— Балагызны кызганыгыз. Кайгырып кына файда чыкмас. Уйлашырбыз, киңәшербез, якын арада квартир алырга тырышырбыз.

Гета Кәрамга күз кысты:

— Ишеттеңме?

— Ишеттем. Кайчан?

— Бу кышка түзсәгез, икенче кышны мондый хәлдә каршыламассыз. Анысына ышандырырга булыр,— диде Фәез,— ә җәй көне монда ул чаклы кыен да түгел.

Ир белән хатынның чырайлары яктырмаса да, аларда баягы өметсезлек һәм каушау юк иде инде. Килешәчәкләренә, татуланачакларына да ышанырга мөмкин иде. Сәбәп квартирда гына, Кәрам юри куерта...

Аның каравы, Фәез үз башындагы күңелсез һәм буталчык уйларны куа алмый. Кешеләр мәхәббәтен, кешеләр тормышын кайгырта, ә үз тормышы бөтенләй буш... Бигрәк тә шунысы кызганыч — ул моның өчен беркемне дә гаепли алмый, бары тик бер кеше — үзе генә гаепле.

* * *

Фәез Иске Чурайдан кичке сәгать уннарда гына кайтып керде. Иртән уянып китсә, сәгать җиде булган. Битләрен югач, бер стакан салкын су эчте дә чыгып чапты. Беренче булып диспетчерлыкка керде. Андыймондый үзгәреш юк, бөтенесе үз урынында диярлек иде.

Аннан соң, гадәттәгечә, объектларга китте. Аларда да чаң сугарлык хәлләр тапмады. Ә менә автобазаның тимерчелек цехында аны күңелсезлек көткән — теге чакта сызымнарга үзе үзгәреш керткән, калай табакларыннан ясалган түшәмне инженер-куратор кабул итмәгән икән. Фәез аркасында түгел, сәбәп бүтән — түшәмнең урта бер җирендә калай тишелгән, ялгыш басканнар, күрәсең.

Фәезнең кәефе болай да бик шәптән түгел иде. Никадәр сиздермәскә тырышса да, кечкенә генә кимчелек аркасында зур тоткарлык килеп чыгуы, көндәлек ритмга зыян китерүе тагын да ныграк үртәлергә мәҗбүр итте. Пичугин аның шелтәсен тыңлаганда агарынып куйды:

— Ярый, бригадирга әйтермен, бүген үк төзәтербез.

— Миңа ул гына җитми, төзәтелсен дә, кураторга да тапшырылсын. Булдымы?

— Ярый, тырышырбыз.— Фәезнең күз карашында ачулы очкыннар күрепме, прораб сүзен төзәтергә ашыкты.— Тапшырырбыз.

— Килештек.

Фәезне мондый кырыс кыяфәттә беренче тапкыр күргәнлектән, прораб гаҗәпләнебрәк калды.

Һәм бу эштән башка урынга күчкән бригадасы янына барып тормыйча, инструментлар эзләп, складка үзе кереп китте...

Фәез исә, иртәнге сәяхәтен дәвам итәрәк, башка объектларга юл тотты. Кәеф җимерерлек нәрсәгә туры килмәгәнлектән, шлюзга кайтып җиткәнче андый-мондый усаллык эшләмәде. Ә ай ахырында көтелмәгән хәлләр дә килеп чыга ул. Бу юлы, шлюзга кайтып җиткәч — борын төбендә! — тагын да күңелсезрәк хәл каршылады: опалубкаларны куптарсалар, бетон эчендә тишек-тошыклар — буран уларлык. Вибраторлар тиешенчә эшләмәгән. Әлеге дә баягы, Борис югында...

Блок — таш тау. Бетон килгән, бетон салынган, әмма кирәгенчә эшләнмәгән.

Фәез участок будкасына чабып керде, бетончылар карта суга. Каушап аягүрә бастылар басуын, ә карталарын яшереп өлгермәделәр. Фәез, артык ачуланудан, бер сүз әйтмичә генә, карталарны кесәсенә салып, участок начальнигы бүлмәсенә узды. Монда Фәез сирәк күренгәнгәме, гаебен сизепме, дусты булуга карамастан, Борис та сикереп торды.

— Әйдә утыр,— диде ул, ачуын тыярга азапланган иптәшеннән күз алмыйча.— Берәр хәл юктыр бит?

— Әле нәрсә килеп чыкканны да белмисеңмени? — Фәез алай ук ярамаганын сизә торып акырды, чөнки дустының шуннан башкага лаек түгеллеге көн кебек ачык иде. Һәм дәвам итте:— Нәрсә карадың? Нәрсә карап утырасың?

Сүз, әлбәттә, бетон хакында бара — Борис моны Фәез шашынып кергәч үк төшенде, тик, һаман белмәгәнгә сабышып, (бәладән күз йомып котыла, янәсе!) Фәезне тагын да ныграк котыртты.

— Нәрсә турында әйтәсең син, Фәез?..

— Атаң башы турында.

— Фәез, ипләбрәк.

— Ипләрмен мин сиңа, яме. Бик ипле итеп урнаштырам мин сине хәзер, исләрең китеп торыр үзеңнең дә. Әйт, нәрсә карап утырдың?

— Мин юк идем.

— Әһә, алай икән! Ап-ансат! Ул булмаган! Таныш бу миңа, бик яхшы таныш бу миңа. Бетон сәгать дүрт тулып, минут ярым соң килгән алайса.

— Кичке алтыда килгән.

— Ә син аның киләсен белденме? Белдең!

— Мин аларга шалтыраттым — иртәнгә калдырыгыз дип... Тыңламаганнар, китергәннәр...

— Алар синең кем икәнне белмәгәннәр, димәк. Син үзеңнең кем икәнеңне бөтен дөньяга танытып өлгермәгән әле, димәк. Менә хәзер таныттың инде, данлы егет!

— Дан миңа кирәкми, ул сезгә кирәк.

Яшерен-батырың түгел, Фәезнең күңеленә килгән беренче теләк — янда гына торган табуретка белән Борисның оятсыз йөзенә бәрү иде. Тегесе үзе дә моңа дустының урындыкка карап куюыннан сизгәндер. Ләкин ярамаган эштән дустын коткарып калырга ашыкты:

— Фәез, акылыңа кил.

Фәез чынлап та бәладән читкәрәк тайпылды, бөтен гәүдәсенең пружина төсле актык чиктә кысылуын абайлап, үзен чак кына булса да тынычландырырга тырышып, бүлмә буйлап әйләнә башлады.

— Менә нәрсә әйтәм мин сиңа, дустым, яхшылык белән үтә син аны. Теләсәгез ничек итегез, кирәгем исә тешегез белән кимерегез, мин икенче монда килүгә бу тау кураторлар кабул итәрлек блокка әйләнсен.— Шулай дип, ул дустының күзләренә карады.

Борисның йөзендә нинди дә булса үзгәреш күрү кыен иде. Шуңа күрә Фәез катгый итеп боерды:

— Иртәгә мин килүгә әзер булсын!..

Борис бәлки гаебен белеп эндәшми калса да яраган булыр иде — юк, нәрсә дип тора юньсез:

— Уйламыйм да.

Фәезнең күзләре кысылды, хәтта ул күкрәгендә ниндидер калтырау да сизде. Ләкин, урыныннан кузгалмыйча, уйлана калды. Борис болай үрти ала икән, димәк, аның ниндидер ышанычлы нигезе, дәлиле бар. Шуны белми торып, сөйләшүне дәвам иттерү мөмкин түгел.

Фәез тагын бүлмә буйлап йөренергә кереште һәм туктап, тыныч ук диярлек хәлгә килеп, Борис урынына утырды. Бу юлы ул моны Борисның эш буенча үзеңә буйсынган кеше икәненә басым ясап, ачыграк күрсәтү өчен эшләде.

— Ә нәрсә уйлыйсың?

— Берни уйламыйм.

— Уйлыйсың. Син үзеңне бүтәннәрдән акыллырак дип уйлыйсың.

— Бүтәннәрдә минем эшем юк, мин үзем белгәнчә, үзем теләгәнчә эшлим.

— Ә без үзебез теләгәнчә эшләргә кушсак?

— Закон белән билгеләнгән срокларда — пожалуйста. Ә эш сәгатеннән соң — гафу итегез. Анысы минем карамакта — аңа мин хуҗа. Рәхим ит, фәлән кубометр бетонны харап итте дип, судка бир — суд расходын үзең күтәрәчәксең, ә мине гаепли алмаячаксың.

— Ә менә бүтәннәр, менә без... андый ук оятсызлыкка нишләп бара алмыйбыз икән?

— Әйттем бит, сез — заман геройлары, сезгә дан кирәк.

— Безгә эш кирәк! Безгә менә төзергә кирәк — ГЭС һәм торак йортлар, промбазалар, заводлар! Шуңа күрә без вакыт белән исәпләшмибез. Синең кебек тән рәхәте дип чапмыйбыз, ә бүтән эшләр артыннан чабабыз.

— Үзегез гаепле, сез үзегезне эксплуатацияләргә ирек куясыз.

— Ба! Актарып чыгарды сүз!

— Кайчак иске сүзләр дә кирәк була, стиль өчен.

— Тфү, чорт, нинди бәндә син?

— Мин просто тәртип ярата торган кеше. Менә син план диден, айлык задание үтәлмәгәнгә чыгырыңнан ычкындың. Шуның өчен сез көннәр һәм төннәрегезне каһарманнарча корбан итәсез, чын каһарман-

нарча... Тик бу каһарманлык ахмаклык дәрәҗәсендә. Чөнки кемнәрнеңдер үз эшләрен башкара белмәүләре яки әкрен кузгалулары аркасында, алар эшлисе эшне сез үзегезнең расписаниедән тыш эшләү исәбенә үз җилкәгездә күтәреп барасыз. Нәрсә дисең соң моны? Беләм, бик ямьсез сүз, эксплуатация! Ләкин ямьсез булса да — хак сүз.

— Чит илдә ятлап кайткан сүзләреңне онытырга киңәш бирәм мин сиңа...

Хәзер инде Фәез төсле итеп Борис арлы-бирле йөренә — кулларын артка куйган, әйтерсең, остаз укучысына дәрес бирә:

— Менә шулай ул. Әйтик, безнең төзелеш. Дөресен генә әйткәндә, аның һәр көненә хәтле расписание төзелгән, график дигән нәрсә барлык предприятиеләрдә һәм проектлаштыру оешмаларында тикшерелеп хәл ителгән һәм кул куелган. Әгәр шуның нигезендә эшләсәң, без барыбыз да минем кебек эшләр идек. Мин — норма. Ә фактта сез мине аномалия итеп күрәсез. Чынлыкта — сез гарип, сез хаксыз. Бүтәннәр үзенә тапшырылган эшне, иң әйбәт дигәндә, үти алмый, сәләте җитми, ә күпчелек очракта үзен югары тотып, сезнең кебекләрне ялындырыр өчен, үзенең бәясен күтәрер өчен шулай эшли. Тиешле материалны тизрәк һәм күбрәк алыйм дип, сине начар хәлгә куеп булса да, аны бүтән кешеләр эләктерергә тырыша. Авыз ачып калмас өчен, син аннан да өлгеррәк булырга, аннан да остарак юллар табарга тырышасың. Менә китә ярыш, китә буталыш. Үз вакытында кирәкле әйберне җибәрмәгән өчен фактта аңа җәза тиешле, ә ул сезгә үз ихтыярын тага — үзен сездән дә югарырак тота. Шуңа күрә сез материал артыннан чабарга тиеш — чөнки иң беренче дистанция — сез, төзелешнең начар баруы сездә күренә. Ә бүтән җирдә — кәгазь, сүз... Ул оешмалар яки предприятиеләрдәге бюрократлыкка көчегез җитмичә, үзегезне авыр хәлдән чыгару өчен сез үзегезнең бөтен тормышыгызны бүтәннәр кимчелеген каплауга багышлыйсыз. Шуңа күрә сез геройлар, каһарманнар!

Фәезнең җавап бирми торуын Борис үзенең хаклы булуыннан дип уйлап, тагын да тынычрак тавышка күчте.

— Сез генә түгел, дустым, мин дә көрәшәм. Чынлап көрәшәм. Мин сезнең акылларга, характерларга үз карашларымның кереп урнашуын телим, сезнең басымыгыз, тиргәү-каһәрләүләрегезгә түзәм, тормышта мин башлаган юнәлеш кайчан да булса җиңәчәгенә ышанам! Тәртип, акыл һәм культура җиңәчәк, әлбәттә. Шунда без җәмгыять өчен дә күбрәк эшли алачакбыз, үзебез дә чын яшәү белән яшәячәкбез. Ирекле вакыт законы буенча.

— Тән рәхәте тоеп...

— Мин производство хакында сөйләдем, дустым. Башыңны җүләрлеккә салма. Уйласаң төшенерсең, күп җирләрдә инде мин теләгәнчә эшлиләр.

— Кайда ул син теләгәнчә? Күптән түгел кайткан җирләреңдәме?

— Мәсәлән, шунда.

— Син сөйләгәнчә идеаль тәртипме?

— Идеаль булмаса да — тәртип. Без анда нәкъ менә мин сөйләгәнчә эшләдек, һәм эшебез аксамады. Без совет инженерлары исеменнән шулай эшләдек, алар данына зыян китермәдек. Димәк, теләсәк, эшли алабыз икән. Безнең горурлыкка кагылырга кирәк, шул чакта гына без тәртип тудыра беләбез. Безне шундый хәлгә куярга кирәк — өйрәтергә, тукмый-тукмый өйрәтергә кирәк. Бу инде бюрократик тәртипләрне юк итүгә китерәчәк.

— Болай булсаң, шактый тукмалырсың әле, дустым.

— Түзәрмен! Барыбер үземнекен исбат итәрмен...

— Капиталистик илдә булган гадәтләрне монда да күчерергә телисең икән, ялгышасың.

— Ну, шулай дисәм? Ә ни өчен без капиталистлардан начаррак булырга тиеш? Алардан тәртипсезрәк булырга тиеш? Кирәк икән, дошманның да яхшы ягын күрә бел. Менә булырсың кеше.

— Ярый, Борис, синең сүзнең ахыры күренми. Без үзебезчә тәзибез, сезнекечә түгел.

— Кем ул «сезнекечә»?

— Ну, тәртипле кешеләр, джентельменнарча...

— Көлке түгел.

— Ярый, бетердек. Барыбер мин үз сүземдә калам. Бетон тауны...

Шул вакыт телефон шалтырап, Фәез Бориска трубканы алырга ымлады:

— Тыңлыйм. Әйе. Насыйбуллин? Монда. Пожалуйста.

Фәез трубканы алгач та үз колагына үзе ышанмыйча шаккатып торды. Ләкин бу сүзләр чын иде.

— Тимерчелектә... түшәмнән... Пичугин егылып төшкән...

Фәез зиһене таралып куярга оныткан трубканы өстәлдән Борис алып куйды:

— Нәрсә бар?

— Җиде метр биеклектән егылып төшкән,— Фәез бу сүзләрне көчкә генә җыеп әйтә алды.

— Батюшки! — Ләкин Борис, ни өчендер, кайгырыр урында елмайды:

Елмаю — яктылык, елмаю — күңел яхшылыгы, дибез. Барыбыз да шуңа күнеккән инде — хәзер гадәт буенча шулай уйлыйбыз, шигырьләр язабыз, җырлар җырлыйбыз. Дөньяга исеме кешелеклелек, дуслык җырчысы буларак таралган Сент-Экзюпери да җир йөзендәге барлык кешеләрне бер-берсенә елмаерга, ешрак елмаерга чакырган бит. Елмаю — иминлек, тынычлык вәгъдә итә.

Әмма елмаюларның төрлесе була.

Ачы һәм явыз мәгънәле елмаюлар да була. Берәү сине рәнҗетә дә, син җавап кайтарыйм дип газапланганда, ул сиңа югарыдан карап, көчсезлегеңне күреп, мәсхәрәле елмая... Яхшылык билгесеме шул? Елмаю бит! Кемдер бәхәсләшеп, отыла, ялгыша һәм авыр хәлгә кала. Кемдер, үзенең хаклы булып чыгуыннан тантана итеп, авыр хәлгә калган иптәшенә карап елмая: күр инде менә минем өстенлегемне! — ди. Яктылык билгесеме бу?

Борис та елмайды. Ник? Ник елмайды ул?

Кешеләр, җир йөзендәге барлык кешеләр, үз арагызда калыккан һәм калкырга ихтимал булган боз тауларын эретер яки бөтенләй булдырмас өчен, бер-берегезгә ешрак елмаегыз, ләкин чынлап, яхшылык, йомшаклык, җылылык, иминлек вәгъдә итеп елмаегыз. Югыйсә, Фәез белән Борис арасында кинәт калыккан хәерсез бетон тау кебек, боз таулары гына түгел, араларда бетон таулар калкып чыгуы ихтимал.

Борис елмайды... Фәез моның мәгънәсен төшенә, билгеле. Төшенә...

Проектка үзгәреш керткән кеше шул үзгәреш аркасында килеп чыккан авария өчен җаваплы. Үзгәреш керттеңме, гонорар белән бергә, җаваплылык та аласың диган сүз. Тимерчелек түшәмен беркетүгә Фәез керткән яңалыкны Борис белә, кат-кат сөйләшкәннәре бар. Һәм менә сиңа үзгәреш, менә сиңа вакыйга — Пичугин түшәмнән егылып төшкән... Фәезне күңелле хәл көтми торгандыр. Нәрсә көтә? Ихтимал, Борис монысын да беләдер — югыйсә ник елмая дисең?

Фәез бүлмәдән чыгып киткәндә аркасына шул елмаюның ук төсле кадалуын сизде... Мондый да хурлыклы авырту, мондый да аңлаешсыз бәланең бәлки аның гомерендә беренче тапкыр килеп чыгуыдыр. Авырту — аркада һәм күкрәктә.

Аркада — Борис елмаюы.

Күкрәктә — Пичугин җәрәхәте...

* * *

Тимерчелеккә йөгереп килсә, Пичугинны ашыгыч ярдәм белән алып киткәннәр. Шулай да Фәез туп-туры ул егылган төшкә килде. Пичугинның үзен алып китсәләр дә, кайгысы калган — кешеләр, авыз ачып сүз әйтергә көч таба алмыйча, бер-берсенә авыр караш белән карыйлар. Фәез дә егылган җирне бик тиз күреп алды — идәндә кан...

Бетон идәндәге бу эзләр тиз генә бетәр дисезме? Бәлки монда бетәр... Ә Фәез вөҗданында бетмәс. Ул үзен шул канга буялгандай хис итте...

Тимерчелектән чыккач, Фәез больницага ашыкты, ләкин анда да Пичугинны күрә алмады — дөресрәге, күрсәтергә мөмкин түгел, диделәр. Кешегә күрсәтә алмаслык дәрәҗәдә теткәләндеме икәнни? «Исән калырмы?» дигәч тә өметләнерлек сүз әйтә алмадылар.

Пичугинны болай яхшы ук белсә дә, Фәезгә аның белән якыннан аралашырга туры килгәне юк — барлык очрашу, сөйләшүләре — эш буенча гына. Ләкин шул көрешүләрдә дә әйбәт, җылы тәэсирләр калган, һәм гаять дәрәҗәдә тыйнак, саф күңелле шул кешенең югалуы әйтеп бетергесез ачы хәсрәт булыр иде. Шулай ук харап булдымы икәнни?

Фәезгә, ихтимал, рәхмәт әйтмәсләр, җәза бирү кирәк дияргә дә күп алмаслар — кыен форсаттан файдаланып калырга тырышучылар да табылыр. Тырышсалар, тырышсыннар иде әле, кирәк булса, җавабын да бирер. Фәез түзә белә һәм түзәр. Ә менә кешесе кызганыч... Фәезгә бирелгән җәза исәбенә ана җиңеллек килермени? Ул тереләрме шуннан?

Тәүлек чамасы үткәч, Пичугин аңына килгән, диделәр. Ләкин янына хатыныннан башка беркемне дә кертмиләр икән әле. Фәезгә атна-ун көн узгач кына керергә туры килде.

Пичугин мескенкәй! Бөтенләй кешегә ошамаган — бөтен гәүдәсен гипска катырып куйганнар да селкенә дә алмыйча ята, бөтен җире ап-ак марля белән биләнгән. Бары тик күзләре, акыллы күк күзләре генә елтырап күренә.

— Исәнме, Коля!

Пичугин күзләрен генә йомгалады — ни дигән сүзедер, теләсәң ничек аңла — карашыннан үпкәләү, ачулану галәмәте дә, кичерү, аңлау билгесе дә күрерлек түгел. Дөресрәге, андый нәрсәләрне уйларлык хәле дә юктыр әле аның — бөтен көче авыртуны җиңәргә китеп бетә торгандыр.

Пичугинга карап, башыннан шундый уйлар узганнан соң гына, Фәез бүлмәдә үзе генә түгеллеген, монда бер хатын-кыз һәм... Филиновның да барлыгын абайлады. Фәез хатынга карады — аның йөзендә курку, каушау билгеләре күренми инде — тыныч моңсулык. Кайгы башта гына каты бәрелә, никадәр нык сугылмасын, соңыннан авырту барыбер кими — тик шеш сулкылдавы гына кала.

— Сез Пичугинның хатынымы?
— Әйе.
— Сөйләшә алганы юкмы әле?
— Юк шул әле.
— Ә врачлар нәрсә ди?
— Алар нәрсә әйтсен инде.
— Кай төшләре имгәнгән икән?
— Ике аягы, ике кулы.
— Бүтән җирләре таза-саумы?

Филинов сүзгә кушылды:

— Житмәгәнме шулар?

Хатын да, Фәез дә аңа карап кына куйдылар.

— Сезгә билгелеме икән — аның егылуында эз генә минем катнаш та бар бугай бит.

— Әйттеләр.

Хатын үзе дә сизмәстән Бориска карады һәм Фәез шуннан барысын да аңлады.

Өлгергән икән. Халык житез.

Борис башын читкә борды.

— Судка бирергә кушамы? — дип сорады Фәез хатыннан.

Сизелер-сизелмәс кенә баш кагу — җавап шул.

«Боря, син шулкадәр үк түбән төшә аласыңмы? Әйтүең хак булса, Пичугин белән бергә син дә егылгансың, мәтәлгәнсең бит!»

Кара, фантазия ничек эшли, ә? Нинди кискен нәтиҗә чыкты да куйды! Бәлки Борисның мондый уй башына да кермәгәндер, ул бөтенләй гөнаһсыздыр? Менә бит елмаю, тегө зәһәр елмаю — араларны хәерсез бетон тау белән аерды да куйды. Ах, шул елмаю! Хәтергә килде исә, Бориска карата теләсә нинди начар уйны фараз кыларга мәҗбүр итә. Хәзер теләсәң-теләмәсәң дә элекке Борис юк, моңарчы искә дә кермәгән усаллык эшләргә сәләтле Борис кына бар һәм ул усаллыкның нәрсәдән гыйбарәт икәнен белергә тырышу хисе бар.

Пичугин белән саубуллашканда Фәез аның маңгаендагы марлясын сыйпады:

— Ярый, дустым, ачуланма, аңласаң, миндә гаеп юк. Ачуланмыйсыңмы?

Юк. Пичугин телгә килмәде — бары тик тынычсыз бер төстә керфекләрен каккалап, күзләрен генә йомды.

— Син тереләчәксең, элекке кебек сау-сәламәт булырсың. Хуш.

Пичугинның күзләренә хатыны да, Филинов та иелә төшеп карадылар.

— Хуш.

— Кичке якта тагын килермен.

Авыр уйлар һәм шикләр белән өчесе өч якка юл тотты.

Пичугинның хатыны начар кешегә охшамаган — тегенди-мондый гауга кузгатмас. Ләкин Борис, якын дус... Бозылды егет, бозылды, хәзер аның нишләрен дә белеп булмый. Нәрсә уйлый ул, нишләргә җыена?

Фәез моны соңыннан бик нык лап аңлады, әлбәттә, ләкин ул чакта баш җитәрлек нәрсә түгел иде шул әле.

Шлюзда бетон тау юк инде. Күп җирләрен җимертеп, яңа бетон белән сипләгәч, ул гадәти блокка әверелде. Иң кызыгы: бетон катуда аның сыйфатын китереп җиткермәгән завод гаепле дип акт төзелгән һәм «махсус фикер» баш идарәгә җиткерелгән иде. Икенче төрле әйткәндә, айлык задание өзелә язуда Борис «гаепсез» булып чыкты. Әмма Фәез белән аның арасында бетон тау, күзгә күренми торган тау, барыбер калды.

Гадәттән тыш хәлнең җиңел генә төзәлүенә Лебедев кодрәте читтә калмаганны чамаларга мөмкин иде. Лазарев унбиш көнгә Мәскәүгә китү сәбәпле, бу көннәрдә төзелеш тулысынча Лебедев кулында иде. Ләкин бу ярдәмнең нәрсә исәбенә эшләнгәнен Фәез ул чакта башына китерә алмый иде. Чөнки ике кеше арасында гына булган сүзсез килешү аның өчен сер иде.

Фәезнең үтәми калсаң участок белән саубуллашуга китерәчәк бурычын ничек үтәп чыгарга дип уйланып йөргәндә, Бориска кызыклы уй килде: «Лебедев менә үз итә кебек. Бәлки ул ярдәм дә итә алыр? Бүтән чара юк, бары тик аның белән генә уртак тел табарга мөмкин — арада иң кешелекле, кешечә яшәргә тырышучыларны аңларлык бер ул гына дисәң дә зур ялгыш булмас».

Башына шул уй килгәч, Борисның эченә чак кына җылы да кергәндәй тоелды һәм ул, эш сәгате беткәнне дә көтмичә, Лебедев бүлмәсенә килде. Бәхеткә каршы, баш инженер янында беркем дә юк иде.

— Исәнмесез, Казимир Романович.

— Исәнме. Әйбәт, утыр.

Борис утырды, үзе дә сизмәстән авыр сулап куйды һәм шактый ара сүз әйтә алмыйча интеккәч, тегесе үзе сорады:

— Нәрсә бар?

— Бар шул. Хәлләр авыр.

— Пичугин егылган. Больницада ята, диделәр. Шулмы?

— Шул да, бүтәне дә бар.

— Авариянең сәбәбе нәрсә?

— Да, безнең Фәез... сызымнарга үзгәреш керткән иде. Шуның аркасында.

— Егетләр исән — икесе дә.

— Әйе шул. Тик Фәез үзе мине бер дә кызганмый башлады.

— Ничек?

Борис шунда үз хәлен сөйләп бирде һәм, кыенлык белән булса да, үтенечен аңлатты:

— Өстәмә бетон китертергә кирәк. Блокны ике көн эчендә тапшырырга... Үтәмичә калсам, ул мине эштән алу хакында сүз башларга вәгъдә итте.

— Матур вәгъдә түгел икән.

— Ямьсезгәрәк китте шул. Минем сезгә килеп егылу инде, Казимир Романович. Бәлки сез...

— Бетонның маркасы туры килмәү хакында акт төзегез. Завод каршы килмәс дип уйлыйм.

Борис җанланып китте:

— Әйбәт булыр иде, ә! Гомер онытмас идем.

— Ярар, мин сөйләшермен. Тагын ниләр бар?

Шактый озак сөйләштеләр. Ахырда сүз, гомумән, тресттагы вакыйгалар һәм хәл-əхвәлләргә күчте.

— Кешечә, нормаль яшәгән кешегә бездә әллә ничек — аюга караган кебек карыйлар. Кемдер, нәрсәсендер корбан итәргә тиеш. Ә бу «нәрсәдер» күпчелек очракта иң матур елларны әрәм иту, сәламәтлекне, димәк, күпмедер гомерне шушы суга, Камага салырга мәҗбүр итүгә әверелә. Кемнән башлана торгандыр бу, әйтүе кыен, әмма, минемчә, рәхимсез, шәфкатьсез практика бу.

— Сез бу практиканың барлыгын нинди конкрет мисалларда күрәсез?

Бориска озак уйланырга туры килмәде, ул инде бөтен нәрсәне ачыклаган һәм сүзе дә әзер иде:

— Менә шушы кышкы челләдә күпме кеше бронвахтада тора — хәтта гаиләле кешеләр, яшь балалары белән. Минемчә, анда яшәп караган кешегә ким дигәндә өч катлы чир әзер.

— Әһә...

— Күпме кеше авылдан йөреп эшли, күпмесе шәһәрдә кеше ишек төбендә, квартирсыз интегә. Шул ук практика хикмәте бу — кешедән корбан таләп итүне нормаль хәл дип карау... Шундый караш. Кешеләр энтузиазмыннан кешелексез файдалану. Эшкә алалар, ә яшәргә урын бирмиләр. Хәзер без аларга вакытлыча булса да түбә ясарга — кешеләр урамда калмасын өчен, времянкалар төзергә тиеш бит. Ләкин юк. Кешеләр шулай да түзә, кешеләр нык, кешеләр герой. Ә бервакыт төзелеш житәкчелеген тиргәргә тотынырлар — соң булыр.

— Соң булмасын өчен, без нәрсә дә булса эшли алабызмы соң?

— Нишлисең, управляющий үзе үк шундый караштa торгач.

— Управляющий безнең кебек үк кеше, аңа да әйтергә мөмкин, аңлатырга.

— Куды чыгарды, вәссәлам.

— Соң аның урынын белеп әйтергә мөмкин.

— Кайда?

— Җыелышлар күп була бит бездә. Шунда чыгыш ясарга мөмкин.

— Мөмкин шул.
— Әйбәтләп, хәзер миңа сөйләгән кебек дәлилләп сөйләгез...
— Тырышырга мөмкин,— Лебедев сүзсез торган арада Борис тагын өстәде:— Шул ук Пичугин вакыйгасы да кешелексезлек мисалы бит инде.
— Ихтимал.
— Ихтимал түгел, ә точно.
— Ярый, белгән барлык мисалларыңны китерерсең. Хәзер моның өчен бик җайлы чак. Горком секретаре иптәш Шакировның управляющийга карашы бик үк шәп түгел вакыт. Үзең беләсең, Шакировны обком секретаре алдында хур иткән Насыйбуллинны ул идарә начальнигы итеп күтәрде. Гомумән, буйсынмау галәмәтләре бар. Аларга хаталарын аңларга ярдәм итәргә кирәк. Башта начарлык эшләгәндәй тоелсак та, соңыннан әйбәтлек булып чыгар бу. Җитәкчелек итүдәге кешелексез юнәлешне туктату, җиңү булып чыгар. Әлбәттә, җиңә алсак.
— Бездән калмас, Казимир Романович, югалтыр нәрсә юк, без ул хәтле зур начальник түгел бит. Шушыннан да түбән төшерә алмаслар.
— Дөреслек өчен көрәшү — гомумән һәр рәтле кешенең вөҗдан эше инде ул.
— Булды, сөйләштек,— дип, Борис урыныннан кузгалды һәм сораулы караш белән тукталып калды.
— Ә мин заводка шалтыратырмын, өстәмә бетонны да китерерләр,— диде баш инженер, аны тынычландырып.
— Рәхмәт.
Фәез белергә теләгән һәм ул вакытта сизенүдән узмаган, ләкин шик рәвешендә борчыган җавапсыз сорау, мөгаен, менә шушы сөйләшү булгандыр. Ләкин соңыннан да ул бу килешүне үзенә каршы эшләнгән эш дип кабул итмәде. Ике кешенең бертөсле уйлавы мөмкин түгелмени? Үз фикерләрен хәтта җыелышта да әйтергә курыкмаган кешене үзенчә фикерләгән өчен генә ничек гаеплисең?
Фәез каршылыкны законсыл дип исәпли, ләкин бирелергә, үзен рәнҗетергә һич уйламый. Ул ахыр чиккәчә үз сүзендә калачак — чөнки аның да үзенчә фикер йөртергә хакы бар.
Берничә көннән соң Бориска әйткән боерыгы үтәлгәч — бетон салынгач, Фәезнең ачуы кимегәндәй тоелды. Ләкин Борис белән аралар һаман ераклаша һәм суына бара. Рәсми сөйләшүдән ары китеш юк. Нәрсәгә, кая барып тоташыр бу киеренкелек — әйтүе кыен.

* * *

Кышкы аяз чиллә.
Чыпчык очса, тыны куырыла да җиргә таш шикелле егылып төшә һәм, күтәреп алмасаң, канатларын бүтән җилпи дә алмый. Кемнәрдер коткарып калган чыпчыклар терелеп яңа иркен кибетләрдә очынып йөри — анда мескеннәргә җылы, рәхәт...
Кышкы аяз чиллә көннәрендә, гидрострой поселогының нәкъ уртасында, беркем дә күрми калмаслык түрендә, буе ким дигәндә ике йөз метрлы агач барак калкып чыкты. Лебедев аның нигезен кешеләргә яхшылык итү дип исемләнгән, ышанычлы, сыналган ташлардан салдырды, стеналарын (хуш исләр аңкып торган өр-яңа нарат такталардан гына түгел) шушы салкын чиллә квартирсыз интеккән кешеләрнең бу эшне яклаячакларына исәпләнгән өметләреннән куйдырды, ә түбәсен...
Ә түбәсен яптырып өлгермәде — срогыннан иртәрәк Мәскәүдән Лазарев кайтып төште.

Лазарев Мәскәүдән кайтып төшкәч сәгать тә үтмәгәндер, яшь нарат-лык янында төзелеп килгән йортлар һәм мәйданнар ягыннан берегә таба ике бульдозер килә башлады. Бульдозерларның берсенә Рәшит утырган иде.

Агач өй ап-ак, өр-яңа, әйтерсең түбәсе зәп-зәңгәр күк гөмбәзе белән ябылган. Кай арада килеп өлгергәннәрдер, әллә ничаклы халык, дөбер-шатыр китереп, шул өйне сүтәргә дә кереште. Арттырыбрак әйтсәк, һәр кешегә берәр тактадан ары тимәгәндер. Кырмыскалар төсле өстерәделәр дә киттеләр. Өр-яңа өй, бөтенләй булмагандай, күз алдында юкка чыкты. Ә зәңгәр түбә жимерелмәде...

Фәезнең үз кайгылары житәрлек булганга, бу сәер күренешне ул күрми калды. Ә Борис шунда иде. Тиз арада шушы йортка күчәргә тиешле кешеләр дә, шул исәптән Кәрам да, сәер хәлне манзара кылып тора иде. Аларның ник авыз ерып кына торуын, гаугa куптармавын аңламаган Борис Кәрамнан сорый куйды:

— Сезгә буласы фатир иде ич, ни карап тордыгыз?

Кәрам кул гына селтәде:

— Әй, мин инде кооперативка кердем. Жилстрой исәбенә үзебез салабыз, эштән соң йөреп. Таш йорт.

Рәшит узып барышлый гына кычкырды:

— Миңа нәрсә, куштылар миңа...

Шуннан соң Борис бүтәннәр белән сөйләшеп тә тормады. Туп-туры үз өстенә ташланган бульдозердан куркып, кинәт читкә тайпылды. Ике яктан үкереп килгән ике бульдозер, ватык-сытык агачларны бер читкә эшереп өйгәч, жирне актара башладылар. Нәкъ шушы урында яңа кирпечләрдән салынган, бер кварталга диярлек сузылган йорт калкып, яп-якты тәрәзәләре белән балкып, мәктәп утырачак икән.

Кышкы аяз чиллә...

## ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

Киңәшмә шактый киң булып чыкты — шәһәр комитетының конференц-залы шыгрым тулы иде. Бу юлы, киресенчә, алгы урыннар алынып беткәнгә, Фәезгә арткы рәтләрнең берсенә, читтәге урындыкка утырырга туры килде. Танышлар байтак. Күбесе белән елмаеп, кайберсе белән баш кагып кына исәнләште. Ерак та түгел Борис утыра. Фәез аның белән дә исәнләшмәкче иде, тегесе ни өчендер күрмәмешкә салышып, башын читкә борды. Жүләр, күз карашының иң нечкә бер чаткысы гына кагылып үтсә дә, ниятеннең ниндиләгeн сизә торган кеше Фәез. Юкка тырышасың, син миннән бер нәрсә дә яшерә алмыйсың, иптәш, уйлама. Күңелеңдә начар уй бар һәм шуны миңа сиздермәскә тырышасың син, шуңа күрә читләшү хәерлерәк дисең. Үзеңә кара, синең белән без исәнләшмәгәннән күк гөмбәзе жимерелмәс. Кама агуында булыр.

Ниһаять, зал каршында сәхнәдәге өстәл янына алгы ишектән узган шәһәр комитеты секретаре Шакиров күренде. Аның артыннан килүче Фәезгә таныш булмаган берничә кеше арасында Анатолий Самойлович та бар иде. Ул да президиумда.

Секретарь торып басуга залдагы гөжләү тынды һәм көр тавыш ишетелде. Иң әүвәл Шакиров төзелешнең бөтен ил күләмендә зур әһәмиятле удар төзелеш икәнен, шуңа күрә партия һәм хөкүмәтебезнең аңа зур игътибар бирүләрен, барлык төзү предприятиеләренә, шәһәр партия оешмасы һәм район советы башкарма комитетына изге бурыч йөкләнгән булуын, аны үтәү өчен барлык көчләрнең бергә тупланган булырга тиешлеген әйтте. Инде ике елдан артык вакыт эчендә кайбер тенденцияләр барлыкка килүен, шуларның унайларына тагын да киңрәк юл урам ачып, тискәреләренә юлны бикләү чаралары күрелергә тиешлеген.

мена бүгенге җыелышның шул хакта киңәшер өчен җыелганлыгын үзенә хас, конкрет һәм рәсми лексика белән тасвирлагач, җыелышны ачык дип игълан итте дә төзелешнең гомуми торышы белән таныштыру өчен трест управляющие Анатолий Самойлович Лазаревка сүз бирде.

Управляющийның төп фикере: специальләштерелгән идарәләр төзү исәбенә эш күләмен арттыру. Генераль линия — промышленность базалары булдыру, гидростанциянең үз корылмаларын эшләү, кешеләргә капиталь йортлар салу. Шушы курсның барышына зыян китерә торган барлык эшләрдән баш тарту. Бу юнәлешне төзелештәге барлык звенолар яклый һәм, әгәр бүгенге көндә кайбер уңышларыбыз бар икән, без аларны үз позициябезнең дөрес сайлануы аркасында ирешелгән уңышлар дип карыйбыз. Кимчелекләр дә бар, әлбәттә, мондый зур төзелештә алардан тулысынча котылу, бәлки, мөмкин дә булмас. Ләкин котылырга тырышырга кирәк. Бүгенге сөйләшү шуңа булышыр, безгә тәнкыйть фикерләре әйтелер, тәнкыйть үзебез күрмәгән кимчелекләрне күрергә ярдәм итәр.

Чыгыш ясаучылар күп булды — алар, мөгаен, Анатолий Самойлович өметен аклаганнардыр, туры мәгънәсендә файдалы киңәшләр әйткәннәрдер: чөнки Фәез күреп утыра — Лазаревның кәефе тагы да күтәрелә төште шикелле. Берничә минут кына элек ул, бигрәк тә үз чыгышына хәтле, ничектер, артык дәрәҗәдә кырыс кыяфәт белән кул астындагы язуларына карап кына утыра иде. Ә хәзер янындагы кешеләр белән сөйләшә, елмая ук башлады. Гик Лебедевка сүз бирелгәч һәм тегесе сөйли башлагач, елмаюы әкренләп сүрелә-сүрелә бөтенләй юкка чыкты, чырае тагын салкынлык белән капланды. Ләкин анда курку, ачулану галәмәте күренми һәм аның шулай үзен кулда тота алуы Фәезгә ошый. Югыйсә, Лазарев кискен холыклы кеше — кирәкмәгән чакта дөрләп кабынуы бар. Болай тыныч утыра ала икән, ул үзенең хаклыгына, җиңәренә ышана, димәк.

Лебедев үз сүзләренең кемгә кагылганын яхшы чамалый һәм шуңа күрә үзе дә, тыштан сиздермәскә тырышса да, эчтән шактый авыр кичерә төсле. Аның тавышы кинәт-кинәт калтырап куя.

Чыгышының бисмилласы секретарь сүзләреннән аерылмалы диярлек: «Иптәш Шакиров бик дөрес күрсәтеп үткәнчә...» Гадәти, таныш сүзләр — аларга беркемнең дә исе китмәде, юхалану дип тә кабул итмәде.

— Кимчелекләр бар, әлбәттә, һәм бик җитди. Мин бу сүзләрне бәлки монда сөйләмәскә дә тиешмендер. Ләкин, коммунист буларак, күңелдәген әйтми кала алмыйм. Иптәш Лазарев, безнең хөрмәтле управляющиебыз, үзенең чыгышында безнең төзелештә урнашкан юнәлешләрне дөрес күрсәтте. Ул бу юнәлешләрнең берсен, аерып алып, генераль линия дип атады һәм моның белән дә килешергә мөмкин, чөнки безнең төп максат — гидростанция. Бу — актык чик, соңгы җиңү. Әмма без шул җиңүгә карата бәяләрдә бераз гына аерылабыз. Иптәш Лазарев өчен гидростанция — төп максат кына түгел, үзмаксат та. Ә чынлыкта исә һич алай түгел: безнең максатыбыз — үзебезнең бәхетебезне матур итеп кору, киңрәк әйтсәк, халкыбыз тормышын тагын да җиңеләйтү, яхшырту. Моны безнең баш идарәдә мещанлыкның бер төре дип тә аңлаучылар бар, ләкин мин курыкмыйм, чөнки безнең программабызда шулай язылган, чөнки коммунизм — кешеләрнең үзләре теләгәнчә яхшы яшәве дигән сүз, ә карап сокланыр өчен төзелгән сәнгать әсәре түгел ул. Без бүгенге тормышны да дөнья күләмендә үз җиңүләребез белән горурланыр өчен түгел, ә кешеләр максимум әйбәт яшәсеннәр өчен төзедек. Без дөньяга җай килгән саен «Яшәсен, яшәсен!» дип кычкыру өчен түгел, ә яшәр өчен, чын мәгънәсендә яшәр өчен, мөмкин булган барлык рәхәтләрне күрер өчен — һәм материаль, һәм рухи байлыкларны үзебезгә хезмәт иттерер өчен килдек. Димәк, без, киләчәккә хезмәт итү

белән бергә, бүгенгә көндә үзебез дә яшибез яки яшәргә тиешбез. Әмма бу вакытта, безнең авыз тутырып «яшибез» диярга мөмкинлегебез юк әле, иптәшләр. Безнең төзелештә, безнең шәһәрдә, әйтергә кирәк, кешегә, халыкка, үзебезгә яшәү шартлары тудырырга тырышу — гаеп эш, гөнаһлы омтылыш кебегрәк кабул ителә. Искәрмә буларак, шунысын әйтим, хәлбуки, партия һәм хөкүмәт безгә һич тә алай кушмый. Партия һәм хөкүмәт элек-электән безнең илдә кешеләр гомере иң кыйммәтле капитал дип өйрәтә килде. Безнең трестта эшчеләрнең көнкүрешен тәэмин итү буенча управляющийның махсус урынбасары штат буенча куелган, барлык инстанцияләрдә расланган, яклангаи икән, бу факт үзе үк безнең нәкъ менә яшәү шартлары дигән нәрсәнең кыланыр, тәти булып күренер өчен, ялган авторитет яулап алырга тырышу өчен генә түгеллеге, ә чынлап кайгырту кирәклеге хакында сөйли торгандыр, чөнки шуның өчен махсус акча тотыла. Хәлбуки, без управляющий урынбасарының бу хакта тавышын ишетмибез, эше турында әйтәсе дә юк инде. Ямьсез булып күренәсе килми иптәшләрнең. Шуңа күрә безгә кала. Хәерле булсын, без ямьсез күреник.

Минем фикерләрем баш идарәдә күптән билгеле инде. Минем ничек фикер йөртүем беркемгә дә сер түгел, чөнки мин аларны җай чыккан саен әйтә киләм. Бу иптәш Лазарев өчен дә яңалык түгел, ул да аларны яхшы белә, ләкин ул таләпләрне үтәү өчен артык зур көч куймый. Әлеге дә баягы, төп бурычны, төп максатны дөрес аңлап бетермәүдән килә бу. Әлбәттә, аның үз мәнфәгатьләре биеклегеннән генә караучы каты күңелле кеше булганы аркасында гына түгел.

Иптәш Лазарев төзелештәге төп принципларны барлык звенолар яклый дип белдерде. Дөрес түгел бу, иптәшләр, ясалма иминлек, үзебезне тынычландыру өчен генә әйтелгән сүзләр болар. Юк, кайбер мәсьәләләр буенча без барыбыз да, кызганычка каршы, бертөсле уйламыйбыз әле. Киресенчә, безнең арада җитди каршылыклар бар. Хәзерге вакытта кайбер нәрсәләр белән килешмәүче кеше, мәсәлән, менә мин фәкыйрегез. Мин моны сездән яшерергә тиеш тапмыйм.

Мин бер тамыр мәсьәләдә иптәш Лазарев белән килешә алмыйм — эшчеләрнең хәзерге яшәү шартлары белән. Курыкмыйча, үзебездә җаваплылык хисе тоеп әйтик: мөмкин булган дәрәҗәдән чагыштыргысыз начар яшиләр безнең кешеләребез. Аларның яртысы диярлек частный квартирларда, аерым почмакларда, вагоннарда, бронвахталарда тора. Хәтта гаиләле кешеләр дә шундый хәлдә. Безнең киләчәгебез шуларда туңа һәм алгы көннәргә төрле авырулар белән китәргә әзерләнә. Көне җиткәч, алар безне тиргәрләр һәм хаклы булырлар. Мин мондый хәлнең килеп чыгачагын башта ук сиздем һәм башта ук, иң беренче бурыч итеп, кадрлар бүлегенә керүче барлык гаиләләргә ачкыч тоттырып чыгарырлык шартлар тудырырга мөмкинлек барын әйттем. Моның өчен безгә бик гади бер нәрсә эшләргә — ягъни тиз арада времянкалар салырга кирәк иде. Ләкин иптәш Лазарев күпмедер вакыт һәм акча кызганып, времянкаларга катгый каршы чыгып зур йортлар гына сала икән, инде гомумән капиталь йортлар төзегәндә ашыгуның мәкерле юлдаш булуы көн кебек ачык. Ашык-пошык төзүдән әнә нинди поселок калыкты. Иптәш Насыйбуллин әйткәнчә (ә ул хаклы бу мәсьәләдә, мин аны яклыйм), поселок түгел, адәм көлкесе. Бәхәстә кемнең җиңәчәген күрсәтә торган аяныч дәлилләр шулай берәм-берәм каршыбызга килеп баса торачак. Шунысы гаҗәп, күзгә бәрелеп торган шул нәтиҗәләрдән оялучы юк. Менә мин тагын кабатларга мәҗбүрмен: мин, зур йортлар салу белән бергә, времянкалар салуны да тизләтергә дип тәкъдим итеп килдем һәм хәзер дә тәкъдим итәм. Тәкъдим генә түгел, таләп итәм — үзем өчен түгел. Без үзебез барыбыз да газлы һәм ванналы квартирларда яшибез. Бронвахталарда, салкын өйләрдә, кешеләр ишек төбендә яшәүчеләр, авылларда торып көн саен җиде-сигез чакрым

җирдән килеп эшләүчеләр исеменнән әйтәм: без кешеләр хәлен речьләрдә генә түгел, эштә, практикада кайгыртырга тиешбез».

Фәез өчен кызыксыз тоелган берничә чыгыштан соң Филиновка сүз бирделәр.

«Кара, миңа берни әйтмәде, бер идарә кешесе буларак әйтелергә тиеш фикерләр уртаклашылмады. Шәхси чыгыш микәнни? Нәрсә сөйләргә җыена икән?» — Борис залда ашыга-ашыга атлаганда һәм трибунага килгән арада Фәезнең күңеленнән шундый уйлар узды.

Борис дулкынлана иде: битләре кызарган, күзләре гадәттәгедән ныграк ялтырый — авыру кеше күзләре төслерәк. Күңелендә шундыйрак хисләрдер инде.

Башта ул Лебедев сүзләрен җөпләде. «Мин шул чыгышта әйтелгән положениеләргә кайбер мисаллар китерү өчен сүз алдым»,— диде һәм мисалларга күчте.

«Безнең идарәдә андый фактлар аеруча күп. Әйтик, менә моннан ике генә көн элек, тимерчелек түшәмен төзәткәндә бер кешебез җиде метр биеклектән егылып төште. Мин икенче участок начальнигы Пичугин Николайны күздә тотам. Аның егылуында бердәнбер кеше, безнең идарә начальнигы иптәш... иптәш Насыйбуллин гаепле. Чөнки ул баш инженер чагында түшәмне ныгыту принцибына үзгәреш керткән иде. Димәк, аның рационализаторлык тәкъдиме кертәсе килгән. Тик нәрсә килеп чыга, аннан соң кем нинди бәлагә дучар ителергә мөмкин — әлбәттә, ул хакта уйлау юк. Моны кешелексезлек галәмәте дип аңларга кирәк, бүтән берни дә түгел. Ә шуңа, кешелексезлек фактына бәя бирергә теләк кенә булса да булырга тиеш бит инде бездә. Законлы теләк бу. Ләкин, мин әйтәм, безнең идарәдә, хәтта баш идарәнең куркынычсызлык техникасы белән бәйле бүлекләрендә дә бу вакыйгага бернинди реакция күзгатмады. Иптәш Насыйбуллин белән ул темага сөйләшкән кеше юк әле һәм күренми дә. Ә инструкция шулай өйрәтә: проектка син керткән үзгәреш аркасында авария килеп чыга икән, акча ала белгән кебек, җавабын да бирә бел. Мондый мисалларны безнең идарәдә шактый күп табарга мөмкин булыр иде. Ләкин мин, сезнең вакытыгызны алмас өчен, әйтелгән белән чикләнәм. Теләгем шул гына: иптәш Лебедев әйткәнчә, безнең трестта чын эш обстановкасы тудыру өчен кайбер мәсьәләләр хакында югары җитәкчелек уйланса яхшы булыр иде, дигән фикер әйтү. Бөтенесе бер нәрсәгә — кешелексезлек тенденциясенә кайтып кала. Җитәкче итеп шундыйрак кешеләрне сайлау инде практикага әверелде. Төзелештә принципиаль каршылыклы ике тенденция яши. Кайсыбыз хаклы — шуны ачыкларга вакыт җитте, минемчә.»

Трибунадан залга төшеп барган вакытта өстәл янында тукталып, ораторыбыз Шакировка:

— Менә шушының аркасында кеше һәлак булды,— дип, аңа калай деталь сузды.

Кәтүк сыман бу нәрсәнең ни икәнен тиз танып алды Фәез — ул ясаган сәдәпләр, фиксатор... Менә нинди җинаять билгесе тапкан ул, нинди зур каптыргыч тапкан!

Фәез сүз сорап өлгергәнче, тәнәфес игълан иттеләр. Гомуми хәрәкәткә буйсынып, Фәез дә урыныннан торды һәм фойега чыкты. Шунда ул, үзе дә көтмәгәндә-теләмәгәндә, Филиновка тап булды. Күзләре очрашкач, Борис тиз генә узып китмәкче иде, тик Фәез юри рәсми тон белән (яхшымы-яманмы — ул начальник бит әле!) эндәште:

— Филинов!

Тегесе, билгеле, туктарга мәҗбүр:

— Нәрсә бар? — Филиновның иреннәре кысылды, битләре агарынды.

— Әйтәсе сүзем бар.

— Нинди сүз икән,— дип, Борис каушый-каушый Фәезгә якынлашты.

— Син нәрсә дип халыкны алдыйсың? — Фәезнең тавышы житәрлек кадәр генә коры, ләкин житди иде.

— Нәрсә? Чын түгелме әллә? Мин Пичугин янында тагын булдым. Тагын аның жүйгән — бик начар хәл.

Фәез нәкъ кирәк сүзне барлык йөрәк әрнүләрен жинеп әйтә алды:

— Пичугин дисеңме? Ә син үзең? Синең хәл аныкыннан да мөшкел бит — син аңардан да җайсызрак егылдың... һәм гариплəндең...

— Ничек гариплəндем?

— Мондый да каты егылган кешене минем беренче тапкыр күрүем.

— Син әйтерсең инде.

— Тик белеп тор, сине барыбер минем урынга куймаячаклар.

— Рәхмәт. Китәргә мөмкинме?

Аның мыскыллап сораган рөхсәтен Фәез юри чынга әйләндерде:

— Мөмкин.

Борис киткәч, Фәез борчылып уйланырга кереште. «Эх, Пичугин, Пичугин! Усал кешеләр өчен нинди җайлы сылтау булып чыктың син! Эх, Пичугин, дустым, син яшәргә тиеш бит! Үзең өчен, семьяң өчен һәм, ниһаять, минем өчен. Әгәр син тиз терелмәсәң, безгә дә җиңел булмаячак».

Горкомның иң якын бер бүлмәсенә кереп, больницага шалтыратса... Пичугин чыннан да тагын һушын җуйган икән. Фәез җыелыш залына кәефе тәмам кырылган хәлдә керде. Лазарев белән киңәшеп алырга иде, соңлады — звонок булды. Утырыша башладылар.

Ораторлар сөйләгән арада, Фәез төпле бер карарга килеп: «Анатолий Самойлович, нишләргә, Филиновка җавап бирергәме?» — дигән записка җибәрде. Менә Фәезнең күзләре шул запискада. Менә өстәлгә язу килде. Секретарь аны ачты да, Лазаревның исем-фамилиясен күргәч тә, записканы ары җибәрде. Лазарев исә, тиз генә күз төшергәч, залдан Фәезгә «Әлбәттә!» дигән мәгънә белән баш какты. Димәк, Фәез чыгыш ясарга тиеш.

Президиум өстәленә шундук икенче записка китте: «Сүз сорыйм, Насыйбуллин».

Язу тагын секретарьга барып житте. Ул аны тыныч кына кыяфәт белән карап, бүтән запискалар рәтенә куйды. «Сүз бирерләрме?» Шакиров белән Лазарев икесе нәрсә хакындадыр сөйләшеп алдылар — секретарь, мөгаен, Лазаревның фикере белән кызыксынгандыр. Бу хәрәкәтләр башка ораторлар кызып-кызып сөйләгән арада булды. Начальство бәлки тыңлый-тыңлый да сөйләшә ала торгандыр, ә Фәезгә килгәндә исә, ул кем сөйләгәнгә дә игътибар итә алмады. Хәзер ул үзенең сөйләячәк фикерләрен тәртипкә китерергә тырыша иде...

— Дүртенче төзелеш идарәсе начальнигы Фәез Насыйбуллинга сүз бирелә.

Бу белдерүне Фәез аң белән түгел, ниндидер инстинкт кебегрәк нәрсә ярдәмендә генә ишетте. Хәле беркайчан да болай кыен булганы юк иде әле аның. Башында һаман Пичугин, һаман бер сорау: әгәр Пичугин үлсә? Үлмәскә тиеш, үлмәскә тиеш һәм үлмәячәк!»

Шулай дигәч, чак кына тынычлангандай тоелды. Трибунага менеп ике-өч сүз әйткәч исә каушавы бөтенләй диярлек бетте, чөнки залда утыручыларның да, президиумдагыларның да бернинди чит сүз һәм мәшәкатьләр белән булашмыйча, үзенә текәлеп тынганын күреп тору аны да фикерләрен тиз тупларга мәҗбүр итте һәм ул моның үзенә игътибар, ихтирам билгесе икәнен аңламый калмады. Димәк, шуны аклярлык итеп сөйләргә кирәк.

— Иптәшләр, монда чыгыш ясаучыларның берсе минем адреска шактый зур гаепләр ташлады — аңа җавап бирми калдырсам, сезгә бу аңлашылып житмәс иде дип уйлыйм. Шуңа күрә, чыгышымның төп өлешенә керешкәнче, кечкенә генә белешмә бирергә кирәк саныйм.

Минем, дөресен генә әйткәндә, иптәш Филиновка бик нык хәтерем калды — чөнки үзенең тәнкыйть фикерләрен әйтер өчен ул авыртып, сулкылдап торган нәрсәләргә кагылды һәм чамадан тыш саксыз оргалап ташлады. Пичугинның хәле чынлап та авыр — мина бу хакта сөйләве дә кыен. Нишлисең, әйтергә туры килә. Пичугин терелгәч, мәсьәлә тулысынча ачыкланыр, әлбәттә, ләкин хәзер үк инде хәл ул хәтле аңлашылмаслык дәрәҗәдә катлаулы түгел. Филинов Пичугинның кинәт кенә бик якын дустына әверелсә дә, үзен аның мәнфәгатен яклаучы бердәнбер шәхес итеп күрсәтергә тырышса да, моннан бернәрсә дә чыкмаячак. Чөнки Пичугинның егылуы проектка кергән үзгәреш аркасында түгел — моның ничектер саксызлык күрсәтү аркасында гына килеп чыгуы мөмкин. Бәхәсне мин кертксән үзгәреш буенча салынган түшәмгә яңадан менеп карау белән беркинди катлаулы исәпләрсез дә хәл итәргә мөмкин булачак.

— Ә син үзең менеп кара, бар! — дип кычкырды Борис.

— Кирәк икән, менеп тә карарбыз. Сезгә кушмабыз — егылырмын дип котыгыз алынмасын, иптәш Филинов. Безнең җиде метрлы биеклектән генә баш әйләнерлек түгел — шөкер! Кабатлап әйтәм — Пичугинның егылуы, кызганычка каршы, аның үз саксызлыгы аркасында гына килеп чыккан булуы мөмкин. Терелгәч, ул моны үзе әйтер, әлбәттә... Менә, иптәшләр, Филинов унбиш минутлык нотык тоткан проблема белән эш шулай тора.

...Аннары ул, гадәтенчә, Кама турында, андагы күренешләр хакында сөйләп, мондый тәкъдим кертте:

— Безнең эшкә, хезмәт житештерүчәнлегенә бераз зыян китерүе, күп кенә расходлар таләп итүе мөмкин булса да, без шундый практиканы, ил биргән законны тормышка ашырырга тиеш: күпме мәйданда урман киселә, шул күләмдә агач утыртырга. Шәһәрдә генә түгел, бөтен район күләмендә хәл итәлергә тиештер бу. Әлбәттә, су астында каласы жирләре булган бүтән район кешеләренең дә безнең үрнәккә иярәчәкләренә минем иманым камил. Ә үзебез бу изге эшкә барлык мәктәпләрне, комсомол оешмаларын жәлеп итәргә тиеш булырбыз. Ныклап тотынсак, бик матур бәйрәмгә әвереләчәк эш бу — үзебезнең күңел дә, шәһәребезнең йөзе, Каманың чырае да яктырып китәчәк, шатлыкларыбыз, жиңүләребез тагын да бөтенрәк, мәгънәлерәк булачак.

Трибунадан төшеп барганда, аны Лазарев туктатты:

— Җыелыштан соң Шакиров кабинетына керәбез.

— Ярый.

Җыелыш резолюция кабул итмәде — Шакиров чыгышы белән тәгәлләнде. Ул, әйтелгән фикерләргә бәя биргәннән соң, бурычларның һәм кимчелекләрнең әйтелмәгәннәрен үзе өстәп, Фәезне беренче дәрәҗәдә кызыксындырган нәрсәләрнең — шәһәр төзелешендәге ялгышларның төзәтелергә тиешлеген әйтте дә, моңа керешергә тиешле оешмаларны санагач, җыелышны ябык дип белдерде.

* * *

Ә кабинетка, иптәш Шакировның үзеннән тыш, горком кешеләреннән ике-өч кеше, төзүчеләрдән шулай ук өч кеше — Лазарев, Лебедев һәм Фәез кергән иде. Таныш озын өстәл тирәсенә утырдылар.

Лазарев белән Лебедевның секретарь янында ук бер-берсенә капма-каршы утырулары башта ук кызык кебек, мөгезләр шакылдый башлар шикелле тоелды һәм, кызганычка каршы, юраган юш та килде.

Шакировның кыяфәте ачулану дәрәҗәсендә кырыс иде. Ул Лазарев белән Лебедевка туп-туры карап сүзгә дә кереште:

— Бер үк предприятие исеменнән чыгыш ясаганда, сүзләрне алдан чама белән килештереп куялар. Бер кеше төзелешнең төрле якларын ачып бетерә алмый, әлбәттә. Шуңа күрә, картина яхшырак ачылсын өчен, чыгышлар берсен-берсе тулыландыра торган була. Баш идарә житәкчеләре бу юлы ни өчендер алай итмәгәннәр. Ник? Минем беләсем килә.— Секретарь шулай сорагач, «ике мөгез» дә түбән иелде.

— Алар болай икесе ике нәрсә хакында әйтергә тырышты,— диде горком кешеләреннән берсе.

— Бер үк мәсьәләгә принципиаль капма-каршы позициядән торып якын килделәр,— диде икенчесе.

— Фикерләрнең төрле булуы табигый түгелмени? — диде Лебедев гаҗәпләнеп.

Секретарь бу сүзләргә ни өчендер җавап бирмичә, үз фикерен куәтләде:

— Карашларның төрле якка таркалуы безнең өчен кызыклы түгел — кысла, аккош һәм чуртан әкияте әле дә искермәгән дип уйлыйм мин. Безгә йөк тартырга кирәк — без зур төзелеш мәйданын тартып барабыз — аны ахырга илтеп җиткерергә кирәк. Минем шуны беләсем килә: ни өчен сез халык каршысына чыгар алдыннан, чама белән генә булса да, кайсыгызның нәрсә хакында сөйләячәге белән кызыксынмадыгыз? Менә сез, иптәш Лазарев, ник шулай эшләргә тиеш тапмадыгыз?

— Ул миңа бу мәсьәлә белән килмәде. Мин аның чыгыш ясаячагын белмәдем.

— Ул мине бу мәсьәлә белән чакырмады,— диде Лебедев, секретарь сораганны да көтмәстән.

— Менә бит ничек — берсе килмәгән, икенчесе чакырмаган. Минемчә, сез икегез дә бер-берегезгә баш бирмәскә тырышасыз. Җитди кыланыш түгел бу, минемчә, гафу итегез туры сүз өчен, минемчә, малайларчарак килеп чыга бу.

— Сезнең сүзегездә хаклык зур, иптәш Шакиров. Минем бу хакта аның белән сөйләшмәвемнең сере әллә ни тирән түгел, чөнки мин аның нәрсә һәм ничек уйлаганын беләм, чыгышы белән танышкач, карашымны әйткән булсам да, ул минем белән барыбер килешмәс иде. Чөнки без чынлап та капма-каршы позицияләрдә торабыз.

Казимир Романовичка җавап урынына, Шакиров кискен төстә үзе сорады:

— Я, яхшымы инде бу?

Лебедев та, Лазарев та «белмибез инде» дигәндәй ишарәләр ясау белән чикләнделәр.

— Сез икегез — ике зур фигура, оештыручы көч. Сезгә буйсынган кешеләр дә, димәк, ике төрле уйлаячак. Начар үрнәк йогышлы була...

— Кешеләр ике төрле уйласа табигый түгелмени? — диде Лебедев кабатлап.

— Ә ник ясалма рәвештә ике фикер тудырырга? Кешеләрне конфликтка тартыр өченме? Бер төзелештә ике лагерь?

— Бигрәк шәп — ике лагерь берсен-берсе тәнкыйтьләсен — эш яхшырак барыр.— Лебедевның бирешергә нияте юк иде.

— Берең алга, берең артка тартканда, нинди яхшылык көтәргә мөмкин?

— Ә без икебез дә алга тартабыз — беребез дә эшләмәскә өндәми. Бары тик яхшырак эшләү юлы барын гына әйтә. Фәнни коммунизм үзе дә тәнкыйть, үзара тәнкыйть безнең җәмгыятьне хәрәкәткә китерүче көч дип өйрәтә бит. Ник аны формаль төшенчәгә әйләндерергә?!

— Ләкин бер төркем халык арасында ризасызлык тудырып, аның кәефен бозып, авырлыкларны җиңү урынына аларны күпертеп кемгәдер сылтау һәм зарлануга караганда, мораль бердәмлек яхшырак.

Шакиров бу сүзләрне пафос беләнрәк сөйләгәнгә һәм чын күңелдән сөйләгәнгә күрә, бәхәскә керергә кыюлык итүче табылмады. Һәм ул тагын сүзен дәвам иттерде:

— Хәзер миңа ачык кына әйтегез — сез бу бәхәсне туктата аласызмы, юкмы?

Эндәшүче булмагач, тагын Лазаревка мөрәҗәгать итте:

— Сез ничек уйлыйсыз?

Лазарев үз алдындагы нәрсәләрдер сызгалаган кәгазен бөтәрләргә кереште:

— Сөйли китсәң, хәл монда җитди, әлбәттә. Мин сизәм: монда тулы мәгънәсендә килешү мөмкин түгелдер, чөнки үзегез сорагач, ничек уйлавымны вөҗдан кушканча әйтим. Филинов чыгышын тыңладыгыз. Үз начальнигын ничек итеп хурлап чыкты. Сизенүемчә, бу — намуссыз уен. Чөнки ул үзеннән яшьрәк кешенең үзенә житәкче булуы белән килешә алмый. Кыскасын гына әйткәндә, моның нигезендә карьерага омтылыш кебек бозык гадәт ята. Шуны белгәнгә күрә, юри, Филиновның сәләтен сизә торып, мин аны һаман участокта тотам — төзәлгәнче, беренче чиратта гомум мәнфәгатьләр хакында уйларга өйрәнгәнче, мин аңа югарыга юл ачмаячакмын. Шундый ук омтылышны мин Лебедевта да сизәм. Аңа нәрсә кирәк? Билгеле инде нәрсә кирәге... Аңа төзелешнең ялгыш юлдан алып барылуын исбат итәргә кирәк. Менә шуннан китә фәлсәфә, шуннан башлана яхшы абзый булып кылану, законсыз бараклар салу... Капитал туплый, янәсе.

— Сез провокация белән шөгыльләнәсез, иптәш Лазарев, һәм файдасызга...— Лебедев тагын нидер әйтмәкче иде, секретарь зур кызыл карандашын өстәл пыяласына суккалап, кулы белән ишарәләде:

— Дөрес, әгәр кем дә булса үзен артык гуманист итеп күреп, артык төчеләнә башласа, ул мине дә шикләндерә башлый. Дәвам ит, Лазарев.

— Ә минем сүзем бетте, иптәш Шакиров. Үзегез хәл итегез.

— Ә сезнең? — Секретарь Лебедевка карады.

— Минем әле берни әйткәнем юк.

— Рәхим итегез. Тик кыскарак тотыгыз.

— Миңа карата кискен әйтелгән кебек, минем дә кискен җавап бирергә хакым бардыр. Мин Лазарев белән тамырыннан килешә алмадым һәм хәзер дә килешә алмыйм. Ул, үзенең күңеле начар булгач, башкаларны да шулай дип уйлый... Шуның аркасында, һәр әйтелгән тәнкыйть сүзе аны управляющийлыктан алып ташлау нияте белән әйтелә дип уйлый. Үзенең яхшы ниятләр белән яшәвен аңлатканнан соң, Казимир Романович «демагогия» дигән нәрсәне үзенең ничек аңлавы хакында әйтте:— Янәсе, бераү дәүләт байлыгына экономия ясый, тизрәк төзеп бетерә — төзүчеләрнең энтузиазмын купшы сүзләр белән күпертергә тырыша. Үзенә шул рәвешле шөһрәт, капитал туплый. Менә шул була инде — чын демагогия. Менә шул була инде ул — чын спекуляция.

Лазарев секретарьга мөрәҗәгать итте:

— Менә шушылай яшибез инде без.

— Да, болай эшләп булмый,— диде секретарь икесенә дә карап куйгач.

— Мин дә шулай уйлыйм,— диде Лебедев.

Лазарев та каршы килмәде:

— Икебезнең беребез төзелештән китәргә тиеш.

Урнашкан тынлыкка һич зыян китермичә, аны тагын да тирәнәйтә торган сүз әйтте секретарь:

— Мин сезнең белән килешәм.

Беркем беркемгә күтәрелеп карамады.

Бу вакыт икесенең берсе, ихтимал, «Ә кайсыбыз китәргә тиеш?» дип сорарга тиеш булгандыр. Ләкин андый сүз әйтелмәде. Икесенең дә китәргә бик үк ашкынып тормавын шуннан чамаларга мөмкин иде.

— Мин болай уйлыйм: сез бу нәрсәне үзегез хәл итәргә тиеш. Икегез дә житди һәм тәҗрибәле кешеләр, кайсыгызга булса да тәкъдим ясау кимсетер кебек. Шуңа күрә үзегез хәл итегез. Булдымы?

— Булды,— диде Лазарев.

Управляющийның күк күкрәүле тавышы каядыр югалган иде бу чакта. Аның сүзе шактый йомшак ишетелде. Лебедев исә баш кына какты.

Фәезнең күңелендә Борис сөйләгәндәгедән дә яманрак хис кузгалды, әллә нинди авыр хис. Үз кайгысы, үз бәхетләре аңа бөтенләй кечкенә тоела башлады. Лазаревны да, Лебедевны да чын күңелдән кызганды. Фәезгә кыен булгач, аларның нинди хәлдә икәне ачык инде. Планнарны таштан корырга кирәк шул, агачтан корсаң җимерелә... Җимерелә...

Берничә көннән соң Лебедев эштән генә түгел, шәһәрдән үк китә икән дигән хәбәр таралды. Хәлнең ничек килеп чыкканы беркемгә дә билгеле түгел, бөтен шәһәр өчен ул сер булып калды. Ничек кенә белергә, сорашырга тырышса да, Фәез бернигә ирешмәде. Ә аннары эш, аңардан да бигрәк үз хәлләре, ул хакта артык уйланырга ирек бирмәде.

*Дәвамы бар*

## Зиннур Насыйбуллин

•

Булды еллар...
Шәһәр һәм авыллар
Янган чорда ялкын эчендә,
Без күршегә кердек тоз өчен дә,
Ике бөртек шырпы өчен дә.

Тәмәкече картлар таш гасырның
Истәлеге — чакма йөретте,
Ә әниләр безне, соскы биреп,
Күршеләргә утка йөгертте.

Кайчакларда шулай өч-дүрт малай
Бер үк йортка барып керәсең:
Кем морҗасы төтәр икән, диеп,
Күпләр көтеп торган, күрәсең.

Буш кул белән кайтмый идек болай —
Чәй куела, мичкә ягыла.
Һәм күршенең алтын күмерләре
Җылы бирә тәнгә, җанына.

Ул елларда шулай утка кадәр
Уртаклаша иде күршеләр.
Төзегәнне утка очырып түгел,
Һәркем өчен уртак ут тергезеп
Кеше булган ласа кешеләр.

### Һәйкәл янында

Чәчәкләр дә сине үз күрәләр,
Чәчәкләр дә сине сагына.
Таныйсыңдыр, Муса,
Син җырлаган канлы чәчәкләрнең
Сеңелләре килә янына.

Тик моңсулар алар,
Башкайлары
Җил искәнгә микән нелгән?
Җилләр дә бит сафлык ташый монда
Болыннардан, иркен Иделдән.

Гөлләр — гөлләр инде,
Ир-егетләр,
Башын иеп,ниләр кичерә?
Баш июне белмәгәне өчен
Баш исәң дә ярый кешегә.

Күзләрдә яшь булса,
Гаҗәпләнмә, Муса,
Җил кисә бит,
Җил исә бит, әнә, Иделдән.
Башларыбыз, Муса, болай гына,
Синең алда гына иелгән.

Синең белән бер кан, бер җан бит без,
Тамырдашлар, Муса, туганнар;
Синең кебек җырлап яши торган
Һәм елмаеп үлә торганнар.

Синең алда башын иеп ирләр
Син кичергән хисне кичерә.
Баш июне белмәгәне өчен
Баш исәң дә ярый кешегә!

## Безнең көнгә карый Спартак

Үлемсезлек кленә вәкилләрне
Иләгән ул тарих, җилгәргән;
Кибәк кенә торып калган бары
«Мин кем!» дигән әллә кемнәрдән.

Ә Спартак атлый!
Чорлар аша
Барасы да аңа барасы...
Тоеп торам: әле безнең көнгә
Төбәгән ул горур карашын.

Хөр күңелендә, бөркет күзләрендә
Нәфрәт саклап, бетмәс үч саклап,
Вьетнамлы, африкалы булып
Күтәрелеп чыга Спартак.

Атлый Спартак,
Киләчәккә атлый —
Дәверләрне кичеп чыныккан;
Халыкларны азат итәсе бар
Коллыктан һәм
Шул коллыктан калган холыктан.

Шуның өчен бөркет күзләрендә
Нәфрәт саклап, бетмәс үч саклап,
Синең күзләр минем күзләр белән
Безнең көнгә карый, Спартак.

●

Кеше үзеннән соң өч нәрсә
калдырырга тиеш:
яхшы эшен,
якты исем,
изге васыять.

Үлем түшәгендә ята кеше,
Соңгы газапларын кичерә:
Бу дөньяда инде ни булса да
Барыбердер кебек кешегә.

Барыберме?
Авыраеп калган
Күз кабагын кеше күтәрә,
Күңеленә сеңеп калсын дипме
Бүлмә эчен күздән үткәрә...

Әйтергәме әллә җыена ул,
Искә алып бөтен үткәнен:
Тормыш кына бәхил була күрсен,
Үзе аңа бәхил икәнен?

Әллә аңлап
гаять затлы заттан
Әвереләсен гади матдәгә,
Дөнья белән хушлашуы шулмы
Беренче һәм соңгы мәртәбә?

Чү! Тын гына: «Балаларым...— ди ул,—
Соңгы сүзем шушы...
Иң элек
Онытмагыз намус, гаделлекне...
Тыныч тормыш сезгә... Иминлек».

Үлем түшәгендә ята кеше,
Изге теләк аның телендә,
Әйтерсең лә монда имин булса,
Рәхәт булыр аңа тегендә.

## Кара аккош

Ап-ак булса аккош, кардай була.
Ул күңелгә элек-электән
Нәфислекнең, горур матурлыкның
Бер үрнәге булып береккән.

Дөнья булгач, ләкин карасын да
Туры килә икән күрергә.
Үзе — аккош... үзе шундый кара...
Кыен булып китте күңелгә.

Әйтерсең лә яла, гайбәт белән
Буяганнар керсез кешене...
Аккошлыгы барыбер җуелмаган,
Һаман аккош аның исеме!

Шулай булды:
Мин яратыр кызны
Тудырды да башлап хыялым,
Кеше күңеленең барлык гүзәл
Буявына аны буядым.
Кызыгымы, кызганычы микән
Беркатлырак булган чагымның,
Кызларга мин хыялдагы кызның
Сыйфатларын кушып табындым.
Тик берсе дә хыялымдагыча,
Уйдагыча була белмәде;
Шуңа күрә аерылулар булды,
Шуңа буды сагыш элмәге.
Сүнәрмен, дип кабынмаган идем,
Кабынмам, дип сүнәм-кабынам.
Хыянәтсез булдым хыялыма,
Хыял кызын һаман сагынам.

## Флера Гыйззәтуллина

●

Сайлаган юлымнан барыбер ваз кичмәм,
атлавы җиңелме,
авырмы?
Ник кирәк күкрәвем,
ник кирәк явымым
бастыра алмасам давылны?!

Ник кирәк сөюем?
Сөюдән көч алып
иң ачы нәфрәтне җиңмәсәм.
Сөюем хакына җиде кат җан биреп,
җиде кат терелә белмәсәм.

Ник кирәк яшәвем, әгәр дә нибары
яшәсәм тәнемдә җан барга.
Юк, язмыш, шаярма!
Мин инде өйрәндем
җиңәргә, сөяргә, янарга!

●

Гомерләр бар иде —
ишек алды кысан,
урамнар тар иде...

Мин хәтерлим әле
чишмә агышларын,
кояш баешларын,
чәчең алга төшкән,
иңнәреңне кискән
гармун каешларың.

Хәтерлисеңме син
күлмәгемнең алын?
Ул күлмәгем исән!..
Синең белән бергә
Кояш баешында
торган кебек булам,
шул күлмәкне кисәм.

## Туган көнемдә

Зур түгәрәк табын, килдең тагын:
— Котлыйм! — дисең,— туган көнеңдә.
Кандай кызыл, кардай ак чәчәкләр
Шик уята минем күңелдә:

Түтәлләргә кырпак төшкән мәлдә
Чын чәчәкләр җирдә калганмы?
Канга яки карга гына манып
Сузмыйсыңмы икән ялганны?

Кандай кызыл, кардай ак чәчәкләр!..
Их, үрелер идем аларга!
Чәчәк атмый калган үткән язлар
Киртә булып керә арага.

Кандай кызыл, кардай ак чәчәкләр
Минем өчен түгелдер алар?
Икеләнәм: я кар кебек эреп,
Я кан булып саркып агарлар.

## Роберт Миңнуллин

### Үзгәрешләр

Гомер буе
Үзгәрешләр булган
Әле монда,
Әле тегендә.
Кичәгенең бөек ачышлары
Гади булып калган бүгенгә...
Еллар үтү белән батырлыклар,
Шәп гомерләр
Җырга әверелә.
Алышына таҗлар, министрлар,
Үзгәрәләр еллар,
Дәверләр...
Баксаң, без дә
Элеккеләр түгел,
Мәхәббәт тә хәтта башкарак.
Кай арада үзгәрдек соң әле?
Болай идекмени баштарак?
...Үзгәрешләр — Җирдә,
Күңелләрдә,
Үзгәрешләр тулы кайда да.
Дөньялар ул үзгәрмичә тормас,
Үзгәрсен тик безнең файдага.

### Шамун Фидаига

Гомере янар йолдыз булгач,
Нәрсә ул яшь
Шагыйрь өчен!

Яшь идең син.
Яшь-яшь идең.
Гөрләп,
Дөрләп яши идең.
«Күкрәгең — янар тау» иде.
Яшь булсаң да яшен идең.
Бөре генә гомереңдә
Җир тетрәтеп, күкрәп калдың.
Сүнгәндә дә йолдыз төсле
Нур калдырып сүнә алдың.
Син яшь идең —
Яшен идең.

## Татар хатыннары

Хөрмәт итәм
Татар хатыннарын.
Ихтирамым олы, йөрәктә.
Ярата һәм яраттыра алар,
Ирләр була белә кирәктә.

Олы җанлы алар.
Бик нык заттан.
Андый ныклык юктыр ташта да.
Күңеле тулса, бер капланып елый,
Яшь күрсәтми генә башкага.

Чыдамлылар алар.
Чыдадылар,
Еш басса да дөнья иңнәрен.
Күпме хатын, әнә, әле дә булса
Яудан көтә улын, ирләрен...

Ничек инде хөрмәт итмисең ди
Алиһәдәй шундый хатынны!
...Табигате белән тыйнак алар,
Түземлеге белән акыллы.

## Шәһре Болгарда

Мине монда бар да уйландыра,
Бер карасаң,
Берни ят түгел.
Томырылып чапкан толпарларның
Тояк тавышын эзли бу күңел.
Үткәннәрне эзли,
Тыңлый күңел
Ерак калган еллар авазын.
Ә җанымда
Болгарстан күргән
Һәлакәтнең тоям газабын...
Әсәрләнеп мин Болгарда йөрим —
Әйтерсең лә мин үз куышымда.
Токымымның изге биләве бу,
Шәҗәрәмнең башы шушында.

## Сагындыра

Башкорт даласына кунак булып
Ерак юлдан килгәч көнозын,
Башкорт кызы, тустаганга салып,
Сузды миңа тансык кымызын.
Бөтен тәнем калды җиңеләеп,
Бар теләккә гүя ирештем.

Әллә кымыз шундый шифа инде,
Әллә кызның кулы килеште.
Башкорт далалары тылсым икән,
Үзе моңлы, үзе тымызык.
Сагындыра һаман шул даланың
Әллә кызы,
Әллә кымызы.

## Элегия

Таныйсыңмы, эткәй, зур улыңны?
Кайттым әле тагын янына.
Күңелемә нидер җитмәгәнгә,
Җиңел булмасмы дип, җаныма,
Кайттым әле, эткәй, янына.
Син юкка да күптән.
Гомер үткән.
Үзем хәзер эти булырлык.
Әнкәй генә елаштыра менә...
Тулырлык шул күңел,
Тулырлык...
Безнең өчен —
Малайларың өчен
Йөрер чагың да бит куанып.
...Сагышыннан сары чәчәк аткан
Кабереңдәге сәрби куагы.

## Пират исемле этка

Нихәл, брат.
Ахирәтем, Пират,
Өрүенне үлеп сагындым.
Үзең дә бит, әнә, зарыккансың,
Аягыма килеп сарылдың.
Без бит — дуслар,
Бик күптәнге дуслар,
Сезнең халык тугры дуслыкка.
Әмма күпләр никтер аңламыйлар,
Рәнҗетәләр сезне һич юкка.
Ә мин, Пират, усаллардан бер дә
Сүз әйттермәм сиңа, якләрмын.
Юньсезләргә: «Эттән туган!» диеп,
Яманлыкны сиңа якмамын.
...Барысы турында да синең белән
Сөйләшәсе иде бер, Пират...
Борыныңны салындырма әле,
Ни дисәң дә, син дә бит ир-ат.
Эх, брат.

## Диләрә Зөбәерова

# КУШ ӨЯНКЕ ШАҺИТ

хикәя



Авылга чакырганнар. Мәктәпне бергә тәмамлаган классташлар белән очрашасы бар икән. Тора салып кыш уртасында өйдән кузгалуның сәбәбе шул.

Купеда хәзергә ялгызым. Пальтомны элеп, чемоданымны урнаштырган арада, ак төргәк тоткан проводник кыз сугылып китте. Өс-башны алыштырып, төргәктәге җәймәләр белән урын-җирне әмәлләгәч, ыгы-зыгылардан бушанып калдым. Кай арада арылган диген, ял итеп алыргамы соң...

Ерак сәфәргә чыктым. Көпчәкләр секунд саный. Аларга ярга сугылып шапылдаучы дулкыннар шавы кушыла. Кара дингез буйлап чабыш. Малай чак булса, тәрәзәгә капланып, авыз ачып шаккатып барыр идең. Ә хәзер барысы да таныш, гадәти. Гомер дигәнеңнен дә су буйлап ашкынып чапкан шушы поезд кебек узган көне. Өч дистә түгәрәкләнде, дүртенчесен вакладык диген... Берәүләр шул ычкынган гомер йомгакларын яңадан урап кабаттан сүтмәкчеләр. Мин үземне андый үкенечләрдән азат саныйм. Сабый чак белән бергә узган хәсрәтләрне искә алмаганда, болай уңай гына көйләнде кебек тормыш. Арттагыларны көтмәем, яңашадагыларне узмаем дигәндәй, барысы да шулай бер эздән үз көенә атлый әле.

Әйдәгән маршрутлар әйләнгеч булса да, төрләнмәде. Авылга да һаман шул таныш рельслар буйлап барыш. Дөресрәге, атам сапкан юл белән анам үскән яктан кайтам мин. Әнкәем Зәйнәп — аджар кызы — Батумида үскән. Әткәем Зәйнетдин — Ык буе егете, Аджариядә хезмәт иткән. Сөйләүләренә караганда, әүвәл аларны охшаш исемнәр таныштырган. Икесе ике якка аударып русча сөйләшкәннәр, әмма бик шәп аңлашканнар. Тик гомерләре генә кыска булган. Сугыш мине дә ятим итте. Шулай итеп, әбием карамагына — Мөслимгә кайтканда, өч төрле телдә такылдаучы малай идем мин.

Әткәй-әнкәй назы онытылган, әби дигәнебез иркәләми-типкәләми диләрме әле, сабырлык саклап, иплән кенә тәрбияләде. Аның бар теләге шул: мине тәүфыйклы, акыллы кеше итеп күрәсе килде. Заманы да тәэсирсез калмагандыр, кара сугыш еллары иде, үсүләнеп йөрер чак түгел, әбинеке жиңде. Сүз тыңлаучан, томсык малай булып үстем. Андыйлар астыртын булалар. Шуңадыр, кайсы малай әдәпсез, кайсы кыз

кыланчык, нәрсә килешә, нәрсә килешми, дәшми-тынмый гына күзәтеп йөрер идем.

Тагын шунысы бар, астан караучы, юаш сыман малайлар бик кеше арасына да керми бит әле алар. Мин шундый идем, әмма мин — кеше арасында идем. Моңа сәбәпләр шул булгандыр. Беренчедән, әтисез кешеләрнең әниләре бар, ичмасам. Ә мин ике яктан да мәхрүм. Шуңадыр, олысы, кечесе җәлләгәндәй итә, хәл сорашкан була, боегырга ирек бирми иде. Икенчедән, сөйкемле малай дип йөриләр иде мине. Калын кара кашлы, куе керфекле, зур күзле, бөдрә чәчле малайны Тәңкәле авылы ятсынмады, үз итте. Менә ни өчен чакыру хатын алу белән алгысып куйды күңел. Сагынылган икән. Сәбәпсез кузгалырга кыймыйча, салкын сабырлык кына тыеп торган.

Күпер төбендәге алты почмаклы иске өебез... Инеш буендагы калай түбәле мәктәп, солдат гимнастеркасын салмаган нечкә билле укытучы апа... Сыңар аяклы директор абый... Кул-аяклары чебиләнеп беткән бер дә тиктормас малайлар...

Унбиш ел — бер үсмер кеше гомере. Шул кадәр вакыт узган инде без аерылышканнан бирле. Урта мәктәпне тәмамлагач, ояларын калдырган кошлар кебек, кайсыбыз кая таралышып беттек. Мин Казан университетының биология факультетына имтихан тоттым һәм сессияләр башланганны көтеп Казанда калдым.

Мөмкинлек була торып, авылга бер кайтып килмәү үкенечле икән. Самолет күтәрелә алмас, машина кузгала алмас кара көздә авылдан хәсрәт телеграммасы килде. Куна-төнә аэропортта ятсам да, очып булмады, әбине миннән башка җирләделәр.

Авыл белән ара шулай өзелде. Каникулда Грузиягә киттем. Батумида әнкәй ягы туганнарым бар бит әле. Студент чор, ялгыз чак. Кем елмая, шуңа сыенасың. Университетны тәмамлауга тагын чакырып алдылар. Шулай итеп, якорьне мин Кара диңгез буена салдым. Коктебельне узгач, Маһинҗаури дигән поселок бар. Шунда житәрәк — Краснов исемендәге атаклы ботаника бакчасы. Менә унберенче ел — мин шунда гыйльми хезмәткәр. Гашыйк булып, һушым китеп өйләнмәсәм дә, хатынымнан уңдым шикелле. Үзем кебек сабыр, басынкы. Улыма классташым Әнвәр исемен куштым. Әллә, мин әйтәм, исем дигәннең дә тәэсире бармы икән. Малайның шаянлыгы, чаялыгы — тач Әнвәрнеке.

Кызык та малай иде соң ул авылдаш Әнвәр. Язга чыктымы — тәкәрлек күкәе төсле чуар сипкел тибәр үзенә. Тик кайда ни бар, шуннан нинди тамаша чыгарыйм дип ялт-йолт каранып торучы күзләре генә елтырап кала. Ул үрмәләмәгән агач, ул менмәгән түбә калмагандыр авылда. Өендә әз генә тырышса, класста бераз гына телен тыйса, отличник буласы малайның көндәлеге дә үзе шикелле чуп-чуар. Ничә төрле билге куела — барысы да бар анда. Дөресен әйткәндә, койрыклы саннар аның белеменнән битәр, тәртибенә күрә тамалар. Тиешле урынында балык кебек телсез, акбай кебек хыянәтсез иде үзе.

Шулай берчакны без аның белән очраша язып калдык. Иренеп кенә диванда мандарин әрчеп ята идем, хатын кулга урталай бөкләнгән язу тоттырды. Хат-мазар алышкан кешеме соң мин, танымыйм бит язуын. Имзасын куймый гына «очрашыйк» дигән, урынын күрсәткән. Бу ялары яхшы белә булса кирәк. Таныйсың килсә, «шунда танырсың», янәсе. Сәгатькә карасам, кузгалырга вакыт. Кем икән бу, чынлап та. Барыйммы икән? Бармасаң да ярар микән? Гәүдә авыраеп тора, аяк та тартмый. Шулай уйланып яткан арада ярты сәгать узып та киткән.

— Әй,— димен хатынга, яткан җирдән генә,— нindirәк кеше иде соң? Төсе-кыяфәтен әйтәм?

— Синең яраткан актерың Стриженевка тартымрак.

— Кайда тукталганын да әйтмәдеме?

— Сорашмадым.

Шулай итеп, сигезенче ярты узып бара. Яңгыр да явар сыман. Чаж-чож плащ кына киеп йөгерсәм, өлгерермен дә ди, тик килешер микән соң тик торганда шулай кабалану? Әй, ярар ла, бик кирәк булсам, тагын килеп чыгар әле. Адресны тапкан, килә белә. Шулай итеп, кие-релә-сузыла ята торгач, йокланылган.

Үкендерде мине соңыннан бу пошамансыз үткән кич. Атна-ун көн узуга хаты килеп төште теге язу иясенең. Янибызда гына «Дулкын» ди-гән курорт бар, шунда ял итеп яткан булган безнең Әнвәребез. Менә сиңа мә! Әйткән иде аны Стриженев сыманрак дип, сипкелләре генә түгел, кыяфәтләренә кадәр охшашлар ич алар. Башта гафу үтенгән булып иплән кенә хат язмакчы идек тә, тора-бара онытылды. Калган эшкә кар ява ди, бер искә төшкәч, адресын эзләп караган идек, җуйганбыз икән.

Ул кайтмый каламы соң, очрашу авылда инде. Минем хәтердә йөргән-чә һаман да шул, беркатлы булып калса, аңлашырбыз ла. Без ирләр ич.

Ә менә Миңнәхмәт диганебез аның киресе иде.

Яшьтәшләр саналсак та, ашыгыбрак калыккан нәзек озын бу ма-лайның калак сөяге өстендәрәк биш тиен бакыр кадәр миң җәелгән. Су коенганда: «Аркаңа ләм ябышкан, ләм ябышкан» дип, теңкәсенә тигәнебез әле дә истә. Усаллыкка дигәндә Әнвәрдән уздырса да, үзенә тиешле урында «тын» иде безнең Миңнәхмәт. Бәләкәйләрнең теңкәсенә тия, телен чыгара, яный, үрти, өркетә. Өлкәннәр янында менә диган тәртипле малай. Укуы да ташка үлчим генә. «Б» белән «в»не бутый. тапкырлау җәдвәлен белми. Шулай да ерып чыга. Пөхтә дәфтәренә ма-тур гына итеп әзерне күчерә дә дүртле ала. Бишле дә куярлар иде — сизепәләр.

Мондыйлар тормышта да батмыйлар. Аларны дулкыннар йомычка урынына өстә генә тирбәтә дә иплән кенә ярга чыгарып куя. Курыкма, хәйләкәр Миңнәхмәт тә башкалардан өстәдер, өстенрәктер әле.

Тагын кемнәребез бар иде безнең: авызын җыя алмас көләч Иршат, гармунчы Нурулла. Бишектән төшүенә иңенә әрҗә кадәр гармун аскан-гамы, тәбәнәк калган бу кара малайны бот буеннан бичырга («вечерны» авылда шулай диләр иде) йөрттеләр, туйдан калдырмадылар. Шуңадыр, иртә өлгерде, унсигез тулганчы өйләнеп тә куйды. Үзеннән озын уллары бардыр инде.

Укуы чамалырак булса да, аксакалларныкыннан акыллырак сүзләр ычкындыра торган җырчы Гамир, телдән төшми макталучы отличница Мөслимә, аның дусты, теге, директор кызы, чытлыкланырга яратучан Лениза.

Лениза... Чынлап та шундый кыз да бар иде бит әле безнең. Нигә моңа кадәр искә төшми тора соң әле ул? Беренче тапкыр житәкләшкән, авылча итеп әйткәндә, йөргән кызым ич ул минем. Кача-поса хат алыш-кап, чишмә тыкрыгы буйлап куышып, үртәшеп кайткан чаклар кайда калдылар, диген.

Алар икесе алгы партада, без алар артында утыра идек. Чәчүргеч-ләренә кадәр күз алдымда. Югары классларга житкәндә бик төрләнә башладылар ул тасмалар. Кайчагында кызлар мәктәп формаларыннан да ваз кичкәлиләр. Кыландырып тегелгән күлмәкләре тәмам житкән кыз итеп күрсәтә үзләрен.

Бервакытны Ленизада үземә карата ниндидер бер яшерен якынлык сизенә башладым. Турыларыннан үтсәм, тәрәзәгә каплана, спорт залына чыксак, минем тирәгәрәк басарга тырыша, каләм-мазар сорасам, бүләк итеп бушка бирә. Дөресен әйткәндә, миндә дә җан бар — дәрт-дәрман ингән чак. Шуңа күрәдерме, бу кыланмышлар күңелгә бертөрле рәхәт-лек бирә сыман. Аннан соң үзе дә күз төшмәслек кыз түгел. Латыш кызларына тартым озынча йөзе, сөрмә-мазар тартмый да мөлдерәп тор-ган соры күзләре, елмайганда уйнаклап алган яңаклары әле дә хә-тердә. Үзенең бер дә катнашмаган эше юк. Беләгендә — кызыл тасма,

түшендә — значоклар. Сәхнәдән дә төшеп тормый — бии, әйбәт бии. Декламация сөйли, уртачарак сөйли. Җырлый, тик зерәгә генә җырлый — көе дә юк, моңы да.

Сизмәмешкә салышып йөргән бу яшерен «аулашуларның» бер чиге килеп чыкты. Гашыйкларның телен, күңелен ача торган һаман шул бер яз бар бит инде. Умырзаялар калыккан чак иде, каен суы эчәргә мендек.

— Каен суы витаминга бай,— диде фельдшер Сәмига апа кызы,— буйга Миңнәхмәтне куарга теләүчеләр булса, за мной!

— Асыл таш зур булмый,— диде аңа каршы үзе кебек сыгылырга гына торган яшь өрәңгегә таянган Лениза,— агач елатканчы, урман корытканчы, бәләкәй килеш калам мин.

Шәп әйтте директор кызы, әй. Сүзенә куәт биргәндәй, бер тутырып карадым үзенә. Һәм шунда аның алмалары тәгәрәп төшәм дип торган ялварулы матур күзләре белән очраштым. Нигәдер баш әйләнеп киткәндәй булды, күңелдә тел белән генә аңлатып булмый торган бер рәхәт тойгы җәелде. Бу хәл нибары ярты секунд дәвам иткәндер. Күзләребез шундук оялышып бер-береннән качыштылар. Тәэсире калды. Күңел беркайчан булмаганча җилкенеп, гәүдә җиңеләеп китте. Яфраклар яра гына башлаган язгы яшь агачлар нидер кисәтеп, шаулап куйдылар. Урман тавыннан, куыша-куыша, тәгәрәшеп төштек.

Кичке очрашуны телдән әйтергә батырчылык җитмәсә дә, күңелләр, күрәсең, сүз куешкан. Сандыктан имтиханга гына киеп бара торган ак күлмәк чыкты. Ваксы савыты коргаксыган икән, аптырап калмадым. Баскыч куеп тормыйча, чолан өсләп кенә өй түбәсенә үрмәләдем. Анда әбинең тозлы казлары асылынып тора. Шуннан бер чеметеп майлы калҗа йолкыдым да туфлиләремә сөрттем. Яңарып киткәндәй булдылар. Көзгегә баксам, каршымда ыспай гына бер егет басып тора!

Лениза нинди кыяфәткә кергән диегез? Абау... Башта танымый тордым. Үкчәләр бер тотамга күтәрелгән. Өстендә келтифүтләп тегелгән кыштырдык күлмәк. Муенында җиде катлы сәйләнь. Ул чәчләрен, мин сиңа әйтим, ни арада нәрсә белән бөдрәләндергән. Кашлары да үзенеке түгел... бизәнгән, хушбуй сөртенгән. Исе әллә кайдан аңкып тора. Яныннан күрмәмешкә салышып узсам да, капка төпләрендәге куш өянке төбендә көтеп алдым үзен. Тагын бер гаҗәп. Башка чакта чатнап торган чая кызый башын аска иде дә телсез калды. Ул юашланган саен мин кыюланам кебек... Ниһаять, кыяр-кыймас кына, кулларына да үрелдем. Кайнар бармаклар уч төбенә хәрәкәтсез генә яттылар. Кершән исле битләренә орындым, җылы сулышын тойдым. Рәхәт иде миңа. Беренче кат үземнең хатын-кыз дөньясына таба атлавымны сиздем. Исерткеч дөнья, терелткеч дөнья... Кыюлык, егетлек сиздем үземдә. Нәкъ кинолардагыча күкрәгемә кысып кочасым килеп китте үзем. Тик тыелып калдым. Ак беләзекле кулларын иплэп кенә иңемә салмакчы идем, кызым, нидер сизенгәндәй, тартылып куйды. Бу сагаю иде. Мин моны җил уңаена чак кына сыгылып куйган гөл сабагының шунда ук төзәтенеп, масаюлы чәчәк башын яңадан турайтуына охшаттым...

Соңлап кайтуымны әби ошатмады.

— Пошынып беттем,— диде ул, ишек ачарга чыккач.— Нинди хәл бу?.. Кеше төнлә юньлегә йөрми, я бурлык, я бер-бер этлек була аның уенда. Йөземә кара якмасаң ярарые.

Миңа читен булып китте. Әле генә баштан узган татлы минутлар, исерткеч тәэсирләр барысы бергә укмашып күңел почмагына посты. Озаккамы — бүгенгәме, әллә гомергәме... Юк... юк... Тирәнгәрәк китсә... Иптәшләр сизенсә... Әби ишетсә...

Китаплардагы мәхәббәт каһарманнары утларга керә, суларга төшә. Күрәсең, минем яратуым шул кадәр генә булгандыр. Беренче мәхәббәт күгәрми, диләр, югыйсә. Алай дисәң, кая соң әле ул? Очрадымы ул

мина? Юләр хисләрен авызлыклый алган акыллы бәндәләр өчен юкмы әллә ул? Чөнки балаклы чалбар киюгә башлы-күзле булган Нурулла-ларны, яки икенче бер кызны паркка дәшкән өчен ярәшкән егетеннән ваз кичкән курсташ Зәйтүнәләрне һәм көнчелек утына чыдый алмый башын алып олаккан Ленизаларны мин бер дә камил акыллы кеше-ләрдән санамыйм. Курка-өркә башланган беренче очрашуларның соңы әнә шулайрак булды бит әле.

Баштарак мин бу кыз белән чынлап мавыктым. Иптәшләр алдында сер бирмәскә тырышсак та, күнелләр тышаулы иде. Яшерә торган эш-мени ул яратышу? Урман — колак, кыр — күз, диләр, авылда анын шу-лар өстенә борыны да бар. Гөнаһсыз яшь мәхәббәтне аулакта да тота алмыйсын, оялып, кача ул аннан... Әянке төбен саклаулар, чишмә тык-рыгыннан житәкләшеп кайтулар, янәшә урамнарда яшәп, күрше парта-ларда утырсак та, язышкан хатларның эчтәлегенә кадәр «тиешле» ке-шеләренә мәгълүм иде. Тиешлеләренә дигәч тә, әле ул чакта мин дошманнар, дуслар үрчетер дәрәҗәдә түгел идем, әлбәттә. Сүз борыч телле классташлар белән «ул-бу» булмагаеннан шөлләп яшәүче әби турында гына бара. Әбкәйнен алай туры әйтеп оялта, йөз ерта торган гадәте юк. Шулай да, кыеклап-мыеклап дигәндәй, ирештерәсен ирештерә торды. Тик шуны анламадым мин. Әллә директор кызы чынлап ошамый иде ана. Әллә балигъ булганчы юлдан язмасын дип минем өчен борчыла иде ул.

— Бер дә фәтуасын тапмыйм шул Ленүзәгезнен,— диде әби бер чакны сүз югында сүз табып.— Әнә Фарсостанда әүвәл кыз балаларнын тәпиләрен ефәк белән тышаулап куйганнар. Кыз дигәнен вак кына ат-лап, иплән кенә басып йөрергә тиеш. Ә сезнен ул нәмәрсәгез казык ба-шыннан сикерә, самокатка утырып чаба.

Ишетмәмешкә салыштым. Мангай куырылып куйды, эч пошып китте.

— Ирдәүкәрәк бугай ул директор кызы,— диде тагын икенче бер вакытны,— чалбарлы тавыкмыни, малайлар булып киенгән. Әбәү, ки-лешмиме кыз кешегә штаннан йөрү.

Монысын да эчкә салып куйдым. Билен өзгән килешле клюш күлмә-ге бар, ник шуны гына кимәскә.

Өйдә нинди фоторәсем бар, барысы да рамланып стенага кадак-ланган. Әби эше. Төркем белән төшкән бер зур гына фото буфет тәрә-зәсеннән карап тора.

— Башкаларыгызны танийм,— ди бер көн, минем чыгып таярга йөргәнемне сизеп,— менә бу кабак төше сыманрак озынча битлесе кем соң?

Баксам, юри танымаска салышуы — билчәйгән бармагын Лениза турына терткән.

— Әй,— дидем дә борылып киттем. Сабын тышындагы сылу Гөлжи-һаннарга тартым озынча түгәрәк йөз шул минутта төссезләнеп киткән-дәй булды. Анын өстенә әбинен колакка гел тукып торган башка сүзлә-ре дә өстәлде. Шулай итеп, Лениза минем күз алдыннан әкренләп ера-гая башлады.

Таптым авыртмас башка тимер тарак. Әллә чыкмаска инде бүген. Йокы килә, янгыр явар әле иртәгә...

Ә икенче көнне ул мина хат язып бирде. Бик ашыгыч кына әйтәсе бер сүзе бар икән. Утын ярганда гына кия торган якасы типчүле әллинур күлмәктән менеп киттем турыларына. Юлда Әнвәр очрады. Кулында йөгән. Утлаудан кайтуы (мал жанлы малай. Әтисе жигә торган «Магуч»-ны ул илтә, ул алып кайта).

— Гомәр Хаям кая юл сала? — диде ул мина гадәттәгечә юмор белән генә.

— Монда гына...

— Шулайдыр?!

Сер бирәсе килмәде, сүземне сүз итү өчен, тоттым да аңа ияреп кире борылдым.

— «Кругом» командасы булдымы әллә?!

— Ярар ла, син очрамассыңмы дип кенә чыгу иде.

Әнвәр, борын тишекләрен киереп, авызын очлайтты да сызгырып куйды:

— Ну, суфи да инде син, парин. Рас, очрашырга теләмисең икән, нигә чыгарып бастырдың кызны өянке чатына? Шагом марш кире шунда!

Ул сүзне сузарга яратмый. Әйттем дә, бетте дә дигәндәй, йөгәнен болгый-болгый, сызгырынып китеп тә барды. Мин нишләргә белми урам чатында калдым. Әйе, тегесе дә бер сагыз булды. Бер генә елмай, атыла да чыга. Чакырмасаң үзе чакыра башлый. Бармыйм и все! Хәйлә бетмәгән.

Кайткач эш тапкан булып ишек алдында йөрдем, мал-туарны яптым. Аннан соң бер-ике бүкән утын ярдым да, эч пошу басылмасмы дип, чишенми-нитми чоланга кереп аудым. Йокланган. Үпкәли белә икән, икенче көнне күрмәмешкә салышты. Өченче көнне мин... Ялындырышабыз, янәсе.

Имтиханнардан котылгач, чыгарылыш кичәсенә хәзерләнеп йөргән көннәр иде бу. Стена газетасы чыгарып маташабыз. Язуым матур минем, шуңадыр, гел секретарь итеп сайлыйлар. Ә Әхмәт коеп куйган художник инде ул. Ясап куя, мин сиңа әйтим, сурәтләрне, авызыңны ачып карап торасың. Редакторлыкны вожатый Мөнҗия өстенә йөкләдек. Үзе дә былтыр унны гына тәмамлаган. Шуннан ары үрли алмагач, эшли торыйм дип, безгә килде. Мөслимнең үзенеке. Әллә табигать шулай безиме, чибәр, каһәр, шул Ык буе кызлары. Түгәрәк шома йөзе, шуның уртасына кунган матур борыны, куш миләштәй уймак ireннәре әле дә күз алдымда сыман.

Соң таралыштык мәктәптән. Вожатый Мөнҗия авыл очында ук, Тайфәттәйләрдә тора. Кулында сумкасы бар, житмәсә, китап кыстырган. Күтәреп кайтмакчы булдым. Аннан соң кыз баланы бер үзен ничек караңгы тыкрыкка кертеп җибәрәсең инде.

Сөйләшеп атлый торгач, сизми калдык: таныш өянке яныннан узабыз икән. Күзгә бер шәүлә чалынгандай итте. Теге кыз булмагае...

— Шалт Мөхәммәтҗан! — диде Мөнҗия, турыларына килеп җиткәч, кечкенә йодрыгы белән капканы төеп.— Эчтән бикләнгән ич... Кайтып яткан дигәннәрдер инде.

— Әйдә безгә генә,— дидем дә, тик соңыннан ник әйткәнемә үкенеп куйдым: чыңга алуы бар, белмәссең бу кызлар акылын, иярде китте...

— Мәле сумкаңны, айн момент.

Койма араталарына басып өскә үрмәләдем дә «һап» боларның ишек алларына. Терәткеч бастырыкны кузгаткач, шыгырдатмый гына капканы ачтым.

— Рәхим итегез, синьорина.

— Мин сине рыцарь дип уйламый идем,— дигән булды Мөнҗия, сузынкы иркә тавыш белән.

— Сездәй чибәр принцессалар өчен бирәү Җирне күчәреннән тотып күтәргән.

Кызыйның тавышы тагын да бөдрәләнә төште:

— Көлмәсәнә, Гомәр...

Башын әйләндерә күрмим дип сүзне икенчегә борам, ә ул һаман эчкә үрмәли.

— Сине Лениза белән йөри диләр, дөресме ул?

Дәшмим бу юлга. Моңарчы алдашкан юк, я өйрәтерләр. Ычкыныйм булмаса.

— Хуш, Мөнҗия,— дидем мин, аңа кул биреп.— Хуҗаларың чыкканчы тайыйм...

Бу минем тизрәк саубуллашасы килүем иде, ә ул үзенчә аңлаган, куллар ялгануы дип уйлаган...

Туган мәктәп, ягымлы да, кырыс та була белгән укытучылар, үсмер чакның онытылмас хатирәләре булган классташлар белән саубуллашуны мин кеше тормышының ташулы язына охшатам.

Баш әйләнгеч таныш музыка яңгырый, аминлы теләкләр ява, күктә буй житмәс кояш балкый, аста мәңге әйләнеп кайтмас бозлар ага. Кичә генә узды кебек ул көн. Трибунадан яуган гел бер төсле тәбрикләр, төче рәхмәтләр, лимонадлы ак табыннар...

Ни чыкмаган шул Миңнәхмәттән чыга инде: ера-еша яныма килде дә:

— Гомер де Галимов,— диде,— кызлар ашасын печеньесын. Әйдүк, минем арттан.

Як-ягына карангалап ияртеп барды да бер кап-карангы класска төртеп кертте. Аптырап торган арада шешәдән былт-былт бушатты да миңа сузды.

— Егет булып кара әле бер, ато, йөрисең ике арада.

Аракы белән беренче авызлануым шушы булды.

Чыксам, залда музыка. Вальска бөтереләләр. Биючеләргә озаграк карап торгач, башым әйләнә башлады. Барысына да ишетелерлек итеп бер кычкырасым килеп китте. Нәрсә дип? Кемгә? Аңа, әлбәттә! Кая соң әле үзе? Авырайган күзләрем белән залны айкыйм. Аны эзлим. Әнә каршы якта. Таптым. Радиола төбендә Мөслимәсе белән басып тора. Икесе дә, шлапырлы дилә́рме әле, шундыйрак күлмәктән. Яннарына атлыйм мин боларның. Кыюлык шәбәйгән, күңел жилкенә. Әйтәсе сүз күбәйгән. Бу атнада очрашмауларга үч итеп, моңа кадәр телгә дә килмәгән әллә никадәр ят сүзләр пышылдыйсы килә үзенә.

— Лениза...

Биергә дәшкән кулым һавада асылынып калды. Алар, пар аккошлар кебек бер генә талпындылар да, халык арасына кереп югалдылар. Сизенделәр микәнни? Үпкәсе, хурлыгы, аракысы бергә буталды. Кеше-кара искәргәнче дип, унга-сулга карамый, туп-туры ишеккә борылган идем, таныш тавыш ишетелде:

— Гомәр...

— Әү...

Сүземне әйтеп бетерә алмадым. Мөнжиянең мамыктай йомшак, жинел куллары иңнәремә сарылды һәм без дә, музыка хөкеменә буйсынып, биючеләр агымына кушылдык.

Гәрчә күңел дигәнең бик үк тартмаса да, кичәдән соң тагын озата киттем бит әле мин моны.

Икенче көнне чолан тәрәзәсенең ватык өлгесеннән юка гына конверт очып төште. Бу Лениза галәмәте иде. Күренеп тора, ярсулы хат. Эре хәрефләр кәгазьдә бәрелә-сугыла яталар.

«Хат башы, язмагыз каршы.

Хыянәтчене сугышта аталар, Гомәр. Мин дә сине күңелемнән аттым инде.

Мәңгелеккә саубуллашыйк, Гомәр.

Соңгы сәлам белән — Лениза».

Тагын ике көннән мин аның, ата-анасы ризалыгын алмыйча, ялга кайткан күрше кызларына ияреп, Павлодарга киткәнен ишеттем.

Мә сиңа! Холык кешене ни генә эшләтми. Яратыштан талашка бер адым. Институт урынына читкә киту... Дөресен әйткәндә, мин аның мондый дуамал якларын баштарак та сизеп йөрдем. Дуслашуыбыздан соң тагын да сәерләнә төште ул. Кеше арасында чая да, шаян да. Икәү генә калдыкмы — тешләккә әйләнә. Сүзен тартып алып булмый, кызара. Гаепле кешедәй, күзгә туры карарга кыймый. Очрашасы урынга әллә кайчан ук килә дә күренми посып тора. Инде кайтыйм булмаса дигәндә

генә, каяндыр атылып чыга. Ул көттергән, мин көткән, янәсе. Мәхәббәтнең бер төредер инде бу, күрәсең. Тик мондый төрдән котылуыма мин бик разый идем, әлбәттә. Шундыйракка өйләнеп, бер кәефсезрәк чагында хәтерен калдырсаң, һәм ул, үз чиратында, мин сине йөрәгемнән атып бәрдем, дигән язу калдырып, Целиноградка яисә Братскига чыгып тайса, нишләмәк кирәк? Ир кеше башын ташка ора алмый.

Чынлап та, кайда икәнсен син хәзер, үпкәчел кызый? Булмас. Кайткансыңдыр ул сәфәреңнән. Кәрәле-чыгалы акыллылар әллә кая тамыр җәя алмыйлар. Теләсә кайда төпләнеп үз урынын табу өчен икенче рәттәге беренче партада утыручы Мәхмүттәй басынкы, сабыр булырга кирәктер. Ә менә ул, ичмасам, хәзер әллә кем булгандыр инде. Арада иң тырыш, иң төпле малай шул иде. Базык гәүдәле, гел аска карап йөрүче бу күзлекле малайның башкаларда эше юк. Өйгә биргән эшен кучертми, карасын манчытмый. Әләк-чәләкне белми, макталам дип масаймый. Үзе бер автономия. Тумас борын картайган җан кебек: уйнамый, шаярмый, нидер уйланып йөргән көне.

Искә төшәсе исемнәр, яңарасы истәлекләр тагын бар иде әле, йокланып кителгән. Уянсам, купеда без инде икәү. Юлдашым — отставкадагы полковник, сүзчән булып чыкты.

«Классташлар» кичәсенә генә кайтам дип вакланмадым, сәфәрнең максатын киңәйтә төштем:

— Үзем үскән якларны күрим, әби-бабай каберен барлыйм, дим.

— Әйбәт кешегә охшыйсыз,— диде полковник, борын төбендә ике бәләкәй түгәрәк итеп калдырган мыегын сыйпап.— Тәрбиячеләреңне искә алгалау киң күңеллелек ул. Белдегезме? Ашыгыч заманда яшибез, киләчәк турында күбрәк уйланыла. Роботларны биетеп кенә йөртәчәк оныклар турында хыялланып, олыларны онытырга ярамый. Аңлашыламы? Бу турыда очраган бер журналистның, таныш педагогларның исләренә төшергәлим дә, ни, нәтиҗә юк. Тыңлаганга сабышалар, үзләренчә эшлиләр. Күрдеңме?

— Шундый китап та бар,— дидем мин, аның сүзен куәтләп.— Сез әйтергә теләгән идеяне ярган да салган.

Полковнигым җитди төс алды. Каршына утыртып, тын да алдырмый, шуның эчтәлеген сөйләтте.

— Һе. «Әйтелмәгән васыять» диген, ә? Аристотельләрдән килгән, Әбугалисиналар хуплаган, борынгы акыл ияләреннән калган әдәп нормаларын, кешелек, ихтирамлык сыйфатларын онытмаска кушкан бу китап. Дөрес әйтәмме? Үтенеп сорыйм, Гомәр улкай, миңа шул китапны табып җибәрмәссеңме?

Мондый сирәк китап киоскларда аунамас, әлбәттә, шулай да тырышырмын, дидем.

Юлдашлар юлны кыскарта. Тәрәзәгә баксам, соңгы станциягә дә җитәбез. Каршыда таныш кала, ят утлар! Унбиш ел эчендә генә дә никадәр үзгәргән Бөгелмә!

Кайтасымны, ярый, хәбәр итмәгәнмен. Яратмыйм артык мәшәкатьне. Мөслимгә йөрүче өр-яңа җылы автобус Тәңкәле кырыннан үтә икән.

Хәл кергән авылга! Ишәйгән, көрәйгән. Кыяфәте мәһабәт. Бөтен түбәләр шифердан, челтәрле коймаларга уралган. Антенналар күтәргән, чыбыклар белән чәбәләнеп беткән. Иске мәктәп урынында яңа мәктәп. Ике катлы дисәм, кинолардан күрмәкче сөйли диярсез. Хәер, хәзер кая карама, шул инде — ике катлы мәктәп, таш клуб.

Күңелдә моңсу бер сорау туды: кемнәргә туктыйм икән? Тоеп торам, кайсының гына ишеген шакысаң да, колач җәеп каршылаячаклар аңысы. Кунакчыл бу яклар. Шунда кылт итеп искә төште. Җылытып үстергән учакларны сүндерергә ярамый. Әбием нигезенә кайтам.

Капкабызны ачып ябуым булды, ялт итеп берәү баскычка да чыкты. Тәрәзәдән карап каршылау юк бу якта кунакны, чыгып алалар.

— Рәхим итегез,— диде миңа яшьтәшләр чамасы, иненә фуфайка салган ир кеше һәм кулга баскыч янагыннан алып канат тоттырды. Өс-башны кагып торган арада, каерылып өй ишеге дә ачылды. Тышкы салкын белән эчтәге җылы агым кушылып томан хасил булды, мин шуңа уралып, сабый чагымда аунап үскән өйнең бусагасы аша атладым. Каршымда гаҗәпсенүе күзләренә үк чыккан ханым пәйда булды.

— Чишенегез,— диделәр алар — ир белән хатын — бертавыштан.— Әллә Гомәрме сез?..

— Тануыгыз өчен рәхмәт димме...

— Йортыбызның кадерле хуҗасы,— диделәр алар, әле бер-берсенә, әле миңа карап.

Чын күңелдән якын итеп дәшелгән бер җылы сүз синең әллә нинди эчкелтем-төчкелтем сыйларыңнан татлырак. Күңел моңсуланып, нечкәреп китте.

Аш-су арасында үзләре белән дә танышып өлгердем. Бу ягымлы семья күрше авылдан килеп укыта икән. Ир-ат дигәнем Ибраһим атлы булып чыкты, укыту бүлеге мөдире. Буйга да, яшькә дә аннан кайтышрак күренгән йомры бәдәнле хатыны Фәгыйлә югары классларга инглиз теленнән керә икән. Минем хатын шикелле инде. Ул да грузин балаларына шул телне өйрәтә.

Сүз арасында өебез эчен дә күзәтеп утырдым. Үзгәргән... Алгы якның сәкесен сүтеп тахта җәйгәннәр. Урталыкта ялт итеп утырган акшарлы мич стенага кысрыкланган. Матча кашагалары, чуптарлы сөлгеләр, кижеле ашъяулыклар күренми.

Ул арада, минем кайтуны ишетеп, күрше-күлән, туган-тумача сымаграклар кереп тулды. Китте хәл-әхвәл сорашу. Кемнәрем бар, кемнәрем юк, кайда торам, ничек яшим, нигә кайтмыйм, ник хат язмыйм — допрос алалармыни...

Тик күңелле чөкердәшү беразга тынып калды. Ян тәрәзәгә күз салучылар чыш-пыш килеп нәрсәдер әйттеләр.

— Әллә каршына чыгып кире борасыңмы, исерекме?

— Ярар ла инде, ул да кеше бит...

Ул арада какмый-шакымый гына ишек ачылды. Өстенә кыска пальто, башына ямьшәйгән сусар бүрек кигән берәү, ава-түнә, ике кулын сузып, миңа омтылды.

— Го-мә-ә-әр...

Игътибар итсәм, аптырап киттем. Миңнәхмәт! Һәм, шул гаҗәпләнгән килеш, кулымны сүлпән генә суздым. Авыр тынлык урнашты. Шуны сизенепме, хуҗа Әхмәтне, ялт чишендереп, өстәл янына утыртты. Алдына, чәйгүннән генә агызып, авызларны өтәрдәй чәй ясап куйды.

— Чәйне карчыклар эчсен,— диде Миңнәхмәт, йомры белән тәлинкәне читкә этәреп.— Юкмы шунда «пыяла самоварың»?...

Ибраһим кузгалмакчы иде, мин тамак кырдым һәм шул арада тагын ишек ачтылар.

Булмәгә таныш та, ят та сыман күренгән бик интеллигент кыяфәтле берәү атлады. Тукта... Сипкелләре сирәгәйгән, буйга суырылып үскән... Шул инде. Урыннан сикереп тордым. Куллар кысылды.

— Әнвәр, гел танырлык түгелсең!

— Туганнан бирле һаман бер Әнвәр. Картаела. Синең белән очрашу мөнә, ичмаса, сюрприз!

Шул арада ул самовар артына чүгәләгән Миңнәхмәтне шәйләп алды.

— Ах, качкын. Посып утыруыңмыни бездән?

Кочаклашып күрештеләр. Миңнәхмәт айнып киткәндәй булды.

— Рәхмәт, Әнвәр, зурлаганың өчен,— диде ул.

— Нәрсә белән? Комментарий... давай!

Әхмәт, бөтен сыны белән ниндидер «шом» сөйләргә җыенгандай, каршыбызга басты.

— Аекның күңелендә, исерекнең телендә инде ул,— диде, бер кулын Әнвәрнең җилкәсенә салып,— ученый булып бетсәң дә, һаман безнең малай булып калгансың, һы! Күрешүең әйтеп тора, һай, бу дөнья! Аз гына кучәр башың кыегайдымы, таныта башлый дусларыңны. Һы! Беләсеңме ничә төрле күрешү бар дөньяда?!

Ул бераз шешенеп киткән чыраен чытты да кырт кына әйтеп салды:

— «Исәнмесез». Бу — кешене санга сукмыйча, теләмичә, форма өчен генә исәнләшү.

Аннан соң кулын күкрәк турына куйды да башын, чайкабрак, аска иде:

— И-и-и-сән-ме-сез! Бусы, күрәсеңме, мин нинди кече күңелле кеше, синең белән дә ничек әйбәт күрешәм, дигән ясалма күрешү була.

Кулын безгә сузды да йөзен читкә борды:

— Монысы — кешенең кием-салымына, төс-кыяфәтенә карап, ирексездән, интегеп кенә исәнләшү. Ягъни мәсәлән, Гомәрчә күрешү була...

Мин сискәнеп киттем. Ул сүзен дәвам итте:

— Әйе, әйе, синдә элек тә юк түгел иде әнә шундыйрак фокуслар. Һы. Ярый, мин исерек ди. Ярый, мин синнән кай ягым беләндер калышам ди. Пусть, шулай булсын. Арагыздан төшеп калганмын ди. Ничек кенә булмасын, барыбер синең классташың бит әле мин. Мин синнән ярдәм яисә киңәш сорап килгәнме? Хәлеңне дә сорамыйм. Әйбәт күренәсең. Кайтканыңны ишеткәч, шаккатып килгән идем. Ә синең котың очты. Кулыңны төрттең дә йөзеңне чөердең. Аерма кешене кешедән!

Әйтерсең өстемә бер чиләк бозлы су койдылар. Бала йоннарым кабарды. Әнвәрнең дә йөзе чытылды. Бигрәк тә Ибраһим читенсенде. Хуҗа кешең кунаклар татулыгы өчен дә яна бит әле. Шуңадыр ул, ничек кенә булса да араны җылытырга теләгәндәй, самоварга ябышты. Бераздан өйгә сәйлүн чәенең хуш исе җәелде. Ибраһим бая ук ачарга маташкан шешәсен чыгарды. Тик биленә аклы япкан, Әхмәт әйтмешли, «пыяла самовар» бу юлы да муенын сузып утырып калды. Барыбызны да тыкырдатып мәктәпкә алып киттеләр.

Таш баскычтан күтәрелүгә, каршыма юантык гәүдә басты.

— Тукта, таптап үтмә. Без кайтарттык сине, понимаешь.

Игътибар итсәм: Гамир! Кара нинди эшлекле кыяфәткә кергән. Гәүдә белән бергә тавыш та калынайган, олыгайган. Ул арада башкалар сырып алды. Китте кул кысыш. Әйтерсең беркем беркая китмәгән, барысы да үз урынында. Монысы кем соң?.. Фу, шайтан, Нурулла мыек җибәргән икән. Боларын уйлыйм гына, тыштан вәкарь белән эре тотам үземне. Бөгелми-сыгылмый күрешәм. Әйдә, башкалар гүелдәшсен. Килешми ул кадәр шау-шулар. Ул арада кыңгырау шалтырады.

— Иптәшләр,— диде арадан бер таныш тавыш,— залга түгел, классыбызга узыйк.

Карасам, әлеге тавыш без кереп тула башлаган классның түреннән ишетелә. Чү, тавыш кына түгел, Мөслимә ич бу. Элеккегә карый аз гына тартылган. Өстендә ак якалы кара костюм. Түшендә ромба-значок. Мин аның директор булып эшләгәнен ишеткән идем инде. Әгъләм абзыйның шушы нечкә тавышлы кызы мәктәп тиңенте мәктәпне тота диген, ә?

— Барыгыз да элекке урыннарыгызга утырыгыз.

Уртагарак кунмакчы идем дә булмады. Әнвәр белән һаман шул икенче партага кысылдык.

— Иптәшләр,— диде элеккегә карый шактый остарган иркен тон белән директор Мөслимә.— Башланды! Кичәбезнең официаль өлеше ачык. Тәнкәле урта мәктәбен 1954 елда тәмамлаучылар исемлеген тикшерәбез.

— Асфанов!

— Биредә!

Тавыш ягына борылабыз. Һаман шул җырык авызлы Иршат. Тик кара вельветкасын ак курткага алыштырган. Кермәсә дә керми икән кешегә олы сымак кыяфәт.

— Бәйрәмгалин!

— Мин!

Монысына янымдагы Әнвәр җавап биреп утыра. Әллә ул ерелэнгән, әллә мин: янәшә утырып та сүзләр ялганып китә алмый. Себердән кайтканын гына беләм мин аның.

— Гайнетдинова!

— Мин хәзер Мөхәммәтдинова инде!

Тагын көлешү.

— Исмәгыйлова!

Исемен ишеткәч, күңелдә бер юксыну сыманрак нәрсә тугандай итте, буш партага тагын бер карап алдым.

Шул арада чар итеп ишек ачылмасынмы һәм шуннан теге вакыттагы үпкәчел кызыйныкына охшаганрак бер тавыш ишетелмәсенме.

— Мин ул! Керергә рөхсәтме?

Барыбызны да барлап хуҗа булып утырган Мөслимә, кинәт ут чыккандай дөньясын онытып, ишеккә атлады.

— Лен...за!!

— Мөслимәү!

Кочаклаша-елаша ишек артында ук калдылар.

Тагын көлеш. Әй, егетләр! Менә сиңа директор диген, ә? Хет, әллә кем булсын бу җенес, һаман шул җисемен саклый. Беләсе иде, каян кайтты икән соң тегесе? Кыяфәте, килеше болай бер дә далада үз иркендә яшәүчегә тартмаган.

Кемнәр янында утырам, кемнәр булып беткәннәр соң бу Тәңкәле малайлары?

Сорауларыма җавапны табында таптым.

Шампан шәрабы ачылганчы дип дилбегә буе доклад сөйләргә теләүчеләр бар иде — кыскарттылар. Егетләр элеккечә кыюлар, туры әйтә торганнар. Күрешү секундлары болай да санаулы, вакытны бәрәкәтле тотыйк, диделәр.

Яшермим, моңа кадәр мин үземне арада бәхетлерәк, кызыклырак язмышлылардан саный идем. Күрешү кичәбездә дә игътибар уртасында булачагымны сизенеп, кыенсынуларым юкка чыкты. Чәүкә жылатып, мәтәлчек атып үскән шалкан караклары сезме бу, дип акаеп калдым. Элекке класс житәкчебез Җамал апаны күр әле син, кайсыбыз кайларда яши, ничек яши, нәрсә эшли, ничек эшли — каңгылдап, бәбкәләрен барлап торган ана каз кебек тикшерепме тикшереп тора икән шул. Кемгә файдага, кемгә заяга үткән унбиш елга исәп-хисапны ул ясады.

— Яшьләр,— диде ул элеккечә ягымлы, әмма нык тавыш белән,— дөньяның бар тоткасы сезнең кулда. Я, мисаллар да китерик, ди. Районыбызда «Урай» дигән атаклы колхоз бар. Сезне тәрбияләп үстергән колхоз ул. Аның шундый дәрәҗәгә менүенә сезнең класс зур өлеш кертте. Мәсәләнме? Мәсәлән, аның председателе... Безнең Гамирыбыз ич.

Моңа чаклы сәдәфләрен ычкындырып, киерелеп утырган председатель, үз исемен ишеткәч, каешын тарткалап, төзәтенеп куйды.

— Ә син, Асфанов,— диде Җамал апа, һаман шул яктан күзен алмыйча,— кызарлык эш булганы юк бит әле, нигә кулмакчан калдың?

Гел ерык Илшатка кызару килешә икән, кыяфәтенә бераз житдилек кунды. Урындык артына япкан көлсу пиджагын иңенә салгач, гөрләтеп кул чаптык. Ох сине, шымытыр малай. Түшенә Хезмәт Кызыл Байрагы ордены такканнар бит.

— Күрдегезме? — диде Җамал апа, бер безгә, бер орден иясенә карап.— Менә шундый бригадирлары да бар бу колхозыгызның.

— Әнвәр,— диде аннан соң укытучыбыз, чәчләре көмешләнсә дә, әле бер дә сүнәсе юк үткер күзләрен безнең якка сирпеп,— синең кем икәнеңне тәбрик открыткаларыңдагы кайтарма адресларың ук сөйләп тора. Новосибирскидагы академиклар шәһәре кешесе бу! Күренекле Себер галимнәренең берсе — безнең Әнвәребез булыр дип кем уйлаган.

Мин бер мәлгә шундый халәт кичердем: кешене кара әле, тик ятмаган, үзенең кайда, кем икәнен белгертеп торган икән. Алай дисәң, шундый зур эшләр белән мәшгуль Әнвәрнең мактанчыкка әверелүе мөмкин түгел. Мин бу керле уйларым белән үземнең хөрмәтле кешеләремә карата игътибарсызлыгымны гына аклап маташам. Күпме укытучылар, иптәшләр, дус-ишләр бар. Шуларны Яңа ел алдыннан гына булса да берәр искә алганым бармы? Юктыр. Кунак ашы — кара-каршы, андый тәбрикнамәләрдән без үзебез дә мәхрүм.

Укытучы дигәнең дә хәйләкәр, хатаңны тикшереп, исеңә төшереп кенә тора. Аңлашылды бу, Җамал апа, искә алырбыз без аны киләчәктә.

Шулай итеп, чират миңа да житте, Мөслимәләрне дә узды. Дәвам итте.

— Кичә генә «Ык ягы» газетасында «Механизатор» дигән очерк укыдык. Шуның герое кем дип уйлыйсыз?

Башлар өстәл почмагынарак сыенган Нажиягә таба борылдылар.

Ниһаять, күзләр Лениза ягына күчте. Моңа кадәр кыймыйчарак кына утырсам да, кешедән күрмәкче, мин дә шул якка кыегайдым. Хатын-кызны теләсә олыгайта, теләсә яшәртә торган чәч бар. Фасонлы прическа аны кызый иткән. Тик изүе ябык килешле күлмәге һәм муенына аскан чылбырлы алтын сәгате генә затлы кунак икәнен сөйли. Матур күзләре элеккечә көләч булсалар да, кыяфәтенә үз дәрәҗәсен белә торган тотнаклык сеңгән.

— Күрәле, Лениза, сез озаткан корыч айгырларны классташ егетләрең ничек иярли.

Мин сорау тулы күзләремне Җамал апага төбәдем: «Бу ни дигән сүз тагын? Монысын ничек аңларга?»

Шуны сизенепме, класс житәкчебез Лениза исеменә озаграк тукталды.

Шул китүдән кайтмаган икән качкын кыз. Башта далада яшәгән, чирәм күтәрешкән. Ике-өч айлык курстан соң әнә шул беләзекле, балдаклы кечкенә йомры куллары белән комбайн руленә ябышкан.

Хезмәтенә карап хөрмәтен алган. Укуын тансыклаган тырыш кызыйны институтка совхоз үзе озаткан.

Башың әйләнерлек яңалык: инженер-металлург Лениза Харрасова— Павлодар трактор заводында конструктор.

Йөзем шәрабын да уймак рюмкадан гына йотучы абзагыз бүген узынып китте: бер-бер артлы яртышар стакан коньяк жибәрдем. Кыстауга чыдый алмаудан да түгел, исерәсе килеп тә түгел. Болай да башка киткән очрашу тәэсирләреннән айныр өчен чөмердем мин ул йолдызлы зәһәрне. Болганды баш, буталды фикер, нәрсә дигән әле бер акыллысы: эчә белергә дә кирәк! Шулай да аз гына үз дөньямнан ычкынып ике арада айкалып алдым.

Кем идем мин, кем мин хәзер?

Гомерем буе кешеләрдән гаеп эзләп, гаеп түгел, тырнак астыннан кер эзләп, эзләп түгел, күзләп һәм шулардан гыйбрәт җыеп, үземне кисәтеп яшәдем: менә болай булмаска, алай эшләмәскә, аны дус итмәскә, моны иптәшкә санамаска.

Кыскасы, минем канымда сеңгән бер омтылыш бар, башкалар теләсә нишләсен, әмма мин киртәмнән чыгарга тиеш түгел. Менә шушы нәрсә мине җитәкләп йөртте. Чокыр-чакырны читләп уздым — тәгәрәвең бар, текә тауларга үрмәләмәдем — мәтәлләвең мөмкин. Мәхәббәтнең кайнарыннан качтым — яну бар, үткен конфликтларга кермәдем — сынуың мөмкин. Дошманнар ишәйтмәдем, дусларга ачылмадым. Әнә шулай гел бер төсле «тәүфыйклы» гына яшәгән булып, берәү әйтмешли, «ни пычагымны» кырдым. Менә бу озынча өстәлне сарган иптәш классташларым арасында нәрсәм яхшы минем?

Алтыдагы алтмышка бара, ди халык. Бераз салган баш белән мин уйлыйм: канга сеңгән холык-фигылеңнән утыз бишкә җиткәч айнып буламыни?..

Кая соң әле үзе, үзе?.. Күңелнең бер почмагы кытыкланып куйды. Якамны турылап, чәчләремне ыспайлап сыпырам да каш астыннан гына шул якка карыйм һәм катып калам. Аның да күзләре миндә. Тик безнең күзләрдә беренче очрашканда кабынып киткән беренче очкыннар юк инде. Алар бер-беренә үз итеп, кызык итеп, әз генә сагынышып караштылар. Андый чакта музыка гына уйнасын. Моны, куанычы, үткәне, хәзергесе барысы бергә кушылып җырга әйләнә. Мин сабырлык белән шуны көттем һәм морадыма ирештем. Нурулланың баяны элеккедән дә шәбрәк сайрап җибәрде. Күңелләрне оеткыч «Ык буйлары»н өздереп алды да дәртле Чистай вальсына күчте! Кузгалдым. Утырганда сиздермәсә дә, аякка баскач әз генә тулганылды. Ничек тә сер бирмәскә, чигенмәскә иде.

Ипләп кенә атларга тырыштым һәм аның йөзенә, бөтен кыяфәтенә нур коеп торган елмаюлы күзләренә карап сүзсез генә «әйдә»гән булдым. Шунда мин бу карашларның үзгәлегенә тагын бер кат инандым. Сөрмә тартмый да сөрмәле бу күзләр һаман да сөйкемле... Тик алар миннән элеккечә оялып качмыйлар, елмаеп түгел, кычкырып көләләр, әллә шатлыктан... Әллә миннән...

— Ой, Гомәр, синең белән дә бисе көннәр бар икән.

Шундук тапкыр җавап таба алмадым. Аның каравы, килешле җыйнак гәүдәсен, ватыла күрмәсен дигәндәй, өф итеп кенә үземә тарттым да бөтереп алып киттем. Дәртле музыка көчәя төшкәч кенә колагына: «узган кичәдән үзең качып киттең ич», дип пышылдаган булдым. Ә ул миннән чак кына ычкынып киткәндәй итте дә, башын артка ташлап, кеткелдәп куйды.

— Көнләштермәскәең!

Юк, бу көлү генә түгел, бу миңа ирония булып яңгырады. Болай да биленә тиям-тимим дип торган кулларымны бушаттым да, күңелдә ни барын бер сүз белән әйтеп ташладым:

— Үзгәргәнсең син, кызкай.

— Ой, Гомәр, чынлап әйтәсеңме син моны?

— Теләсә ничек аңла!

— Шулай да?

— Яшәргәнсең, чибәрләнгәнсең, әлләкемләнгәнсең...

Лениза назлы сыны белән күкрәгемә сыенгандай итте дә тагын пышылдап кына көлде.

— Юләр малай! Син дә мондый тел бистәсе түгелиең бит.

Мин әллә нишләп киттем, каным кайнап табан асларыма кадәр йөгерде. Үз адресыма «юләр», «тел бистәсе» кебек чүп-чар сүзләр кабул итүче түгел мин. Бу юлы алар мине иркәләп үртәделәр. Шушы залда, бөтен кеше алдында биленнән шытырдатып кысасым һәм үртәгеч күз-

ләренә карап: «Теләсә ни әйтсеннәр, бүгенгә син минеке!» — дип кычкырасым килде. Ормас олы күсәк күтәрер ди, шуның сыман, минем кулдан килә торган эшме шул. Музыкасы да башта әллә кайчангы хәлләрне яңартып шашындырды да, юләрләнеп куймагае бу тагын дип, шып туктап калды. Миңа да акыл кереп китте.

Ленизаны терсәкләреннән тотар-тотмас кына урынына илтеп куйдым.

Беренче мәхәббәт, беренче гайбәт дигән нәрсәдән мин дә мәхрүм түгел икән, бар икән ул. Чынын-шаяруын бергә кушкан үртәгеч сүзләр, инде мин синнән оялмыйм да, курыкмыйм да, син минем нииндилегемне, шаять, төшендең дигәндәй, ятсынмый төбәлгән туры карашлар һәм шуларны куәтләп вакыт-вакыт ялтырап алган атсыз бармактагы алтын балдак тынычлыгымны алды. Йокыга китә алмый гаҗиз булдым. Күңелгә нииндидер өметсез хыяллар инде.

Иртән дә айный алмадым бит әле мин алардан. Дөресрәге, бу исерткеч тәэсирләр миңа көлке дә, рәхәт тә иде. Иртән Мөслимәләр чәйгә дәшкән булганнар. Йокласын әле, кала кешесе соң торучан, дип уятмаганнар. Зерә уятмаганнар. Ник бармаска, бара идем. Ул анда түр башында утырачак иде, әлбәттә. Тагын бер үртәлгән була идем шул миндаль күзләрдән.

Төшке ашка Гамир чакырган иде. Кайтышлый Нуруллалар алып керде. Әхмәтләргә кагылдык. Ирләр төркеме диптер инде, кызлар берсе дә иярмәде. Лениза да үтенеп-үтенеп чакыруларын кире каккан. Өйләрендә пешеренәсе бар, ди, кичкә үзебезне чакырмакчы, ди.

Турыларындагы карт өянке аз гына аяза башлаган уйларны тагын чуалтты. Әллә ул чүккән, әллә мин бераз үскән — башым картайган бәсле ботакларына орынып китте. Әйтерсең ул мине таныды да гаҗәпләнүеннән кагынып куйды. Иңнәремә шыпы-шыпы килеп кар бөртекләре коелды. Гүя алар миңа, кайда йөрдең моңарчы, күзләр үтте, хәзер кыш житте инде, кышшш дип пышылдаштылар...

Бирешкән Шакир абый. Моңа кадәр минем өчен кырыс табигатьле, гайрәтле, рәсми кеше саналган карт укытучының олы башын кече итеп капкалар ачып каршылавы болай да шушы якка авышкан күңелне алгысытып куйды. Әнисе Закирә апа да кече яктан ярты эшен ташлап атылып чыкты. Тик кызлары гына алай ватылмады. Һаман шулай кинаяле елмаеп пальтомны эләргә булышты. Ничек кенә булмасын, әмма кәефне ача торган җан рәхәте тойдым мин үземдә. Бу минутта аның үз итеп каршылаган чал атасы да, кунакчыл анасы да, хәтта чакырылган кунакларына кадәр сөйкемлеләр иде минем өчен. Тик өстәл кырында күңелгә шом салучы ят хәбәр булып ярты битле телеграмма гына ята. Минем шулай кырын-кырын күз аткалавымны сизепме, Шакир абый аны өстәлдән алып тәрәзә башына кыстырды:

— Кияү телефонга чакырган. Ашыктыра бугай. Бер кулыңнан ычкынгач, баш була алмыйсың икән кызыңа.

Барысын да беләм бит инде, югыйсә. Иргә чыгуын да, кызы барын да ишеттем һәм бу очрашуның язылмаячак бер генә пәрдәлек драма булып калачагы да ачык. Әмма менә бу моментта бер дә әйттерәсе килмәгән иде лә Шакир абыйдан шул кияү сүзен.

Таралышыр чак житте. Сөенечкә каршы, Лениза да безнең белән бергә җыенды. Тәбәнәк үкчәле җылы читекләрен, килешле итеп тегелгән кыска-кысмыр тунын, колакчынлы нерпа бүреген дә киеп җибәргәч, бөтенләй яшь кыз булды да калды.

— Сезне озатышлый почтага кагылам,— диде, тәрәзә башындагы телеграммага үрелеп.

— Почтага барышлый, сезне дә озаткан булам диген инде.

— Икесе дә дөрес,— диде Лениза бәхетле тавыш белән.— Сезне онытгым дип, аны да онытырга ярамас.

Гомергә шул аның: әйтсә кистереп әйтә — уйларга калдырмый. Язса өздереп яза — күп нокталар куймый.

Култыклап булмасмы дип янәшәрәк бардым да, өмет өзелгәч, артка калгандай иттем. Алар сөйләшеп сизми калдылар. Мин юри артка калдым.

Дөресен әйткәндә, һаман шул өянке тартты мине үзенә. Яшьлек чирканчыгын шушында алдым — кызлар ирененең тәмен шушында татыдым. Бәлки ул бүген дә узган егет чакларның бер-ике секундын әҗәткә генә булса да кире кайтарыр. Соңгы тапкыр тагын бер генә кат күтәп аласы иде лә үзен шушы өянке төбендә. Әйтәсе сүзем бар кебек, шуны әйтми китсәм, мәңге үкенермен сыман. Ләкин нәрсә ул? Нинди сүз? Нәрсә турында? Хәзергә ачыкланмаган. Каршыма гына килеп бассын, тел үзеннән-үзе чишелер сыман. Мин элекке оялчан, шикчел, әбисе сүзеннән чыкмый торган Гомәр түгел инде.

Төне дә минем буталчык уйларым кебек болытлы. Ае да болыт артыннан үрелеп бер карый да тагын яшеренә...

Озак көттермәде үзе. Әнә борылып та кайта. Аның атлавы. Кешенең йөреше, кыланышы беркайчан да үзгәрми бит. Гаепле кешедәй, өянке артына постым... Үткәнем һәм бүгенгем алдында фәрештә түгеллегемә шушы йолдызсыз төнне, шушы агач төбендә төшендем түгелме мин?!

Адымнар якынлашкан саен кар ныграк шыгырдый.

Нишләргә? Каршына чыгып бассам, курыкмасмы? Тәвәккәллим булмаса, бер-ике... узды... Тукта...

— Лениза, бер генә минутка...

Ул борылды да шаккатып калды.

— Гомәр... Нишләвең бу? Кемгә саныйсың син мине?

Ул боларны, кеше-кара ишетмәсен диптер, пышылдап әйтте. Миңа шул җитә калды, кыюлана төштем:

— Алай ук димә инде. Болай да ансат түгел миңа. Бер генә минутка, бер генә сүз әйтәсем бар, бер генә соравыма җавап бир, бер генә минут сөйләшеп тор син минем белән, бер генә...

Бу минем гомеремдә беренче мәртәбә күңелдә ни барын телгә ни килә шуның белән аңлатырга тырышу иде.

— Гомәр, эчмәдең дә бит син, кай арада исереп өлгердең соң?

— Теләсәң ничек аңла. Тик бер генә, бер генә сүз әйт миңа: бармы хәзер күңелеңдә хет бернәрсә миңа карата?

Кыяфәтенә, үзен тотышына караганда, кычкырып бер кешеләргә һәм капкасын шакылдатып кереп китәргә тиеш иде. Әмма алай итмәде. Хәтта сакланып кына янымa килде:

— Әллә син бәхетсезме?

— Белмим.

— Чынлап торып?

— Моңа кадәр бу хакта уйлаганым юк иде.

— Соң?

— ?!

Ул авыр гына сулап куйды да кинәт бөтенләй ят икенче тавыш белән сорап, сорап кына да түгел, әйтеп салды:

— Башта үзең җавап бир: бар идеме соң синең үзеңдә хис дигән нәрсә теге чакларда?!

— Белмим.

— Алайса бел. Юк иде, Гомәркәем, тамчы да юк иде ул чакта синдә ярату, дуслык, иптәшлек дигән нәмәрсәләр.

Һәр кеше үз башыннан әрнешле бер чир кичерә. Инде тәмам терелеп, онытылып беткәч тә искә төшердеңме, яңадан яңара шул сызлау-

лар. Мин дә Ленизаның әнә шул искә төшерергә яратмаган кичерешләренә орындым бугай.

Туры карарга кыймыйм, шулай да сизеп торам, күзләре зәһәрләнде, тавышы пышылдап түгел, чыжылдабрак чыга башлады.

— Үлеп яраттым бит мин сине, Гомәр, ул чакта, ышанасыңмы, акылдан шашып. Ой, бик кирәк нәрсә бит ул кызларга сизгерлек. Ләкин яшьлек юләрлеге белән мәхәббәт бергә сыеша алмый, күрәсең. Берсен дә сизмәдем мин. Яратмавыңны да, иптәшләр алдында сәламемне алырга хурлануыңны да, гөрбиянлыгыңны да сизмәдем. Минем белән кызык өчен генә, кызлар белән йөргән исемне алу өчен генә очрашуыңны да сизмәдем. Ой, сизмәдем. Чөнки мин сукыр булганмын. Синнән башканы күрмәгәнмен. Чөнки минем өчен дөньяда синнән дә акыллырак, синнән дә батыррак, синнән дә сөйкемлерәк, синнән якынрак беркем юктыр шикелле иде.

Чынлап әйтәм менә, бик газиз идең син миңа ул чакларда.

Шулай бервакытны, хәтерлисеңме икән, киноға барырга сүз куештык. Мин анда синең белән янәшә түгел, син утырган эскәмиянең икенче башында утыруны да олы бәхет саный идем. Без кызлар белән клуб ишеге төбендә басып калдык, син малайлар белән, этә-төртә, алдан кереп киттең, кемнәргәдер урын алып куйгансың, безне утыртмадың. Ә үзең, кино бетүгә үк кайтып киткән иттең дә, берни булмагандай, шушы өянке төбендә көтеп алдың мине.

Ә менә бервакытны, монысын гомеремдә онытасым юк, мәктәпкә таба киткәнеңне шәйләп алгач, кайтуыңны үзем сагалап утырдым. Очрашу өчен генә түгел, гәүдәңне булса да күреп калу өчен. Озак көттердең. Инде кереп китим генә дигәндә, йөрәк сулкылдап куйды — күземә күренәсеңме дип торам, син бер кыз белән килеп тә җиттең, күрмәмешкә салышып узып та киттегез. «Күрдең бит, ник туктатмадың, ник алып калмадың минем Гомәремне?» дип, өянкемне кыйный-кыйный үксегәнем искә төшсә, хәзер дә әллә нишләп китәм.

Нигәдер, шул ук вакытта бик ышанасы да килмәде моңа. Ничек инде, син кешегә санап йөргән кеше, синең тумыштан таныш классташың, яраткан кешең шундый түбәнлеккә төшсен, ди. Очрашасы килми икән, кем көчли аны, аңлатырга теле бар, язып бирсә, кәгазь бар.

Үз-үзеңне юату кызык кына бит ул. Болай гынадыр ла, дисең, миңа гына шулай тоеладыр, дисең.

Сабырлыгымны җуеп, чыгарылыш кичәсен көттем. Сине анда күрүгә йөрәгем сикереп чыга дип торам. Үзем сер бирмим, кичәге хикмәтеңне болай гына калдырмыйм әле, дим. Дәшәсең — җавап бирмим, биергә чакырсаң — чыкмыйм. Ә үзем түземсезлек белән сәгатьне күзәтәм. Кайчан гына кичә таралыр да, ничек кенә итеп күрешербез. Әйтер идем әйтәселәремне. Карыйм, бер мәлне син юк булдың. Иптәшләрдән аерылдым да өянкем янына чабып кайттым. Шунда көтеп торасыңдыр сыман.

Көтмәдең, Гомәр җаным, көтмәдең генә түгел, туктамадың да. Тагын узып киттең бит пионервожатыен култыклап.

Тормышта очраган беренче ачы хәсрәтем шул булды минем. Барысына да менә шушы өянке шаһит. Ул яшьлек күгемне сарган болытлардан куе ботаклары белән ышыклады мине. «Сердәшем дә, юанычым да бер син генә калдың. Кичер мине кичәгем өчен», дип кочаклап еладым ул көнне мин аны. Күз яшьләрем вакытсыз коелган яшь яфраклардай сыгылып тамдылар...

Шундый итеп ярата алуыма һәм шуннан котылу өчен өемне, авылымны, хәтта туган якны ташлап китүемә хәзер дә исем китә. Ләкин бу гыйбрәтле истәлектән мин сабак алдым, яшьлек шаукымымны мәгънәсез юләрлеккә түгел, киләчәгем файдасына сарыф иттем. Сагыштан — хезмәт, авырлыктан акыл коткарды мине. Вакыт минем фай-

дага үтте. Ә калганнары үзеннән-үзе килде. Мәхәббәтнең чыны алда булган икән. Үзем генә белми йөргәнмен.

Чын мәхәббәтемне тапканнан бирле көнелдә бер сорау йөри: ничек ярата алдым икән мин сине, Гомәр! Кызлар чибәргә кызыга, алай дисәң, күзләрең күрмәсә, аякларың йөрмәсә дә яратыр кебек тоя идем мин сине ул чакларда.

Ә хәзер... күреп үк торасың, күңелләребез пар булмаган, икебез ике төрле кеше икән бит без. Шуны да бел, юлларыбыз игез булсалар да, бер-беребезне бәхетле итә алмас идек. Шуңа сөеник.

Дөрес, синең үзең өчен генә файдалы сыйфатларың бар — тыныч син, сабыр син, тыйнак син, шау-шусыз син. Шул ук вакытта ярсыткыч кирелегең, пошмаслыгың, кешеләрне саңга сукмавың кемнедер рәнҗетмиме икән? Шулкадәр тирәнгә үтүем өчен гафу ит.

Сиңа булган бу үпкәмне беркемгә бушатмый унбиш ел буе күтәреп йөрдем. Әйдә, сөйләдем инде, синеке сиңа булсын, ишет ишетмәгәнеңне, ләкин... авырга алма.

Менә хәзер миңа җиңел булып китте. Күңелдә сиңа карата үч тә, ачу да калмады. Татуланышып, дуслар булып аерылышыйк, Гомәр. Ни әйтсәң дә син минем яшьлек ядькарем. Сау бул!

Ул миңа күн бияләеннән чыгарып үң кулын сузды. Ә мин аны ычкындырмаска тырышып, бар көчем белән үземә тарттым. Балдаклы бармагын кысып авырттырдым, ахры, ул уфылдап бөгелә төште, ә мин аны ике яңагыннан учлап тоттым да кайнар иреннәрен суырып үптем. Әле моңа кадәр беркайчан да, беркемне дә шундый тәмле итеп үпкәнем юк иде минем...

Соравына күрә җавабы, җинаятенә күрә җәзасы. Әллә ярсудан, әллә суыктан калтыранган бәләкәй учлар шундый гайрәт белән селтәнделәр ки, күзләремнән утлар чәчрәп китте. Бар икән куәт тә шушы биш тотам гәүдәдә! Үзе, мин сиңа әйтим, бер үкенечле эш эшләгәндәй, ялангач учларын кушырып иреннәренә тидерде. Куллары әрни идеме, әллә үзе мине җәлли идеме, белмәдем. Чөнки, ничек кенә булса да, миңа инде барыбер иде. Узасы язлар узган, киләселәре — башкаларныкы.

Кире яктан салкын җил чыкты. Аптырашып, тыңышып торасы юк. Ялганып китәр сүзләр беткән. Башлап үзем саубуллаштым.

— Кичерә алсаң кичер мине, кызыкай. Хуш.

— Ху-у-ш...

Кызулык белән ашыгыбрак саубуллаштым да... Өянкедән ераклашкан саен үкенә бардым: нигә шул санаулы секундларның кадерен белә алмадым инде? Башта югалып калдым, соңыннан үземне тыя алмас дәрәҗәгә җитеп чыгырымнан чыктым. Әйтәсе сүзләр калды кебек. Я, тагын кайчан күрәм инде мин аны?..

Йокларга дип баш төрткәч тә, төне буе үз-үземә урын таба алмый боргаланып чыктым. Урыны да шундыйрак туры килде: олы яктагы ике кешелек тахтада берүзем ауныйм. Икенче көн, икенче төн инде һаман «шул» чыкмый баштан. Үртәүле матур күзләре, шаяртып елмаюлары, хәтта үземне өянке төбенә терәтеп тиргәвенә кадәр китми күз алдымнан. Күш көн, күш төн генә түгел, атналар, еллар буена да шулай уйланып, сызланып ятарга риза, тик аныкы белән янәшә урамда гына булса да яшәсәң иде... Ләкин болар бары хыял гына, буш хыял гына. Ул китә. Барыбер китә, иртәгә үк китә. Кара таңнан торып китә. Аэропортка кадәр Гамир машинасы илтеп куячак аны — шулай сөйләштеләр. Юлдашлар да түгелбез, ичмасам, икебез ике якка, капма-каршы якка сарганбыз юлларны, капма-каршы якка...

Урамнан узган машина тавышына сискәнеп уяндым. Шул машина инде ул, аны олактырып кайтачак машина... Мин йокласын диптер, радиоларын басып торган булганнар. Кыймылдавымны абайлап, кәчәй-

теп куйдылар. Иртәнге концерт, миндәй читтә гомер итүчеләр өчен аеруча тансык концерт бара. Җитмәсә, Илһам Шакиров җырлый.

...Атларда чабып кына-а-а-а...,
Яшьлегемнән килер идем
Тик сине алып кына ла...
Атларда чабып кына...

Заказ биреп юри җырлаталармыни. Уффф, нишләтәләр бит болай да бәйдәге юртак аттай кая керер урын тапмый җилкенгән күңелне...

Кайтыр идем, мин дә кайтып сине генә алып килер идем, әгәр яшьлек дигән ул серле дөньяга кабат кайтып булса. Ләкин булмый, булмый дигәч булмый икән инде ул кулыңнан бер ычкынган бәхет кошың-ны куып җитүләр.

Тагын бер көнгә калдым әле мин Тәңкәледә. Аның өчен дисәң дә була...

Уйламасыннар әле мине яланаяк баскан җиреннән ваз кичкән зимагур итеп. Юктыр, мин бүген алар рәтенә кермимдер.

Төшкә чаклы кунаклар озатышып йөрдем, аннан соң аларның әле суынып та өлгермәгән эзләрен барладым, ә төштән соң авыл почмагындагы зиратка менеп төштем.

Бик читенсенеп, оялып кайттым мин аннан. Бурасы черегән, ләхете иңгәндер, күрәсең — әбием кабере ишелгән булып чыкты. Мине дөнья мәшәкатьләреннән коткарган, ашның кайнарын ашатып, күлмәкнең керсезен кидереп үстергән әбием кабере... Бабам каберен чамалый алмадым, югалтканмын инде...

Кайтышлый авыл аксакалы Мортаза бабайларга тукталдым. Председатель-мазарга йомыш кушып булмас, хуҗалык эшләренә болай да муеннан баткан. Карт-коры исә дөнья шөгыльләреннән азатрак. Чардуганлык хакны шул Мортаза бабайга калдырдым. Әбинең дус карчыкларыннан да исәннәрен очратып фатиха алдым, күңелләре булды. Кайту белән Грузия гөле орлыкларын җибәрермен мин аларга. Әбием каберенә чәчәрләр. Тәрәз төпләренә утыртырлар. Аралашып яшәргә кирәк.

Бу юлы да буш купега эләктем. Мондый кәеф белән ялгыз кайтуың хәерлерәк. Кыш уртасы. Пассажирлар бу чакта аз йөриләр.

Менә шулай, кемнәрнеңдер гайбәтенә төшеп, кемнәрнедер булдыксызга санап, үзеннән бик канәгать булып аунап, йокымсырап килгән ваемсыз абзагыз, өй ягына борылгач, кабаланып чапкан бахбайдай ашкынып кайта. Ашкынып дигәнем шул: юлда гына түгел, тормышта да шактый йокымсыраганмын, ахрысы, мин. Институт тәмамлап, ояна мая салу гына «теләгемә ирештем» түгел икән. Мин моны яшьлектә тин итмәүдән, хәзер буй җитмәүдән насыйп була алмаган мәхәббәтем газабыннан әрнеп әйтмим. Кайчандыр шалкан урлашкан партадаш дустым Әнвәргә сынатуым һәм шуның нәтиҗәсендә аның белән уртак сүз таба алмаудан офтануы дип тә уйламагыз. Кайсыннан кара манчып, кайсыннан өй эше күчереп әзер-бәзергә укып чыккан Әхмәт булып Әхмәттән тәнкыйтьләнүенә гарьләнә дип тә уйлый күрмәгез... Әйтәсе килгән фикерем бераз гына рәсмирәк, ягъни, менә болайрак минем: туган мәктәпкә кайтып остазлар, классташлар белән күрешкәч, кайберәүләргә сокланып, әз-мәз гыйбрәтләнеп, бераз гына сабак та алып өлгергәч, чыгарылыш имтиханда язган иншам искә төште. Ул «Гомер кешегә бер генә бирелә» дип атала иде бугай. Островский әйткән гаҗәеп олы фикернең асылына мин әле генә төшендем. Чынлап та, үз өлешеңә төшкән көмешең — шул бер тотам гомерне нигә кешечә, ягъни булдыклы кешечә, мәсәлән, Әнвәрчә, Ленизача, Әхмәтчә яшәмәскә! Моның өчен йөрәгең икеләтә артык тибәргә, пыскып түгел, кабынып, ялкынланып янарга тиештер.

Әйтерсең мине, шулай тетәп кенә яткан йөрәкне, дөрләтеп жибәрделәр. Күңел төбенә утырган юшкыннарны кубарып, пошмаска әйләнгән жанны уятып давыл сыман нәрсә узды. Шуның галәмәтедер, күгем аязып китте, алда тау кадәр мәшәкатьләр — башланган, башланмаган эшләр калыкты.

Әй, нигә туктады соң әле бу поезд?

Үзем дә инде, шундый ашыгыч чакта, һаман шул тирбәтеп йоклата торган рельслар буйлап үрмәлим. Бәлки самолетка күчеп утырыргадыр?

— Әй, проводник туташ, бу кайсы станция?

Җавабын аңлап бетермәдем, иңемә пальтомны салдым да, чемоданымны эләктереп, тамбурга атылдым. Хәер, кайда төшсәң дә барыбер түгелмени? Эзләгәнеңне күздән ычкындырганчы, куып житүең хәерлерәк. Мин моңа соңлап булса да инана башладым, ахры.

Кысан купедан иркен һавага чыккач, гәүдәм жиңеләеп, күңелем ачылып китте. Мин вокзалдан аэродромга ашыктым.

Самолет мине упкыннар, сахралар өстенә күтәрде. Шул чак, мотор гүләвенә кушылып, бер мәкаль искә төште: әйләнгечтән юл туры...

Түгелдер... Мәкаль дә кешесенә карап иярә. Минем ише һәрнәрсәгә битараф булып, иртә бар, кич бар, ашыгып ни эш бар, дип пошмый яшәүчеләр өчен шәп юлдаш бу. Тик мин аннан бүген ваз кичәм. Әйләнеп-тулганып йөргәнче, дәррәү ярып туры бар икән. Упкыннар аша күпер салыр куәт кимесә дә, ерганаклар аша басма сузар рәт бар аны. Бар, тик...

Шул чак юл мәшәкате белән аз гына читенеп торган «ул» яңадан каршыма килеп басты. Чынлапмы, сынапмы, тутырып караган үткер күзләре, елмайганда гел уйнаклап торган матур яңаклары, кашлы булавкалар белән чормалган калын чәчләре, уртак өянкебез төбендә пышылдаган соңгы сүзләре болай да мең төрле тәэсирдән чуалган башымны әллә никадәр сораулар белән миңрәтте.

Ярый, сабак булсын, моннан соң үз ишләремне иш итеп алар белән бергәрәк атлармын, кайберләрен, бәлки, узармын да, ди. Көрәшергә туры килсә, көч сынашудан авырсынмам. Җиңгән, жиңелгән чаклар да булыр. Адәм баласы шуның өчен яралган. Тик менә күңел битлегенә кара миң булып тамган шушы беренче һәм соңгы мәхәббәтем хакына мин ни кыла алам инде хәзер... Яшьлек чатында бер аймылышкач, нигә кирәге бар иде соң бу очрашуның? Бер шагыйрь әйтмешли, әллә мәхәббәтнең чыны табын узгач кына килә торган кунакмы? Алай дисәң, кай яктан һәм кайчан киләсен ник хәбәр итми икән соң ул? Бер зирәге әйтмешли, башта кадерен белми кире боргач, соңынтын үкенүдән ни файда? Алай дисәң, егет чакта ялтырап киткән гөнаһсыз яшьлек шаукымының еллар үткәч олы мәхәббәткә әверелеп дөрләвендә минем ни гаебем бар соң?

Акланумы бу? Бәлки, шулайдыр. Мин моңа аэропорт капкасы янындагы күрешү вакытында төшендем... «Әтием» дигән кадерле тавыш уйларның бер өлешен сыдырып аткандай тоелса да, яңалары калыкты. Каршы алырга төшкән улым белән ирләрчә кул тотышып күрешсәк тә, әнисенең сагыну катыш ялварулы карашы жавапсыз калды. Ярый әле, кеше күңеле теләсә кем актара торган китап түгел. Шулай да, минем дәшмәвем аңа узгынчы жилдәй бәрелеп кенә узды бугай: аның йөз сызыклары үзгәрмәде. Гүя ки, бу секундларда минем ялгыз түгеллегемнән бик разый булуымны сизенә иде ул. Өебез бусагасын атлагач та, мин бер мәлгә әсәреп калдым: түребез иркенәеп, түшәмебез биегәеп, тәрәзәләребез яктырыбрак киткән сыман тоелды миңа.

Бу минем гаиләм, якыннарым, тормышым белән яңача күрешүем, дөньяма сагаеп түгел, үз итеп, яратып карый башлавым иде, ахрысы.

## Роберт Бернс

*Шотландия унбишенче гасырда ук инде чын мәгънәсендә олы шигърияте ил була. Ләкин зур фаҗига туа — ил, үзенең бәйсезлеге белән бергә, әдәби теленнән дә мәхрум кала. Рәсми тел итеп инглиз теле санала башлый. Ләкин халыкның җанын үтерү мөмкин түгел. Ә халык җаны — аның җырларында, әкият-дастаннарында. Рәсми рәвештә тыелган шигърият әнә шул җырларда, әкият-дастаннарда, телдән-телгә күчеп, үзенең яшәвен дәвам итә. Телнең сакчылары — шагыйрьләр. Һәлакәткә дучар ителгән шотланд телен яклап, аңа гомер даулап, шагыйрьләр күтәрелә. «Шотланд Горацие» дип йөртелгән шагыйрь Аллан Рамзей, егерме дүрт яшендә акылыннан язып һәлак булган Роберт Фергюссон, шотланд халык иҗатына таянып, рәсми канунга каршы набат сугалар.*

*Тик халыкның чыннан да үз шагыйре, безнең Тукайча, милли телнең бөтен гүзәллеген аңлаган, тойган, халыкның ачы хәсрәтен, җиңелмәс рухын җырлап бирә алырдай шагыйрь тумый әле.*

*Ниһаять, 1759 елның 25 январенда Аллоуэй дигән кечкенә авылдагы салам түбәле балчык өйдә Роберт Бернс туа.*

*Ул көнне Шотландия үзенең мәңгелек горурлыгы булачак, шотланд теленә үлемсезлек китерәчәк кешенең дөньяга килгәнен белми, әлбәттә. Үсмер Роберт рәсми тел— инглиз телен искиткеч яхшы белүе белән сокландыра. Укытучылары аны инглиз теленә, бөек инглиз әдәбиятына гашыйк итәләр. Эшләр шулай дәвам иткәндә, мөгаен, Роберт Бернс классик инглиз стилендә иҗат итә башлаган булыр иде. Ләкин дөньяда тиңдәше булмаган бердәнбер укытучы — ана бар. Ул гап-гади батраклар, фермерлар сөйләшкән, канун тарафыннан «урам теле» дип исәпләнгән телдә борынгы җырлар җырлый, искиткеч матур әкиятләр сөйли. Һәм шушы укытучы башкаларны җиңеп чыга.*

*Роберт Бернсның хатыннан бер өзек: «Безнең авылда шундый йола бар: иген урган чакта егетләргә ярдәм итәр өчен берәр кыз бирәләр. Миңа унбиш яшь тулган көзне ярдәмчем үземнән бер генә язга яшьрәк гүзәл бер кыз иде... Мин беркайчан да Неллига яратуымны сиздермәдем... Ул искиткеч матур җырлый иде. Ул яраткан көйгә беренче мәртәбә үземнең тойгыларымны рифмага салып әйтергә омтылыш ясадым... Китаптагы шигырьләрне бары тик грек яки латин телен белүчеләр генә яза дип уйлый идем, әлбәттә. Ләкин кыз... фермер язган җырны җырлый, ул рифмалаганны нигә миңа да рифмалап карамаска, ул миннән акыллырак түгел бит әле... Минем өчен мәхәббәт һәм шигърият әнә шулай башланды...»*

*Абыйсы Гильберт бик еш кына сабан артыннан баручы Робертның нидер мыгырдап барганын ишеткәли. Ә икенче көнне шәһәрләр, авыллар буйлап өр-яңа җыр тарала. Кешеләр аны бер-берсеннән отып алалар. Бернс үзенең җырында мәсхәрә иткән дошманнардан көлә. Халыкка җыр аларның үзләре өчен, алар исеменнән язылган кебек тоела.*

*Егерме җиде яшендә Роберт Бернсның «Ике эт» дигән беренче җыентыгы басылып чыга. Шаян шигырьләрдән торган алты йөз данәле бу китап берничә көн эчендә таралып бетә.*

*Шагыйрьнең даны бөтен илгә тарала.*

*Лондон газеталары Роберт Бернс исеме белән чуарлана.*

*Әмма Бернс көчеп килгән Эдинбург шәһәренең аксөякләре, шагыйрь белән бик нык мавыксалар да, аның бөек шагыйрь икәнен танырга теләмиләр. Ниһаять, Бернс өчен дә Тукай фаҗигасе башлана. Наширләр сөлек булып аның йөрәгенә кадалалар.*

*1787 елда Эдинбургта басылган шигырьләр җыентыгын Лондон, Бельфаст, Дублин наширләре күчереп баса. Ләкин барлык акча Бернсның Эдинбургтагы нашире кесәсенә керә.*

*Бернс Шотландия буйлап зур сәяхәтләр ясый. Әмма яңадан «иске дусты» — сабан янына әйләнеп кайта.*

*Бернсның соңгы авыр еллары Дамфриз дигән бәләкәй генә бер шәһәрдә үтә. Француз революциясе. Бастилия җимерелгән көннәр. Ирекне яклап тавыш бирүчеләрне бөтен Шотландия буйлап эзәрлекли башлыйлар. Бернсның сөргеннән котылып калуына сәбәп бер генә: ул, хисләрен яшереп, рәсми шигърият белән шөгыльләнә. Бер үк вакытта лирик шигырьләр дә иҗат итә.*

*Үләренә ун көн калгач, шагыйрьне түлисе бурычлары өчен судка бирәләр. 1796 елның егерме беренче июле көнне, иртәнге сәгать биштә, утыз җиде яшьлек даһиның күзләре мәңгегә йомыла.*

*Шотланд иле шагыйрь үлгәннән соң гына кемне югалтканын аңлый. Тукай әйтмешли:*

> *Бармыни бездә гомумән чын кеше кадрен белү?!*
> *Без аны кайдан белик, мескен, үлеп аңлатмагач?!*

*Кайчандыр, күпмедер бурычы өчен шагыйрьне судка биргән Шотландия бүгенге көндә шагыйрьгә исәпсез-хисапсыз бурычлы. Шагыйрьнең шигырьләре иленең даны, горурлыгы булып һаман саен еракларга тарала тора. Шагыйрьнең каберга кергәненә инде гасырлар үтте. Ләкин аның тавышы заман узган саен биеккәрәк күтәрелеп яңгырый.*

## Тауларда минем йөрәгем

Тауларда минем йөрәгем... һәм мин үзем дә
Очам-чабам шул тауларда болан эзеннән.
Болан, кәҗә өркетәм мин, табам да эзен,
Тауларда минем йөрәгем... Түбәндә үзем.

Сау бул, минем туган җирем, төньягым минем,
Батырлык һәм дан ватаны, әй, туган илем.
Дөнья буйлап язмыш мине куып йөртсә дә,
Улың булып калырмын мин — гүргә кертсә дә!

Хушыгыз, тау түбәләрен каплаган карлар,
Хушыгыз, тау үзәннәре, упкыннар, ярлар,
Хушыгыз, упкын өстендә моңсу урманнар,
Хушыгыз, урман чишмәсе көйләгән моңнар.

Тауларда минем йөрәгем... һәм мин үзем дә
Очам-чабам шул тауларда болан эзеннән.
Болан-кәҗә өркетәм мин, табам да эзен,
Тауларда минем йөрәгем... Түбәндә үзем.

## Сәфәрче төн кунган йорт

Тауга энгер төште, мин кичектем,
Гыйнвар җиле исә, бозлы кар.
Кунар урын тапмый арып беттем,
Бикләнгәннәр төнгә бар йортлар.

Бәхетемә, өстен буран сарган
Кыз очрады — күңел яктырды.
Ул, оялып кына, үзе торган
Ышыктагы йортка чакырды.

Түбәнчелек белән мин баш идем,
Йолып калган өчен бураннан.
Хөрмәт белән аңа болай дидем:
— Урын җәеп бирче, багалмам.

Җыйнак ятагына нәфис, юка
Ефәк җәйде, шәраб китерде.
Теләде ул миңа тыныч йокы,
Ә урамда буран үкерде.

Аерыласым һич килмәде минем,
Чыгып китмәсен дип янымнан:
— Мөмкин булса, берәр мендәр,— дидем,—
Китермәссең микән тагын да?

Миңа ап-ак мендәр алып килде,
Баш астыма салды, шул чакта
Бик матур, бик ягымлы иде —
Кысып алдым үзен кочакка.

Каннарына капкан кайнар утлар
Йөгерде күк ике битеннән:
— Әгәр мине яратсагыз, зинһар,
Кагылмагыз миңа, үтенәм!

Чәче сары, сүс төслерәк иде,
Колмак кебек бөдрә, дөресе,
Гөлләрдән дә хуш ислерәк иде
Миңа урын җәеп бирүче.

Күкрәкләре исә әйтерсең лә
Иртә кышның җиле, талпынып,
Үз сулышы белән шушы төндә
Өеп куйган ике калкулык...

Назладым мин иреннәрен үбеп
Урын җәйгән кызны бу төнне,
Саф иде ул тау бураны кебек,
Саф иде ул ак кар шикелле.

Ул әйтмәде миңа каршы сүзләр,
Башын салды минем кулыма,
Йомык иде бу ягымлы күзләр —
Ул йокыга талды соң гына.

Кояш әле чыккан гына иде,
Тагын сөйдем аны, яраттым.
— Харап кына иттегез бит! — диде,
Мин чәчләрен аның тараттым.

Үптем аның яшьле керфекләрен,
Колмак төсле ефәк бөдрәсен,

Әйттем: — Бик күп тапкыр эле, бәгърем,
Миңа урын җәеп бирерсең.

Аннан көмеш энә алып кулга,
Шул яп-якты гыйнвар таңында,
Озатканчы мине олы юлга,
Күлмәк текте тәрәз янында.

Саный вакыт көннәр, елларымны,
Гөлләр ачыла, буран себерә...
Урын җәеп биргән шул ярымны
Онытмамын ләкин гомергә!

## Финдлей

— Кара төндә кем ул шакый?
«Кем булсын, мин —
Финдлей!»
— Кайт өеңә. Барсы йоклый!
«Ә син?» — диде Финдлей.

— Курыкмыйча ничек килдең?
«Килдем!» — диде Финдлей.
— Әллә нишләвең бар синең...
«Бар! Бар!» — диде Финдлей.

— Сиңа ишек ачсам әгәр...
«Я, ач!» — диде Финдлей.
— Йокы булмас таңга кадәр!
«Булмас!» — диде Финдлей.

— Сине өйгә керттем исә...
«Я, керт!» — диде Финдлей.
— Чыкмассың шул төн үтмичә.
«Чыкмам!» — диде Финдлей.

— Төн үткәрсәм синең белән...
«Үткәр!» — диде Финдлей.
— Тагын килерсең син, беләм,
«Тагын!» — диде Финдлей.

— Бергә йоклаганны, мәгәр...
«Бергә!» — диде Финдлей.
— Син ләм-мим кабергә кадәр!
«Була!» — диде Финдлей.

ЗӨЛФӘТ тәрҗемәләре.

●

Син мине ташладың, Джеми,
Мине ташладың.
Гомергә ташладың, Джеми,
Әйе, ташладың.

Син шаяртып кына йөрдең,
Бәгърем, алдадың.
Мәңге сөяргә сүз бирдең,
Аннан ташладың, Джеми,
Аннан ташладың.

Без бергә булмабыз, Джеми,
Булмабыз бергә.
Беркайчан да без, Джеми,
Булмабыз бергә.
Тизрәк салсын иде мине
Үлем кабергә.
Мин йомар идем күземне,
Мин йомар идем, Джеми,
Гомер-гомергә!

●

Кырларның янгыр, карларын
Сиңа тидермәм,
Дустым, тидермәм.
Җиләнем белән капалармын
Кышкы җиленнән,
Зәмһәрireннән.

Әгәр газаплар китерсә
Язмышың синең,
Язмышың синең,
Мин әзермен бүлешергә
Җан дусым минем,
Җан дусым минем.

Калсам да киң далаларда
Караңгы төндә,
Караңгы төндә,
Кояш табармын анда да,
Без булсак бергә,
Без булсак бергә.

Ник бирмиләр миңа шунда
Бөтен җир шарын,
Бөтен җир шарын.
Мин тик синең белән генә
Бәхетле, ярым,
Бәхетле, ярым.

РӘДИФ ГАТАУЛЛИН тәрҗемәләре.

## Җыр

Көттермәм мин сине,— сызгырырсың, яме,
Көттермәм мин сине,— сызгырырсың, яме,
Әрләсен әниләр, әрләмәгәйләре!
Көттермәм мин сине,— сызгырырсың, яме!

Тик безгә килгәндә аларга кара син,
Коймадан керергә бер ярык табарсың,
Ай нуры яктырткан өч баскыч күрерсең.
Шулай кил, гүя син һич миңа килмисең,
Шулай кил, гүя син миңа дип килмисең.

Истә тот: очрашсак чиркәүгә килгәч тә,
Эндәш дус кызыма, ә миңа эндәшмә.
Яшертен генә бер елмаеп кара да,
Аннары бер генә тапкыр да карама,
Аннары бер генә тапкыр да карама!

Ятларга сиздермә вәгъдәбез барлыгын,
Әйтерсең барыбер юклыгым-барлыгым.
Шаярткан чакта да саклан син, уйла син,
Ятларның берәрсе каратып куймасын,
Чыннан да берәрсе каратып куймасын!

Көттермәм мин сине — сызгырырсың, яме,
Көттермәм мин сине,— сызгырырсың, яме.
Әрләсен әниләр, әрләмәгәйләре!
Көттермәм мин сине,— сызгырырсың, яме?!

## Җыр

*(Вилли)*

Бер анда, бер монда — тынгылык белми,
Китә дә югала диңгезләр ягына...
Тизрәк кайт инде, кадерлем Вилли,
Әйт миңа, кайттым дип үзгәрми янына.

Болытлар бик түбән, кышкы җил җилли,
Озаттым сәфәргә мин сине еракка.
Тагын да җәй килер, кайтырсың, Вилли,
Кырларга, урманга, үзеннең кочакка.

Комнарга капланып океан йокласын,
Дулкыннар шавыннан төннәрем борчулы.
Ялларын кабартып дулкыннар купмасын,
Сак кына илтсеннәр өенә юлчыны.

Хыянәт итсә ул, онытса әгәр дә,
Тәүлекләр буена дулкыннар гүләсен.
Корабын көтмичә керәм мин кабергә,
Белмичә, Виллинең янына килмәсен.

Бер анда, бер монда — тынгылык белми,
Китә дә югала диңгезләр ягына...
Тизрәк кайт инде, кадерлем Вилли,
Борылып кайт кире, үзгәрми янына.

МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ *тәрҗемәләре.*

Рәмзи Максудов

# ШӘЙМОРЗА КЕШЕЛӘРЕ

## Радия Алиева



Иске Шәйморза бай булуы белән әйләнә-тирәдә дан тоткан, диләр. Әле революциягә кадәрле үк бу якның купецы һәм завод тотучысы Сирай Бәрхиев өендә телефон булган, шул телефон аша предприятиеләре белән сөйләшә алган. Әле бүген дә авыл уртасында таш подваллы, тимерләнгән ишекле, икешәр катлы купец йортлары бар. Бу подвалларда кызыл мал сакланган, ашлык сакланган. Ләкин ул хәзинәләрнең тирә-як халкына файдасы тимәгән. Игеннәр урылып, көзге яңгырлар башлангач, крестьян агай Рәчәйнең төрле якларына бәхет эзләп чыгып киткән. Тик аларның бик азы гына олы урамга салырдай яхшы агач өйлек акча эшли алган.

Авылда ике мәдрәсә булган. Конверт тышына адрес язарга туры килгәч, авыл агайлары күрше урыс авылына йөгергәннәр.

Хәзер ничек дип сорарсыз. Хәзер авыл үзгәргән. Бүгенге Шәйморзаның япь-яшь егетләре, буй житкән кызлары моннан ярты гасыр гына элек булган ул хәлләрне күз алларына да китерә алмыйлар. Ник дигәндә, авылда сакланып калган бай абзыйның йорты бүгенге гади колхозчының алты почмаклы, верандалы йортыннан кечерәк булып калган. Кайчандыр конверт тышына язу яздырырга күрше авылга йөргән Шәйморзаның үзендә генә дә бүген югары белемле кырык белгеч эшли. XXII партсъезд исемендәге колхоз миллион сум табыш ала...

Ләкин минем «фәлән булган, фәлән эшләнгән» дигән нәрсәләрне бармак бөгеп санап утырасым килми. Бүгенге Шәйморзаны танымаслык итеп үзгәрткән алтын куллы, батыр йөрәкле кешеләр турында сөйләп бирәсем килә.

Безнең беренче сүзебез Радия Алиева турында булыр. Радия — Шәйморзаның үз кешесе. Шушында туып, шушында үскән. Унбиш ел бардыр инде — китапханәче булып эшли. Төп эше янына җәмагать эшен дә китереп кушсак, аның кыяфәте укучыларга ныграк охшар. Авылның ун йортында агитатор булып эшли Радия.

Радия, китапханә ишеген бикләп, үзенә беркетелгән йортларга барырга дип кенә тора иде, башына кызыл шарф бөркәнгән уникe яшьләрендәге кыз йөгереп килеп житте. Китапханәче апасының тиз генә китеп барырга теләвен күреп, бусагадан ук китапларын суза башлады.

— Ой-ой, Радия апа, мине китапсыз калдыра күрмәгез. «Космонавтлар урамы»н укып бетердем. Рус телендәге китапны да укып бетердем. Тагын нинди китап бирәсез? — дип такмаклап тезеп алып китте кызый.

— Тукта, ашыгып сөйләмә, Миңнурый. Син шытыр-пытыр сөйләп бетерәсең дә мин бернәрсә дә аңламый калам. Син бит бу китапны өченче көн генә алган идең.

— Алсани? Укып бетергәч, нишләп мин аны өйдә тотыйм? — дип кызый куе кара кашларын җимерде.

— Укып чыккан булсаң, әлбәттә, өйдә тотарга ярамый китапны,— диде китапханәче апасы, аның белән килешеп.— Менә сиңа Толстойның «Гроза в лесу» дигән китабы, рус телендә, ә татарча нәрсә бирергә соң сиңа? — Китапханәче өстәл янындагы китапларны өемен актара башлады.— «Космонавтлар урамы» ошадымы соң?

— Юк, ошамады,— диде Миңнурый.— Ул Алик дигәннәре шундый мактанчык, шундый мактанчык, нәкъ менә безнең класстагы Равил. Җитмәсә әле үзе космонавт булам дигән була! Бик кирәге бар иде космоска андый йокы чүлмәкләренең! Ә менә Камил әйбәт... Алик аны юкка яратмый,— дип ярсынып сөйләргә кереште Миңнурый.

— Ярый, әйт әле, шулай да сиңа китап ошамадымы, әллә Аликмы?

— Алик ошамады. Китап шундый кызык, шундый кызык. Аннары Алик төзәлә, әйбәт малай булып китә, аннары алар әле Камил белән дуслашалар да.

— Син бу китапны кем язганын онытмадыңмы?

Кызый китаплар арасыннан тиз генә үзе алып килгән китапны эзләп тапты, китап тышыннан авторның исемен эзләп тапты һәм китапханәче апасы әйткәнче үзе әйтеп калырга ашыгып:

— Ихсанова! — диде.

— Дөрес әйттең, Ләбибә Ихсанова. Ул балаларны бик ярата, шуңа күрә сезнең өчен кызыклы китапларны гел язып тора,— дип сөйләп китте китапханәче апа. Ул бәләкәй укучысының автор исеменә игътибар итмәвен сизеп алган иде.— Ихсанова апаның тагын бер китабын биримме сиңа?

— Бирегез, Радия апа.

— Мин сиңа «Көмеш елга» китабын бирәм. Укып чыккач та миңа эчтәлеген сөйләрсең, яме.

— Ярый, апа,— диде кыз һәм ишектән елт кына чыга башлады.

— Туктале, Миңнурый, Толстой китабын алмадың бит. Аннары беләсеңме нишлә, әтиең белән әниеңә әйт, Радия апа килэм, дип әйтте диген.

— Ярый, апа, әйтермен.

Радия Миңнурый Сәләхованы күптән белә. Китап яратып уку өстенә ул өйдә дә бик күп эш эшли. Үзе әле бишенче класста гына, үзе өйдә хуҗа. Сеңелләренең дәрес хәзерләгәнме-юкмы икәннәрен дә тикшерергә өлгерә, өйне дә ялт итеп җыештырып куя. Кайчагында әнисе урынына хатлар таратып чыгарга да житешә. Ут борчасы кебек! Ә кичләрен барысы бергә җыелгач, Миңнурый яраткан китабын кычкырып укый.

Сәләхнекеләр дус яши. Дус булгач, тормышлары да көйле. Исмәгыйль абзый мәктәптә ат караучы булып эшли, Мәдинә апа — хат ташучы. Икесен дә авыл кешеләре ихтирам итә. Исмәгыйльне атларын яхшы тәрбияләп, көр тотканы, иренмәгәне өчен яратсалар, Мәдинәне яхшы хәбәрне үз вакытында, сәгате-минуты белән китереп җиткергәне өчен үз итәләр. Заманалар елдан-ел матурлана, тормышлар елдан-ел бөтенәя, Мәдинәгә дә хәзер шатлыклы хәбәрне күп китерергә туры килә. Шуның өстенә ул матбугат таратуга бик җаваплы карап, газета-журналлар алдыруда үрнәк тә күрсәтә бит әле. Балаларга дип «Яшь ленинчы», «Пионерская правда», үзләренә «Социалистик Татарстан», «Азат хатын», район газетасы «Яңа юл»ны алдыралар. Миңнурый инде өй-

ләрендә үз китапханәләрен җыя башлады, әнисе кебек, башкаларга китап биреп укытырга бик ярата.

Өлкәннәрне өлкән итмәгән үзе беркайчан да өлкән булмас, дип әйтә халык. Сәләхнекеләр әнә шул алтын кагыйдәне күз карасы кебек саклыйлар. Хәлидә әби инде сигез дистәнең теге ягына чыкты, әмма бу йортта аның киңәшеннән башка берни эшләмиләр. Өстәл янында иң хөрмәтле урын аныкы. Алар белән бергә тагын Мәдинәнең туганы Хәтимә яши. Көнкүреш комбинатында Хәтимә беренче кул тегү остасы. Авыл хатын-кызлары аңардан күлмәк тектерү өчен чират торалар. Йорт салыйм дисә, йорт салырлык, фатир кирәм дисә, фатир керерлек кенә хәле бар аның. Юк, шушы йортның бәхете аны җылытып, күңелен киңәйтеп тора.

Радия Алиева Сәләхнекеләрдә булырга бик ярата. Бар нәрсә мул, бар нәрсә иркен. Шәйморзаның түбән очыннан да, югарыгы очыннан да бәйрәмнәрдә бу йортка туган-тумача килеп тула. Иң күзгә ташланганы — барысының да бәхете түгәрәк, холыклары, тыныч аккан зур елга кебек, сабыр.

Сәләхнекеләр белән янәшә укытучы Әхмәтҗановлар яши. Иркен һәм пөхтә яшиләр. Ишек алды дисеңме, өй каршы бакчасы дисеңме, кайчан карама, ялт иткән булыр. Шәйморза укытучылары сыер-сарык асрауны укытучыларның вакытын әрәм итү дип карыйлар.

Җәүдәт Әхмәтҗанов мәктәптә тарих укыта, авылдашларына халыкара хәлләр турында лекцияләр укый, өстәвенә XXII партсъезд исемендәге колхозга караган Космовский авылында марксизм-ленинизм нигезләре мәктәбендә дәресләр бирә. Фәһимә агитатор булып эшли, Казан педагогия институтында читтән торып укый. Казаннан, Ленин китапханәсеннән соратып алган китапларны Радия Фәһимәгә китерде дә инде. Бер килгән уңайда Радия Җәүдәттән республиканың 50 еллыгына багышланган әңгәмәләрне әзерләүдә булышуын да сорады. Ленинның тууына йөз ел тулуга багышланган әңгәмә тезисларын алар үйлашканнар һәм төзегәннәр дә иде инде, андый әңгәмәләр үткәрелеп тә киләләр, ә республиканың юбилеена карата булган әңгәмәләрнең тематикалары турында алар әле бер сүзгә килгәнче сөйләшеп бетермәгәннәр иде.

— Республиканың төзелү, үсү тарихын үз колхозыбыз, үз авылыбыз үрнәгендә сөйләсәк тә әйбәт булыр,— диде Җәүдәт һәм педагогларга хас булганча, шундук планын җәеп, киңәйтеп аңлата да башлады.— Мәктәп музеенда авылда Совет власте урнашуы турындагы материаллар җитәрлек җыелган. Район газетасында да әйбәт кенә мәкаләләр басылып чыкты. Космовский турында да мәкалә булды. Безнең авыл шул комиссар Космовский исемен йөртә бит инде. Халыклар, милләтләр дуслыгы, аларның хезмәттәш булуы турында нәкъ безнең колхоз үрнәгендә сөйләргә мөмкин, бездә чувашы да, татары да, урысы да яши. Колхоз төзелү турында синең әтиең Сөнгатулла бабай сөйли ала. Аның сәламәтлеге ничегрәк соң әле, больницада дип ишеткән идем,— дип сүзен бүлеп сорады Җәүдәт.

— Хәзер әйбәтләнде инде. Картлык галәмәте, диде врач, биксәнне тутыра бит инде.

— Мин үзем дә хәлен белә барырга тырышырмын, сез дә барган чакта миннән сәлам тапшырырга онытмагыз,— диде Җәүдәт. Аннан авылның тарихы турындагы сүзгә күчте.— Кызыклы хәлләр онытылмасын өчен, эзлеклерәк булсын өчен Сөнгатулла бабай сөйлисе сүзен башта язып чыксын. Кызыклы мисаллар, булган хәлләр кыстырып сөйләгәндә тыңлаучылар ялыкмый. Анысына,— диде Җәүдәт елмаеп,— Сөнгатулла бабайны өйрәтәсе юк. Сөнгатулла бабай колхоз төзелүнең беренче көннәре, баштагы еллары турында сөйләр. Инде колхозны механизацияләү турында. Безнең урамда ук, ул синең участокка кирә,

Тимерша абзый Хәсәнов яши. Ул безнең колхозның беренче тракторчысы. Беренче тракторны 1935 елны Ульяновскидан ул алып кайтты. Трактор белән беренче буразнаны ул салды. Ә бүгенге көннәр турында сөйләгәндә, Азат Алиуллинны чакыр. Минемчә, бүгенге көн, хәзерге заман колхозчысы нәкъ менә Азат кебектер инде ул. Техниканы биш бармагы кебек белә. Беләм дип һаваланмый, һаман өйрәнә, укый. Яше дә бар, семьясы да, кызы инде икенче класста укый, ә Азат һаман укырга омтыла. Техник училище тәмамлаган, хәзер авыл хуҗалыгы институтында укый.

Радия Азатны авылдашларына караганда күбрәк белә. Алар бер мәктәптә укыдылар, яшьтәшләр. Ул чагында да ул алдынгылардан санала иде. Теләсә, мәктәптән соң ук институтка кергән булыр иде, юк, ул институт димәде, Буага техник училищега барып керде. Тизрәк һөнәр аласы да, тизрәк әнисенә булышасы булды,— өйдә әле Азаттан башка сеңелләр, энекәшләр бар, аларны аякка бастыру Азат өстендә иде. Аның каравы, бүгенге тормышы сөенеп бетәрлек түгел. Икесе дә эшли. Азатка яңа трактор бирделәр. Солтаниясе фермада сыер сава. Өйләрендә муллык. Радиоприемникны Азатка яхшы эшләгәне өчен бүләк итеп бирделәр. Кер юу машинасын, тагын әллә нәрсәләрне үзләре сатып алды. Телевизор алырга җыеналар. Күршеләре дә, туганнары да «Рекорд» алырга киңәш итәләр, янәсе ул әйбәт маркалы телевизор, ә Азат белән Солтания — аның экраны кечкенә, диләр, алгач-алгач «Электрон» алмакчы булалар. Азат аны Казанга барып алып кайтмакчы инде.

Бу кичне Радия участогындагы кешеләрнең барысына да йөреп чыкты. Ибәтовлар гаиләсендә Радиядән сельпо председателе белән сөйләшүен үтенделәр. Мәктәпкә барыр вакыт житеп килә, малайның чалбары тузган, алыйм дисәң, кибеттә юк, малайны мәктәпкә ертык чалбар белән җибәрмәссең бит инде.

Тимерша абзыйларга кергәч, Радия аннан колхозчылар белән әңгәмәгә хәзерләнүен үтенде. Колхозлашуның беренче көннәре турында Тимерша абзыйдан да яхшы белгән кеше авылда бүтән беркем юк. Радия участогына колхозчылар шушы өйдә җыелып сөйләшәләр инде. «За рубежом» журналының соңгы санында басылган кызыклы хәбәрләрне кыскача сөйләп бирде. Хуш исле варенье белән чәй эчүдән дә баш тартмады. Чөнки бу өйдә чәй янына утырмау, вареньедан авыз итмәү — Тимерша абзый белән Гаделниса апаны рәнҗетү дигән сүз. Авылда алар атаклы бакчачылар, авылдашларын бакча җимешләре үстерергә үгетләүчеләр дә алар. Бөтен буш вакытын Тимерша абзый бакчада үткәрә, җиләк-җимеш үстерә, ә Гаделниса апа тәмле-тәмле вареньелар, компотлар кайната. Һәр көзне алар туган-тумачаларына, күрше-күләннәренә бакча күчтәнәче өләшәләр, җиләк-җимешне үстерү, тәрбияләү турында иренмичә, вәземләп сөйлиләр. Алардан күреп җиләк-җимеш үстерә башлаучылар да бар инде авылда. Һәр йортның бәрәңге бакчасында, түр бакчасында алмагачы, чия үсеп утыра, кайберәүләр хәтта виктория — җир җиләге дә утырткан.

Йөри торгач, Радия Сәләхи бабай белән Бибиҗамал әбиләрнең өенә дә килеп житте, алар өендә Радия озаграк булды. Сатдиновлар — колхоз пенсионерлары. Заманында алар да колхоз активистлары булган. Хәзер алар колхоз тәрбиясендә. Балалары үсеп, кеше булып беткәннәр, һәркайсы үз йорты белән тора, һәркайсы ата-анасын үзенә чакыра. Ә картлар кузгалмый, төп нигездә яши бирәләр. Кече уллары Гиматдин Ульяновскидан кайтып ай буе торды, ай буе әти-әнисен үзенә китәргә кыстады, барыбер берни чыкмады, картлар барыбер нигезләрен ташлап китәргә риза булмадылар. Дөрес, картлар авылда да ялгыз түгел. Кызларының кызы Миңсылуның бабаларына керми калган көне юктыр. Ул өйләрен җыештыра, керләрен уа, мич ашы пешереп ашата.

Хәмидулла кияүләре белән кызлары Зәйнәп ат белән килеп мунча кертергә алып китәләр. Радия дә бу өйгә башкаларга караганда ешрак килә. Бу килүләрендә ул әби белән бабайга әле яңа гына булып үткән колхоз җыелышы турында, бу җыелышта да колхоз председателе Абдреевнын аларны яхшы сүз белән искә алуы турында әйтте, әтисеннән сәлам тапшырды.

Элегрәк елларны Радия Сатдиновлар күршесендә яшәгән тол хатын Җәмилә Гыйниятуллиналарга да керми үтми иде. Ә хәзер ул йорт юк инде. Җәмилә апа Ленин урамындагы яңа йортка күчеп китте, авыл Советы аңа яңа йорт салып бирде. Шулай да Радия аның ничек урнашуын, ничек яшәп ятуын барып күрмичә тынычланмас инде.

Участогына кергән йортларның барысында да булып чыкты агитатор Алиева бу кичне. Бер-ике көн үтүгә яңадан килеп чыгачак. Беркем әйтмичә, беркем чакырмыйча, гадәттән тыш хәлләр чыгуын көтмичә киләчәк ул бу кешеләр янына. Нигә, дисезме? Чөнки ул йөрәге белән бу кешеләргә кирәкле булуын, аларга файда китерүен сизә. Ә кешене канатландырган нәрсә шул бит инде.

## Сабрия Каюмова



Иске Шәйморзада урта һәм сигезьеллык мәктәп бар. Һәр елны йөз сиксән бала мәктәп тәмамлап чыга. Статистика күрсәтүенә караганда, конкурслы сынауларда да сынатмый Шәйморза укучылары: алтмыш процентлап укучылар урта һәм югары уку йортларында укуларын дәвам итә.

Инде менә яшь буын шәйморзаларның берсе турында сөйләмәкче булам.

Иске Шәйморза урта мәктәбен тәмамлап Буа медицина училищесына керергә теләүчеләр ун кешегә җыелды. Шулар арасында кыска гына буйлы, йомры гәүдәле кыз Сабрия Каюмова да бар иде. Киң ачылган кара күзләре бигрәк ышанып, бигрәк самими карый иде дөньяга.

Медицина уку йортларына конкурсның беркайчан да кечкенә булганы юк, ә ул елны гаризалар бигрәк күп бирелгән иде. Сынау барасы көннәр алдыннан училище алдында төркем-төркем булып врач булырга теләүчеләр җыела. Иске Шәйморза кызлары имтиханга бергә киләләр, тәүге адымны ясап бусаганы атлап керергә тәвәккәлли алмыйча бик озак ишек төбендә таптанып торалар.

Беренче көннәрне үк үтү баллының унбиш булуы, отличниклар арасыннан да әле нәселендә врач булган укучыларны гына алулары турында хәбәр таралды. Сабрия ул хәбәрләрнең барысына да ышанды, рус теле һәм әдәбияты буенча соңгы имтиханга бөтенләй кәефсезләнеп, эчепошкан хәлдә килде. Химия белән тарихтан дүртле алды, сочинениегә бишле куйсалар да, училищега кая инде ул керү. Менә шундыйрак уйлар белән язды ул сочинениене. Ләкин тора-бара үтү балының унөч икәне беленде, керер өчен нәкъ шул бишленең кирәк булуы ачыкланды. Бер балл Сабриянең үз гаебе аркасында җитмәде, сочинениене инде керү ышанычын югалтып, тегеләй-болай гына язды бит.

Сабрия документларын алгач урамга чыкты. Август кояшы көйдереп кыздырмый, ягымлы рәхәт итеп кенә җылыта. Әкрен генә искән җил болыннан чәчәк исе алып килә. Ләкин Сабрия боларның берсен дә сизми. Башын түбән игән килеш бара да бара. Йөзендә өметсезлек кайгысы чагыла. Бар да бетте! дип уйлый ул, киләчәге карангы, юк, алай гына да түгел, киләчәге юк бит инде аның, бөтенләй юк!

Шулай өметсезлеккә бирелеп барган чагында ул үзенең яшьтәше Равия Сәлимжанованы очрата. Ул да Иске Шәйморза мәктәбен бетергән, ләкин гаризаны медицина училищесына түгел, ветеринария техникумына биргән иде һәм менә бүген училищега алынганын белеп килә иде. Сөенеченнән ана бөтен дөнья үзе шикелле бәхетледер сыман тоела, бу бит анын беренче җиңүе! Шул сәбәпле ул Сабриянең дә хәлен абайлап өлгермәде, аны кочаклап алды да бөтерелә башлады.

— Сабрия, дускаем, карачы, көне нинди...— шунда гына дустының йөзен күреп алды:— үтмәденмени?..— диде әкрен генә. Җавабын да көтеп тормады, дустының күзләре яшь белән тулганын күреп, яңадан җилтерәтә башлады.

— Тукта, сабыр ит, елама гына. Әйдә, киттек минем белән. Менә күр дә тор, бар да әйбәт булыр. Бездә яңадан имтихан тот, бездә керми калмассын. Ветеринария техникумы да медицина училищесы бит инде.

Алар ике катлы таш бина ишек алдына икәүләп керделәр. Ветеринария техникумы шунда урнашкан иде. Кабул итү бүлмәсендә документлар алып торучы кыз каршына Равия Сабрияне житәкләп алып килде.

Сабрия имтиханнарны уңышлы тапшырды. Уку башланыр алдыннан әнисе белән энесенең хәлен белергә дип өенә кайтып килде. Әнисе белән тегермәнгә барып кышлыкка бодай тарттырып кайттылар, яшелчәсен колхоз келәтеннән алдылар, бәрәңгесен бакчаларыннан.

— Өлкән кеше булып өйдә син каласың,— диде ул Камилгә,— әнигә булышсаң, мәктәпкә йөртергә чын кыр сумкасы алып кайтып бирермен.

Тулай торакта алар бер бүлмәдә җиде кыз торды. Бар да татар дисәң дә ярый, чөнки бердәнбер чуваш кызы татарчаны русчага караганда яхшырак белә иде. Әй кыен да иде соң башта лекцияләр тыңлавы! Шуңа күрә алар бүлмәдә дә русча сөйләшергә сүз куештылар, сүзне бозган кешегә штраф түләтергә карар иттеләр.

Соңгы курска житкәч, Сабрия медицина училищесына керергә омтылуына үзе дә гажәпләнеп бетә алмады. Карап карасаң, ветеринар техник булуы да мавыктыргыч икән ләбаса!

Техникум тәмамлагач, Сабриянең сабакташлары республиканың һәм Ульяновск өлкәсенең төрле районнарына таралышты, Сабрияне Буада, ветеринария участогында калдырдылар. Үзенә калса, ул туган авылына үзбаш эшләргә кайтып киткән булыр иде.

Өченче елны әйбәт кенә эшләп килгәндә, аны производство идарәсенә баш зоотехник чакыртып алды.

— Эшегезне бик яхшы эшлисез, участогыгызда хезмәт күрсәтүне әйбәт оештыргансыз, диделәр сезнең турыда иптәшләр,— диде баш зоотехник.— Сабрия Нуретдиновна, Городище ветеринария участогының мөдире итеп куярга ният бар сезне, ни диярсез шуңа?

Городищеда күптәннән инде мөдир булмавы турында Сабрия белә иде. Ләкин бит анда мөдир булу өчен ветеринар врач булырга кирәк, ә ул бары техник кына. Аннан, Городищега китәргә ризалык бирсәң, Иске Шәйморзага кайтулар бетте инде. Ә анда сыер абзарларын таштан салганнар, дуңгыз фермасында да типовой биналар төзиләр. Шәп итеп төзиләр, сулар кертеп, су белән жылыта торган итеп, яхшы вентиляцияләр куеп төзиләр. Соңгы килүендә колхоз председателе Абдреев Әхмәтгәрәй абзый әйтте бит, төзелеш тәмамлану белән колхоз правлениесе ферма специалистлары турындагы мәсьәләне караячак, диде. Сабриянең бер урында төпләнеп эшлисе килә, хәзерге кебек фермадан фермага йөрисе килми аның. Идарәнең баш зоотехнигына ул нәкъ менә шулай диде. Городище участогына специалист бик кирәк булса да, баш зоотехник Сабрияне ирексезләмәде, аның дәлилләрен дөрес дип тапты.

Шул көнне үк Сабрия Иске Шәйморзага кайтты. Озакламый колхоз

правлениесе аны дуңгыз фермасының ветеринар техникы итеп билгеләде.

Бу ферма — малга азык хәзерләү, дуңгыз балаларын үстерү, симертү цехлары булган бер фабрика ул. Анда чын осталар, хайванны яраткан кешеләр хезмәт итә. Беренче көненнән үк дуслашты Сабрия алар белән. Аларны ул болай да әллә кайчаннан бирле белә иде инде. Мәктәптә укыган чагында фермага килеп йөри иде. Ветеринария техникумын бетергәч тә кыска гына вакытка булса да килә иде, шунда Зоя Ивановна Акимова, Лидия Александровна Павлова аннан киңәш сорарлар иде, үзләре дә киңәш бирерләр иде.

Сабрия кайтып эшли башлаган елда ук яңа туган дуңгыз балаларына яшел үлән ашатуны җайлап җибәрделәр. Ялгаш сыман озын-озын тартмаларда арыш, солы чәчеп уҗым үстерделәр. Гомумән, хайваннарны игътибар беләнрәк тәрбияли башладылар. Колхоз кварцлы лампы алдырды, кыш көне кояш нурлары җитми башлагач, хайваннарны ультрафиолет нурлар белән җылытуны да оештырдылар. Ферма эшчеләре дә яшь ветеринар техникның тырышулары бушка чыкмавын күреп аның һәр сүзен, һәр киңәшен тотып эшләделәр.

Менә шулай эшләр җайлы гына бара дигәндә, Сабрия янына сулуы кабып Лидия Александровна йөгереп килде.

— Кызым, әйдә әле, минем бүлеккә барыйк әле, әллә нәрсә булды дуңгыз балаларына,— диде ул бик борчылган кыяфәттә.— Ике дуңгыз баласы иртәдән бирле берни капмады, гел стенага терәлеп кенә, ятарга гына торалар. Яман чир әләкмәде микән, дим. Әйдә әле, Сабрия, барып карыйк әле.

Сабрия әлеге ике дуңгыз баласын шунда ук күреп алды. Берсе Сабрия килә башлагач торып баскан булды, ләкин хәлсезләнеп шундук кире ятты. Сабрия дуңгыз баласына кулын тидерүгә тартып алгандай итте, хәер, карап-нитеп торасы да түгел, болай да күренә: тиресе кызарган, муенында, ян ягында кызгылт таплар тибеп чыккан.

— Лидия Александровна, бу дуңгыз балаларын кичектермичә аерып ябыгыз, ачылмый торган ишек янындагы бүлеккә, ышык урынга ябыгыз. Мин хәзер килермен.

Бик куркыныч йогышлы авыру булуында шиге калмады Сабриянең. Авыруның беренче билгеләре беленүгә ике сәгатьтән ары вакыт үтмәгәндә, дуңгыз балаларын коткарып була әле. Аларның канына сыворотка кертергә кирәк. Сабрия кабинетына йөгереп килеп керде, кулына шприц алды, киштәләрдән сыворотка эзли башлады. Кая соң әле ул?!

— Аптечкагызда витаминнар булмаса да, хлористый кальций булмаса да хәтәр түгел әле. Ферроглюкин булмаса да куркыныч түгел. Ләкин рожа шикелле куркыныч авыруга каршы сыворотка һәрвакыт булырга тиеш! — Карт укытучысы шулай ди иде Сабриянең.

Кая соң сыворотка?! Юк иде шул сыворотка аның аптечкасында. Дуңгыз баласына ул пенициллин эретмәсе кертте. Калтыранган куллары белән укол ясап ятканда, Зоя Ивановна килеп җитте. Дуңгыз балаларына күз салу белән барысын да аңлап алды. Ун ел бит инде аның фермада эшләвенә, мондый хәлне дә күргәне булды Зоя Ивановнаның.

— Сыворотка кертәсеңме? — дип сорады ул Сабриядән. Сабрия дәшмәде. Укол ясап бетергәч торды да:

— Зоя Ивановна, ферма мөдирен табып әйтегез әле, зинһар, тиз генә районга сыворотка алырга җибәрсен. Безнең юк икән,— диде.

Нәкъ шул чакта ишектән Алиуллов үзе килеп керде. Сабрия аңа омтылды:

— Миргалифан Насыйбуллович, мине соңыннан ачуланыгыз, җәзасын бирегез, ә хәзер, зинһар дим, сыворотка алырга җибәрегез.

Апрель урталары иде. Кар эри башлаган, юл буйларында, тау бит-

ләрендә гөрләвекләр ага, Шәйморза халкы зур йомыш булмаганда мондый чакта юлга чыкмаска тырыша. Мондый чакта тракторга гына ышаныч. Сыворотка алырга районга трактор белән киттеләр.

Сыворотка алып кайтканчы тагын ике дуңгыз баласы авырды. Аларын да аерып яптылар. Сабрия аларга да пенициллин кадады. Ләкин пенициллинның файдасы булмасын ул белә иде. Сыворотка белән кушып кадаганда гына шифасы була пенициллинның.

Сыворотка алып кайтып житкергәч, дуңгыз балаларын дәваларга ферма эшчеләре берсе калмый булышты. Төн уртасы житкәнче эшләделәр. Аннан Алиуллов эшчеләрне черем итеп алырга жибәрде, дежурныйлар гына калдырды. Берәү дә өенә кайтып китмәде. Төн узганчы тагын өч дуңгыз баласын аерып яптылар. Башта чирләгән икесе инде бүтән бер дә тормады, алары су да эчмәс булдылар.

Икенче көнне иртә белән һәркем үзенең эшенә тотынды. Һәркем үз эшен эшләп бетерүгә, дуңгыз балалары цехына йөгерә. Бары азык әзерләү цехы мастеры Габделгали Вахитовка гына дуңгыз балалары авырган бинага керергә рөхсәт итмәделәр. Хәер, ул үзе дә керәм дип бик тырышмады. Аның үз эше бик кирәкле эш: бәрәңгесен юдырта, чөгендерен болгата, барысын чамалап кушарга кирәк, әйбәтләп әзерләргә кирәк.

Иртәгесе көнне бер дуңгыз баласы да авырмады. Төн дә ул-бу булмыйча тыныч кына үтте. Алай да әле тагын бер тәүлек сакта тордылар. Авыруның юлы киселде. Тик иң башлап чирләгән ике дуңгыз баласын гына коткарып булмады. Яшь дуңгыз балалары группасында үлү очрагы шуның белән соңгысы иде. Бу хәл яхшы сабак булды Сабриягә: дару дисеңме, сыворотка дисеңме — хәзер аптечкада бар да житәрлек алынган. Бер жыелышта аңа хәтта әйттеләр дә, дару алу өчен зур расход ясыйсың, диделәр. Анысы да дөрес, максат бит дәвалау түгел, хайваннарны үстерү, симертү. Малны яхшы ашатып, яхшы тәрбияләү, авыруларга бирешмәслек итеп үстерү.

Ә теге вакыттагы төнлә дежур торуларның ферма эшчеләренә бик зур тәэсире булды. Кешеләр бер-берсен яхшырак, якыннанрак белде, коллективның көченә ышанып калдылар. Шушы тойгы онытылмасын, көндәлек мәшәкатьләр астында күмелеп калмасын, дип Сабрия яңадан барысын бергә жыярга карар итте.

Терлекчеләр өен ялт итеп жыештырдылар, тәрәзәләргә шыгырдап торган чөлтәр пәрдәләр элделәр, каравылчы абзый хатыны Ашура апа чын татар токмачы пешереп бирәм, дип вәгъдә итте. Мондый бәйрәм өчен азык-төлек табуны ферма мөдире үз өстенә алды. Ә Сабрия кичәгә гармунчы Зөфәр Сөләймановны чакырды. Караңгы төшкәч, йортларның тәрәзәләрендә утлар кабынгач, фермага дуңгыз караучылар жыелды. Киенеп-ясанып килделәр. Килгән берсе табынга дип күчтәнәч күтәреп килде. Килүен килделәр, әмма эштә тупасланып беткән киң учлы зур кулларын кая куярга белмичә аптырап, уңайсызланып калдылар. Ярый әле бу хәлдән Зыя абзый коткарды.

— Нәрсә сез аулак өйгә жыелган шикелле почмак саен посып беттегез,— диде ул.— Ягез, өстәл янына утырышыгыз, Ашура апагыз пешергән токмачны ашап карагыз.

Терлекчеләр йортының тәрәзәләре бик озак балкыды ул төнне. Ярты төнгә чаклы көлгән, жырлаган тавышлар ишетелеп торды.

Шәйморза терлекчеләренең бәйрәм кичләрен шулай күңелле итеп үткәрү гадәте менә шул кичне башланды.

Озак та тормый, бөтен коллектив коммунистик хезмәт фермасы исеме алу өчен ярыша башлады. Дәүләтебезнең юбилее көннәрендә ферма бу мактаулы исемгә лаек булды.

Шул ук елны Сабрия Коммунистлар партиясе сафына алуны үтенеп гариза бирде. Бүген ул Ленин партиясе члены.

# Минрасих Алиуллин



Кабинетка кызарынып-бүртенеп бригадир килеп керде дә туп-туры Минрасих Алиуллин өстәленә таба китте. Куллары белән өстәлгә таянып, парторг каршысына басты.

— Теләсәң нишләт, парторг, мин Салихны эшеннән алдым. Ул кичтән наряд буенча бирелгән эштән баш тартты.

— Тынычланыгыз, утырыгыз, ни булганын ипләп кенә сөйләгез әле,— диде Алиуллин.

— Утырып торырга вакыт тар, урамда яз. Һәр минуты кадерле хәзер, ә безнең тракторчы да юк әле.

— Моңарчы Салих әйбәт кенә эшләп килде бит. Узган елда аның бригадасы шикәр чөгендереннән нинди уңыш алды, исегездәме. Партиягә керү өчен аңа рекомендацияне сез биргән идегез түгелме соң? Ничек була соң әле бу?

— Шулай да була икән ул. Трактор паркыннан чүп чыгарырга наряд биргән идем, чыгармыйм, ди, эшегез дә кирәкми, үзегез дә, ди.

— Чүп түгүне калдырып торыргамы әллә бүгенгә? Салихны кырга, культивациягә чыгарсаң, яхшырак булмасмы? — дип сабыр гына сорады Алиуллин.

— Нишләп инде калдырып торырга... Кемне нинди эшкә куярга икәнен белмимме әллә мин? Алайга киткәч, кем соң монда бригадир. Әгәр сезгә бригадирлык эше күбрәк ошый икән, рәхим итегез, мин каршы түгел. Тик алдан кисәтеп әйтәм, сез кушканны коммунистлар үтәмәсә, бригада белән җитәкчелек итеп булыр микән?

Бригадир ачуы басылмаган килеш ишекне шартлатып ябып чыгып китте. Ул чыгып киткәч, Алиуллин урыныннан торып тәрәзә янына килде. Узган елда правление бинасы алдында бүлеп алган бакчада яшел чирәм төртеп чыга башлаган. Өянке бөреләре инде бүрткән, менә-менә ачылырга тора, ә алмагач белән чия агачы әле кыш көнендәге кебек шәп-шәрә килеш тора. Бер-ике көн үтү белән алар да уяныр, кәүсәләргә, ботакларга тамырлардан су менәр, бөреләре тулыша башлар. Менә шунда алмагач та, чия агачы да өянке яфрак ярып өлгергәнче ап-ак чәчәккә күмелүе дә ихтимал бит әле.

Әмма алдагы ике-өч көн — иң кыен, иң киеренке көннәр. Туфракны эшкәртү һәм сабан ашлыкны чәчү вакытын һич кенә дә ычкындырырга ярамый. Шундый чакта механизаторы кирелләнеп маташсын, имеш. Салихның бер сәбәпсез эштән баш тартуына Алиуллинның ышанасы килмәде. Коммунист булырга җыенган башы белән... Башкаларга үрнәк булырга тиеш, дигән сүз бит инде ул. Менә сиңа мә, шундый кызу эш өстендә эштән баш тарт диген инде.

Бюро утырышын колхоз председателе кабинетында җыйдылар. Бюро членнарыннан тыш коммунист механизаторларны чакырдылар. Колхоз председателе дә килде.

Алиуллин гадәттән тыш хәл килеп чыгуын, ягъни партиягә членлыкка кандидат булган кешенең эштән баш тартуы турында, бу хәлне тикшерергә кирәклек турында хәбәр итте.

Тикшергәндә аңлашылганча, Салих звеносы шикәр чөгендере эшкәрткән җиргә, үз участогына чыгарга җыенган, ләкин анда икенче тракторчы киткәнен белеп алган. Моның ничек шулай килеп чыкканын ачыкларга теләп сүз башлаган, тыныч кына ачыклап бетерә алмаган, бригадир белән бәхәсләшә башлаган. Икесе дә кызып киткәннәр, тупас сүзләр әйткәннәр бер-берсенә, өстәвенә, механизатор трактор паркында тракторын, чүп төялгән арбасын калдырып өенә кайтып та киткән.

Коммунистлар Салихны бу ярамаган эше өчен бик каты шелтәләделәр, бригадирны да читтә калдырмадылар. Үзеннең житешсезлеген, өлгер һәм тәвәккәл булмавыкны механизатордан, бигрәк тә эшли генә башлаган яшь кешедән күрү, аңа сылтап кую егетлек түгелдер бит инде. Эшнең ничек булганын, ни өчен аның бу юлы трактор паркында эшләргә тиеш икәнен ул Салихка иплэп кенә аңлатып бирә алмый идемени. Башка нәрсәләр дә ачыкланды бюро утырышында. Сөрү тракторларында эшләгән механизаторлар җәй буе кыр эшендә, кышын да транспорт эшеннән бушамыйлар. Туфракны да алар эшкәртә, алар чәчә, чәчүлекне дә җәй буе алар карый. Кыш килдеме, чана тактыралар да янадан төрле эшкә йөртәләр. Ә хезмәт хакын тасмалы зур тракторларда эшләгән тракторчылардан шактый ким алалар икән.

Утырыш беткәндәрәк, Салих урыныннан торып, бригадирдан тупаслыгы һәм әдәпсезлеге өчен гафу үтенде. Намуслы хезмәтем белән гаебемне җуярмын, дип ышандырды. Бер юлга утырышта тикшерү, кисәтү ясау белән чикләнергә булдылар. Утырыш тәмамланды, кешеләр таралышты, колхоз председателе кабинетында Алиуллин гына калды. Механизаторларның эш нормаларын һәм хезмәт хакын яңадан тикшереп чыгу кирәклеге турында әйтелгән сүзләрен ул хак сүз дип тапкан иде.

— Рөхсәт итсәгез, сөрәнле тракторларда эшләүчеләрнең хезмәт хакларын яңадан билгеләп чыгарбыз. Кыр эшләрен тәмамлаганчы житешербез дип уйлыйм,— диде ул.

Тиздән яңа бәяләр билгеләнеп колхоз идарәсе утырышында тикшерелде һәм расланды, алга таба бик яхшы нәтиҗәләр күрсәтте.

Ә Салих ул елда гектарыннан ике йөз егерме центнер шикәр чөгендере алды һәм колхоз ярышында беренче урынны яулады.

Иршат Бәшировны Минрасих абзый мәктәптә укыган чагыннан ук белә. Оялчан гына бу егет лекцияләрне зур игътибар белән тыңлап утыра, мәктәп янындагы участокта тырышып эшли иде. Сигезенче классны тәмамлау белән, ул зурлар белән беррәттән җиң сызганып колхозда эшли башлады. Мәктәп тәмамлагач, Казанга авыл хуҗалыгы институтына керергә дип килә. Конкурс буенча үтә алмый, кире колхозга кайта, грузчик булып эшли башлый. Беренче елны акча күп төшкәнгә сөенеп йөри, өс-башын карый, энесе Фәриткә дә кием-салым ала. Тора-бара уйга кала, кулы, аркасы арыганчы эшләсә дә, башы гел ял итә, янәсе. Аның белән бергә мәктәп тәмамлаган һәм институтларга керә алмый калган иптәш малайлары кайсы мастерскойда эшли, кайсы Казанга яки Ульяновскига ук китеп анда эшкә урнаштылар. Бер очрашуында ул Алиуллинга уйларын сөйләп бирде. Парторг аңа хәзерге заманда теләсә нинди эшнең мактаулы булуы турында сөйләп тормады, берәр атнадан үзе янына кереп чыгарга кушты.

Ул арада трактор бригадасы хисапчысы урыны бушады. Аның урынына Алиуллин киңәше буенча Иршатны куйдылар.

Яңа эшне Иршат бик тырышып үти башлады, үзенә беркетелгән бригадаларда үрнәк булырлык учет куйды. Комсомол оешмасы кушуы буенча колхозда спорт-масса эшен дә җайга салды, төрле секцияләр төзеде, үзе яшьләрне иркле стильдәге көрәшкә өйрәтә башлады. Аннан командасын республика ярышларына алып китте. Казанда бик уңышлы көрәшеп күрсәткәннән соң аның көрәшчеләрен «Урожай» җәмгыятенең җыелма командасына керттеләр һәм Бөтенроссия ярышларында катнаштырдылар.

Көрәшчеләренең уңышлары турында ул сөенә-сөенә Минрасих абзыйга сөйләде. Гомумән, сөенечен дә, көенечен дә ул аңа сөйләргә гадәтләнеп китте, этисе сугыштан кайтмаганга күрәдер инде, Минрасихны этисе шикелле күрә башлады.

Ул вакытларда инде Иршат авыл хуҗалыгы институтының механика факультетына читтән торып укырга да кергән иде.

— Җиңүләрең бик күбәеп китте әле синең, егет,— диде аңа бер очрашуында Алиуллин,— укулар ничек бара соң синең, кышкы сессиягә дә бармый калдың түгелме соң?

— Ташларга булдым мин укуны, Минрасих абзый. Математика бармый минем, вакыты да юк.

Минрасих абзый аның сүзләренә илтифат итмичә үзенең 1949 елда кырчылык мәктәбен тәмамлап агроном булып эшли башлаган чаклары турында сөйли башлады.

Киңәшмәгә дип чакырырлар иде, 30 чакрымны җәяү китәр иде. Киез итекләрен култык астына кыстырыр, үзе юлда чабата киеп барыр иде. Район үзәгенә килеп җитәр алдыннан гына чабатасын салып итекләрен кияр иде, ни дисәң дә, агроном кисәге, киңәшмәгә чабатадан килеп кермәс бит инде.

Берсендә шулай, киңәшмә бетеп кайтырга җыенып ятканда, МТС директоры көтәргә куша, машинасына утыртып кайтырмын, ди. Юлда Алиуллинның култык астындагы төргәккә күзе төшә.

— Әниеңә күчтәнәч алып кайтасыңмыни? — дип сорый. Күчтәнәч димәкче була Алиуллин, тик шунда машина сикертеп җибәрә, төргән кәгазь ертыла, ертыктан чабата башы килеп чыга. 16 яшьлек Минрасихтан кала өйләрендә тагын алты бала бар икәнен директор шул вакытка чаклы белмәгән була.

Аннан Свияжскидагы агрономнар мәктәбенә укырга керә. Өч еллык программаны ике елда укып чыга. Институтны да вакытыннан элгәре бетермәкче була, әмма:— Лаборатория эшләре мөмкинлек бирмәде,— ди Алиуллин көлә-көлә.

— Экономика бүлегенә күчсәм, яхшырак булмас микән?

— Нәкъ шулай дияргә тора идем үзем дә. Экономист эше сиңа кулайрак булыр шикелле. Аннан бит син әле дә инде экономик эш алып барасың түгелме соң, хисап-учет шулайрак инде ул.

Хәзер Иршат институтның икенче курсын бетереп килә. Энесе Фәрит Казан ветеринария институтында укый.

Беренче бригаданың башлангыч партоешма секретаре, республиканың атказанган агрономы Минрасих Миннулла улы Алиуллин эшендә һәм тормышында очраган кызыклы да, гыйбрәтле дә вакыйгалар турында сөйли башласа, бик күп алар.

— Алты яшьлек кызым бар минем,— ди Минрасих абзый булган хәлләрнең барысына күңеленнән йомгак ясагандай.— Менә шул әйтә бер көнне: — Әти, нишләп әкиятләрең барысы да бер төсле? — ди.— Мәче балалары шырпы белән уйнаса, ут чыкмый калмый, каз бәбкәләре бернәрсәдән дә курыкмый... Андый әкиятләр сөйләмә миңа,— ди.— Син миңа кызганыч та булсын, көлке дә булсын, шундый әкиятләр сөйлә,— ди.— Әнинең әйткәннәре шикелле синең әкиятләрең — шырпыга кагылма, караңгыдан курыкма, яланаяк йөрмә... Менә мин кешеләр белән эшләгәндә дә нәкъ кызыма әкият сөйләгәндәгечә чыкмагае дип куркам. Тәрбия эше алып бару урынына өйрәтеп кенә утырмыйм микән,— дип сүзен тәмамлый партбюро секретаре.

Рафаэль Мостафин

# ТРАДИЦИЯЛӘРНЕ ҮСТЕРИК, ТИРӘНӘЙТИК

*Татар прозасында хезмәт кешесе*

Матур әдәбиятта хезмәт кешесен тасвирлауның күптәннән килә торган традицияләре, нык һәм тирән тамырлары бар. Максим Горькийның «Ана» романыннан башлап, җәмгыятьне актив рәвештә үзгәртеп коручы хезмәт кешесе социалистик реализм әдәбиятының төп герое булып килә. Иҗади хезмәт темасы күп милләтле совет әдәбияты үсешенең барлык этапларында төп, магистраль темаларның берсе булды һәм шулай булып калачак та.

«Социалистик реализм,— дип язды М. Горький,— чынбарлык тормышны кеше эшчәнлеге, иҗат буларак раслый, аның төп максаты — кешенең табигать көчләре өстеннән җиңүе хакына, аның сәламәтлеге һәм озак яшәве хакына, бер гаилә булып берләшкән кешелек өчен менә дигән тору урыны булган җирдә яшәү бәхете хакына кешенең иң кыйммәтле индивидуаль сәләтләрен өзлексез үстерүдән гыйбарәт»[1].

Хезмәт темасы татар язучылары игътибарыннан да читтә калмый. Дөрес, безнең язучылар озак еллар буе нигездә авыл хезмәтен сурәтләү белән чикләнеп килделәр. Бу аңлашыла да. Революциягә кадәр Казан губернасы Россиянең экономик яктан иң артта калган төбәкләреннән берсе була. Татарстанда социалистик индустрия үсү белән бергә, татар әдәбиятында эшчеләр темасы да киңрәк урын ала бара.

Бу темага багышланган беренче әсәрләр рәтенә Шәриф Камалның «Акчарлаклар» повестен кертергә мөмкин. Нибары өч басма табак күләмдәге шушы әсәрдә язучы Каспий балык промыселларындагы сезонлы эшчеләр тормышының бөтен авырлыгын күрсәтә алган. Әле Октябрь революциясенә кадәр үк язылган бу повесть эксплуататор сыйныфларга карата кискен нәфрәт, ә хезмәт кешеләренә, аларның акыл һәм рухи көченә тирән ышаныч хисләре белән сугарылган. Әсәрдәге Шәрәфи карт, аның кызы Газизә, Газизәнең сөйгәне Гариф кебек образлар бүгенге укучыларны да дулкынландырырлык дәрәҗәдә оста эшләнгән. Һәм шунысы кызыклы, хәтта әнә шул түзә алмаслык кыен шартларда, тынчу һавалы кысан баракларда, җәберләнгән һәм алданган эшчеләрнең хөерчә тормышында Шәриф Камал хезмәт поэзиясен, аның дөньяны үзгәртеп корырга сәләтле иҗади көч булуын күрә алган. Нәкъ менә шуңа да повесть укучылар күңелендә якты хисләр уята, аның төп каһарманнары исә үзләрен чолгап алган дөньяны, изүгә һәм рәхимсез эксплуатациягә корылган дөньяны үзгәртеп корырга сәләтле кешеләр булып хәтердә калалар.

Азат хезмәтнең яңа дөнья корырга сәләтле көч булуы Ш. Камалның Октябрь

[1] М. Горький о литературе. Рус телендә. Мәскәү. 718 бит.

революциясеннән соң язган «Матур туганда» романында аеруча көчле яңгырый. Язучы хезмәт кешеләренә, үз халкының бәхетле киләчәгенә ышана — аның иҗатындагы якты оптимизм хисе әнә шуннан килә. Хезмәт аның романында кеше тормышындагы гүзәл бер башлангыч, эстетик категория буларак катнаша, чөнки ул хезмәт кешене рухи коллыктан коткара, аңа үзен эшлекле кеше, тормышны үзгәртеп коручы итеп тоярга булыша.

Үзенең «Таң атканда» исемле икенче романында Шәриф Камал «Акчарлаклар» повестендагы төп геройларның соңгы чор язмышын сурәтли. Бу романның иске строй шартларында бәхетле тормышка ирешә алмаган персонажлары илдә барган зур социаль вакыйгаларга катнашып китәләр, үзләрен рухи яктан да, социаль яктан да яңадан тугандай хис итәләр. Әдәби эшләнеш дәрәҗәсе ягыннан кайбер кимчелекләре булуга да карамастан, роман язучы аңында хезмәт кешеләре темасының никадәр зур урын алуын күрсәтүе белән кызыклы.

Шушы ук тема Галимҗан Ибраһимовның да һәр әсәрендә диярлек күтәрелә. Без аның «Безнең көннәр», «Казакъ кызы» кебек мәшһүр романнарын яки «Татар хатыны ниләр күрми» һәм «Кызыл чәчәкләр» кебек повестьларын алабызмы — аларның һәркайсында хезмәт кешеләренең гаять тормышчан, тотып-әйләндереп карар дәрәҗәдә җанлы образларын очратабыз. Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романын 20 нче еллар татар прозасындагы югары бер казаныш дип бәяләргә мөмкин. Бу — авыл һәм шәһәр җирендәге кискен сыйнфый бәрелешләр турындагы, яңа, социалистик үсеш юлына аяк баскан җәмгыять тормышындагы тирән социаль үзгәрешләр хакындагы роман.

Шәриф Камалның «Матур туганда» романы да, Галимҗан Ибраһимовның «Тирән тамырлар»ы да — һәркайсы истә калырлык калку образларның бөтен бер галереясын биргән зур әсәрләр. Аларда хәзерге язучылар өчен дә өйрәнерлек нәрсәләр күп.

...Мәҗит Гафуриның «Шагыйрьнең алтын приискасында» повестенда алтын шахталарында эшләүче эшчеләр, прииска хуҗаларының аларны рәхимсез эксплуатацияләве турында сөйләнә. Уралның караңгы, тынчу шахталарында М. Гафури үзе дә эшли, татар һәм башкорт эшчеләренең ачы язмышларын үз күзләре белән күрә, язылышы белән автобиографик характердагы бу әсәрнең тормышчанлыгы, эмоциональ тәэсир көче әнә шуннан килә булса кирәк.

Шул кадәресен билгеләп үтәргә кирәк, 20 нче еллар прозасында хезмәт кешеләрен тасвирлаганда критик башлангыч өстенлек итә. Иске тормышта халык арасыннан чыккан гади кешеләрнең нинди социаль һәм рухи изелүләргә дучар булуларын сурәтләүгә басым ясала. Аерым алганда, без моны Афзал Таһиров, Хәсни Кәрим, Фатих Сәйфи-Казанлы, Афзал Шамов һәм башкаларның әсәрләрендә күрәбез. Шуның белән бергә, татар әдәбиятында үткән белән бүгенгенең закончалыклы бәйләнеше, буыннан-буынга тарихи көчә баруы турындагы фикерләр дә торган саен көчлерәк яңгырый башлый. Мәсәлән, ул чагында әле яшь прозаикларның берсе саналган Шамил Усманов элек изелеп яшәгән татар эшчеләре һәм крестьяннарының аңлы рәвештә яңа тормыш төзүчеләр сафына басуларын күрсәтә алды. Кави Нәҗминең «Якты сукмак», «Кояшлы яңгыр» кебек повестьларында яңа, социалистик авыл кешеләренең рухи коллыктан котылуы, хуҗалык итүнең коллектив формаларына күчүнең закончалыклы күренеш булуы сурәтләнә.

30 нчы еллар башына Татарстанда халык хуҗалыгын торгызу эшләре тәмамлана, индустриаль бишьеллыклар дәвере башлана. Шуның белән бер үк вакытта татар әдәбиятында эшчеләр темасы да үзенә тиешле урынны ала. Ләкин мәсьәләнең шул ягын да истән чыгармаска кирәк, безнең әдәбиятта авыл кешеләрен сурәтләүнең күптәнге традицияләре булса, промышленность хезмәте кешеләрен тасвирлаганда язучылар шактый җитди кыенлыклар белән очрашалар. Беренче чорларда, эшчеләр характерын тудырганда, ясалма шартлылык, схематизм кебек нәрсәләрдән котылып җитә алмыйлар. Шулай да «яңа кыйтгалар» акрынлап үзләштерелә.

Татар совет әдәбиятында бу теманы кузгатучы пионерлар рәтенә Ибраһим Газины кертергә мөмкин. Аның «Кәмеш сулы Нурминкә», «Бригадир кыз» кебек беренче повестьларында эшче яшьләрнең тормышы сурәтләнә. Автор билгеле бер дәрәҗәдә схематизмнан котылып җитә алмаса да, аның бу повестьларында сурәтләнгән кыю йөрәкле, үз эшләренең хаклыгына нык ышанган, яңа тормыш, яңа мораль өчен көрәш юлындагы кыенлыклардан курыкмый торган комсомолкалардан Фәридә белән Галияне татар әдәбиятының мәгълүм бер уңышы дип санарга була. Мәхмүт Сәндек-

ләчең «Донбасс ударниклары», Идрис Туктарның «Магнитка хикәяләре» кебек, 30 нчы еллар башында чыккан җыентыкларда да эшчеләр сыйныфының тормышы турында ышандырырлык итеп сөйләнә. И. Туктарның «81 нче штольня» повестен утызынчы еллар әдәбиятындагы эшче сыйныфына багышланган иң яхшы әсәрләр рәтенә кертергә мөмкин. Әсәрнең үзәгендә башта әле, ничектер, самимирәк, хәтта беркатлырак күренгән гади шахтер Гәрәй Мостафин образы тора. Әмма шахта партия оешмасының, коммунистларның уңай тәэсире йогынтысында акрынлап аның аңы үсә, характеры ныгый. Ул сыйнфый дошманнарның чын йөзен аерырга өйрәнә, тормышта үзенә ошаган дөрес юлны таба. Рахман Ильясның «Горизонт» исемле кызыклы повесте Баку нефть промыселларындагы эшчеләрнең тормышын тасвирлауга багышланган. Шунысы аеруча игътибарга лаек, талантлы язылган бу тормышчан әсәрендә язучы үзенең төп игътибарын коммунист образларын иҗат итүгә юнәлтә.

30 нчы еллар татар әдәбиятындагы эшчеләр сыйныфы темасын яктыртуга багышланган әсәрләрдә шактый җитди сыйфат үзгәрешләре барлыкка килә. Әдәбият характерлар тудыруда акрынлап схематизмнан, вульгар социологизмнан, уңай герой образларын артык берьяклы аңлатулардан котыла башлый. Максим Горький язучыларны социалистик реализм чаралары ярдәмендә «сүз сәнгатенең мөмкин булган бөтен көчен һәм куәтен файдаланып эшче сыйныфның, яңа тормыш төзүчеләрнең батырлыгын чагылдырган эпик сәнгать»[1] тудырырга чакырган иде. Татар язучылары, үз карамакларында булган материалга һәм сурәтләү чараларына таянып, бөек пролетар әдибе куйган әнә шул бурычны тормышка ашырырга омтылалар.

Инде 30 нчы еллар ахырына яңа кеше, хезмәт кешесе темасы татар әдәбиятындагы мөһим урыннарның берсен алып кына калмый, ул безнең әдәбиятның йөзен билгели торган темага, теге яки бу язучы иҗатының идея-эстетик әһәмиятен бәяли торган әлгәгә әйләнә.

Әйе, бүгенге татар язучыларының бу җәһәттән талантлы әлгәрләре, курыкмый таянырлык традицияләре бар. Мәсьәләгә шул күзлектән карап, мин соңгы елларда хезмәт темасына багышлап язылган кайбер иң мөһим әсәрләргә тукталырга һәм алар турындагы тәэсирләрем белән уртаклашырга телим.

Ни өчен соң әле соңгы елларда без социалистик реализм әдәбиятының социаль һәм сыйнфый ролен басым ясый, әдәбиятта хезмәт кешесенең чагылышы турында болай күп сөйли башладык? 20—30 елларда «сыйныфлар», «сыйнфыйлык» кебек төшенчәләр кайбер тәнкыйтьчеләр тарафыннан вульгар социологизм планында артык туры сызыклы итеп аңлатыла иде. Әгәр әдәби әсәрдә эксплуататор, дошман сыйныфлар вәкиле алынса, андый тәнкыйтьчеләр фикеренчә, ул образда кешегә хас бер генә уңай сыйфат та була алмый. Ул үзенең тышкы кыяфәте белән дә, гаилә, мәхәббәт мәсьәләләренә карашлары белән дә укучыларда бары нәфрәт хисләре генә тәрбияләргә тиеш. Һәм, киресенчә, әгәр берәр ялчы, ярлы халык арасыннан чыккан кеше алынса, ул һәряктан уңай, һәр мәсьәләдә үрнәк булыр дәрәҗәдә идеаль герой итеп бирелергә тиеш була. Заманында Фатих Хөснинең «Утызынчы ел» романы нәкъ менә шундый вульгар социологизм позицияләреннән чыгып тәнкыйть ителә.

Тулаем алганда, безнең әдәбият мондый балалык авыруыннан күптән котылды инде. Әмма, вульгар социологизмнан арыну белән бер үк вакытта, икенче читкә ташлану да сизелә. Безнең әдәбият турындагы мәкаләләребездән образның «сыйнфый йөзе», аның «социаль эчтәлеге» кебек төшенчәләр, ничектер, югала бара, аларның урынын «гомуми кешелек проблемалары», «гуманизм», «гомумән кеше» кебек абстракт терминнар били. Шундый ук тенденция матур әдәбият өлкәсендә дә сизелә. Язучылар гомумән җәмгыять, гомумән кеше, бөтен дөнья турында яза башладылар. Хәлбуки, гомумән кеше юк, мәгълүм бер тарихи эпоханың продукты булган конкрет индивидуум гына бар, гомумән кешелек җәмгыяте дә юк, берничек тә татулаштырып булмый торган идеология һәм сәясәт көрәше белән икегә бүленгән дөнья, социализм һәм капитализм дөньясы гына бар.

Социаль критерийларның зәгыйфьләнүе аерым язучыларны, бигрәк тә яшь авторларны, билгеле бер күләмдә сәяси чикләнгәнлеккә китерде, шуның турыдан-туры нәтиҗәсе буларак, безнең бүгенге чынбарлыкны тасвирлауда берьяклырак бизүлар естенлек ала башлады.

Нурихан Фәттахның «Бала күңеле далада» романы тәнкыйть тарафыннан нигездә,

[1] М. Горький. Собрание сочинений. Рус телендә. 26 том, 1953 ел. 245 бит.

һичшиксез, кызыклы, тирән эчтәлекле һәм кырыс хакыйкатьне тасвирлаган әсәр дип бәяләнде. Шулай да, чирәм җирләр үзләштерүчеләрнең героик хезмәтенә багышланган шушы роман белән танышкач, нигәдер күңелдә канәгатьсезлек хисе кала. Мәсьәлә авторның чирәм җирләрне үзләштерүчеләрнең авыр хезмәтен күрсәтүендә, алар тормышындагы җитешсез якларны сурәтләвендә генә булмаса кирәк. Хикмәт шунда, автор үзенең геройларын артык җиргә төшереп, урыны-урыны белән хәтта натуралистик планда тасвирлаган. Язучы хезмәт процессының шигърияттен, гадәти тормыштагы батырлыкны күрә алмаган. Романның төп герое Һарун — тар карашлы, вак, урыны-урыны белән хәтта түбән омтылышлар кешесе. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, мондый герой яшьләргә үрнәк була да, аларны үз артыннан ияртә дә алмый. Мин Н. Фәттах аңлы рәвештә «дегероизация» теориясенә ияргәндер дип уйламыйм, әмма мәсьәләгә объектив тестә якын килгәндә, әсәрдә мондый тенденция шактый сизелә. (Мине дөрес аңласыннар, моның белән мин уңай герой һәр яктан идеаль булырга тиеш дигән капма-каршы карашны якларга җыенмыйм. Юк, мин юри күпертеп яки юри түбәнгә төшерелгән герой яклы түгел, ә бәлки тормышчан, реаль герой тарафдары.)

Шундый ук тенденция күпмедер дәрәҗәдә икенче бер яшь прозаигыбыз Әхсән Баянов иҗатында да сизелә. Ул, һичшиксез, талантлы язучы. Яшь прозаик дөньяны үзенчә күрә, үзенең игътибарын чынбарлыкның башка язучылар күзеннән читтә калган якларына юнәлтә белә. Аның әсәрләрендә тирән психологизм һәм шигъри тел дә, дөнья турында мөстәкыйль фикер йөртә белү дә бар. Шуның белән бергә, аның күп кенә геройларының кимчелекле булуы да күзгә ташлана. Язучы еш кына эченә «корт төшкән», алай гына да түгел, «чери башлаган» геройларны сайлый. Аның вакытында җитди тәнкыйтькә очраган «Яшьлегемне эзлим» повестена шул нәрсә хас иде, шул ук кимчелекне без авторның зур күләмле соңгы әсәрләреннән «Декабрьның 13 көне» исемле повестенда да күрәбез. Кагыйдә буларак, Ә. Баянов үз образларын җитештерүчән иҗади хезмәттән читтә тасвирлый, геройларының социаль йөгенә тиешле игътибар бирми — аның каһарманнарының кимчелекле булуының сере, бәлки, шундадыр.

Соңгы вакыттагы социаль тетрәнүләр: капитал илләрендә барган расачылык һәм сыйныфлар көрәше, бөтен дөнья күләмендәге идеологик көрәшнең нык кискенләшүе, Вьетнамдагы сугыш, Якын Көнчыгыштагы кризис, соңгы елларда булып узган башка вакыйгалар бүгенге сәнгать әһелләрен социаль мәсьәләләргә аеруча игътибарлы булырга мәҗбүр итә. Зур социаль мәсьәләләрне дөрес аңлау һәм дөрес бәяләү өчен исә марксизм-ленинизм идеяләре белән ныклап коралланган булу сорала.

Юк, бу — язучыларны яңадан 20—30 нчы еллардагы вульгар социологизмга әйләнеп кайтырга чакыру түгел. Безнең аерым әсәрләргә яхшы мәгънәдәге, зур күләмле социаль күренешләрне аңлый белү, вакыйгаларга һәм кешеләргә партиячел дөрес бәя бирә белү мәгънәсендәге социальлек җитенкерәми. Бүгенге чынбарлыкны хезмәт кешесен — революцион идеяләрне төп таратучы, революцион үткәннең сугышчан традицияләрен саклаучы һәм дәвам иттерүче кешене тасвирлаудан башка дөрес аңлап булмый.

Габдрахман Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар» исемле романының нигезенә узгандагы данлы революцион традицияләрнең буыннан-буынга күчә бару идеясе, аларның бүгенге көнебез белән аерылгысыз бәйләнгән булуы турындагы фикер салынган. Сәнгатьчә эшләнешендә аерым кимчелекләре булуга да карамастан, эшчеләр темасына багышланган бу әсәр сугыштан соңгы әдәбиятыбызның җитди уңышы булып тора.

Гариф Ахуновның Татарстан нефтьчеләре тормышына багышланган «Хәзинә» романы да үз вакытында тәнкыйть әһәмиятле бер казаныш буларак билгеләп узган иде. Дөресен әйтергә кирәк, Татарстан нефте турында зур күләмле, масштаблы әсәрләр шактый язылды. Бу фикернең дөреслеген раслау өчен, Г. Белянкинның «Сәрия», А. Коптяеваның «Җир хәзинәсе», И. Газиның «Гади кешеләр» кебек романнарын санау да җитәр төсле.

Бүген, әлеге романнарның барчасын җыеп тикшереп баккач, шул нәрсә ачык күренә: һәммәсе арасыннан иң яхшысы, аеруча тормышчаны «Хәзинә» булган икән. Һәм бу, минем фикеремчә, очраклы хәл түгел. Язучы күп еллар буе үзе нефтьчеләр арасында яши, һәр көн булачак геройлары белән аралаша, алар белән бер һаваны сулый, нефтьчеләр эшчәнлегендәге тышкы детальләрне өйрәнү белән генә чикләнмичә, иң мөһимен — аларның җанын аңларга өйрәнә. Билгеле булганча, әдәбиятта җиңел юллар юк. Гариф Ахунов нәкъ

менә авыр, тапталмаган юлны сайлый. Шул аңа уңыш китерә.

Шул уңайдан заманында шактый модада булган «производство романы» дигән терминга тукталып узасым килә. Кайчандыр бу термин теләсә нинди нәшрият ишекләрен ачарлык тылсымлы ачкыч иде. Ләкин миңа калса, термин үзе дөрес түгел. Әдәбиятта производство романы дигән жанр юк. Коры спекулятив исәп белән әвәләнгән халтура, начар язмалар гына бар. Нәкъ менә шундый салкын кан белән язылган һәм шуңа да укучы тарафыннан кире кагылган язмаларга заманында «производство романы» дигән яман печать сугылды. «Производство романы» дигән терминның яман атын чыгару кайбер язучыларны производствога кагылышлы әсәр язудан бөтенләй баш тартуга китерде. Шуңа күрә прозада, поэзиядә, драматургиядә булсын, интим мөнәсәбәткә багышланган тар сулышлы әсәрләр, тышкы дөньядан биек койма белән аерылып торган, вак конфликтларга корылган әсәрләр күбәйде. Хәлбуки, югарыда бер тапкыр әйтелгәнчә, хезмәттән, бүгенге производство даирәсеннән тыш заман кешесенең эчке дөньясын аңлый да, аңлата да алмаячакбыз. Бу әле кирәксә-кирәкмәсә производство мәсьәләләренә кереп чумарга һәм һәртөрле техник процессларны тасвирларга кирәк дигән сүз түгел. Промышленность өлкәсендәге бүгенге үсеш этапларына карап хөкем йөрткәндә, саф промышленность каршылыкларына корылган конфликт әсәр дөньяга чыкканчы ук искерергә мөмкин. Производство даирәсе үзалдына гына алганда артык әһәмияткә ия түгел, ул әхлакый, социаль мәсьәләләрне тасвирлау өчен кирәк. Мисалга Атилла Расихның галимнәр тормышына багышланган «Ике буйдак» романын алырга мөмкин. Бер караганда, бу романда гади укучыларга бик үк аңлаешлы булмаган нәрсәләр буенча саф фәнни бәхәс бара сыман. Әмма язучыны бу конфликтның фәнни аспектлары түгел, ә кеше язмышына кагылышлы яклары кызыксындыра. Без бер үк мәсьәлә турында капма-каршы ике караш белән генә танышып калмыйбыз, бәлки фәнгә, тормышка ике төрле караш белән очрашабыз, ахыр килеп, әлеге конфликт барышында берсе икенчесенә бөтенләй охшамаган ике характер ачыла. Мин романның уңышын һәм авторның чын мәгънәсендәге гражданлык кыюлыгын нәкъ менә шунда — үз геройларын социаль аспектта ача белүдә күрәм.

Кызганычка каршы, безнең язучылар мондый бөтенлеккә хәзергә сирәк ирешәләр. Еш кына производство һәм производство мәсьәләләре бер ягы белән дә аерылып тормаган гадәти геройларга хәрәкәт итү өчен фон ролен генә үти. Мәхмүт Хәсәновның «Юллар, юллар» романында, мәсәлән, эш шулай тора. Үзенең «Зәй энҗеләре» повестенда сәләтле прозаик Аяз Гыйләҗев тә шул кимчелектән котыла алмаган. Ә тормыш үткен, катлаулы каршылыкларны минут саен тудыра тора, аларда замандашларыбыз бөтен тулылыгына ачыла алыр иде. Экономик стимуллаштыру һәм планлаштыруның яңа системасына күчүне генә алыйк. Ул безнең экономикада әр-яңа бер этап булып тора, өстәвенә, үзенә төрле кеше төрлечә карый. Кемнәрдер иске тәртипләр хөкем сөргәндә тынычрак яшәгән, шуңа алар иске традиция һәм гадәтләргә ябышып яталар. Шушы теманың Эдуард Касыймовның «Томан аша» исемле романында ничек хәл ителүен күзәтик.

Э. Касыймов романы — кызыклы һәм җитди, күп планлы әсәр. Автор материалны җентекләп өйрәнгән, кешеләр психологиясен аңлый, дөньяны һәм тормышны әйбәт белә. Аны производство процессларын читләтеп узуда да гаепләп булмый. Роман геройлары белән бергә, без химия предприятиесенең цехларына керәбез, төрле производство киңәшмәләрендә утырабыз, лаборатор анализ серләренә үтеп керәбез. Автор начар әсәрләргә, әзер штампларга иярүдән котыла алган. Шулай да никадәр генә тырышып һәм күп көч куеп эшләмәсен, Эдуард Касыймов романы да минә тулысынча канәгатьләндерә алмады. Минемчә, моның берничә сәбәбе бар. Беренчедән, хәзергә әсәрнең беренче китабы гына дөньяга чыкты, икенче кисәген автор язып ята. Күп кенә образларның өтек-тәтек булуы, сюжет линияләренең тәмамланмый калуы, композициядәге таркаулык шуннан килә, күрәсең. Әйтергә кирәк, дәвамлы романнар язу белән бер Эдуард кына мавыкмый. Минем фикеремчә, беренче китапта әйтеп бетерә алмаган нәрсәләрне икенчесен язганда эшләргә вәгъдә бирү — күпчелек очракта сәнгатьчә зәгыйфьлек билгесе, авторның иҗади яктан өлгереп җитмәгән булуы турында сөйли торган факт.

Рус совет һәм дөнья әдәбияты күп булса 200—250 битлек күләмгә бер зур социаль проблема, үзенең иң мөһим моментлары белән тормышның бер катламын

сыйдырырлык лаконик һәм күп сыйдырышлы роман формасы тудырды. Мондый әсәрләрнең геройлары безгә бөтен ваклыклары белән үз биографияләрен сөйләп тормыйлар, ә безнең алда үз тормышларының борылыш моментларында гына күренәләр. Билгеле, мин бары шушы бер форманы гына канунлаштырырга чакырмыйм. Мондый типтагы социаль-психологик романнар белән бергә, роман-эпопея, тарихи романнар, роман-монологлар да яшәргә хаклы. Минем бары әдәби осталыкка дөньячың иң яхшы романчыларыннан өйрәнергә кирәк дип кенә әйтәсем килә.

Безнең романнарны исә еш кына коры тасвирчылык күмеп китә, һәм алар, барыннан да элек, әсәрнең төп проблемасы белән бәйләнмәгән икенче дәрәҗәдәге, кирәкмәс ваклыклар хисабына калынаялар. Әсәргә яңа герой килеп кердеме — аның бөтен биографиясе сөйләнеп чыгыла, укучыга аның турында дөнья хәтле нәрсә хәбәр ителә. Геройның күзенә ни ташланса, шуларның һәммәсе җентекләп тасвирлап чыгыла, хәлбуки, авторның төп фикере өчен аларның байтагы бөтенләй кирәксез була.

Эдуард Касыймовның икенче кимчелеге шунда, романның баш герое әсәрдә күтәрелгән төп мәсьәлә белән тыгыз бәйләнмәгән. «Томан аша» романында җиһазларны яңарту, хезмәтне интенсивлаштыру, планлаштыруның яңа алымнарына күчү кебек бүгенге химия промышленносте өчен актуаль проблемалар күзгатыла. Әмма шушы мәсьәләләр белән турыдан-туры шөгыльләнүче кешеләрдән завод директоры, баш инженер һәм үзәк лаборатория мөдиренең образлары йомшак һәм таркау чыккан. Романның үзәк персонажы Фуат исә шактый чикләнгән, хулиганлык эшләп, кайчандыр төрмәдә утырган кеше. Романдагы вакыйгалар барышында, вак җинаять эшләүдә гаепләп, аны тагын 15 тәүлеккә утырталар. Сүз дә юк, әдәбиятта мондый образлар да яшәргә хаклы, өстәвенә, ахырга таба Фуат төзәлә, намуслы хезмәт юлына аяк баса. Әмма бер нәрсә бәхәссез, Фуат манарасыннан торып, автор күзгаткан производство мәсьәләләрен тулы яктырту кыен эш. Менә шуңа да «Томан аша» романында Фуат үзенә аерым, ә производство мәсьәләләре үзләренә аерым яшиләр. Бу кимчелекләрдән автор, бәлки, икенче китапны язганда котыла алыр.

Безнең язучылар тормыштагы яңалыклар артыннан өлгермиләр дип сөйләү дә чәйнәлгән фикергә әйләнеп бетте. Кабатлау булса да, аларны яңадан искә төшерергә туры килә. Безнең көннәрдә иҗтимагый тормыш һәм производство өлкәсендә үзгәрешләр шундый кызу темплар белән бара ки, гадәтләнгән адымнар белән эшләгәндә язучыга аларны куып җитү кыен булачак. Карагыз, нихәтле бай һәм күп төрле безнең тормышыбыз, бай рухлы, кызыклы кешеләр никадәр күп бездә.

Мин Уфа нефть эшкәртү заводында эшли торган бер татар егетен беләм. Ул аппаратчы, эшли дә, читтән торып техник ВУЗ да тәмамлап килә, белем ягыннан кайбер инженерларга биргесез. Поэзия әсәрләрен ярата, классик музыка язылган пластинкалар җыя. Мин белгәндә, 400 ләп пластинкасы бар иде, хәзер күбрәктер дә.

Бервакыт шундый хәл була. Производство практикасы узу өчен заводка ниндидер студентлар килә. Аңа да ике студент кыз беркетәләр. Ул, производство җиһазлары белән таныштыру өчен, аларны «этажерка» дип аталган приборлар янына алып китә. Кызлар үзләрен бик эре тоткан булалар, ни дисәң дә алар студентлар, ә ул гади эшче. Юлда инглиз телендә гайбәт сатарга да өлгерәләр: «Егете болай ярыйсы икән, ләкин аның белән ниндидер этажеркалар арасында йөргәнче, берәр тын почмакта үбешеп тору артыграк булыр иде»,— ди берсе. Ул, чыннан да, ярыйсы егет, зәвык белән киенә белә торган, зифа буйлы, интеллигент кыяфәтле чибәр кеше. Шул чак егет үзе дә сүзгә катнаша һәм саф инглиз телендә: «Кызлар, гафу итегез, мин инглизчә аңлыйм бит, әгәр яшерен серләрегез булса, башка берәр телдә сөйләшегез»,— ди. Кызлар гаҗәпләнүдән аптырап калалар. Шулай ул аларның кикрикләрен бик тиз шиңдерә.

Бер уйлаганда бәләкәй, әмма бик кызыклы факт, бүгенге эшче сыйныфының рухи үсешен күрсәтә торган, нәкъ менә бүгенге эпоха, фәнни-техника революциясе эпохасы өчен характерлы факт. Бүгенге автоматик линия янында, исәп-хисап станциясенең приборлар щиты каршында басып торган эшчеләр көрәк белән түң җир, кайлә белән канау казыган, коры кул белән беренче бишьеллыклар төзелешләренең нигезләрен салган кешеләрдән тышкы кыяфәтләре белән генә түгел, рухи үсешләре ягыннан да нык аерылалар. Мин моны безнең абыйларны һәм әтиләрне кимсетү

өчен әйтмим. Аларның үз матурлыгы, үз энтузиазмы һәм үз хезмәт пафосы булган. Минем бары бүгенге эшче инде нык үзгәрде, һәм әдәбият аның рухи дөньясына үтеп керергә, алдынгы эшче образын тулы канлы сәнгатьчә образларда гәүдәләндерергә тиеш дип кенә әйтәсем килә.

Безнең әдәби геройларыбызга иҗтимагый һәм социаль активлык җитми. Әдәби китапларыбыз битендә яңаны тәзүче актив герой белән очрашасы килә. Күптән түгел Хәсән Сарьянның «Әткәм һөнәре» повесте 100 мең данә тираж белән рус телендә басылып чыкты. Сүз дә юк, ул — җылы, лирик буяулар белән язылган кызыклы әсәр. Ләкин нәшрият кешеләреннән берсе аны хезмәт темасына багышланган һәм хезмәтнең шигърияттен ача торган әсәрләр төркеменә керткәч, мин бераз сагаеп калдым. Дөрес, «Әткәм һөнәре»ндә хезмәт поэзиясе бар, ләкин нинди хезмәт поэзиясе?.. Әсәрнең төп өлешендә шабашниклар хезмәте, колхоз эшеннән качып, ата бер җулякка зур суммага йорт салучылар турында сөйләнә. Әлбәттә, бу очракта да хезмәт хезмәт булып кала, ләкин безнең өчен хезмәт үзе түгел, аның иҗтимагый эчтәлеге, максаты һәм җәмгыять өчен файдалы булуы мөһим. Дөрес, Х. Сарьян повестеның төп герое, ахыры килеп, шабашниклар белән араны бөтенләй өзә, хәтта дәүләт урманын урлап сатучы каракларны да фаш итә. Шулай да аның иҗтимагый йөзе бик аз ачылган, колхоз бригадасы коллективында эшли башлагач, ул үзен ничегрәк тотар — ул кадәресе әле билгесез. Чыннан да, 50 еллар элек мондый персонаж менә дигән герой саналыр иде. Әмма безнең бүгенге кешеләр Сарьян повестенда сурәтләнгәннән күп тапкыр активрак, баерак һәм кызыклырак.

Безнең әдәбият алдында катлаулы, әмма мактаулы бурыч тора. Ул бурыч хезмәт кешесенең интеллектуаль дөньясын, аның теләк-омтылышларын һәм социаль асылын ачудан гыйбарәт. Бу юнәлештә омтылышлар булмады түгел. Мисалга Рафаил Төхфәтуллинның «Тамчылар ни сөйли» һәм «Агымсу» повестьларын, Газиз Мөхәммәтшинның «Йөрәктәге эзләр»ен һәм башка әсәрләрне китерергә мөмкин. Әмма чын мәгънәсендәге әдәби ачышлар хәзергә азрак әле. Бигрәк тә инженер хезмәтендәге кешеләрнең, бүгенге җитәкчеләрнең үзенчәлеген ачу кыен мәсьәлә булып кала бирә. Моңа идеаль геройның йөзе турындагы шаблон карашлар да комачаулый булса кирәк. Әйтик, безнең күп кенә әсәрләрдә уңай герой физик яктан гаять көчле кеше итеп бирелә. Сүз дә юк, бу әйбәт сыйфат, ләкин андый геройны укучылар да ярата. Әйтик, Гариф Ахуновның «Хуҗалар» романының төп герое Арслан Гобәйдуллин — эре нефтепромысел идарәсенең начальнигы — әкият героедай батыр итеп күрсәтелә. Ул бернинди әзерлексез сабан туенда көрәшеп батыр кала, унлап хулиганны эһ тә итми тукмап ташлый, янгын вакытында хәтта махсус өйрәтелгән кешеләр дә керергә җөрьәт итмәгән иң хәтәр урыннарга барып керә һ. б. һ. б. Башкарган эшләре күп кебек, ә чын мәгънәсендәге җитәкче барыбер күз алдына басмый. Чөнки бүгенге җитәкченең көче мускулларында түгел, ә производствоны көйли, башкалар хезмәтен оештыра белүендә күренә. Минемчә, начальник кешенең янып торган утка ташлануы һич мәҗбүри түгел. Яхшы җитәкче икән, ул аварияга юл куймаска, инде янгын чыккан икән, аны тизрәк сүндерү чараларын күрергә тиеш иде. Үзенең «Агымсу» повестенда Рафаил Төхфәтуллин да нәкъ шул юлдан китә. Аның герое яшь малай чакта билен сындыра, төзелгәч тә күп еллар корсет киеп йөри. Һәм алдагы бүлекләрдә һич уйламаганда без аны Иван Поддубный кебек үк батыр итеп күрәбез. Безгә уңай геройларыбызны бу рәвешчә беркатлы тасвирлаудан арынырга күптән вакыт инде.

Миңа калса, эшчеләр сыйныфы турындагы әдәбият кешене станок янында сурәтләү һәм шуның белән тиешле графага билге кую өчен генә яшәми. Юк, һәр сәнгать әсәре кебек үк, хезмәт кешесе турындагы роман да безнең бөтен тормышыбызны яктыртырга, безнең заманны, замандашыбызның йөзен аңларга булышырга тиеш. Шул ук Р. Төхфәтуллинның «Авылдашым Нәби» повестендагы гади ат караучы образы, мәсәлән, шундый иде. Никадәр җылылык һәм шигърилек белән, хезмәт кешесенең психологиясен никадәр тирән белеп эшләнгән бу образ! Нәби бер генә секунд та эшсез тора алмый. Әнә ул урам буйлап үтеп бара, шунда берәүгә йөген рәтләшергә булыша, ул да түгел, тол хатынның ауган рәшәткәләрен рәтләп китә, өченче авылдашына тагын нинди дә булса берәр яхшылык эшли. Электән килгән гадәт буенча «кечкенә кеше» дип йөртелгән шушы образда Р. Төхфәтуллин сугыштан соңгы еллардагы авыл халкына хас теләк-омтылышларны күрсәтә алган.

Гомәр Бәшировның «Намус» романында-

гы Нәфисә дә шундый матур ачышларның берсе саналырга хаклы. Дөрес, әлеге әсәрләрнең һәр икесендә дә сүз авыл кешеләре турында бара. Ләкин эшче темасына иҗат итүче авторлар өчен нәкъ менә шушы әсәрләрдә өйрәнер нәрсә шактый күп. Яисә Михаил Шолоховның «Күтәрелгән чирәм» романыннан Давыдов образын искә төшерик. Аның бу әсәрен «производство романнары» рәтенә кертеп йөртмәсәләр дә, ул нәкъ менә эшче сыйныфының сугышчан традицияләрен, коммунистлар партиясенең югары идеяләрен гәүдәләндерүче сәнгать әсәре. Николай Островскийның «Корыч ничек чыныкты» романындагы Павел Корчагин да үз сыйныфы идеологиясенең үзләштергән егетләрнең берсе. Моның белән минем эшче әдәбияты дип йөртелгән ниндидер аерым әдәбият юк, гомуми бер әдәбият, М. Горький сүзләре белән әйткәндә, кешене өйрәнүче әдәбият кына бар дип әйтәсем килә. Шуңа күрә барлык әсәрләргә карата да эстетик критерийлар һәм үлчәүләр бертөсле булырга тиеш.

Кызганычка каршы, кайчакта әле тәнкыйтьчеләр һәм кайбер нәшрият кешеләре тарафыннан теманың актуальлегенә, «мәсьәләнең мөһимлеге»нә ташлама ясаулар очраштыргалый. Мондый караш чи, эшләнеп бетмәгән әсәрне дөньяга чыгарып мөһим теманың яман атын таратырга гына ярый. Ян Винецкийның Татарстан нефтьчеләре тормышына багышланган «Тот, кто верит» дигән романы белән шундый хәл булды. Редакторларның таләпчән булмаулары һәм авторның үзенең талымсызлыгы аркасында, язучының изге омтылышлары тормышка ашмаган, хәтта ул теләгәннәрнең киресенә китергән.

Хезмәт кешесе — абстракт төшенчә түгел. Ул безнең арада яши, материаль байлыклар җитештерә торган теге яки бу конкрет сыйныф вәкиле генә булмыйча, мәгълүм бер милләт кешесе дә. Шуннан эшче сыйныф турындагы әдәби геройның милли үзенчәлеге дигән мәсьәлә күтәрелеп чыга. Эш шунда, авыл җирендә, телдә булсын, гореф-гадәтләр, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрендә булсын, милли үзенчәлек ныграк, күбрәк сизелеп тора. Шуңа күрә дә безнең язучылар авыл турында язуны артыграк күрәләр. Әмма тикшерә китсәң, эшчеләрнең дә зур күпчелеге шул ук авылдан чыккан кешеләр. Кайберәүләр уйлаганча, аның милли үзенчәлеге фабрика казанында кайнап юкка чыкмый, ә башка формалар гына ала. Шуны күрә белү, ышандырырлык формаларда сурәтләп бирә белү, билгеле, авыр, әмма мактаулы миссия.

Тагын бер өлгергән мәсьәләне кузгатасы килә. Тәнкыйтьче Х. Хәйри соңгы 15 елны романнар һәм повестьлар дәвере дип саный. Бу билгеләмәдә билгеле бер хаклык бар. Чыннан да, галимнең исәплауләренә караганда, безнең язучылар тарафыннан Ватан сугышына кадәрге чор эчендә 18—20 роман язылган булса, сугыштан соңгы елларда 40 тан артык роман дөнья күргән икән. Бу, әлбәттә, шатлыклы күренеш, чөнки роман — әдәбиятның өлгерү дәрәҗәсе хакында сөйли торган жанр. Әмма шушы шатлыклы күренешнең үзенең тискәре яклары да бар. Бездә хәзер һәркем, хәтта яшь һәм башлап язучылар да романга тотына. Хикәя язуга караганда да тизрәк алыналар. Бездә хәзер хикәя кытлыгы турында күп сөйләнә икән, бу юкка гына түгел. Хәлбуки, эшче сыйныфы тормышының төрле якларын нәкъ менә хикәя кебек кыска һәм күп сыйдырышлы форма уңышлы яктырта алыр иде. Бездә яхшы хикәяләр аз языла, эшче темасына караганнары бигрәк тә. Шуңа күрә яшь прозаик Марсель Зариповның күптән түгел дөньяга чыккан хикәяләр җыентыгын куанычлы бер вакыйга буларак билгеләп узасы килә. Урта кул хикәяләр, гадәти хикәяләр белән бергә, җыентыкта нефтьчеләр тормышыннан алып язылган менә дигән әйбәтләре дә очрый.

Очерк жанры белән эш тагын да кыенрак тора. Кайчандыр бу өлкәдә безнең әдәбиятның иң күренекле вәкилләре эшләгән. Мисалга Афзал Шамов, Шәйхи Маннур, Ибраһим Гази кебек язучыларның бик күп очеркларын китерергә мөмкин. Хәзер исә, кызганычка каршы, бу жанрдан өркәләр, аңа, ничектер, икенче дәрәҗәдәге, әһәмиятсез бер нәрсә итеп карыйлар. Ә менә Герман Крыловның атаклы нефтьче Белоглазов турындагы «Тынгысызларны онытмыйлар» исемле очеркы бик күп повестьларга биргесез. Безгә гадәти тасвирый очерк кына җитми, тормышның яңа катламнарын, яңа проблемаларын күтәргән проблемалы очерклар кирәк.

Күптән түгел мин Анатолий Аграновскийның соңгы елларда иҗат иткән очеркларыннан төзелгән җыентыгын кулга төшердем. Заманында язучының «Кулыгызны бирегез, Иван Иванович» исемле һәм Казан дәүләт университеты турындагы очерклары күңелдә онытылмаслык тәэсир калдырган

иде. Алар бүген дә искермәгәннәр — кабат укыгач, шуңа ышандым. Дөрес, безне бүген бераз башкарак проблемалар дулкынландыра. Ләкин очерклардагы ялкын, пафос сүрелмәгән. Шуңа ул очерклар бүген дә мавыгып укыла. Кызганычка каршы, безнең татар әдәбиятында Анатолий Аграновский, Валентин Овечкин кебек очеркистлар юк әле. Дөрес, гаделлек хакына, Ш. Бикчуриннның тәэүчеләр тормышын тирән белеп язылган очерклар китабын, шулай ук Гариф Ахуновның берничә проблемалы очеркын телгә алырга мөмкин. Әдип Маликов һәм Эдуард Касыймовларның хезмәт кешеләре хакындагы тирән мәгънәле һәм матур очерклары истә калган. Ләкин, кызганычка каршы, андый уңышлар хәзергә бик аз әле.

Ә тормышыбызда андый әсәрләр иҗат итәргә бай материал бар. Партиянең XXIII съездыннан соң узган вакыт эчендә илебез экономикасы үсешендә искитмәле үзгәрешләр булды. КПССның XXIV съезды исә экономика өлкәсендә зур, яңа бурычлар билгеләде. Яңа экономик политиканың нинди уңышларга китерүен үзебезнең Татарстан республикасы мисалында да ачык күрергә мөмкин. Егерме өченче съезддан соң узган елларда бездә зур химия флагманы — Казан оргсинтез заводы бөтен көченә эшли башлады. Илебездәге иң эре комбинатларның берсе булган Түбән Кама химия комбинаты сафка басты. Кама автомобиль гиганты төзелә башлады. Татарстан нефтьчеләре елына 100 000 000 тонна нефть бирүгә ирештеләр. Бер сүз белән әйткәндә, иҗат кешесенә уйланып, көчне сынап карар өчен мөмкинлекләр җитәрлек.

КПССның XXIV съездында кабул ителгән Директиваларда безнең республикадагы яңа төзелешләр турында әйтелә:

«...Татарстан АССРда йөк машиналары житештерә торган заводлар комплексы төзергә... Түбән Камада нефтехимия предприятиеләре комплексын төзүне тизләтергә... Тольяттида, Волжскида, Казанда, Уфада, Яңа Чебоксарда химия предприятиеләрен төзүне тәмамларга... Түбән Кама һәм Чебоксар гидроэлектростанцияләрен төзүне дәвам итәргә...»

Директиваларда безнең республика әйләнәсендә перспективалы районнарның берсе дип күрсәтелә. Бездә промышленность үсешенең темплары ил күләмендәге гомуми күрсәткечләрдән шактый югары булачак. Менә бер генә факт. Түбән Кама нефтехимия комбинатында продукция эшләп чыгару бу бишьеллыкта, 1970 ел белән чагыштырганда, 10 мартәбә, ә хезмәт житештерүчәнлеге 5,4 мартәбәгә үсәчәк. Директиваларлагы шундый гади, әмма ифрат гыйбрәтле саннар белән танышкач, күңелне горурлык хисләре били. Безнең давылды чорның үсеш адымнарыннан артта калмас өчен, язучыларга нык, бик нык активлашырга кирәк.

Соңгы елларда безнең әдәбиятка яшьләр бик күп килә, һәм алар алдында бик зур перспективалар ачылып тора. Әмма алар бер нәрсәне истән чыгармасыннар: үз әсәрләренә төшкән миссияне уңышлы башкарырга теләсәләр, узгандагы традицияләрнең иң яхшы якларын файдалана белергә һәм бүгенге көннән артта калмаска тиешләр.

◇◇◇◇◇◇◇◇◇

## Фарваз Миңнуллин

# ҮСЕШ БАСКЫЧЛАРЫ

Мәдинә Маликованың «Юлдашлар» исемле беренче җыентыгы 1967 елда дөнья күргән иде. Быел менә «Казан каласы — таш кала» исемле яңа китабы[1] басылып чыкты. Ике арада дүрт ел гомер ята. Шул еллар эчендә яшь прозаик иҗатында нинди үзгәрешләр барлыкка килгән? Алга киткәнме ул, әллә бер урындарак таптанганмы?

Әлеге сорауларга җавап эзләп, яшь авторның беренче китабын кабат кулга алам, кайчандыр укыган хикәяләрен тагын бер кат күздән кичерәм. Болай ярыйсы гына булганнар икән. Шактый җыйнаклар һәм бөтеннәр. Автор күзәтә белә, тормышчан, характерлы детальләр тота алган. Һәр хикәясендә диярлек истә калырлык образлар, матур эпизодлар очрый. Шул ук вакытта, зур таләпләр югарылыгыннан торып тикшерергә тотындыңмы, ул хикәяләрнең йомшак яклары, кимчелекләре дә күренә башлый. Иң элек, аларда язучының үз йөзен, тормышка үзенчә карашын тою читен. Шуңа күрә хикәяләр ничектер чырайсыз һәм төссез күренәләр. Алар кемнәргәдер ияреп, кемнәрдәндер өйрәнеп язылган урта кул хикәяләр сыман. Бу — аларның темаларында да, күтәргән мәсьәләләрне чишү алымнарында да, образлар бирелешендә дә сизелә.

Менә «Алтын читлек» исемле хикәя. Болай әйбәт кенә язылган.

Көзге матур көннәрнең берендә шәһәрдән Мәрхәбә әбинең бердәнбер улы Зәбир кайтып төшә: әнисен үз янында торырга Казанга алып китмәкче икән. Ул хәзер зур гына заводның баш инженеры булып алган. Шәһәрдә аның газлы-ванналы, ялт-йолт итеп торган затлы мебельле шәп фатиры бар, ди. Карчык баштарак риза да була кебек. Әмма мәсьәлә тәмам хәл ителде, җыенып чыгып китәбез дигәндә — кире уйлый. Туып-үскән җирен, гомер иткән йортын ташлап китәсе килми Мәрхәбә әбинең. Бик табигый һәм аңлашыла торган хисләр.

Әмма мәсьәләнең икенче ягы бар әле. Безнең әдәбиятта, Мәрхәбә әби кебек, авылдан китәргә теләмәгән карчыклар һәм картлар турында күп язылды. Мәдинә бу мәсьәләне чишүгә нинди яңалык өсти алган? Хикмәт менә нәрсәдә. Безнеңчә, ул үзенә кадәр әйтелгән фикерләрдән узып нинди дә булса яңа сүз әйтә алмаган. Ә бит тормыш үзгәреп тора. Авыл халкы күпләп шәһәргә күчә. Никадәр генә кыен һәм читен булмасын, Мәрхәбә әбиләргә ахыр чиктә барыбер уллары-кызлары янына күчәргә туры киләчәк. Хикәядә мәсьәләнең нәкъ өнә шул ягы искә алынмаган шикелле.

Шундыйрак нәрсә «Кыр ягы» исемле хикәядә дә сизелә. Дилбәр укый торган факультет студентларын, кыр эшләрендә булышу өчен, «Чишмә» колхозына җибәрәләр. Хикәя беренче мәртәбә авыл җиренә килеп эләккән әлеге кыз исеменнән языла. Автор үзенең төп игътибарын Дилбәр күңелендә җиргә, авыл кешеләренә карата хөрмәт һәм мәхәббәт хисләре уянуын күрсәтүгә юнәлткән. Бераз таркаурак эшләнсә дә, хикәя шулай ук әйбәт тәэсир калдыра. Әсәрдә авыл табигате матур бирелгән, анда авыр һәм гыйбрәтле язмышлы Сорур апалар, шаян һәм көр күңелле Нурзаһитлар бар. Әмма яңалык, мәсьәләгә мөстәкыйль төстә якын килә

---

[1] М. Маликова. Казан каласы — таш кала. Повесть һәм хикәяләр. Казан. 1971 ел.

белу биредә дә җитеп бетми. Әмирхан Еникинең һәм башка күренекле язучыларыбызның шушы ук темага язылган әсәрләре белән таныш укучыга Мәдинә хикәясе әллә ни өсти алмый.

Чама тойгысы, осталык һәм тәҗрибә җитмәү аерым хикәяләрдәге образларның эшләнешенә дә үз эзен салган. Язучы күбрәк ак һәм кара төсләргә буяулар белән эш итәргә ярата. Геройларның уңайлары артык пакьлар һәм аклар. Тискәреләре исә адәм карамаслык начарлар. Шул ук «Кыр ягы» хикәясендә, Дилбәрне әйбәт күрсәтәм дип, язучы кирәкмәгәнгә аның иптәш кызлары Разия белән Санияне каралтып ташлый. «Юлдашлар»дагы Зиннәт турында да шуны ук әйтергә кирәк. Ул карак та, мораль тотнаксыз да, миһербансыз да... Каян килгән бу кадәр әшәке кеше, аны ничек җир күтәреп тора, дип гаҗәпләнергә генә кала.

Әмма ни генә булмасын, кимчелекләре һәм җитешсезлекләре никадәр генә күп күренмәсен, әлеге хикәяләрдә үк инде бүгенге Мәдинә өчен хас чалымнарны сизәргә, аның бүгенге иҗаты өчен характерлы якларны чамаларга мөмкин. Мәхәббәт темасын, гаилә бәхете мәсьәләсен алыйк. Бу — аның иҗатында даими төстә яктыртылып килә торган үзәк темаларның берсе. Еллар узу белән авторның гаилә, мәхәббәт мәсьәләләренә карашы ни рәвешле үсәүзгәрә баруын күрсәтү өчен, аның төрле елларда язылган ике хикәясен чагыштырып карыйк. Аларның берсе «Чаллы баскычлары» дип атала. Ул авторның 1967 елгы җыентыгына кертелгән. Икенчесе «Күрше бәхете» исемле хикәя. Бусы—быелгы китапта. Һәр икесе гаилә бәхете, ир белән хатын арасындагы мәхәббәт мәсьәләләренә багышланган. Аерма әлеге мәсьәләне ничек чишүдә, тирәнлектә.

Рәүф исемле шофер егет Чаллыга кеше алырга барган җиреннән бер чибәр кыз утыртып кайта. Сөйләшеп кайта торгач, танышып китәләр. Кыз күрше авылныкы икән, Ләйсән исемле икән. Әлеге танышлык тора-бара дуслыкка әйләнә. Тагын бер елдан, өйләнешеп, матур гына гаилә корып җибәрәләр. Тик аларның гаилә тормышы кыска гомерле булып чыга. Ләйсән, иренең ай-вәенә карамый, врачлыкка укырга дип, шәһәргә китеп бара. Тегесе, аңа ачу итеп, Хәлисә исемле күрше кызына өйләнеп ташлый. Ахырдан ялгышканын аңлый, бу эше өчен бик нык үкенә башлый. Ләкин соң инде... Хикәя ашыгып Хәлисәгә өйләнгән Рәүфне үкендерү өчен язылган. Минем, укучы буларак, нәкъ шул мәсьәләдә автор белән бераз бәхәскә керәсем килә. Хатын өстеннән хатын алып йөргән Рәүфләрне үкендереп кенә калу аз түгелме икән?.. Аннан соң автор бер дә юкка Хәлисәне начарга чыгарырга тырыша. Имеш, ул Ләйсән кебек шигъри җанлы түгел, имеш, ул гүзәллекне, матурлыкны аңламый... Булмаса соң, аңламаса соң! Аның караваы, Хәлисәнең үз матурлыгы, үз өстенлеге бар. Ул сабыр һәм басынкы, эшчән һәм тырыш кыз. Бу хикәяне укыганда мин Хәлисә кебек тыйнак кызларны җәлләп утырдым. Ә менә «Күрше бәхете»ндә бу мәсьәлә дөресрәк тә, кешелеклерәк тә хәл ителә кебек.

Хәдичә апа белән Шакир абзый шулай әлеккечә яшәп ятырлар иде әле, мөгаен. Ләкин күршедәге буш йортка, уйламагандә-көтмәгәндә дигәндәй, шәһәрдән яңа бер гаилә күчеп килә. Яңа күршеләре Рөстәм белән Фәридәнең үзара мөнәсәбәте, берберсе өчен үлеп торулары Хәдичә апаның инде сүнеп-сүрелеп барган күңел кылларын терелтеп җибәрә. Кара син аны, ул да яшәгән инде ир хатыны булып!.. Кузгалган, ярсыган күңел яшьлек елларына әйләнеп кайта. Күз алдыннан бөтен гомер юлы уза. Башына берсеннән-берсе үкенечлерәк уйлар килә.

Яшь чагында шул сары чәчле Фәридә өсе генә идеме Хәдичә апагыз. Кече урамның беренче чибәре иде. Шакирга чыккач кына кадере калмаган икән...

Нәкъ шул елларда аның яшьтәшләре төрле курсларга укырга киттеләр. Хәдичәне дә димләгәннәр иде. Ләкин ул бармады. «Гаиләбез зур, күбесе ирләр, ничек ташлап китим», дип калды. Зирәк иде, югыйсә, Хәдичә. Иренә, каенана белән каенатага, каенишләргә хезмәт күрсәтәсем бар, дип калды.

Ә Шакир аның кебек басылып калмады. Армиядән аң-белем алып, күтәрелеп кайтты да чит авылларда җитәкчелек итеп йөрде. Тормышның бөтен мәшәкате, ыгызыгысы тагын Хәдичә иңенә өелеп калды. Аннан авыр сугыш еллары... «Тукта, картның кәефе кырылмасын», «Тукта, балалар бераз исәйсен», «Тукта, тагын аз гына түзим», дия-дия утыз ел гомер үткән. Шул гомер эчендә берәү дә аңа ярарга тырышмаган, берәү дә аның уй-хисләре белән кызыксынмаган. Утыз ел эчендә ничаклы сүзләр сөйләнелмичә күңелгә төер булып утырган! Күпме бәйрәмнәр, бәхетле булырдай минутлар сизелми үтеп киткәннәр!

Никадәр сөелү-назлашу күрелми калган!.. Хәзер менә ничек кенә тырышсаң, күпме көч куйсаң да, ул елларны кайтарып алып булмый инде. Хәдичә апа соңга, бик соңга калып шул хакыйкатьне аңлый. Кешелекле хикәя, уйландыра торган гыйбрәтле хикәя. «Чаллы баскычлары» белән чагыштырганда, монда гаилә бәхете мәсьәләсе тирәнрәк, эмоциональрәк һәм дөресрәк хәл ителә. Әмма шулай да Мәдинә элекке традицияләр йогынтысыннан барыбер котылып җитә алмаган. Безнең кайбер башка язучылар кебек үк, ул да ир белән хатын-кызның тигез хокуклыгын гадиләштереп һәм беркатлырак итеп аңлата кебек. Миңа калса, гаилә бәхете, тигезлек өчен ирләрнең бала чүпрәге яки идән юуы, я булмаса шәл бәйләргә өйрәнүе, ә хатын-кызның урман кисеп, тирес түгүе һич мәҗбүри түгел. Ир кешенең үз урынында, хатын-кызның үз урынында булганы яхшы. Һич югы, кем нәрсәгә сәләтле, шул эшне башкарырга тиеш. Авторның хәзер генә без тикшергән «Күрше бәхете» хикәясендә һәм кайбер башка әсәрләрендә ир-атны хатын-кыз эшенә кушарга тырышу тенденциясе сизелә. Әмма ни генә булмасын, «Күрше бәхете» дә, җыентыктагы «Янар таулар аша» исемле икенче бер хикәя дә авторның иҗат кешесе буларак тагын да үсүе, алга китүе турында сөйли.

Мәдинә Маликованың бөтен язганы шушы ике җыентыкка гына сыеп бетмәгән, билгеле. Соңгы елларда ул маҗаралы жанрда шактый актив эшләп алды. Аның «Хөкем» исемле бер повесте «Азат хатын» журналының 1969 елгы саннарында басылып та чыкты. Укучылар хәтерлидер, әсәрнык, ышанычлы кул белән, маҗаралы жанрның кануннарын белеп язылган иде. Ул бөтен һәм җыйнак, мавыгып укырлык иде. Мәдинәнең хәзергә дөньяга чыкмаган тагын ике маҗаралы повесте бар. Аларында да кызыклы һәм актуаль мәсьәләләр күтәрелә, алары да яратып һәм мавыгып укырлыклар.

Маҗаралы жанр өлкәсендә эшләү яшь прозаикны үткен һәм отышлы ситуацияләр табарга, сюжет-композиция бөтенлегенә өйрәтә, әсәрләренең тизеклегенә, архитектоникасына уңай йогынты ясый. Күләмле әсәрләр иҗат иткәндә бу тәҗрибәнең файдасы киләчәктә дә зур булыр дип ышаныйк.

Шулай да Мәдинә Маликованың әлегә кадәр язылган иң җитди, иң мөһим әсәре «Казан каласы — таш кала» повесте, билгеле. Күп геройлы, күп планлы бу әсәр язучы иҗатында аерым урын тота. Шуңа күрә дә аңа киңрәк тукталасы килә.

Яңа гына Түбән Камадан командировкадан кайтып төшкән Мәрьям, арыган булуына, котырган буранга да карамастан, үзе эшли торган проект институтына чаба. Юкка гына ашыккан. Аны күңелсез хәбәр белән каршылыйлар. Институт җитәкчеләренә аның өстеннән язылган жалоба килеп кергән. Бу аңа яшен суккандай тәэсир итә. Балалар бакчасына кызы Фәйрүзәне алырга барганда да, аннан кире Сәҗидә апаларга кайтканда да Мәрьям шул турыда уйлый. Кара син аны, берсен дә калдырмаганнар диген. Ул эшләгән проектларны тетеп салганнар. Болай булгач, Ташлыярдагы микрорайон проектын раслауны тагын кичектерәләр инде. Семья хәлләренә тыкшынганнар, шәхси тормышында казынганнар, Шәүкәтне дә телгә алганнар... Сәҗидә апаларның җылы өендә кич утырганда да аның уйлары гел шул тирәдә әйләнә. Берәздән һәммәсе йокларга ята. Тик Мәрьямнең күзенә генә йокы керми. Аның күз алдыннан шатлык-сөенечләр, борчу-мәшәкатьләр белән тулы тынгысыз иҗат юлы, гыйбрәтле һәм төрле вакыйгаларга бай шәхси тормышы, биш-алты еллык гаилә тормышы уза. Мәрьям таңга кадәр йокысыз ята, яшәүнең мәгънәсе, гаилә бәхете, иҗади хезмәт белән бәйләнешле мәсьәләләр турында уйланып ята. Әле кайчан гына алар ашкынып-дәртләнеп Шәүкәт белән яратышып йөргәннәр иде. Ахыры гына күңелсезрәк тәмамланды. Аннан Мәрьям кияүгә чыкты, биш-алты ел гомере Вильдан белән узды. Тормышлары әйбәт бармады, аерылышырга туры килде. Семья мәшәкатьләренә эштәге кыенлыклар өстәлә торды. Хәзер менә әлеге жалоба...

Мәрьямгә ияртеп, автор безне дә повестьта тасвирланган вакыйгалар эченә алып керә. Иҗади хезмәт, гаилә бәхете белән бәйләнешле катлаулы мәсьәләләр турында уйланырга мәҗбүр итә. Күреп торасыз, автор повестеның архитектоникасын оста корган, үзе күтәргән мәсьәләләрне хәл итү өчен ифрат отышлы һәм күп сыйдырышлы әдәби форма тапкан.

Повесть беренче тапкыр «Казан утлары» журналының 1968 елгы 4—5 саннарында басылган иде. Ул укучылар арасында төрле фикер уятты. Аны мактаучылар, хуплап каршы алучылар булган кебек, автор адресына усал гына тәнкыйть сүзләре әйтүчеләр дә булмады түгел. Күренекле язучыларыбыздан Фатих Хөсни, мәсәлән, ав-

торкы мәхәббәт, гаилә кору кебек җитди мәсьәләләргә җавапсыз һәм җиңел карауда гаепләп чыкты (Ф. Хөсни. Кайда сез, олы язмышлар? «Казан утлары» журналы. 1969 ел. 6 сан.). Җыентыкка керткәндә, Мәдинә Маликова бу повестен яңадан эшләгән. Яңа вариантны эшләгәндә, автор үз адресына карата әйтелгән тәнкыйть фикерләрен, шул исәптән Фатих ага Хөсни әйткән сүзләрне дә истә тотарга тырышкан. Беренчесе белән чагыштырганда, яңа вариант нык камилләшкән, күп яхшырган.

Журнал вариантында Мәрьямнең гаиләдән тыш тормышына, архитектор буларак эшчәнлегенә урын азрак бирелгән кебек иде. Хәзер бу тармак нык үстерелгән. Хикмәт коры күләмдә, Мәрьямнең архитекторлык эшчәнлегенә күбрәк урын бирелүдә генә түгел. Хикмәт сыйфатта. Автор архитектура мәсьәләләрен белеп, аңлап яза. Алай гына да түгел, аның архитектура сәнгатенең үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында үз фикере, үз карашы бар. Архитекторлык һөнәре Мәрьямгә ябыштырылып, тагып кына куелган бер нәрсә түгел. Ул аның холкына, характерына, үз-үзен тотышына, тормышка һәм кешеләргә мөнәсәбәтенә мәгълүм бер эз салган. Иҗат кешесе, архитектор булуы Мәрьямнең һәр адымыннан сизелеп тора. Әгәр бу теманың безнең әдәбият өчен яңа булуын да исәпкә алсак, әсәрнең әһәмияте тагын да арта, бәясе тагын да күтәрелә төшәр. «Казан каласы — таш кала» әдәбиятыбызның тематикасын, офыгын киңәйтергә булыша.

Фатих ага белән килешергә туры килә, беренче вариантта Мәрьям белән Вильдан арасындагы мөнәсәбәтләр, чыннан да, җиңелчәрәк хәл ителә иде. Җиңел генә танышалар, Мәрьям, алдын-артын уйлап тормый гына, Вильдан янында куна кала, шуннан артык мәшәкатьләнми генә өйләнешәләр, бергә тора башлыйлар. Һәм шулай ук җиңел генә аерылышалар иде. Хәзер әсәрнең бу ягы яңадан эшләнгән. Мәрьямнең ни өчен Вильдан белән танышып китүе, аңа кияүгә чыгуы һәм биш ел бергә торганнан соң аерылышырга мәҗбүр булулары — һәммәсе дә ышандырырлык итеп тасвирланган, психологик яктан акланган.

Шәүкәтнең хыянәте Мәрьямгә ифрат авыр тәэсир ясый. Шуңа нишләргә белми кайгырып, гарьләнеп һәм күңелсезләнеп йөргән көннәрдә ул Вильданны очрата. Чибәр, игътибарлы һәм әдәпле егет булып күренә Вильдан. Өрсезләнми, ялынып-ялварып йөрми. Шәүкәт белән булган тетрәнүләрдән айнып та җитмәгән килеш, дәресрәге, Шәүкәткә, үз-үзенә, дөньяга ачу итеп, кияүгә чыга. Тора башлыйлар. Юк, начар ир булып чыкмый Вильдан. Эштән вакытында кайта, эчми-тартмый, кычкырышмый-сугышмый. Икенче бер кешегә өйләнгән булса, ихтимал, алар бик бәхетле яшәрләр иде. Ләкин хатын һәм ана булудан тыш, Мәрьям иҗат кешесе дә бит әле. Аңа рухи дөньясы булган, серләшерлек, киңәшерлек иптәш тә кирәк. Маҗаралы китаплардан башка нәрсә белән кызыксынмаган Вильдан андый киңәшче була алмый. Идеаллар капма-каршы, теләкләр туры килми. Шуңа күрә алар аерылышырга мәҗбүр булалар.

Аннан соң, бу повестьта мәхәббәт укучының күңелен кытыклау, аның игътибарын җәлеп итү, башкача әйткәндә, коры конфликт өчен генә алынмаган. Ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләр, гаилә бәхете мәсьәләләре, үзәккә куелып, проблема буларак тикшерелә. Ничек хәл итә, дөрес чишәме? Анысы — икенче мәсьәлә. Әмма автор проблеманы күтәрә, куя белгән, шуңа безнең игътибарыбызны юнәлтә алган. Язучы буларак, Мәдинә Маликованың уңышы әнә шунда, минемчә.

Повестьта мәхәббәт, гаилә мәсьәләләренә иҗат мәсьәләләре, кеше тормышының мәгънәсе, асылы турындагы уйланулар килеп тоташа. Әнә шулай әсәргә Шәүкәтләр, Морат, Шәфикъ абый, Газизләр, Камәрия Гаделшиналар килеп керә. Повестьның кысалары киңәя, тема-проблемалары катлаулана, ул күп геройлы, күп планлы әсәргә әйләнә.

Китап вариантында Мәрьям — Шәүкәт сызыгына да байтак үзгәреш кертелгән. Ләкин әсәрнең бу ягы әле һаман канәгатьләндерми. Шәүкәт, образ буларак, камил эшләнмәгән, Мәрьям белән алар арасындагы мөнәсәбәтләр эволюциясе дә аңлашылып җитми.

Әйе, чибәр, матур егет була, талантлы була Шәүкәт. Зур иҗат планнары белән яши, үз «Джоконда»сын тудыру хыялы белән ашкынып йөри. Шундый бер егеткә Мәрьямнең күзе төшкән, алар арасында мәхәббәт утлары дөрләп кабынган икән, бу — табигый нәрсә. Ләкин тормыш дигәнең Шәүкәт алдына кыен сынаулар әзерләп куйган. Аның диплом эшенә «дүртле» генә куялар, зур өметләр баглап торган картинасы күргәзмәгә узмый. Шуннан егетебез сыгылып төшә. Картинасын тураклап таш-

лый, Мәрьямне оныта. Мәхәббәт сүнә, идеаллар җиргә салып таптала. Шәүкәт белән Мәрьям арасындагы мөнәсәбәтләр дә, ул мөнәсәбәтләрнең шулай күңелсез тәмамлануы да ышандыра. Һәммәсе дөрес, һәммәсе акланган.

Шуннан алар байтак еллар очрашмыйкүрешми яшиләр. Билгеле булганча, Мәрьям иргә чыга, баласы була. Ире Вильдан белән аралары суынып килгән көннәрдә ул тагын Шәүкәтне очрата. Мәрьям белән Шәүкәт арасындагы мөнәсәбәтләрнең икенче этабы башлана. Теге вакытта янган ут сүнеп-сүрелеп үк бетмәгән икән, янәсе. Очрашкач, тагын дөрләп кабына. Яңадан яшь чактагы кебек су коенулар, төннәрне, таңнарны бер итеп серләшеп-сөешеп йөрүләр башлана. Дөрес, алар арасында кайнар хисләр бу юлы да күпкә бармый, тиз сүнә. Ләкин мине болары гаҗәпләндерми. Алар арасындагы мәхәббәтнең яңадан кабынып китә алуы гаҗәпләндерә. Яшьлек хыялларыннан, иҗат принципларыннан, барлык идеалларыннан ваз кичкән, илһамсыз, дәртсез, натуралистик картина язуга кадәр төшеп җиткән Шәүкәтнең нәрсәсенә, кай ягына кызыкты икән Мәрьям?!. Дөрес, ул әле һаман чибәр, дәртле, хатыннар күзе төшәрлек гайрәтле ир була. Ләкин автор мәхәббәт проблемасын киңрәк планда, иҗат принциплары, дөньяга караш мәсьәләләре белән бәйләнештә ачарга теләгән иде бит. Мәрьям белән Шәүкәт арасындагы мөнәсәбәтләрнең икенче этабына шул нәрсә җитми. Күрәсең, мәсьәләнең бу яклары авторның үзе өчен дә чишелмәгән төен килеш калган булса кирәк... Журнал һәм китап вариантлары арасындагы төп үзгәрешләр әнә шулар. Үзегез дә сизгәнсездер, тулаем алганда, повестьның китап варианты нык яхшырган, әйбәтләнгән. Ул авторның язучы һәм гражданин буларак үсә төшүе, үзе күтәргән мәсьәләләр турында тагын да җитдирәк уйлана башлавы турында сөйли. Әсәр баштан ахырга кадәр тормышны танып-белергә омтылу, тынгысызлык, эзләнү рухы белән сугарылган. Кайчандыр М. Маликова тормыш вакыйгаларының тышкы ягы белән, эчтәлек сөйләү белән мавыга иде («Юлдашлар» һәм башка хикәяләр). Хәзер вакыйгаларга ул тормышны танып белү, образларны ачу чарасы итеп карый. Шулай да авторның иҗади үсеше, барыннан да бигрәк, образлар иҗат итүдә нык сизелә. Повестьта тасвирланган вакыйгаларда дистәләрчә образ катнаша. Автор аларның үз йөзен, үзләренә генә хас индивидуаль сыйфатларын табарга тырышкан. Камәрия белән Саҗидә апаны, Газиз белән Шәүкәтне, Морат белән Шәфикъ абыйны, я булмаса Вильдан белән Шәүкәтне янәшә куеп, чагыштырып карагыз. Шактый ук катлаулы, тормышчан һәм җанлы образлар алар.

«Казан каласы — таш кала»да Мәдинә Маликова үзе күтәргән мәсьәләләр, кешеләр тормышы, бүгенге дөнья турында тиешле югарылыктан торып, заманча фикер йөртә белә.

Ниһаять, «Казан каласы— таш кала» повесте яшь язучының үз йөзе, үз стиле формалашып килүе турында да сөйли. Ул әллә каян кычкырып, ялтырап торган буяуларны яратмый, гади, тыйнак язарга омтыла. Тормышның үзеннән, классикларыбыздан ук килә торган гадилек, табигый агым аның иҗатында елдан-ел калыплана, ныгый бара.

Дүрт-биш ел вакыт эчендә яшь прозаик шактый зур һәм нәтиҗәле үсеш юлы узган. Кеше күңеленең хатын-кыз гына аңлардай нечкәлекләрен күрсәтү, тормышыбызның киң карашлы, тирән белемле язучы гына сурәтли алырдай зур мәсьәләләрен яктыртуга ул зур җитдилек белән керешергә тиеш.

**Әсрар Галиев**

# КЕРӘШЕН ТАТАРЛАРЫ ҖЫРЫ

Керәшен татарларынын авыз иҗаты элек-электән фольклорчы галимнәрнең игътибар үзәгендә булып килә. Казан губернасындагы керәшен татарларының иҗатын узган гасырның житмешенче елларында венгр галиме Г. Балинт җыеп ала һәм аерым китап итеп бастырып чыгара. Күренекле галимнең бу китабында Казан, Лаеш, Мамадыш өязләрендә яшәүче керәшеннәрнең җырлары, әкиятләре һәм мәзәкләре тупланган. Безнең уебызча, арада иң әһәмиятлесе — Балинт җыйган җырлар. Керәшен татарларынын җырлары барысы да диярлек озын үлчәүдә. Кайберләре татар җырларындагы сүзләргә «кай-кәй», «дай-дәй» кебек кушымчалар өстәп «керәшенләштерелгән» җырлар. Керәшен җырлары поэтик сурәтләргә, үткен фикергә бай. Балинт җыйган җырларнын күбесе — мәхәббәт җырлары. Бу җырларның тексты белән танышкач, керәшен халкының поэтик рухына, шагыйрьлегенә сокланмыйча мөмкин түгел.

**Ак каеннарга ник мендем?**
**Җилбердәп торган туз өчен.**
**Быел җәйне мин саргайдым**
**Аклы яулык япкан кыз өчен.**

**Тартар кычкырадыр куактин,**
**Таннар сызыладыр ерактин.**
**Кысма, җаныкаем, беләктин,**
**Дәрткенәем китми йөрәктин.**

**Урамнан үттем, күрдеңме?**
**Төшләремә кердең, тойдыңмы?**
**Тордым да, төшем юрадым,**
**Бер кодайдан сине сорадым.**

Халык җырларындагы шигъри бизәкләр хакында язуы шактый авыр эш. Мондый вакытта иң яхшысы — җырның үзен уку.

Бу санда без Красно-Баран авылында язып алынган җырларны бирәбез.

Байчыклы Бәрәнгул елгасы буенда, урман эчендә утырган авылның элекке исеме Байчыклы Бәрәнгул булган. Аның тарихы Болгар чорына барып тоташа. Соңыннан, җирле халыкларны чукындыру политикасы үткәрелгәч, Байчыклы Бәрәнгул авылы халкы керәшен татарлары дип йөртелә башлый һәм авыл — Керәшен Бараны дип аталып китә. Ә егерме тугызынчы елдан Красно-Баран исеме бирелә. Елга исеме исә һаман элеккечә Байчыклы Бәрәнгул килеш кала. Бу авылда ике йөзгә якын йорт булып, сигез йөздән артык кешесе бар. Халкы бик кунакчыл.

Авыл өйләре пөхтә итеп җыештырылган. Чисталык урамнан ук башлана. Капка төбеннән баскычка кадәр такта яки цемент җәелгән. Аяк кнемен баскыч төбенә салалар. Баскыч, өйалды, идәннәр сап-сары итеп юылган. Идән юуу өчен махсус урман үләне хәзерләнә. Ул ышлан дип атала.

**Алтын да ла микән, көмеш тә микән**
**Безнең кодаларның баскычы,—**

дип, керәшен татарлары тикмәгә генә җырламый икән.

Әле беркем дә язып алмаган һәм беркая да басылып чыкмаган җырлар күп монда. Туйда җырлана торган борынгы җырлар гына да ике йөздән артык, диц сөйлиләр. Аларда фольклорчы галим И. Надиров җыеп чыгарган туй, кыз озату, кияү керту йоласы җырлары белән охшашлык зур. Бирега венгр галиме Г. Балинт китабындагы җырлар да очрый. Димәк, борынгы җырлар халык күңелендә әле дә яшиләр. Тик биредә язып алынган вариантларда алар беразы «заманлаштырылганнар» — җырны суза торган кисәкләреннән «чистартылганнар». Түбәндәге җырлар 77 яшьлек Степан Филиппович Иванов, аның 76 яшьлек хатыны Марина Ивановна Иванова һәм аларның 36 яшьлек кызлары Мария Степановна Бәшировалардан язып алынды.

## Туй һәм кунак җырлары

Казакии бауларым күк төймә,
Күк төймә лә түгел каптырма,
Кияү канатым, сиңа әйтәм,
Үзеңнән бүтәнгә лә каптырма.

Табакай табада ла борчак,
Чәчми генә түкми ашагыз,
Безнен кызыбыз сезгә кала,
Какмый гына сукмый асрагыз.

Ай-ли, шау нарат, шау нарат,
Нигә шаулый икән бу нарат?
Шауламас не бу нарат,
Аерыла бездән бер канат.

Урындыкларым, әй, алмалы,
Утырмаган кеше калмады;
Кызларыбыз матур булгач,
Сокланмаган егет калмады.

Канат очына кер тиермәм,
Канат очым алсуга күрә;
Без кызыбызны сезгә бирдек,
Нәселегез асылга күрә.

Ике җирән атыгыз,
Анын берсен безгә сатыгыз;
Киявегез оцарлык булмаса,
Кызыгызны алып кайтыгыз.

Иртә генә торып тышка чыксам,
Мыжылдыйлар байнын кортлары [1],
Алтын гына капка, көмеш койма,
Шушы микән кода йортлары.

Ишек алдында бер кискә [2],
Кисеп кенә алдым бер мичкә;
Китәселәребез бер дә килми,
Калдырырсыз микән бер кичкә.

---

[1] Кортлары — умарта кортлары.
[2] Кискә — киселгән агач.

Биеккәй лә тауның башыннан
Алтын балдак таптым әләли,
Алтын балдак табу бер ни түгел,
Бер туй итүләре әллә ни.

Ачыла кибет, ай, ачыла,
Башыгызга бирнә ябыла,
Кияү акчалары килеп кергәч,
Бирнәләре аның табыла.

Алтын да ла микән, көмеш тә микән
Безнең кодаларның баскычы?
Кодагый канатым, кил каршыма,
Шушымы чемодан ачкычы?

Ай, килдек без, килдек без,
Иделләрне кичеп килдек без;
Иделләр кичеп, юллар кунып,
Кыз озатырга ла килдек без.

Ай-һай диләр, ай-һай диләр,
Чемоданның эче тар диләр;
Чемодан эче тар булса да,
Кодаларның малы бар диләр.
(Тар булса да өмет бар диләр,
Тагын әле бер күркәсе бар диләр.)

Ишегалларым ла, ай, каралты,
Каралты [1] ла әләре калмады,
Сез кодаларны көтә-көтә,
Ике күзләремне кан алды.

Җиңсез туннарыма җиң куйдырдым
Утлый гына җанган дарайдан [2];
Сез кодаларым ла килгәчтен,
Сикереп төштем биек сарайдан.

Кара сыерларның мөгезен
Каерып алырга ла килдек без;
Әнкәсеннән генә бәбкәсен
Аерып алырга ла килдек без.

Зәңгәрле лә ыштан, зәңгәр ыштан,
Аның арасына ак кушкан;
Безне генә кодай [3] сөеп кушкан,
Аермасын иде лә бер дошман.

Ай-һай, ашык без, ай-һай, ашык,
Ашлар ашый торган кашык без;
Шушы туйларның ла барышында
Алдан йөри торган башлык без [4].

---

[1] Каралты — биредә юылган кер мәгънәсендә.
[2] Дарай — асыл тукымадан дигән төшенчә.
[3] Кодай — ходай.
[4] Бу жырны аргышлар башкара. Аргыш — туйбаш — туйны алып баручы. Туйда һәр ике яктан да аргыш була.

Атларың булса шундый булсын,
Шундый ла булсын;
Аның арт аяклары ак булсын.
Җырларны белеп җырламасак та,
Аргыш булуыбыз хак булсын.

Ай-һай, ай, диләр, ай, диләр,
Безнең 'кодаларны бай диләр;
Идән асларында сигез мичкә
Серкәләгән балы бар диләр.

Чәчләремне биштән үрер идем,—
Чәчен биштән үргән димәсләр,
Сезнең өчен генә үләр идем,—
Сезнең өчен үлгән димәсләр.

Сызгырадыр елан, ай, сызгыра,
Саздагы ла сары бака өчен;
Туганайлар, сезгә мин әйтәмен,
Ташлашмыек алла хакы өчен.

Биеккәй тауның, ай, башында
Җир җиләге тездем тезләнеп;
Сез туганнардан аерылгач,
Минем җаннар җөрер эзләнеп.

Биеккә тауның, ай, башына
Шәлчедән кибән кем куйган;
Ашыек, эчиек без, туганнар,
Ашам-эчемнәрдән кем туйган.

Туп-туп та баскан туры атның
Су җыела баскан эзенә;
Ышанам, туган, мин үзеңә,
Ташламам дигән сүзеңә.

Туп-туп баскан туры атым
Урта юлларына бер баса;
Бу илләргә ничек килер идем,
Сез туганнарым булмаса.

Урман ди буйлары иманлек
Иманлек буйлары игенлек;
Ул ди игеннәрне бергә игиек,
Гомерләргә бергә йөриек.

Агоннардан[1] камыр ла издермәм,
Издерсәм дә кешегә сиздермәм;
Җанымнан да якын туганнарны
Үзем үлмиенчә биздермәм.

Ишек алларым таслы үлән,
Таслы үләннән килмә, юлдан кил!
И туганкаем, сиңа әйтәм:
Сагындырып килмә, ел да кил.

[1] Агоннардан — ак оннардан.

Яшел лә чирәм өстеннән
Тек-тек басып килә ак куян;
Син туганнарым килер дип,
Өлешенне аерып куям.

Көмеш тә йөзек койдырдым
Чынкай гына көмеш акчадан,
Сез туганнарны эзләп таптым
Алмалары пешкән бакчадан.

Агыйделкәйләрнең лә күбегеи
Җыеп кына алдым бер уймак;
Сез туганнарны эзләп таптым
Сакраларга[1] чыгып бер буйлап.

Су буйларына төшәр ием
Су тавыгы тезелгән чакка;
Туганнар янына барыр ием,
Ач үзәгем өзелгән чакта.

Сандугачлар булып сайрар ием,
Өй арткынаемда сад булса;
Жаннарымны ярып бирер ием,
Якын итүегез хак булса.

Аклы ла яулыкның парчасы
Һәрбер яулыкларда булсачы;
Сез туганнарның нурлы йөзе
Көн лә күз алдымда булсачы.

Кара урманнарны өч әйләндем,
Таянырга терәк тапмадым;
Күпләр эзләдем мин, күп сорадым,
Сездәй туганнарны тапмадым.

Өстәл өсләрем лә эскәтер,
Эскәтер өсләре чынаяк,
Чынаяк түгел, чынкай көмеш —
Безнең лә дускайлар шушы, имеш.

Сырга[2] бауларым билдәндер,
Алтынчылар коеп биргәндер;
Кашларың-күзләрең килгәндер,
Бер кодаем сөеп биргәндер.

Башымдагы гына ла ак яулыгым
Очып кынай барган кош кеби[3];
Бу ди ашаганнар, бу эчкәннәр
Йокы арасындагы төш кеби.

Башымдагы гына бүрегемне
Әллә илтерме[4], дип сорыйлар.

---

[1] Сакраларга — сахраларга. Керәшенкәр «х» урынына еш кына «к» авазы кулланалар.
[2] Сырга — алка.
[3] Кеби — кебек.
[4] Илтер — бөдрә бәрән тиресе.

Атларын жигеп юлга чыккач,
Әллә алпуатмы[1], дип сорыйлар.

Самауырлар куйдым мин кайнарга,
Чистайлардан килгән байларга;
Сез дускайларны охшатамын
Кечатна көн туган айларга.

Аякларымдагы ла итегемне
Басалмыйча торам таяр дип;
Син ди дускайларым килеп кергәч,
Танымыйча торам бояр дип.

Беләзеккәйләрем сары алтын,
Иптәш, күңелләрең ник салкын?
Иптәш, күңелең салкынлыктан,
Яна йөрәгем ут-ялкын.

Жир жиләге генә жыя-жыя,
Ике жиңнәрем тулды инде,
Сез туганнар белән бер күрешкәч,
Минем күңелләрем булды инде.

Кара урманнарның уртасында
Карчыгалар микән кагынган;
Ычкылыклар тотса, тот исеңдә —
Мин булырмын сезне сагынган.

Гармуным булса уйнар идем,
Әрле дә бирле боргалап;
Матур кызлар булсам, йөрер идем,
Тутый кошлар кебек юргалап.

Беләзеккәйләрем, ай, бөгелми,
Бөгелмәләрдән килгән түгелме?
Сөям дә сөям дип әйтәсең,
Сөюләрең хәйлә түгелме?!

Тугыздан башмаклар[2] мин ясаттым,
Икәү генә киеп туздырыйк;
Яшьли генә бергә без кушылдык,
Гомерләрне бергә уздырыйк.

Агыйделләргә без төшәрбез,
Колачларны жәеп йөзәрбез,
Йөзүен бергәләп йөзәрбез,
Аерылгач ничек түзәрбез.

Иптәшем, матур буласың
Пустау чикмәннәрең кигәчтен,
— Сөясеңме? — диеп син сорыйсың,
Нигә сөймим жаным сөйгәчтен?!

Синең чәчләрең бигрәк сары,
Алтын кайчы белән кискәнгә;
Синең буйларың бигрәк зифа,
Багалмасы ашап үскәнгә.

---

[1] Алпуат — алпавыт.
[2] Тугыздан башмак — тугызлап үрелгән юкә башмак.

Синең чәчләрең гедерә[1],
Гедерәгә күрә жил өрә;
Синең буйларың бигрәк зифа,
Чакырым жирләрдән күренә.

Кырларга чыктым, кыргый аттым,
Кыр түренә житкәч тагы аттым;
Бу күрүләремдә бик яраттым,
Тагы да кайчан күрермен, канатым.

Кырларга чыктым, исем китте —
Элмәләрнең ни элгәненә;
Үземә-үзем исем китте,
Сезне күреп сөенгәнемә.

Ураккай урдым, зурат куйдым,
Арасыннан очты карлыгач,
Син карлыгач булсаң, мин сандугач,
Сайрашырбыз икәү сагынгач.

Кара урманнарның, ай, артында
Ишетелә чалгы кайравы;
Сез туганнарның сөйләгән сүзе —
Сары сандугачның сайравы.

Минем якаларымда алты талир,
Алтысы да аның бер манер.
Сез туганнар белән күрешергә
Язган икән безгә, и кадыйр[2].

Шыңгыр да шыңгыр дугалар,
Әнә китеп бара кодалар,
Китмәсләр ие кодалар,
Калдык аракыны соналар.

Миңа этекәем атлар ла бирде,
Таулардан тауларга йөр, диде.
Миңа этекәем шулай ла әйтте:
«Туйлардан туйларга ла йөр!» — диде.

Кечерәккәй жиләп, ай-һай, басма эчле,
Аны кияр кечерәккәй кеше.
Кечкенә лә диеп сез хурламагыз,
Ул ризыклы, дәүләтле кеше.

Без стаканнарның шунысын сөябез,
Мөлдер генә, мөлдерәп лә торганын;
Без кодачаларның шунысын сөябез,
Каршыбызда жырлап ла торганын.

Бөтен жиләккәйләр, ай, арасында
Жир жиләккәйләре лә үтемле;
Бөтен кодачалар, ай, арасында
Үз кодачаларым ла сөйкемле.

Безнең лә урамнар киртләч-киртләч,
Киртләчләре бетәр лә кар киткәч;
Безнең лә урамнар, ай, ямьле иде,
Ай, ямьнәре бетәр лә туй үткәч.

---

[1] Гедерә — бөдрә.
[2] Кадыйр — ходай.

Ильтани Илялова

# АКТЕРНЫҢ ИҖАТ ЮЛЫ



1970 елда Шәүкәт Биктимеров өчен дулкынландыргыч көннәр күп булды. Кояшлы апрель аенда, туган илебез, бөтен дөнья В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу бәйрәмен билгеләгәндә, Ш. Биктимеров сәхнәдә бөек юлбашчы ролен уйнады. Бу образны уйнарга хәзерләнгән көннәрдә артистның никадәр дулкынлануын әйтеп-сөйләп тору кирәк микән?.. Б. Щукин «Мылтыклы кеше» пьесасында Ленин образын уйнарга хәзерләнгәндә болай дип язган иде: «Кешедәге иң яхшы гадәтсыйфатлар... Акыллылык, ихлас күңеллелек, даһилык... Югары культура. Тыйнаклык. Философ, галим, оештыручы һәм юлбашчы кешедәге иң яхшы сыйфатларның кушылмасы. Ильичның даһи акылы, көчле ихтыяры. Көр күңеллелеге. Халыкка ышануы. Халыкны яратуы» [1].

Табигый, татар артисты да әнә шул юнәлештә эзләнә.

Ш. Биктимеров йомшак табигатьле, лирик пландагы артист. Аның актерлык манерасына беркадәр, Чехов геройларындагыча, йомшаклык хас кебек. Актер шәхесендәге бу сыйфатлар Ленин образына тирәнрәк үтеп керергә, аңа интеллигент кешегә хас якларны тулырак ачарга ярдәм иткән. Бу бик әһәмиятле нәрсә, чөнки Ленин — эшчеләр сыйныфы юлбашчысы, ул бөтен барлыгы белән алдынгы рус интеллигенциясе вәкиле.

Ш. Биктимеров Ленин образын Н. Погодин трилогиясенең соңгы кисәге саналган «Третья патетическая» исемле драмада уйнады. (Татарчага тәрҗемәсендә «Баһадирлар» дип атала.) Совет драматургиясендә Ленинның үлеме турында язылган беренче әсәр бу. Шуңа күрә ул — трилогиянең иң авыр кичерешле, иң патетик кисәге. Исеме дә әнә шул мәгънәне аңлата.

Бу драмада артист каршына өстәмә кыенлыклар — юлбашчы гомеренең соңгы елларын күрсәтү кыенлыгы килеп баса. Ш. Биктимеров вакыт-вакыт тулысынча характер чынлыгына ирешә, әерым урыннарда исә бу дәрәслек беркадәр кими дә төшә.

Тамашачы Ленин белән беренче тапкыр заводта очраша. Бу күренештә актер үзенең героен көр, шат күңелле җитәкче итеп уйный. Ул шаярта, көлә, тормышыбызда туып килгән яңалыкларны күреп сөенә. Шулай да беренче пәрдәне актерның зур уңышы дип әйтеп булмый, монда әле образ иҗат итүдән бигрәк автор язганны уйнау күбрәк. Бу пәрдәдә драматург сузма палас «мәсьәләсе»нә күп игътибар бирә. Шул сәбәпле, Ленинның заводка килүенең төп максаты арткы пландарак кала. Һәм әлеге

[1] Н. Лебедев. Щукин — кино актеры. Рус телендә. Госкнигоиздат. 1944 ел. 94 бит.

палас уңае белән шаярту сүзләре күп әйтелү аркасында, Ленин образында шаяртып-көлеп йөри торган җиңел табигатьле кеше сыйфаты артып китә.

Аның каравы, драматург уйнар өчен чын материал биргән урында актер да зур уңыш казана. Горкидагы күренеш әнә шундый. Бу күренеш дәвамында тамашачылар әледән-әле кул чабалар. Горкидагы күренеш арага кысылган бер эпизод кына түгел, драмадагы төп вакыйганың үсешендә, аның идеясен ачуда бик кирәкле бер буын булып тора.

Хатерлисездер, бу күренештә Ленин янына Ирина килә һәм Владимир Ильичтан энесенә карата чыгарылган хөкем җәзасын йомшартуын үтенә (Иринаның энесе җинаять эшләгән — бер спекулянттан взятка алган). Менә шундый киеренке бер хәлгә куеп, актер Ленинның революционер буларак гаделлеген генә түгел, аның кешелек характерын да ачып бирә.

Ленин-Биктимеров Иринага карата ягымлы, игътибарлы, ул аның кичерешләрен аңлап чын-чыннан борчыла. Үтенеч язуын укыгач, Ленинның чырае моңсуланып һәм беркадәр кырысланып та китә. Взятка алган энесен яклауны үтенеп килгән өчен Ленин Иринага ачуланмый. Аның йөзенә бик борчылган төс кенә чыга. Чөнки Совет дәүләтендә революциягә катнашучы кешеләр тарафыннан шундый эш эшләнүе акылга сыймаслык бер хәл. Аның Иринаны рәнҗетәсе килми, шул ук вакытта ярдәм дә итә алмый. «Сезнең кайгыгыз бик зур, шул сәбәпле мондый хәлиткеч мәсьәләне аңлавы кыен сезгә, ләкин мин сездән мине дәүләт эшлеклесе итеп каравыгызны сорыйм. Ә дәүләт эшлеклесе андый эшләрне яклаучы була алмый, якларга тиеш тә түгел. Ярамый, мөмкин эш түгел бу! Аңлагыз мине»,— ди Ленин Иринага.



Ирина барын да аңлый, сүзсез генә чыгып китә. Ленин, тирән уйга чумып, эскәмиядә утырып кала. Шул минутта без үз өстенә коточкыч зур җаваплылык һәм авырлыклар күтәргән, дөньяны үзгәртеп коручы даһи кешене күрәбез. Бөтен спектакль эчендә, образны ачу ягыннан да, Горкидагы бу күренеш арада иң яхшысы. Безнең күз алдыбызга һәрвакыт киеренке уйлар эчендә яшәүче, революция эшенә килгәндә тугрылыгыннан бер адым да чигенмәүче тынгысыз кеше образы килеп баса. Шушы күренештә без беренче тапкыр Ленинның авырган чагын күрәбез. Гик спектакльдә бу хәвефле, дәресрәге, фаҗигале сызык беркадәр йомылыбрак кала.

Татар театры сәхнәсендә Ш. Биктимеров тудырган Ленин образы актерның иң соңгы эшләреннән берсе. Үзенең иҗат гомерендәге иң кыен, иң катлаулы бу рольне гәүдәләндерүгә ул нинди юл үтеп килгән соң?

Моның өчен аңа, әлбәттә, авыр иҗат юлы узарга туры килгән.

...1945 ел. Ватан сугышының яңа беткән чагы. Шул көзне Казанда театр техникумы ачыла. Авылдан калага килгән унҗиде яшьлек егетебез әнә шул техникумга укырга керергә карар кыла. Авылда ул җидееллык мәктәпне тәмамлаган. Шуннан соң берничә ел колхозда эшләгән...

Авылга театр килсә, аның өчен зур бәхет була. Шәүкәт, тын да алмыйча, сәхнәдә артистлар уйнаганны карап утыра. Аның малай чакта театр яратуы алдагы тормыш юлын сайлауда, һичшиксез, зур роль уйный. Икенче яктан, апасы Галимә Ибраһимованың Татар академия театры артисты булуы да Шәүкәткә билгеле бер йогынты ясагандыр, билгеле. Шулай итеп, артистлык профессиясе билгеле бер дәрәҗәдә аларның гаилә профессиясе булып китә, дияргә була. Техникумда уку



«Баһадирлар» спектаклендә *В. И. Ленин.*

дәверендә Шәүкәт актерлык сәнгатенең мәгънәсенә төшенергә тырыша. Ул дөньяда бик шәп театрлар, зур сәхнә осталары барлыгын белә. Техникум педагоглары, курс җитәкчесе Ш. Сарымсаков үз укучыларында МХАТка һәм аның традицияләренә мәхәббәт тәрбияилиләр. Шуңа күрә Биктимеров бу атаклы коллективка карата күңелендә хәзер дә тирән мәхәббәт саклый.

Бүгенгә көндә Ш. Биктимеровның сәхнәдә уйнавын чын ләззәт белән карыйсың да, ул актер профессиясен сайлап дөрес эшләгән дигән фикергә киләсең. Ул — сәнгать остасы алдына куела торган иң зур таләпләргә җавап бирерлек артист.

Театр техникумын тәмамлаганнан соң Шәүкәт баш-күз алырга да өлгерми — армиягә китә. Анда радист булып хезмәт итә. Хезмәттән буш вакытларын, солдат үзешчәнлеге дәрәҗәсендә генә булса да, сәнгатькә багышлый. Армиядә хезмәт итү еллары узып китә. Шәүкәт Казанга кайта. 1953—54 еллар сезонында аны Татар академия театры сәхнәсенә алалар. Чынлыкта әнә шул вакыттан алып инде аның иҗади тормыш юлы башлана.

Ш. Биктимеров театрга килү белән татар театрының өлкән осталары Г. Болгарская, Х. Әбҗәлилов, Г. Камская, Х. Уразиков һәм Ф. Ильскаялар белән бергә уйный. Ул аларның акыллы һәм файдалы киңәшләр бирүләрен рәхмәт белән искә ала.

Ш. Биктимеровка хас бер сыйфат бар: ул бернинди рольдән дә баш тартмый, биргән рольләрнең барысын да уйный. Бу уңайдан К. С. Станиславскийның: «Бүген Гамлет, иртәгә статист. Әмма статист булып уйнасаң да, син артист булырга тиешсең», дигән сүзләре искә төшә. Бу сүзләр турыдан-туры Биктимеровка да карый. Әмма ул берьюлы гына оста артист булып китми әле. Тегә яки бу рольне чын итеп тудырырга өйрәнгәнче, дистәләгән роль уйнарга туры килә.

Үзенең беренче рольләрдә ничек уйнавын хәзер ул елмаеп искә ала. Армиядән кайтканның дүртенче көнендә, труппага кабул ителгәч, актерга «Баҗалар» спектак-

ләндәге Гадел ролен бирәләр. «Ул рольне ничек уйнаганымны һәм дүрт көн эчендә нәрсә «иҗат итә» алганымны хәзер үзем дә хәтерләмим»,— ди Биктимеров.

Ул уйнаган беренче рольләрне искә төшерсәк, күз алдыбыздан Тәкать исемле пычранып беткән малай (М. Әблиевның «Шәмсекамәр»еннән), кара чәчле, уйчан йөзле Фәридүн (Х. Уразиковның «Тау чәчкәсе»ннән) узар. Алар артыннан нәзакәтле Леон (Флетчерның «Хатынны ничек кулда тотарга» исемле комедиясеннән), яхшы, саф күңелле яшь егет Тәлгать (Х. Вахитның «Беренче мәхәббәт»еннән) гәүдәләнер. Н. Исәнбәтнең «Гөлҗамал»ындагы Сәетгәрәй дә хәтердә яхшы кала. Артистның оста уйнавы аркасында бу спектакльдәге ике күренеш иң әйбәтләреннән саналырлык.

...Менә әкрен генә шарык көе яңгырый башлый. Сәхнәгә Гөлҗамал белән Сәетгәрәй чыга. Сәетгәрәй бер сүз дә сөйләшми диярлек, кызга гашыйк булып, яратып, тып-тын гына елмаеп карый. Гөлҗамалны күргәч сөенүен, үзен шул кадәр бәхетле хис итүен аның бөтен йөзе, нурланып киткән күзләре үк әйтеп тора, тел белән аңлатып торуның кирәге дә юк.

Шуннан соң яшь артистка бер-бер артлы төрле рольләр бирә башлыйлар. 1956 елда инде, яшь артистларның республика смотрыннан соң, матбугат Ш. Биктимеровның Мелузов ролендә уйнавын (А. Островскийның «Талантлар һәм баш иючеләр» исемле драмасыннан) бертавыштан яхшы дип бәяли. Мелузов образын уйнарга хәзерләнгәндә актер эшне әдәби чыганакларны, геройның заманын, ул заманның гореф-гадәт, йолаларын өйрәнүдән башлый. Аның герое — демократ-разночинец, намуслы, гадел кеше. Зур мохтаҗлыклар да бу ярлы укытучының горурлыгын сындыра алмый.

Мелузовтан соң Ә. Фәйзинең «Рәуфә» пьесасындагы Жарков образы өстендә эшли. Аннары — театр тарафыннан бик шәп куелган «Ташкыннар» спектаклендәге уәсүзле Нургали. Үз өстендә даими эшләү, махсус әдәбиятны өйрәнү, Мәскәүгә иҗат командировкаларына бару — болар барысы яшь артистка үсәргә ярдәм итә.

Ш. Биктимеров һәр уйнаган роленнән үзенә файда ала белә. Бер караганда, радио тапшыруларына катнашу артистларга әллә ни илһам бирми кебек, турысын гына әйткәндә, радиоспектакльләр сәхнә өсәреннән шактый аерылалар. Шуңа да карамастан, Астров роле (Чеховның «Дядя Ваня» пьесасыннан) Шәукәткә артист булып үсәргә шактый ярдәм итә. Шуннан соңрак Ш. Биктимеров Чеховның «Олы юлда» исемле бер пәрдәлек драматик этюдындагы эчкече, сукбай һәм бунтарь Мерик ролен уйный. Шушы ике роль Биктимеровка: «Талантлы язучы Чехов тудырган образлар өстендә эшләү кеше психологиясен, аның күңел халәтен аңлауда бик күп ярдәм итә», дип әйтергә нигез бирә.

Бу елларда Биктимеровның иң яраткан рольләреннән Ш. Камалның «Карчыга» пьесасындагы Габбас Галин образы була. Ш. Биктимеров башкаруында Галин үз эшенә фанатикларча бирелгән, бик намуслы бер кеше. Ул бала артыннан балага тарыкканда да югалып калмый, киресенчә, тагы да каруланыбрак эшләргә керешә. Характеры кырыслана, кешеләр белән сөйләшмәс була. Йокысызлыктан кызарган күзләре һәм сулып калган йөзе генә аның авыр кичерешләр эчендә яшәвен, бик зур ихтыяр көче белән генә үзен тыеп торуын күрсәтә. Ул бик ачык һәм анык фикер йөртә. Ш. Биктимеров башкаруында коммунист, гражданин Галин образы тулысынча ачылып җитә.

Бары тик зур сәнгать әсәрләре белән эш иткәндә генә чын мәгънәсендә осталыкны үстерергә мөмкин һәм үз нәүбәтендә шундый әсәрләрне уйнап үскән сәхнә осталары гына тәмам җитлеккән образлар тудыра алалар. Үткән заманнарда яшәгән һәм бүгенге көндәге бөек артистларның репертуарларын хәтерләсәк, татар театрының зур сәхнә осталарын искә төшерсәк, шул хәл аңлашылыр: Ильская татар һәм дөнья классикасы җирлегендә исем казанды, Әбҗәлилов Хуҗа Насретдин, Биктимер, король Лир образларын тудырганнан соң гына Әбҗәлилов булып китте. Мондый мисалларны байтак китерергә мөмкин булыр иде. Ш. Биктимеров, театр сөючеләр теле белән әйткәндә, беренче елларында гел бер типтагы — социаль геройларны гына уйный ала торган артист булып саналды. Чыннан да, баштагы ун ел эчендә ул гел уңай геройларны уйный. Бер яктан, бу нәрсә яхшыдыр да. Әмма, икенче яктан, бер-беренә охшаган рольләрне генә уйнау нәтиҗәсендә артистның иҗаты өчен иң куркыныч нәрсә — штамп туа. Биктимеров М. Әмирнең «Хөррият» һәм Ю. Әминев

нең «Умырзаялар» исемле пьесаларындагы бер үк төрле рольләрне уйнаганнан соң әнә шундый аяныч хәл күренде. Бер типтагы образ бер тапкыр иҗат ителгәч, аны яңадан иҗат итәсе булмый, шуңа күрә бу эш актердан күп көч тә, фантазия да, тырышлык та сорамый. Ә менә уйланып иҗат итә, актерлык хезмәтен сәнгать эше дип карый торган артист өчен зур бәла ул. Шуңа күрә андый очракта, бер тапканны кабатлауга караганда, мондый рольләрне уйнаудан баш тарту хәерлерәктер, бәлки.

Театрда эшли башлаган беренче елларда Биктимеров белән кызыклы хәл килеп туа: актерлар да, тамашачылар да — бөтенесе беравыздан аны, һичшиксез, талантлы артист дип бәялиләр. Беренче елларда уйнаган рольләре нәкъ шуны раслый да. Ул иҗат иткән барлык образлардан актерның ихлас күңел белән, бик табигый итеп уйнавы күренеп тора. Театрның өлкән артистлары: «Шәүкәт үзенең сәләте, рольләрне уйнау рәвеше белән татар театрының сәнгать осталарын хәтерләтә»,— диләр. Әмма, актерның бу сыйфатын таныган хәлдә дә, без аның баштагы ун елда бик шәп башкарган нинди дә берәр ролен атап әйтә алмыйбыз. Бу хәлнең берничә сәбәбе булса кирәк. Беренче сәбәп, һичшиксез, актерның яшь булуы. Сәхнәгә беренче тапкыр аяк басу белән үк ялтырап китү бик сирәк артистларның гына сәләтеннән килә. Шуңа күрә Шәүкәтнең сәхнәдәге беренче ун елы әле өйрәнү чоры гына була.

Икенчедән, алда саналган рольләрдән күренгәнчә, Ш. Биктимеровка башлыча татар пьесаларындагы бер үк төрле уңай герой рольләрен генә биреп киләләр. Бу хәл персонажларны уйнаудагы бер төрлелеккә, аннан да бигрәк иҗат кешесе өчен иң куркынычы — бер урында таптануга китерә.

1964—65 елларда артист башка пландагы берничә роль уйный. Болар — Ф. Хөснинең «Бертуган Таһировлар»ындагы Заһит, Ә. Баяновның «Күзләре нинди иде» пьесасындагы Хәмитов, А. Расихның «Ике буйдак» романы инсценировкасындагы Рәхим образлары. Шушы өч спектакль арасыннан иң уңышлысы «Бертуган Таһировлар» булгандыр. «Бертуган Таһировлар» спектакле — татар драматургиясенең дә, Г. Камал исемендәге академия театрының да җитди уңышы»,— дип язды «Советская Татария» газетасы үзенең 1965 елгы 5 февраль санында. Фатих Хөснинең бу әсәре — совет җәмгыятенең төкәнмәс көче, безнең кешеләрнең мораль ныклыгы, кеше күңеленең яхшылыгы һәм яманлыгы турында зур гражданлык хисе белән сөйли торган җитди психологик драма.

Ш. Биктимеров бу спектакльдә бертуган Таһировлардан иң кечесен — Заһитны уйный. Биредә дә ул рольне ышандыргыч, чын итеп уйный. Күптән түгел генә лагерьдан кайткан Заһитның йөрәк яралары да төзәлеп җитмәгән әле. Шуңа күрә Заһит һәрвакыт уйчан, басынкы йөри. Ләкин, шул сыйфатлар белән бергә, бу образны уйнауда беркадәр сентиментальлек, үз героеңны кызгану да сизелә иде. Безнеңчә, алай булырга тиеш түгел иде. Дөреслек, хаклык Заһит ягында бит!

Ә. Баяновның «Күзләре нинди иде» әсәре дә кызыклы гына спектакльгә әйләнә алган булыр иде. Бу драмада яшәүнең, кеше хезмәтенең мәгънәсе нидә, дигән җитди мәсьәлә куела. Бу спектакльдә Ш. Биктимеровка, ниһаять, моңарчы уйнаганнарына бөтенләй охшамаган бер рольне — Хәмитов ролен бирәләр. Хәмитов — эштә сыналган кеше, зур төзелеш җитәкчесе. Ләкин ул зур объектлар төзегән чакта, аны тизрәк башкарып чыгу өчен, башка кечерәк төзелешләрдәге эшне тарката, төзү материалларын читкә җибәреп әрәм-шәрәм итә, кемгәдер дача салып бирә, 80 квартиралы бер йортны «кулдан ычкындыра» һ. б. Болар берсе дә аның үз файдасы өчен эшләнми (бөтен драматизм да әнә шунда), бәлки төзелешне тизрәк тәмамларга ярдәм итәрдәй кирәкле кешеләрне «майлау» өчен эшләнә. Хәмитов зур эш башкарып чыгу өчен кечерәкләрен корбан итәргә дә мөмкин, дип уйлый. Хәмитовка, аның төзелештәге эш итү методларына яшь хатын Айсә да ышана. Алай гына да түгел, ул аның мондый эшләрен яшереп килә, ялган нарядларга кул куйганда, ире Салаватны Хәмитовның дөрес эшләвенә ышандырырга тырыша. Айсә Хәмитовка шулкадәр ышана — вакыт-вакыт ул ачыктан-ачык алдашу юлына баса. Шушы капма-каршы ике ара-сында — бер яктагы Хәмитов белән Айсә, икенче яктагы Салават һәм аның бригадасы арасында — каты көрәш башлана. Нәтиҗәдә Айсәнең тормыш идеаллары җимерелеп челпәрәмә килә. Үзенең никадәр хурлыклы эш эшләгәнлеген аңлагач, Айсә үзен-үзе үтерә. Драматург әнә шундый конкрет тормыш мисалында Хәмитовларның

зарарлы йогынтыларын ачып сала. Хәмитов ише кешеләрнең «максат чараны аклый» дигән принцибы кешелексез, зарарлы бер принцип булып чыга. Шушы пьеса нигезендә партияле ачык караш һәм зур гражданлык хисе белән сугарылган спектакль куярга мөмкин иде. Ләкин академия театры, аның режиссерлары әсәрне сәхнәгә тиешенчә куя алмадылар, шуның нәтиҗәсендә драма уңышсызлыкка очрады.

1966 ел Татар академия театрының иҗади үсешендә яңа бер кузгалыш елы булды. Кыш буена җыелып килеп, язын шаулап-гөрләп ташу сулары кузгалган кебек, академия театрының да алдагы елларда туплап килгән иҗат көче, ниндидер киртәләрне җимергән кебек, ташып, ачылып китте. «Гүзәлем Әсәл» спектакле әнә шул язның беренче карлыгачы булды. Бу спектакль Ш. Биктимеровның иҗат үсешенә дә бер этәргеч ясады. Шул спектакльдәге Байтимер ролен уйнаган өчен аңа Тукай премиясе бирелде.

Безнең күз алдыбызда кинәт кенә искиткеч бер кеше табигате, кеше күңеле ачылды. Ул шулкадәр яхшы күңелле, эчкерсез бер кеше, аңардагы күңел җылылыгы сәхнәдә генә калмыйча, залга күчеп, тамашачыларга да барып житә кебек. Ул гади бер юл эшчесе, беренче карагандa игътибар итәрлек, кызыксындырырлык бер нәрсәсе дә юк кебек. Әмма якыннанрак танышкач, бу кешедә никадәр җан җылысы, акыл зирәклеге, күңел сафлыгы барлыгын күреп гаҗәпкә каласың. Ул, гади генә бер эш кешесе, үзендәге зур кешелек хисе белән, бәхеткә юкукын даулый. Шактый олыгаеп барган бу кеше үз гомерендә бик күпне күргән, күпне кичергән. Әмма ялгызлык та, кайгы-хәсрәт тә аны өмет-ышанычын җуйган, бәгыре каткан бер кешегә әйләндерә алмаган. Кешеләр белән сөйләшкән чагында аның йөзе ягымлыланып, яктырып китә. Йөргәндә дә җиргә йомшак кына басып йөри ул. Байтимер-Биктимеров тормыш ачысын күп татыган, шуңа күрә ул кешеләргә булышырга, яхшылык итәргә һәрвакыт әзер. Биктимеровның әнә шул Байтимер образын уйнавын күз алдыннан кичергәч, артист моңарчы театрда нигә Чехов әсәрләрендәге бер рольне дә уйнамады икән дип уйлыйсың. Бик шәп дядя Ваня, Тузенбах булыр иде бит ул... Ш. Биктимеровның соңгы елларда күренгән үзенә генә хас талант сыйфатлары әнә шул Байтимер образында ук инде калку булып ачылды.



«Гүзәлем Әсәл»дә Байтимер.

Ш. Биктимеров рольгә хәзерләнгәндә җете буяулар, ярылып яткан сызыклар белән эш итми. Тамашачыга тәэсир итү чаралары сайлауда бик саран ул. Аның геройлары берьюлы күзгә ташланмый, җай белән әкренләп ачыла баралар һәм ачылып җиткәч, тамашачының күңелен биләп алалар. Ул уйнаган уңай геройларга күңел йомшаклыгы, интеллигент сыйфатлары, эчке ягымлылык, мөлаемлылык хас. Т. Гыйззәтнең «Чаткылар»ындагы Орлов, Сәхиб Җамалның «Фатыйма Сабри» пьесасындагы Фәрхад, Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романы буенча эшләнгән спектакльдәге Садыйк, «Ике буйдак»тагы Рәхим — шундыйлар.

Ш. Биктимеровның соңгы еллардагы иҗатында яңа сыйфат шул — ул, төрле характерлы рольләрне уйный башлап, талантының өр-яңа якларын күрсәтте. Бүгенге академия театрының уңай геройларын уйнап чыккан актер — А. Островскийның «Соңгы корбан»ындагы алдакчы Дульчин, Ш. Хөсәеновның «Әни килде» пьесасындагы түбән җанлы Ислам, Н. Исәнбәтнең «Миркәй белән Айсылу»ындагы әшәке Замир Даули, Т. Миңнуллинның «Зәңгәр шәл»ендәге ике йөзле ишан рольләрен бик шәп башкарып чыгар дип кем уйлаган. Әмма бу образларның барысына да — уңайларына да, тискәреләренә дә — Ш. Биктимеровка хас бер сыйфат уртак: алар барысы да сәхнәдә фикер йөртә беләләр.

Ялган романтик пафос, кирәккә-кирәкмәскә дә «хис түгү» актерга хас түге Тыштан ул артык тыенкы. Әмма шулай сабыр күренсә дә, актер зур темпераме белән, бөтен хәрәкәтен уйлап, күңел салып уйный.

Әлбәттә, сәнгатьнең һәр тирәндәге кебек, актер иҗатына да заман зур йогынт ясый. Безнең марксистик эстетика да шул хосусиятккә нигезләнгән. Ленинчыл чагылдыр теориясе дә шул хакта сөйли. Бүгенге заман театрына ни өчен интеллект, лаконизм һәм кырыслык хас соң? Бу сорауга тормыш үзе җавап бирә.

Икенче бөтендөнья сугышының коточкыч газап-михнәтләрен башыннан кичерг совет кешесе тормышка хәзер аеграк күз белән карарга өйрәнде.

Безнең сугыштан соңгы буын киеренке халыкара хәл шартларында, атом төше таркату, атом бомбасы һәм Хиросима заманында үсә. Ул фән өлкәсендәге зур ачыш лар заманында яши, капиталистик Көнба тышта бу ачышлардан ни өчен файдалан ларын күреп үсә. Бүген, халыклар ара сында аралашу үтә зур тизлек белән бар ган бер заманда, без бөтен дөнья халла реннән аерылып яшәмибез һәм яши а алмыйбыз. Сугыш һәм тынычлыкка кагы лышлы уртак мәсьәләләр бөтен кешеле дөньясын борчый. Шуңа күрә без, карты быз, яшебез, сугышка кадәр чордагыда бөтенләй башка кешеләр. Шуңа күрә дә бү генге заман кешесе чагыштырмача акыллы рак та, ул күбрәк тә уйлана. Шул сәбәпле у иң ярсулы тойгыларын да моннан егерме утыз ел элеккегә караганда кырысрак тыенкырак чагылдыра. Бүгенге заман кеше ләре өчен хис-тойгы кысылып килгән каты пружинага никадәр якынрак булса, шулка дәр үтемлерәк ул.



«Фатыйма Сабри» спектаклендә Фәрһад Сабри.

«Менә шуңа күрә дә интеллектны, уй фикер киеренкелеген артистның сәнгате заманча итә торган иң кирәкле сыйфат ди санныйм мин. Әгәр элегрәк бу сыйфат кай бер зур художникларның индивидуал үзенчәлеге генә булган булса, хәзер у һәрбер актерның уйнау стилендә төп сый фат булырга тиеш. Сәхнәдә киеренке ре вештә уйлап уйный белмәгәндә, актерны сәнгате заманча була алмый»,— дип яз талантлы совет режиссеры Г. Товстоногов

Бу уңайдан бүгенге заман стилен шундый билгеләмә бирүгә каршы килүчеләр, авыз ерып: «Ә Хмелев белән Качалов сәнгате уй-фикерсез булганмы?» — дигән сорау куялар. Һич тә алай түгел. Ләкин алар берәмләп санарлык кына булганнар бит. Ә хәзер без ул хакта гомуми юнәлеш итеп сөйлибез.

Бүгенге заманча уйнау турында сөйләгәндә, без еш кына интеллект сүзен тел алабыз. Ләкин ул сүз «коры акыл» дигән мәгънәне генә аңлатмый. Ш. Биктимеровта уй-фикер, тыенкылык-сабырлык булу белән бергә, хис-тойгы куәсе дә, темперамент та бар. Шуңа күрә бүгенге театр турындагы әдәбиятта «уй-фикер темпераменты» дигән терминның очравы бер дә очраклы түгел.

Актерда зур хис-тойгы көче бар. Аның уй-фикере һәрвакыт эш-хәрәкәтле, эш-хәрәкәте һәрвакыт уйлап, төшенеп башкарыла. Актер уенындагы интеллектуальлекнең сере әнә шунда. Биктимеровта талант, акыл, тәҗрибә, заман тойгысы һәм тормыш хәлләрен партиячел караш белән аңлау — болар барысы да бар.

Моңа мисал итеп беренче чиратта Ленин образын, аннары Байтимерне, шуннан соң артистның иҗатындагы бөтенләй башка рольләрне — Дульчин белән Исламны китерергә мөмкин.

«Соңгы корбан»дагы Дульчин артист тарафыннан чын сәхнә осталарынча иҗат ителгән.

«Соңгы корбан» — мәхәббәт турындагы әсәр. М. Новохижин тарафыннан сәхнәгә куелган бу спектакль Тугинаның чын, тирән, зур мәхәббәте, мәхәббәт — табыш, Прибытковның мәхәббәте — фаҗигале, Дульчинның сатлык мәхәббәте турындагы әсәр. Акча-алтын дөньясында чын мәхәббәт һәлак була. Акча мәхәббәтне харап итә. Яңа булмаса да, искерми торган мәңге яшь тема бу. Бер карaганда, күп кабатланган төсле күренгән бу сюжетта, персонажларның үзара мөнәсәбәтләрендә катлаулы кеше характерлары, кеше язмышлары, ул язмышларның асылы — чын һәм ялган булуы ачыла.

Режиссер куйган бурычны актер бик шәп башкара.

Менә бик пөхтә-ыспай киенгән, бизәнгән-төзәнгән чибәр бер егет Юлия янына йөгереп килеп керә. Күгәрчен кебек гөрләп Тугина янында бөтерелә. Башын аның тезенә куеп, кәйсез, иркә бер бала кебек, ниләрдер сөйләнә — кулыннан үенчыгын алсаң, авызын турсайтып елап та җибәрер шикелле. Дульчин-Биктимеров шул хәтле оятсыз алдаша, кайвакыт ул үз ялганына үзе дә ышана башлый кебек. Аның бөтен барлыгы алдашу, ялган, хәйләдән генә торадыр шикелле. Дульчинны карагaнда, ни өчендер гел Хлестаков искә төшә. Аларның охшашлыгы алдауга хирес буш җанлы кеше булуларындадырмы, акча артыннан куууларында һәм ялган эчле булуларындадырмы — ходай белсен. Әмма спектакльдә Дульчин артында Гоголь персонажының образы һаман шәүләләнеп тора.

Вадим Дульчинның төп омтылганы акча аның бөтен гомер юлы буйлап кызыл җеп кебек сузылып уза. Ул кайда гына булмасын, ни генә эшләмәсен, кем белән генә сөйләшмәсен, шул уй бервакытта да аның күңеленнән чыкмый.

Әнә ул диванда Юлияне кочып иркәләп утыра, ә үзе күңеле, уйлары белән әллә кайда еракта йөри. Хәзер ул өзелеп сөюче ир ролен генә башкара. Ирэн белән сөйләшкәндә дә Вадимның уйлары читтә, ул назланган-кыланган шикелле сүзләрен сузып-сузып сөйли. Әмма күңеле һаман үзенекен — акча, байлык турында, алдатмау, берәр төрле мөмкинлекне кулдан ычкындырмау турында уйлый. Шуңа күрә ул, нәрсәдер артыннан куган кебек, гел хәрәкәттә. Тышкы ясалма шомалык, әдәп-инсафлык аша буш салкын җанлы, эгоист бер кешенең табигате күренеп тора.

Ш. Биктимеров моннан соңгы эшен инде икенче төрле буяулар, икенче сызыклар белән тасвирлый. Анысы — Ш. Хәсәеновның «Әни килде» драмасындагы Ислам образы. К. Симоновның сугыш елларында ук язган «Шулай булачак» исемле пьесасында майор Гречның бик матур бер фикере бар: «Ул талантлы түгел, әмма кеше ул, ә кеше була белү — талант, андый талант бөтен кешегә дә бирелеп бетми»,— ди ул.

Нәрсә ул кеше, аның җәмгыять тормышындагы урыны нинди, тормыш хәлләре эчендә, каты бәрелешләрдә аның чын эчке асылы ничек ачыла? Бүгенге совет кешесе нинди? Аңардагы кадерле төп сыйфат нәрсә? М. Сәлимҗанов тарафыннан куелган «Әни килде» спектакле әнә шул хакта.

Пьесада Ислам роле аерым урын алып тора. Ш. Биктимеров безнең тормышка чит булган типның тискәре сыйфатларын күрсәтеп, андый кешеләрне зур нәфрәт белән фаш итә.

Ягымлы карашлы, йомшак табигатьле мөлаем артист Шәүкәт Биктимеровны без күптән беләбез. Һәм аны уңай герой образларын уйнаучы артист буларак беләбез. Аның палитрасыннан ямьсез кара буяуларны табып та булмас кебек. Әмма без Ш. Биктимеровның иҗат сәләтен әле белеп бетермәгәнбез икән. Аның соңгы ролендә без моңарчы күреп гадәтләнгәннең нәкъ киресен күрдек.

Тыштан караганда, Ислам ярыйсы ук чибәр генә бер кеше булып күренә. Өс-башы бик пөхтә, әйбәт. Үзенә тимәсәләр, ул туганнары белән дә ягымлы, ачык сөйләшә. Ә аның яшәү максаты — кулга мөмкин кадәр күбрәк акча, мал төшерергә тырышу. Аның үз йорты, үз машинасы, үз бакчасы бар — алар фәкать аныкы гына. Бу максатка ирешү өчен ул бернидән дә тартынмый, хәтта сугыш елларында дезертир булып та кала. Үзенең тормышка карашын, мәсләген яклый башлагач, Ислам-Биктимеров безнең күз алдыбызда бөтенләй икенче кешегә әверелә. Йөзенә яман бер ачу чыга, күзләре белән һәркемне тишәрдәй итеп карый. Юлына аркылы төшсәң, ул үз милкен саклап, сине үтереп тә китәр иде.

Баштарак Ислам бүтән туганнары арасыннан берние белән дә аерылып тормый. Башкалар кебек ул да шаярта-көлә, шау-гөр килә. Аннары шундый бер деталь күренә: Ислам комсызланып тыгыла-төелә компот эчә, савытка кулы белән тыгыла— менә шунда инде безнең аңа беркадәр карашыбыз үзгәрә, сәерсенә башлыйбыз.

Икенче бер штрих — Ислам корсагын киереп, аякларын сузып юл өстенә утырган да узган-барганның абынуыннан рәхәтләнеп кеткелдәп көлә. Кешеләргә уңайсызлавы аңа зур ләззәт бирә.

Менә ул нинди юллар белән үзенә машина алуы турында, шул эшне әле яңа гына эшләгән кебек тәмләп, кеткелдәп көлә-көлә сөйли.

Исламның характерындагы әнә шундый сыйфатларны күргән саен, тамашачы аның әшәке, түбән җанлы бер бәндә икәнлегенә ышана бара. Исламның түбән җанлылыгы энесе Инсаф белән талашуында тагы да ачыла төшә. Энесе каты-каты итеп җавап кайтаргач һәм чын намуслылык, гаделлекнең нәрсә икәнен аңлата башлагач, Ислам түзми, бөтен әшәкелеген ачып сала, чөнки аның дөньяда яшәү, малга хиреслек принципларына китереп бастылар, бу юлы инде шаяртып сөйләнеп кенә котыла алмыйсың. Ислам, күзен-башын җимереп, минем бай яшәргә хакым бар, дип кычкыра. Ш. Биктимеров үзенең героен шул хәтле чын, шул хәтле оста итеп уйный, Исламга карата күңелдә ачу-нәфрәт, җирәнү тойгысы уяна.

Коммунист һәм гражданин актер бу очракта иске заманнан калган һәм яшәргә хакы булмаган әнә шундый тормыш күренешләрен рәхимсез рәвештә хөкем итә. Әнә шулай, тискәре типларны фаш итеп, ул әхлак идеалын алга сөрә.

Мәскәүдәге гастрольләре вакытында Татар академия театрының спектакльләрен караганнан соң, 1970 елның 1 август санында «Правда» газетасы:

«Бай сәнгать традицияләре, актер осталыгы, сәнгатьчә яңа чаралар табарга омтылу — болар барысы театрның зур сәхнә культурасы барлыгы турында сөйли»,— дип язды.

Бу сүзләр тулысы белән Ш. Биктимеровка да карый. 1970 елның июнь аенда аңа зур исем — РСФСРның халык артисты исеме бирелде. Актерның хәзер бөтен иҗат сәләте чәчәк аткан чоры. Без әле аның чын сәхнә осталарынча тагын бик күп роль уйнавын көтәбез.

Александр Скрыпник

# МОГҖИЗАНЫҢ КИРЕ ЯГЫ

Италиягә китәр алдыннан мин бу ил турындагы күп санлы юлъязмаларны укып тормаска булдым. Моңарчы таныш булмаган илгә үземчә, яңача итеп карарга, үзем иң әһәмиятле санаган нәрсәләрне генә язып барырга күңелемә беркетеп куйдым. Ләкин без автобуска утырып аэропорттан шәһәргә таба кузгалып китәргә дә өлгермәдек, минем бу өметләрем челпәрәмә килде.

— Алга карагыз,— диде тәрҗемәче кыз.— Анда сез атаклы Рим наратларын күрәсез...

Мин кабалана-кабалана кесәмнән куен дәфтәремне чыгарып, аэропорт исемен язып куйган арада, әлеге наратлар автобус яныннан йөгереп үтеп тә киттеләр, мин аларны рәтләп күрә дә алмадым. Мин, укытучысы әйтеп яздырганда иң кирәкле сүзне язарга өлгерә алмый калган мәктәп баласыдай, сагаеп кына, янымда утыручы ханымның куен дәфтәренә күз салдым һәм анда түбәндәге юлларны укыдым: «Рим. Фумичино аэропорты. Алга карагыз: сез анда атаклы Рим наратларын күрерсез...» Мин бу юлларны укып торганда, әлеге ханым тагын яза башлады: «Сулга карагыз: сез анда...»

Мин як-ягыма карадым. Автобустагы утыз ике кешенең барысы да куен дәфтәрләренә текәлгәннәр иде. Тик тәрҗемәче кыз гына, үз уйларына чумып, әйләнә-тирәне күзәтә. Менә шул минутта мин юлдашларымның Рим наратлары турында да, Венециядә ничә канал һәм ничә күпер булуы турында да, Римдагы Преви фонтанына көмеш акча ыргытулары турында да бәйнә-бәйнә язачакларына ышандым.

Туган илгә кайтып, Италия турында язылган бер кочак очеркларны укып чыкканнан соң мин бу иптәшләремне (алардан да битәр укучыларны) кызганып куйдым: боларның барысы турында да инде күптән язылган лабаса!

Шуңа да карамастан, мин Италиягә баруым турында язарга булдым. Очраклы гына очрашулар турында, бәхәсләр һәм әңгәмәләр турында. Чөнки, миңа калса, сәяхәтнең иң кызыклы ягы да шул инде аның: яңа кешеләр күрү, аларның тормышын белү.

## Болонья

Бу шәһәрдә мин бик аз булдым. Һәм, дөресен генә әйткәндә, изге Петринио соборыннан бүтән бернәрсә дә күрә алмадым. Шулай да бу шәһәрдә булган бер очрашу турында сөйлисем килә.

—Ул кеше Маджорада мәйданында минем янга килде дә, күкрәгемдә Ленин рәсеме төшерелгән значокны күргәч, шатланып кычкырып җибәрде:

— Здравствуй. Ельки-пальки! Руки вверх!..

Мин дә аңардан калышырга теләмәдем, шундыйрак итеп җавап бирдем:

— Салюте. Аривидерчи. Грацие![1]

Шулай итеп, без рус һәм итальян телләрендә бар белгәнебезне бер тын алуда әйтеп бетердек тә өлешчә немецчәгә, ә башлыча «халыкара телгә» — ымнар, ишарәләр ярдәмендә сөйләшүгә күчтек.

— Мин сиңа бер күрүдә үк игътибар иттем,— диде ул миңа.

— Минем буй озын бит, шуңа алай игътибар иткәнсездер,— дидем мин көлеп.

— Эш буйда гына түгел. Туристны аны ерактан ук танып була. Турист менә болай йөри...

Һәм ул ияген югары чөйде дә йөреп күрсәтте.

— Турист соборга карый, кибет витриналарына карый.

Аннары яңа танышым Данило Учело (ул минем куен дәфтәремә үз кулы белән шулай дип язып куйды), җиңемнән тотып, мине кибетләр рәтенә таба борды.

— Син шуннан әле генә үттең, нәрсә күрдең анда!

Мин бераз уңайсызланып:

— Витриналар...— дип мыгырдандым.

— Әгәр бераз түбәнрәк карасаң!..

Тротуарда, кулындагы кружкасын үтеп баручыларга таба сузып, баштанаяк карадан киенгән бер хатын утыра иде. Аңардан арырак, урам чатында әйбәт кенә киенгән, галстук таккан, кара күзлекле бер ир кеше лоторея билетлары сата. Шунда ук ниндидер кешеләр, җилкәләре белән стена терәтеп, берниндн шөгыльсез басып торалар.

— Ә болары кемнәр! — дип сорадым мин, шуларга ымлап.

— Эшсезләр,— диде Данило.— Аларның акчалары юк.

Кинәт Болонья миңа бөтенләй икенче ягы белән борылгандай булды. Мин, реклама өчен эшләнгән яптыравыклы витриналардан аерылып, шәһәргә бөтенләй икенче күз белән карадым. Күпмедер вакытка мин турист булудан туктап, урамда очраган гади бер итальянның иптәшенә әверелдем.

Без собор баскычына утырдык та сөйләшеп киттек. Мыегын-сакалын бик җентекләп кырган, калын свитер кигән, базык гәүдәле Данило кинәт ничектер шиңеп калгандай булды.

— Витринасы матур,— диде ул,— ә менә витрина артында...

Үткән сугышта Данило Генуя тирәләрендә партизанлык иткән. Анда руслар да күп булган. Алар дуслашып киткәннәр. Кыю йөрәкле, олы җанлы кешеләр булган алар. Данило аларның күбесен бүген дә хәтерли. Башлыча исемнәре, кушаматлары буенча. Рус сүзләрен дә онытмаган. «Давай-давай», «Взять языка и баста» кебек сүзләрне бик дөрес итеп әйтә. Данило Болоньяда туып үскән. Әмма ул чын дусларын итеп Генуяда бергә партизан булып йөргән иптәшләрен саный. Данило үзе шофер. Автобуслар йөрткән. Тик менә ике атна инде эшсез икән.

Ул иңбашларын җыерып куйды: янәсе, нишләмәк кирәк, тормышы шундый. Семьясы шактый зур. Биш баласы бар. Зурысы заводта эшли. Хәзергә аның хәле ярыйсы икән. Бөтен семья шуңа карап тора. Ләкин ул терәк тә ышанычлы түгел. Болоньяда забастовка артыннан забастовка. Ул әле Данилоның улы эшли торган химия заводына гына кагылмаган. Ләкин андый-мондый хәл булса, беренчеләрдән булып, аны чыгарып атачаклар — ул Италия компартиясе члены, активист. Менә шул чак семья кеймәсе бөтенләй комга тереләчәк. Җитмәсә, өйдә, балалардан тыш, картлар — Данилоның һәм хатынының әти-әниләре дә бар икән.

— Эшсез йөргәндә азрак ярдәм итәләрме соң! — дип сорадым мин.

— Итәләр. Өч мең лир.

— Атнагамы!

— Айга.

Бу кешенең очны очка ничек ялгый алуына аптырап, сүзсез тордым. Бер пачка сигарет 400—500 лир торганда, айга 3 мең лир белән ничек көн итәргә мөмкин икәнен күзаллавы кыен иде шул. (Минем эшсез кешене беренче тапкыр күрүем.)

[1] Сәлам. Исәнме.

— Кара көнгә дип саклаган бераз акчабыз бар барын,— диде Данило һәм шунда ук өстәп куйды:— Ләкин аз, бик аз.

Хәленең мөшкелләген аңлату өчен, ул чәнчә бармагын күрсәтте.

— Ул акчагыз беткәч нишләрсез соң! — дидем мин.

— Дусларым бар. Эш табарга, бәлки, ярдәм итәрләр. Ләкин эш табу хәзер бик кыен нәрсә.

— Ни кылмак буласыз соң!

— Генуяга барырга исәп. Дусларым чакыра. Алар анда зур забастовкага хәзерләнәләр. Бармыйча ярамый, дусларга ярдәм итәргә кирәк.

Бу кешенең тормышы авыр икәне күзләреннән, тавышыннан, киеменнән үк күренеп тора. Аңа бик кыен. Әмма ул үзе турында гына уйламый. Сыйныфташлары турында, забастовкага әзерләнүче һәм аны ярдәмгә чакыручы Генуя эшчеләре турында кайгырта...

Аннары без тагын аның Генуядагы партизан дуслары турында сөйләштек. Мин аңардан, Федор Полетаевны белмисеңме, дип сорадым.

— Федор Поетан,— дидем аңа аңлашылсын өчен.

— Ә-ә, Поетан,— диде бу.— Ишеткәнем бар. Әмма күргәнем булмады. Туры килмәде. Аның караваы, бүтән русларны белә идем...

Мин аның хәтерендә калган рус егетләренең исемнәрен язып алдым. Аннары Данило урыныннан кузгалды да:

— Минем дә эшем бар бит әле,— дип, корсагына сугып свитеры эченә яшерелгән сигаретларны күрсәтте.

— Контрабанда,— диде ул, гаепле кеше сыман кыюсыз гына елмаеп: янәсе, нишлисең инде, яшәргә кирәк бит. Аннары сорап куйды:

— Генуяда буласыңмы!

— Булам.

— Бәлки, очрашырбыз әле.

— Сау булыгыз.

— Чр. Аривидерчи.

Миңа Генуяда нәкъ порт эшчеләренең забастовкасы барган көннәрдә булырга туры килде. Алар шәһәр урамнарыннан үз таләпләре язылган лозунглар һәм плакатлар күтәреп баралар иде. Мин аларга шактый озак карап тордым. Аларның күбесе Болоньядагы дустым Данило Учелога охшаган төсле тоелды. Ләкин аның үзен очрата алмадым. Шулай да Данилоның Генуяда икәненә шигем юк иде.

## Венециядә бер төн...

Кабатлау булмасын өчен башта ук шуны әйтеп үтәргә кирәк саныйм. Венеция һаман нәкъ үз урынында, анда булып киткән һәр турист, һичшиксез, телгә ала торган йөз сиксән утраучыкта тора бирә. Изге Марк мәйданы да, элекке Венеция республикасының башында торучылар — дожлар сарае тирәләре дә элеккечә үк туристлардан арынып тормый. Күп санлы каналларның ярларын элеккечә үк дулкын кага һәм элеккечә үк алардан түбән карбыз исе аңкып тора. Гондольерлар, моннан илле һәм йөз ел элек булган кебек үк, ак матроскадан һәм кызыл лента тагылган салам канотье кигәннәр. Искиткәле бу шәһәр һәм аның күп санлы каналлары өстендә элеккечә үк зәңгәр күк гөмбәзе зәңгәрләнеп тора. Ә шәһәрнең урамнары, хәзер дә, кара-каршы килгән ике кеше үтә алмаслык дәрәҗәдә тар.

Венециядә берниндн максатсыз үзең генә йөрү рәхәт. Шунда бер кызыклы кешене очратсаң, тагын да әйбәт. Кемне очратсаң да ярый. Яхшы кеше генә булсын. Венециянең үз кешесе булсын...

Ул яктан мин уңдым. Инде өйгә, без яши торган «Кассиано» пансионына кайтырга җыенып кына торганда, шәрә тәненә озын свитер кигән бер егеткә күзем төште. Ул гондоласына баскан килеш причалдагы ике казык арасына кысылган чылбырны ычкындырырга азаплана иде. Иелеп эшләгәнгә муенындагы медальоны борынына килеп тия, ул аны әледән-әле җилкәсенә таба авыштыра, ә медальон яңадан шуып төшә иде.

— Ярдәм итимме! — дидем мин, Риальто күперенең иң түбәнге баскычында басып торган хәлдә. Егет башын күтәрде, әмма берни аңламыйча тагын үзенең чылбырына тотынды. Мин су буена ук килдем, ымлап, ярдәм итәргә теләвемне аңлаттым. Ул кө-леп җибәрде, әйдә, рәхим ит, дигәндәй кул изәде. Мин гондолага сикердем, һәм без икәүләп көч-хәл белән чылбырны ычкындырдык. Тышкы кыяфәтенә караганда, аның гондоласы яңалардан түгел: буявы купкан, урындыкларындагы күн мендәрчекләр кырылган-таушалган.

— Турист! — дип сорады егет, без әлеге урындыкларга утыргач.

— Турист,— дидем мин һәм үз чиратымда аның кем булуы белән кызыксындым: — Гондольер!

Егет башта минем сүзне җөпләп ияк какты, аннары исә, алай түгел дигән сыман, башын селкеп куйды. Мин моның сәбәбен соңыннан гына аңладым. Ул әле гондольер булырга җыена гына икән. Аннары ым-ишарәләр ярдәмендә без тагын шуны ачык-ладык: аңа каядыр барып, кулындагы конвертын илтеп килергә кирәк. Теләсәң, әйдә, бергәләп барабыз, диде бу. Мин риза булдым.

Гондолага утырып йөрү рәхәт икән. Ул нәкъ май өстеннән шуган кебек (бүтәнчә чагыштыру табып та булмастыр, мөгаен) суда шома гына бара.

Минем яңа танышым традицион киемнән булмаса да, гондолада үзен шактый иркен тота иде. Үзе бертуктаусыз елмая һәм каналга таба ымлый: ошыймы, янәсе. Без Зур каналга чыктык. Аның һәр ике ягында бар утлары ялтырый. Барләрнең өс-тәлләре яр буена, су читенә үк чыгарып куелган. Алда гигант дуга булып Риальто күпере күренә. Канал өстендә безгә каршы килүче бер-берсенә тоташтырылган бер-ничә гондола күренде. Аларга туристлар утырган иде. Ак күлмәк кигән бер егет (махсус ялланган җырчы) традицион «Санта Лючио»ны суза. Менә гондолалар Риальто күпере астына килеп керделәр. Алда каршыга килүче тагын бер төркем гондолалар күренде. Яр буенда, күпер өстендә торучы кешеләр, шул якка таба ымлап, нидер кычкыра башладылар. Минем танышым да кычкырды. Мин аягүрә бастым һәм беренче гондолада утыручы кияү белән кызны күрдем. Алар артындагы гондолада оркестр уйный, кемдер җыр суза иде.

Боларның барысы да — дулкын чайкалуы да, Риальто күперендәге һәм яр буен-дагы кешеләрнең кычкыруы да, җыр һәм музыка тавышлары да — бергә кушылды. Яр буендагы ялтыравык утлар тирә-юньгә зур бәйрәм төсен биреп тора. Әмма бу гади бер көн иде. Дөресрәге — төн.

Без Зур каналдан читкә борылып, өйләр арасыннан йөзеп бара башлагач, минем сорашып белә алган бар нәрсәм шул булды: яңа танышымның исеме Антонио булып, безгә тагын егерме минутлап барырга кирәк икән.

Без ашыкмый гына бардык. Авыр дулкыннар яшькелт төскә кергән стеналарга бәрелеп чупылдыйлар, баскычларның тапталып-ашалып беткән басмаларын, черегән ишек такталарын ялыйлар. Баш өстебездә канал-урамнар аша тартылган бауларга эленгән керләр аксылланып тора. Күпчелек тәрәзәләр ябык. Кая карама — анда таш. Таш һәм су. Ара-тирә стеналарда түбәнгә таба үрмәләп үскән яшеллекләр күзгә ча-лына. Бер тапкыр тәрәзә ачылып китте дә канал өстенә нәкъ безнең гондола янына ук нидер түктеләр. Антонио итальяннарга хас кызулык белән нидер кычкырып җи-бәрде. Тәрәзәдә майка кигән юан гына бер ир кеше күренде һәм безгә тагын да катырак кычкырып җавап бирде. Аларның сөйләшүен мин үземчә шулайрак тәрҗемә иттем: «Син нәрсә, акылыңнан яздыңмы әллә, кеше өстенә түгәсең!», «Күзең чыкма-гандыр бит, карабрак кил! Ни пычагыма төнлә бу тирәдә йөрисез!» Без бер чатка борылдык, аннан икенчесенә, ә теге майкалы кешенең ачулы тавышы әле һаман ишетелеп тора иде.

Без виа Регина урамыннан бераз йөзеп бардык та, күпер астыннан үтеп, виа Боттерига чыктык. Гондолабызны шунда яшел күгәрек белән капланган лайлалы таш баскычлар янына туктаттык. Антонио чылбырын су эченнән чыгып торган ботаклы казыкка урап куйды.

— Алып китмәсләрме соң! — дип сорадым мин. Ул башта аңламый торды. Аңла-гач, көлеп җибәрде: тимәсләр, янәсе, йозак ышанычлы.

Без бераз бардык та кечкенә генә трактир сымак нәрсә — ул итальянча траттория дип атала — янында туктадык. Антонио миңа шунда көтеп торырга кушып, каядыр

китеп барды. Траттория хуҗасы, буфет стойкасы артына баскан килеш, кәгазьдә ниндер хисаплап маташа иде. Кечкенә генә залның түрендә дүрт ир кеше карта уйныйлар. Шунда ук өч егет озын калын стаканнардан сыра чөмереп утыра. Миннән ерак түгел тагын икәү, шактый ук исергәннәр булса кирәк, бер-берсенең пиджак якасыннан тотканнар да «әйт әле, дусмы син миңа, дус түгелме!» кебек сүзләр әйтешәләр. Автоматтан музыка яңгырый. Пластинка әйләнеп бетүгә, егетләрнең берсе барып махсус ярыкка акча салып килә, музыка тагын уйный башлый.

Мин карта уйнаучыларга якын килдем һәм, сүз башлар өчен, белер-белмәс килеш, аларның янына кушылдым. Уйнаучылар шунда ук җанланып киттеләр:

— О-о, рус! Москва. Фиат.

Шатланышып кабалана башладылар. Без бергә утырдык. Карта шунда ук онытылды. Танышларымның икесе азрак немецчә беләләр икән. Сыра алып килделәр, һәм безнең гәп шунда ук куерып китте. Нәрсә турында сөйләштекме! Тормыш турында. Яхшы күңелле, гади кешеләр булып чыктылар алар. Берсе минем «Кассиано» пансионында туктаганлыгымны белгәч:

— Мин иртәләрен катерда азык-төлек таратып йөрим, «Кассиано» яныннан да үтәм, иртәгә сигнал биреп китәрмен, яме! — диде.

Аннары сүз гадәттә гади кешеләр очрашканда сөйләнә торган нәрсәләр турында барды: сездә бу ничек, теге ничек! Эшче кеше күпме ала! Эш табу ягы ничегрәк! Ә пенсия! Квартир хакы! Дәвалану күпмегә төшә! Шулай укмы! Ышанасы да килми...

Чәчләренә көмеш йөгергән өлкән яшьтәге бер кеше (исеме Марио), кулындагы карталары белән уйный-уйный, болайрак диде:

— Венеция — бик әйбәт шәһәр ул. Хәтта кирәгеннән артык матур. Бәлки шуңадыр, монда гади кешегә яшәве кыен. Эш табар хәл юк. Күп кешеләр шуңа күрә бүтән шәһәрләргә күченеп китәләр, чит илләргә дә китәләр. Ләкин монда туган туфрак кала бит. Бар кеше китә дә алмый. Ә калып нишли! Менә ул,— дип Марио кире әйләнеп килергә дә өлгергән Антониога (алар танышлар булып чыкты) ымлады.— лицей бетергән кеше. Ә шөгыле нинди! Гондола! Аның гондоласының нинди икәнен күргәнсездер инде. Ул ялт итеп торсын өчен, аны бай клиентлар да утырырлык итәр өчен акча кирәк. Туристларга хезмәт күрсәтү хокукын алыр өчен дә шактый акча түләмичә булмый. (Ул бармакларын акча санагандагыдай итеп селкетеп куйды.) Ә аның семьясы бар. Әтисе менә өч ел инде урын өстеннән тора алмый ята.

Карт Антониодан тагын нәрсә турындадыр сорады. Тегесе күңелсез генә җавап кайтарды. Карт башын чайкап куйды.

Аннары без тагын сыра эчтек. Әле ярый, безнең ике ил арасында мөнәсәбәтләр ярыйсы, дөньялар имин, дип сөйләштек.

— Фиат — карашо!

Ә янәбызда гына автомат музыка һаман уйнавын белде. Якында гына утыручы теге өч егет калын стаканнарыннан сүзсез генә сыра чөмерүләрен дәвам иттеләр.

Марио карт аларга карап мәгънәле генә көлемсерәп куйды:

— Туристлар. Күңел ачалар.

— Сезнекеләрме! — дип сорадым мин.

— Безнекеләр,— диде карт,— байбәтчәләр күңел ача...

— Шул да булдымы күңел ачу! Бер сүзсез утыралар бит...

— Бүтәнчә булдыра алмыйлар. Алар кирәгеннән артык тук,— диде Марио.

Саубуллашканда без бокалларны чәкештердек, бер-беребезгә «чин-чин» диештек һәм күптәнге дусларча аерылыштык. Бигрәк тә Антонионың китәсе килмәде. Дулкынлануданмы, әллә эчелгән сыраданмы, аның бите кызарды, телләре ачылып китте. Ул миннән шуны төпченде: минем кебек лицей бетерүчеләр сездә ничек бернинди кыенлыксыз эш таба алалар! Хуҗалар булмагач, аларга эшне кем бирә соң!

Ул коммунистик яшьләр союзына керергә нияткәвен әйтте, шул хакта минем киңәш-фикеремне сорады. Ләкин мин җавап бирергә өлгермәдем. Миннән элек үз сүзен Марио әйтте:

— Мин керергә киңәш бирәм, Антонио.

Һәм карт авыр кулын егетнең җилкәсенә салды.

Аның күршесе, катер белән азык-төлек ташучысы, миңа горурлык белән аңлатып бирде:

— Марио — Италия коммунистлар партиясе члены.

Алар безне гондолага тикле озата килделәр. Без гондолага утырдык, ә алар безнең арттан русчалатып:

— Дозвиданя!

— Москва! Фиат! — дип кычкырып калдылар.

Без тын калган буш урамнар буйлап йөзеп кайттык. Төн уртасы күптән җиткән иде инде. Шулай да барларның уты һаман яна. Канал ярларында бик күп мәчеләр йөри. Анда-санда үтеп баручыларның аяк тавышлары ишетелеп китә. Ә без һаман йөзәбез. Болай гына. Бернинди максатсыз. Мин, үземне төшемдә кебек хис итеп, тын гына утырам. Венециядә икәнемә ышанасы килми. Авыр дулкыннар төн караңгылыгында аксылланып күренгән биналарның нигезләрен ялый. Миңа ул ак таш биналар диңгез упкыны эченнән әле яңа гына калкып чыкканнар төсле тоела. Антонио эченнән генә нидер җырлый, аннары миңа өйләрне, күперләрне күрсәтергә, итальянча нидер аңлатырга тотына. Ләкин мин берни дә аңламыйм. Хәер, бу безнең өчен әллә ни мөһим дә түгел. Иң мөһиме шул: менә без Венециянең каналлары буйлап йөзеп барабыз, безнең өстә Италиянең йолдызлы күге, ә мин шуларның барысын да үз күзем белән күрә, биналарның салкын таш стеналарын үз кулларым белән капшый, каналлардагы суны уч тутырып ала алам...

Без Риальто күпере янында тукталдык. Гондоланы бәйләп куйдык. Менә хәзер аерылышабыз. Әкияттәгедәй бу шәһәрне мин озак-озак еллар, бәлки бөтен гомерем буе истә тотармын. Өстенә озын свитер кигән, муенына медальон таккан бу мөлаем егетне дә онытып булмас. Чөнки аның аркасында мин Венеция турында башка берничек тә белеп булмаганнарны белдем. Аның аркасында чын венециялеләр белән таныштым...

Венециядә төн сөйләп-тасвирлап бетергесез матур. Каналлардагы суның серле чупылдавы да. Ярык сыман гына булып калган тар урамнардагы ялгыз аяк тавышлары да. Баш өстендәге йолдызлы аяз күк тә...

## Яңгырлы Флоренция

Без көнозын шәһәрдә йөреп бик нык арган идек. Кичке ашны ашау белән бүлмәләрсбезгә таралыштык. Тик иң чыдам булганнарыбыз гына кунак бүлмәсендә телевизор карарга калды. Карауның максаты: бүген күрсәтеләчәк Америка фильмында ике сәгать эчендә ничә геройны үтерерләр икән — шуны белү. Бүген кич әле студентлар белән очрашу да булырга тиеш иде. Ләкин ул булмый калды, шуңа күрә кичне үзебез теләгәнчә генә үткәрергә булдык. Ләкин шулай дип кенә торганда, тәрҗемәче кыз килеп керде һәм гидыбыз Лоренцоның бүген үк хосусый бер йортта безнең өчен очрашу оештырырга алынуын хәбәр итте. Бернинди программасыз гына очрашу. Яшьләрнең төрлесе җыелачак икән. Студентлар да булачак. Барыбыз да җанланып киттек һәм киемнәрне алыштырырга йөгердек. Телевизор караучылар иллегә якын үтерелгән кешене санап өлгергәннәр иде инде, фильм әле бетәргә дә уйламаганга, алар да безгә кушылырга булдылар...

Без ак таштан салынган биек кенә йортның ишеген какканда, вакыт шактый соң иде инде. Ишек үзеннән-үзе ачылып китте һәм без дүртенче катка күтәрелдек. Зур гына ике бүлмәле квартирның хуҗалары — шактый өлкән яшьтәге ирле-хатынлы архитекторлар безне бик ягымлы каршыладылар, ә бераздан гид Лоренцо белән үзләренең студентка кызлары карамагына калдырып, каядыр китеп бардылар. Лоренцо җимеш суы һәм шәраб тутырылган кувшиннар һәм шешәләр белән тулы өстәл тирәсендә кайнашкан, ә кыз үзенең традицион студент эшләпәсен күрсәткән арада без бүлмәдәге бүтән кешеләр белән дә танышырга өлгердек. Анда ирле-хатынлы ике яшь студент, күптән түгел лицей тәмамлаган һәм хәзер үзенең киләчәк язмышын хәл итеп йөрүче бер егет бар иде. Бераз соңрак тагын ике кыз, яшь хатынын ияртеп, киң җилкәле бер ир кеше килделәр. Соңгылары икесе дә адвокатлар һәм кыяфәтләренә караганда шактый ук хәлле кешеләр иде.

Болардан тыш, тагын өстенә бик тә килешле костюм кигән Альберто исемле ыспай гына бер егет һәм сары чәчле, озын аяклы чандыр гына бер кыз бар иде. Кыз танышканда ук үзенең итальянка түгел икәнен, Австралиядән килгән булуын һәм хәзер эш эзләвен әйтте. Үзе стенографистка икән. Кеше белән аралашучан, шат күңелле бу кыз безнекеләр белән бик тиз дуслашып китте. Альберто минем соравыма каршы үзенең коммерсант икәнен әйтте һәм, бераз сүзсез торганнан соң, басым ясап өстәп куйды:

— Билгеле, мин коммунист түгел.

— Бу очракта моның бернинди әһәмияте юк,— дидем мин.— Өстәвенә, монда сезгә беркем дә үз карашын тагарга җыенмый...

Альберто бик чиста итеп кырынган, чәчен пөхтәләп тараган. Бөтен килеш-кыяфәте аның нечкә зәвыклы купшы булуын гына түгел, аерата көяз, үз-үзеннән үтә канәгать бер кеше икәнлеген дә күрсәтеп тора иде. Ләкин бу мәгънәсез, тупас канәгатьлек түгел. Альбертоның маңгае киң, күзләре зирәк, акыллы. Аның белән без ничектер өзек-өзек сөйләштек. Я аңа, я миңа әле биеп алыр өчен, әле кока-кола эчәр өчен китеп торгаларга туры килде. Сөйләшүебез тәрҗемәче аркылы (лицей тәмамлаган егет бераз русча белә булып чыкты) барды.

Сүз традицион сораулардан башланды:

— Сиңа Флоренция ошыймы!

Мин баш бармакны тырпайтып күрсәттем һәм бу ишарәнең мәгънәсен үзем булдыра алганча аңлатырга тырыштым. Соңыннан ул да бу ишарәне еш кулланды.

Аннары ул миңа Италиядәге «экономик могҗиза» турында сөйләргә тотынды. Бик озак сөйләде. Ләкин мин ул әйткәннәрнең яртысын да аңламадым. Ахырдан ул:

— Менә сез, коммунистлар, социалистик системаның капиталистик системадан өстен булуы турында күп сөйлисез. Алайса нигә соң әлеге могҗиза коммунистик Россиядә түгел, бездә, Италиядә булды! — дип сорап куйды.

Мин үз нәүбәтемдә:

— Тукта әле, нинди могҗиза! — дидем.

— Менә без, мәсәлән, бик әйбәт машиналар эшләп чыгарабыз. Безнең югары сыйфатлы товарларны бөтен дөнья сатып ала...

— Шулай да булсын ди. Сезнең машиналар чыннан да әйбәт. һәм сез аларны бездәгедән күбрәк чыгарасыз. Ә менә эшчеләрнең тормыш дәрәҗәсенә килсәк, хәл ничегрәк соң сездә!

Альберто кулын кулга сугып куйды:

— Я хода, сез итальянның йөзенә генә карагыз: анда мәңгелек елмаю күрерсез.

— Син гафу ит, алайса нигә соң сезнең эшчеләр забастовка күтәрәләр!

Шул чак безнең янга озын буйлы адвокат килде. Без кемнең кайда күбрәк акча эшләвен ачыкларга тотындык. Альберто китерелгән дәлилләр белән теләр-теләмәс кенә килешеп торды да:

— Шулай да Италиядә «экономик могҗиза» дигән нәрсә бар. Моны бөтен дөнья белә,— дип куйды.

— Без хәерче Россияне дөньяда беренче державага әйләндердек — бу могҗиза түгелмени!

Альберто баш бармагын күрсәтте:

— Россия карашо!

Һәм шунда ук тагын төрттереп куйды:

— Алайса нигә сезнең автомобиль заводын безнең «Фиат» төзи!

— Сез дә бит, ходайга шөкер, бездән бик күп нәрсә сатып аласыз. Ике ил арасындагы мөнәсәбәтне шуннан башка күз алдына да китереп булмый.

Адвокат кулы белән бокс ярышындагы төсле хәрәкәт ясады һәм Альбертога карап: «Брэк!» дип куйды. Без дуртәүләп сыра эчтек. Әңгәмә бүтән темага күчте. Кеше бер икмәк белән генә тук була алмый, диештек. Сүз китаплар, фильмнар турында китте. «Китаплар! — диде Альберто.— Алары шул ягы белән ярыйсы: укып чыкпыйны — котылдың, хәтердә тотасы юк». «Америка фильмнары — вестерннар да шулай»,— дип өстәде адвокат.

Мин безнең илдә ничаклы кызыклы, талантлы язучылар булуын, файдалы китаплар чыгарылуын сөйләп киттем. Ә алар җавапка һаман бер нәрсәне кабатладылар:

«Нигә алар белән баш ватарга! Эштә баш вату да бик җиткән». Ә мин һаман бирешмим: «Я, ярый, эш эш инде ул, ә эштән соң!» Җавап тагын әзер: «Барлар, кызлар, кино...» Мин: «Яисә берәрсенә кунакка»,— дип тә өстәгән идем, тәрҗемәче аңлатып бирде: «Бездә кунакка бик сирәк йөриләр. Без гадәттә барларда, тратторияләрдә очрашабыз».

— Анда нәрсә турында сөйләшәсез соң сез! — дип сорадым мин.

— Спорт турында, эш турында...

— Ә политика турында!

— Юк. Бу политиклар эше.

— Тагын!

Алар үзара итальянча нидер сөйләшеп алдылар, һәм Альберто:

— Кыскасы, утырабыз...— дип куйды.

Һәм минем исемә Венеция, анда үткәргән төн, бер сүзсез сыра чөмерүче өч егет килеп төште. Марио карт алар турында әйткән иде бит: «Алар шулай күңел ачалар. Бүтәнчә булдыра алмыйлар. Кирәгеннән артык түк алар...»

Начар егет тә түгел кебек бу Альберто, күзләре дә зирәк күренә, ә менә шул күзләрнең иң түрендә салкынлык, битарафлык, дөньядан туйганлык, төшенкелек чагыла...

Безнең очрашу ахырга якынлашып килә иде инде. Барысы белән дә танышып бетердек. Алмашасы значокларны алмаштык. Сорыйсы нәрсәне сораштык. Китәргә вакыт.

Без төн таңга авышкач аерылыштык. Яңа танышларыбыз безне кул болгап озатып калдылар. Бушап, тынып калган урам юешлектән ялтырап тора. Яңгыр ява, шыксыз, җилсез, вак яңгыр...

ВЕНЕЦИЯ — КАЗАН



**Латыйф Хәмиди**

# ШАГЫЙРЬНЕҢ БЕРЕНЧЕ БЮСТЫ

Укучыларыбыз игътибарына тәкъдим ителә торган Муса Җәлил бюстының бу фотокопиясе Казагыстан ССРның халык артисты, композитор Латыйф ага Хәмиди архивында сакланган. Редакциягә аны өлкән журналист Гариф Миңнул тапшырды. Шагыйрь бюстының кыскача тарихын аңлатып бирүне үтенеп, редакция Латыйф агага мөрәҗәгать иткән иде. Түбәндә без аның җавабын урнаштырабыз.

РЕДАКЦИЯ

Атаклы шагыйребезнең бу беренче бюсты Гимад ага Тимербулатов тарафыннан эшләнгән. Укучыларның, ә Гимад Тимербулатов үзе кем соң, дип сораячакларын алдан ук сизеп торам һәм иң элек шул хакта беркадәр аңлатма биреп китмәкче булам.

Гимад Тимербулатов — минем бала чактагы укытучым. Совет властеның беренче елларында, Мәскәүдән Үзбәкстанның Каттә Курган шәһәренә килеп, берничә ел мәктәп мөдире һәм укытучы, аннары шәһәр мәгариф бүлеге мөдире булып эшләде. Шәһәр байларының зур-зур йортларын конфискацияләп, аларны мәктәп биналарына әйләндерү эшендә башлап йөрде. Каттә Курганда музыка мәктәбе ачу да аның инициативасы белән гамәлгә ашырылды. Шул музыка мәктәбенә укырга керүем өчен дә мин үземне Гимад агага бурычлы дип саныйм: ул мәктәпкә мине Гимад ага үзе урнаштырды.

Ул елларда Үзбәкстан якларында бизгәк авыруы бик нык таралган иде. Гимад ага да, шул авырудан җәфа чигеп, ике-өч ай больницада ятып чыкты. Ләкин авыруы тагын кабатланды. Шуннан соң, врачларның киңәше буенча, ул Урта Азиядән китәргә мәҗбүр булды. Әмма укытучым Мәскәүгә кайтып тора башлагач та минем белән элемтәсен өзмәде. Музыка мәктәбендә ничек укуым белән кызыксынып, хатлар аша сорашып торды. 1927 елда мин Мәскәүнең музыка техникумына укырга килдем һәм, укуга урнашканчы, Әсәдуллаев йорты дип аталган йортта, Гимад ага квартирасында яшәп тордым. Әнә шул көннәрдә Муса Җәлил дә әлеге Әсәдуллаев йортында яшәүче Дәүләтшиннәргә фатирга төште. Муса белән мин электән үк таныш идем. 1925 елларда ул Казан рабфагында, ә мин педагогия техникумында һәм музыка техникумында укыганда ук танышкан идек. Шунлыктан без, иске дуслар буларак, бик җылы итеп

күрештек. Аннары, бер җае туры килгәндә, Мусаны үземнең элекке укытучым Гимад ага Тимербулатов белән дә таныштырдым. Шуннан ары без Гимад агаларга кереп, үзара сөйләшеп тә утыргаладык. Менә шул көннәрдә Муса белән Гимад ага арасында башланган танышлык соңыннан аларны тагын да ныграк якынаюга китерә. Анысы менә болайрак була.

Утызынчы елларның ахырында Гимад аганың сәламәтлегенә сизелерлек дәрәҗәдә кимегәч, ул укытучылык эшеннән китеп, склероз белән авыручыларны дәвалый торган больницага керергә мәҗбүр була. Ләкин анда да тыныч кына ятмый. Больница карамагындагы һөнәр остаханәсенең скульптура бүлегендә укый-өйрәнә башлый. Шунда биш ел укыганнан ары аңа скульптор таныклыгы бирелеп чыгаралар. Һәм ул төрле оешмаларга скульптуралар эшләп көн күрә башлый. Аннары, үзенә кияү тиешле казакъ язучысы Габит Мөсрипов ярдәме белән, Мәскәү тирәсендә дача салдыра. Аларның дача тирәсендә генә Муса Җәлилнең иптәше Әминә ханымның туганнары дачасы да булып, дача сезоны башлангач, Муса да шунда килеп йөри. Менә шунда Гимад ага Муса Җәлил белән яңадан очрашып, аралашып китә. Бервакыт, Гимад аганың дачасына килеп, аның остаханәсенә кергәч, Муса Җәлил андагы скульптураларны бик кызыксынып карый. Шунда Гимад ага Мусаның скульптурасын эшләргә теләвен әйтә. Муса позировать итәргә риза була. Ләкин бер шарт куя: сез эшләгәндә тыныч кына утыра алмам, я китап укып, яки язып утырырмын, ди. Шулай килешәләр һәм Муса берничә көн килеп, позировать итеп утырганнан соң шагыйрьнең бюсты әзер була. Муса да бу бюстны ошата һәм Гимад агадан үзенә дә шушындый бер бюст эшләп бирүне үтенә. Ләкин шуннан соң озак та үтми, Муса Казанга кайтып китә. Аннары сугыш башлана. Муса фронтка китеп баргач, Гимад ага теге скульптураны шагыйрьнең иптәше Әминә ханымга бүләк итеп бирә. Ул бюст Әминә ханымда сакланганмы, юкмы, анысын әйтә алмыйм. Авторы алай атаклы художник булмагач, ул скульптурага әллә ни зур әһәмият бирелмичә калып, аның инде югалган булуы да бик мөмкин. Ә менә ул бюстның фотокопиясе калган. Гимад ага аны өч ягыннан фоторәсемгә төшереп алып калган булган. Журнал укучыларына тәкъдим ителә торган бу рәсем әнә шул фотоларның берсе инде. Моннан ун ел элек Гимад ага Тимербулатов вафат булгач, аның хатыны Шәмсинур ханымның тәкъдиме буенча, ул рәсемнәр миңа тапшырылган иде. Хәзер алар барысы да миндә саклана. Муса Җәлилнең беренче бюстының тарихы кыскача менә шул.

Җае чыгудан файдаланып, бюстның үзе турында да берничә сүз әйтеп китәсем килә. Муса исән чагында Гимад агадан башка бер художник та аның портретын яки скульптурасын натурадан ясавын мин хәтерләмим. Ә ул вафат булганнан соң аның скульптураларын байтак художниклар эшләде инде. Шулар арасында Бакн ага Урманче, В. Е. Цигаль иҗат иткән скульптуралар аеруча уңышлы чыкты һәм алар җәмәгатьчелек тарафыннан югары бәя алдылар. Мусаның скульптураларын художниклар хәзер дә эшли һәм киләчәктә дә эшләрләр. Ул скульптураларның тагын да әйбәтрәкләрен иҗат итүләре дә бик мөмкин. Ләкин, шул ук вакытта, ничек кенә оста эшләнсәләр дә, Мусаның үзенә карап түгел, бәлки рәсеменә карап кына ясалганлыктан, алар барыбер кай яклары беләндер Мусаның үзенә бик үк охшаган булмас. Менә шуңа күрә дә мин Гимад ага Тимербулатовның Муса Җәлил исән чагында аның йөзенә карап эшләп калдырган бу скульптурасына зур әһәмият биреп, аның хакында «Казан утлары» укучыларына хәбәр итүне кирәк дип санадым.

**Барлас Камалов**

# ДРАМАТУРГИЯБЕЗ ГОРУРЛЫГЫ

*Мирхәйдәр Фәйзинең тууына 80 ел*

**Атаклы драматург, бик күп шигырьләр, хикәяләр авторы һәм тәрҗемәче Мирхәйдәр Фәйзи үзенең бер шигырендә халык шагыйре Габдулла Тукайга:**

Син бер гөлме? Милләт бакчасының
Гөлләренә баскан былбылмы? —

дип мөрәҗәгать итә. Әгәр әдәбият һәм сәнгать дөньясын гөлбакчага охшату мөмкин икән, Мирхәйдәр Фәйзинең үз иҗатын ерактан ук күренеп, бүтәннәрдән нык аерылып торган матур чәчкәгә тиңләп була.

Мирхәйдәр Фәйзи — 1905—1907 елгы беренче рус революциясе ташкыны белән әдәбият мәйданына килгән язучыларыбызның берсе. Аның тормыш һәм иҗат юлы — катлаулы эзләнүләр белән тулы, вак буржуаз тирәлектән чыккан интеллигентның күренекле совет язучысы булып җитешү тарихы ул. Егерме еллык иҗат эшчәнлеге дәверендә Мирхәйдәр Фәйзи уналты пьеса, йөзләгән шигырь һәм җыр тексты, дистәгә якын хикәя язарга, күп кенә сәхнә әсәрләре тәрҗемә итәргә өлгерә.

Мирхәйдәр Фәйзи, барыннан да элек, драматург. Аның «Яшьләр алдатмыйлар», «Кызганыч», «Галиябану», «Асыльяр», «Кызыл йолдыз», «Ак калфак» шикелле драма әсәрләрен укучы-тамашачылар бик яхшы белә. Бу олы әдипнең ике томлык сайланма әсәрләре басылып чыккач, әдәбият сөючеләр аның «Авыл бәйрәме», «Урал суы буенда», «Тәкъдирнең шаяруы», «Адашкан күңел», «Ярты алма», «Кәкре каен», «Коммунага!» дигән драма һәм комедияләре, агитацион пьесалары белән дә якыннан таныштылар.

Татар драматургиясендә беренчеләрдән буларак, М. Фәйзи үз иҗатының таүге чорында ук муллаларны, карун байларны, сәүдәгәрләрне сурәтләү белән генә чикләнми, ул гади авыл халкы вәкилләрен, гадел хезмәт белән көн күрүчеләрне сәхнәгә менгерә. Аның иҗатының бу кыйммәтле сыйфатын 1922 елда «Галиябану» драмасының беренче басмасына язган керешендә Галимҗан Ибраһимов басым ясап билгеләп үтә: «Фәйзи иптәшнең «Галиябану»ы, әйтергә мөмкин, театр әдәбияты эчендә бу юлдагы беренче тәҗрибәләрдәндер. Беренче мәртәбә диярлек һичбер буяусыз, саф булганча, үзләренең уен, көйләре, җырлары, музыкалары, гыйшыклары, интригалары, бәетләре, көрәшләре белән крестьян егетләре, крестьян кызлары бу әсәр аркылы безнең театр галәменә килеп керәләр».

Әмма мәшһүр «Галиябану» драмасын иҗат иткәнгә кадәр, гүя аны язу өчен хәстәрлек йөзеннән, драматург бүген дә игътибарга лаеклы берничә әсәр яза, халык җырлары туплап, аларны өйрәнеп һәм үзенчә классификацияләп, кульязма җыентыклар төзи. Халык авыз иҗатын җентекләп өйрәнү һәм бәяләргә омтылуда ул Габдулла Тукай эшен дәвам иттерә.

«Галиябану» драмасы исә М. Фәйзи иҗатындагы иң күркәм әсәр. Алай гына да түгел, XX йөз башы татар әдәбиятында да ул гаять күренекле урын тота. Татар совет язучылары, бу драма үрнәге белән илһамланып, бик күп музыкаль драма һәм комедияләр иҗат итәләр. «Галиябану» драмасы илле биш ел буена сәхнәдән төшми уйнала, профессиональ сәхнәләрдә дә, үзешчән коллективлар башкаруында да уңыш казанып килә.

Билгеле булганча, бу драмада төп проблема — дошман сыйныфлар яшәгән җәмгыятьтәге мәхәббәт трагедиясе. Автор шуны XX йөзнең унынчы елларындагы сыйнфый мөнәсәбәтләр аша чагылдыра. Галиябану образы, конкрет персонаж булуы белән бергә, авторның идеалын да гәүдәләндерә. Чөнки аңарда хезмәт иясенә хас иң гүзәл сыйфатлар тупланган. Шулай да автор Галиябануны чынбарлык җирлегеннән аерып алып, гадәттән тыш шәхес итеп сурәтләми, шуңа күрә дә без аны ул замандагы татар кызларына хас чикләнгәнлекләре белән дә күрәбез. Галиябану язмышында татар кызының азатлыкка талпынуы, кара көчләр боҗрасында интегүе чагыла. Аның драма азагындагы нәфрәт тулы сүзләре ерткыч Исмәгыйльләр дөньясына ләгънәт булып яңгырый. Шул рәвешле, дөнья әдәбиятында шәхес азатлыгын, мәхәббәт иреклеген яклап иҗат ителгән классик әсәрләр һәм легендалар («Ромео һәм Джульетта», «Таһир һәм Зөһрә», «Фәрһад һәм Ширин», «Козы Көрпеш һәм Баянсылу» һ. б.) традицияләрен дәвам итеп, Мирхәйдәр Фәйзи Галиябану һәм Хәлил кебек онытылмас образлар иҗат итә.

Бөек Октябрь социалистик революциясе җиңгән көннәрдә Мирхәйдәр Фәйзи Орск шәһәрендә була. Дөньяны таң калдырган бу үзгәреш аның күңеленә чын-чынлап канат куя. М. Фәйзи культура-агарту фронтында дәртләнеп эшли, күп яза.

1920 елның октябрендә драматург «Фәрештә» («Асылъяр») пьесасының беренче вариантын язып тәмамлый. 1922—1923 елларда ул «Ак калфак» һәм «Адашкан күңел» драмаларын иҗат итә, аларны кат-кат төзәтә. «Адашкан күңел»дә Максим Горький әсәрләренең йогынтысы сизелә. Бу әсәрендә М. Фәйзи үз иҗаты өчен яңа тема күтәрә, эшчеләрнең беренче империалистик сугыш елларындагы тормышын күрсәтә. Пьесада драматургның буржуаз чынбарлыкка, капитализм чорында хакимлек иткән тәртипләргә тирән нәфрәте аерата калку һәм конкрет чагыла. Дөрес, монда әле эшчеләр пролетариатка хас сугышчан сыйфатлар белән бирелмәгәннәр. Аларның яңа җәмгыятьне иҗат итәргә омтылуы һәм ашкынуы, моңа сәләтле икәннәрен тирәнтен аңлаулары тулы күрсәтелмәгән. Әмма эшче егетләр күңелендә капиталистик дөньяга карата көчле нәфрәт туганлыгы бәхәссез. Әсәрдәге шахтер Мотыйның: «...җирне чукыйсың, чукыйсың, күкрәк көчләре белән казып, патша сарайлары салырлык алтын табасың. Карасаң, кесәңдә бакырлар гына ята» дигән нәтиҗәгә килүе дә, шахта эшчесе Вафаның: «...ул байлар бер көн харам малларын сыйдыра алмый шартлар әле» дип, киләчәккә өмет белән яшәве дә очраклы түгел. Мирхәйдәр Фәйзи 1923 елның апрелендә үз иҗатында гына түгел, бәлки бөтен татар совет драматургиясендә күренекле урын алып торган «Кызыл йолдыз» пьесасын язып бетерә. Бу әсәрдә автор социалистик революциядән соң уянып, сыйнфый аңы үсә барган хезмәт ияләренең активлыгын, Советлар республикасына каршы күтәрелгән ак бандитлар белән көрәшен тулы канлы образларда гәүдәләндерә, азат илдәге ирекле мәхәббәтнең тантанасын сурәтли.

«Кызыл йолдыз»ның төп персонажларыннан Сөнгат белән Маһруйның, Гатау белән Гөлйөземнең язмышы Хәлил белән Галиябану хәленнән тамырдан аерыла. «Кызыл йолдыз»дагы яшьләр — совет чоры кешеләре. Алар, революцион халык власте ярдәменә таянып, кулакларны авызлыклыйлар, күмәк көч белән ак бандитларны җиңәләр, мәхәббәтләре юлындагы киртәләрне себереп түгәләр.

Комсомолның Башкортстан өлкә комитеты соравы буенча, 1923 елның маенда М. Фәйзи «Кәкре каен» исемле бер пәрдәлек пьеса яза. Бу әсәр «Яшь юксыл» газетасының дини бәйрәмнәрнең зарарын фаш итүгә багышлап чыгарылган санында

басыла. Әдипнең дөньяга карашы формалашуының эволюциясен исбатлау ягыннан бу әсәрнең зур әһәмияте бар. Пьесаның язылышына, бер яктан, Гафур Коләхметов әсәре — «Ике фикер»нең тәэсире бәхәссез. Икенчедән, М. Фәйзинең бу пьесасы тууга халык авыз иҗатындагы образлар да көч-куәт өстәгән. «Кәкре каен»нан соң да М. Фәйзи агитацион пьесалар язуын дәвам итә. Шундыйлардан «Китап» [1924] һәм «Ленинизм байрагы» [1925] инсценировкаларын атарга мөмкин. Алар басылмыйча калганнар, ләкин драматург үзе исән чакта үзешчән түгәрәкләрнең, агитбригадаларның концерт репертуарларында ныклы урын алып, кат-кат башкарылганнар. Мондый характердагы әсәрләр М. Фәйзинең публицистика өлкәсендә дә ялкынланып эшләвен исбатлыйлар, алар политик үткенлекләре, заманның актуаль темаларына иҗат ителүләре, марксизм-ленинизм идеяләрен актив пропагандалаулары белән әһәмиятлеләр.

Мирхәйдәр Фәйзинең иҗат хәзинәсе халкыбызның күңелендә озак сакланачак. Моның сәбәбе, беренчедән, драматургның табигый талантында, иҗатының көчле лирика, якты моң белән сугарылуында булса, икенчедән, әдипнең халык белән тыгыз элемтәсендә, татар халкының гасырлар буена тупланган авыз иҗатын тырышып өйрәнүендә, аларны үз әсәрләрендә искиткеч осталык белән файдалана белүендә. Персонажларның сөйләме — сәхнә әсәре өчен иң мөһиме. Аларны индивидуальләштерүдә М. Фәйзи һәрчак халык теленнән файдалана. Әсәрләренең афоризмнарга бай булуы, аларга салынган тирән фикерне кирәгенчә тотып ала һәм әсәр тукымасына кирәгенчә кертеп җибәрә белүе белән аңлатыла. Халык иҗаты образлары М. Фәйзи драмаларына состав өлеше буларак береге китә. Әйтик, сәлам-хат — татар халык авыз иҗатындагы иң актив образларның берсе. Мирхәйдәр Фәйзи аны берничә әсәрендә файдалана. Мәсәлән, «Яшьләр алдатмыйлар» комедиясендә Мәгъфүрәнең Шакирга язган хаты хәзрәтнең мәкерле ниятен өзүгә юл ача; «Кызганыч» һәм «Асылъяр» пьесаларындагы хатлар тискәре персонажларның хәйләләрен фаш итүче корал итеп күрсәтелгәннәр. Кульяулык һәм шәльяулык халык җырларына гади бизәк булып кына түгел, еш кына очракларда тирән символик мәгънәгә ия буларак та кергән. М. Фәйзи дә үз әсәрләрендә бу образларны актив куллана. Галиябануның чиккән кульяулыгын, аңа карап Бәдри һәм Галимәбануның куанычлары ташуын һәм, ниһаять, бу бүләкнең Хәлилгә ирешүен төшенеп кулак Исмәгыйльнең шашынуын хәтерлик. Бу очракта чиккән яулык М. Ю. Лермонтовның «Маскарад»ындагы Нинаның беләзеге, В. Шекспирның «Отелло»сындагы Дездемонаның яулыгы шикелле үк әһәмияткә ия. «Кызыл йолдыз» пьесасында кызыл яулык егет белән кызның бергә булырга вәгъдә бирешү билгесе генә түгел, бәлки яшьләрнең «кызыл йолдыз» белән дә берләшүенең билгесе. Яулык, Хәй сүзләре белән әйткәндә, «безнең күңелләребезне җыйган әләм булып җилфердәр», авыл яшьләре бу яулык белән барып, бандитларны себереп түгәләр, авыл Советын кулаклардан тазарталар, бу яулык белән барып, кызыл йолдызларын табалар. Кыскасы, традицион яулык образы азатлык әләме дәрәҗәсенә күтәрелә, революцион колач, сугышчан эчтәлек ала.

Халыкта әүвәл-әүвәлдән яшәп килгән күркәм бәйрәм — туй да М. Фәйзи иҗатында яңа эчтәлек белән баетыла. «Кызыл йолдыз»да яшьләрнең кызыл туе гаять оста тасвирланган, аны хәтта бүгенге яшьләребезгә үрнәк итеп күрсәтәсе килә.

Сәхнә әсәрләре язуның зур остасы, социалистик культураны үстерүдә көчен аямыйча эшләгән олы энтузиаст Мирхәйдәр Фәйзи яңа бер рухлану белән югары күтәрелгәндә, иҗаты яңа темалар һәм образлар белән баеый барган чорда үлде. Ул татар драматургиясенә үзенчәлекле яңалык алып килде, музыкаль драма жанрында новатор булды, үлемсез традицияләр калдырды. Аннан соң әдәбият мәйданына чыккан драматурглар, элекке мирасны иҗади өйрәнгәндә һәм үстергәндә, М. Фәйзи драматургиясен читләтеп үтмиләр, ул тудырган һәм нигезләп калдырган гүзәл башлангычларны дәвам итәләр.

Художникның көче һәм таланты иҗади кыюлык белән аерылмаслык бәйләнгән. М. Фәйзи гадәткә кереп киткән кануннар белән генә канәгатьләнмәде, аларны узып, кыю рәвештә яңалыкка омтылды. Шунлыктан, аның әсәрләре сәхнәдән төшми үйнала, яратып укыла. Бу — язучының үлемсезлеге.

## Гази Кашшаф

# ФӘХРИ ӘСГАТ

*(1901—1926)*

Татар совет әдәбиятын тудыру, үстерү эшенә күп яшь талантлар катнашкан. Фәхри Әсгат — шундыйларның берсе.

Әсгат Йосыф улы Фәхретдинов 1901 елның 13 октябрендә Татарстан АССРның Куйбышев районы Алпар авылында туа. Башлангыч белемне авыл мәктәбендә ала. 1913 елда, Казанга килеп, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый башлый. Революциядән соң Чистай педагогия техникумында һәм авыл хуҗалыгы техникумында укый. 1922 елда яңадан Казанга кайта, Казан авыл хуҗалыгы институтына укырга керә. Ләкин өченче курсны тәмамлаганнан соң, авыру сәбәпле, укуын ташларга мәҗбүр була.

1919—20 еллардан аның әдәби иҗат эшчәнлеге башлана. Ф. Әсгатнең беренче шигырь һәм нәсерләре «Кызыл яшьләр» газетасында, «Безнең юл» журналында басылып бара.

Ф. Әсгатнең каләменә җиңеллек, тапкырлык, үткенлек хас. Ул үз геройларының эчке дөньяларын тасвирлауга нык игътибар итә. Язучы тышкы бизәкләр, плакатчылык, схематизмны, формализмны кире кага һәм үзе белән бергә әдәбиятка килгән талантлар арасында реалистик принципларны яклаучыларның берсе була. Гражданнар сугышы эпизодлары, сугыштан соңгы чорда авылдагы сыйнфый көрәш һәм советлашу процессы, Кызыл Армиядә политик аң, практик күнегү алып кайткан авыл егетләренең кулак куштаннарга каршы көрәше, НЭП елларына хас күренешләр — болар һәммәсе дә Ф. Әсгатнең үткен каләме белән тотып алынган кечкенә детальләр аша җанланалар.

Язучының кыска-кыска хикәяләре, җылы лирик парчалары авторның якты хисләре, сыйнфый көрәш идеяләре белән сугарылган.

Кайвакыт язучы үзенең күңелендә туган хисләрне җыр кебек кыска итеп һәм дулкынланып сөйләп бирә, син аның яшьлеген, дәртлелеген тоясың. Сүзләрдән чәчәкләр ясыйм, ди ул үзе. Аның 1927 елда үзе үлгәч басылган җыентыгы да бик хаклы рәвештә «Сүзләрдән чәчәкләр» дип атала.

## Абдулла Әхмәт

# ХӨРМӘТЛЕ ЯЗУЧЫБЫЗ

Сүнә яшен әнә яшен дигәнче, үтә гомер менә яшим дигәнче, дип бик дөрес әйтә Идрис ага. Әйе, тормыш, искән җил кебек, үтеп кенә тора. Әле кайчан гына без төз буйлы, кара кые чәчле, үткен карашлы, һәрвакыт башын югары күтәреп, горур атлап йөри торган утыз яшьләр тирәсендәге Идрис Туктар белән Уралда «Социализм юлы» исемле газета чыгарып, ыгы-зыгы килеп йөргән идек. Ул шунда ук чыгып килгән «Шәпи агай» исемле көлке журналында каләм тибрәтергә дә вакыт таба иде. Бу журналның һәр санында диярлек прогулчыларны, исерекләрне,

икейөзлеләрне һәм һәртөрле ташбашларны үзенең үткен, көйдергеч каләме белән көн яктысына чыгарып фаш итә иде. Ул көннәрдән бирле дүрт дистә елдан артык вакыт үтте. Аннан соң инде бик күп сулар акты, бик күп җилләр исте.

Идрис Туктар әле патша Россиясе чорында ук өстенә соры шинель кия. 1920—22 елларда кулына мылтык алып, яшь совет хөкүмәтен саклап калуда катнаша. Колчакка каршы өндәү эшләре алып барганлыгы өчен аклар төрмәсендә утырып чыга. 1941 елда туган илебезгә фашист илбасарлары һөҗүм иткәч, Идрис-солдат тагын шинелен кия, Совет илен саклап калу өчен көрәш мәйданына ташлана. Бу сугышта ул Ленин партиясе сафларына керә. Әнә шулай Идрис Туктар Ватаныбыз дошманнарын илебез туфрагыннан куып чыгаруда ике тапкыр якыннан торып катнаша.

Идрис ага ифрат күркәм табигатьле кеше. Ул һәрвакыт шат, күтәренке күңелле, мөлаем булыр. Зарлануны, чырай сытуны белми. Ачулы яшәгән — тиз картайган, көлеп яшәгән — озак яшәгән, ди халык.

Идрис Ильяс улы Туктаров 1896 елның 20 сентябрендә Башкортстанның Сафар районы Булышлы авылында ярлы крестьян семьясында туа. Ул туып күп тә үтми, әтисе Ильяс агай, туган авылын ташлап, Уралдагы Кучкар алтын прискаларына бәхет эзләп китәргә мәҗбүр була. Унике яшьлек Идрис тә алтын приискасында кара эшче булып эшли. Ләкин кечкенәдән зирәк акыллы, укырга, язарга сәләтле булган Идрис, ачлы-туклы яшәп булса да, белем алырга тырыша. Язучы үз сыйныфының алдынгы кешесе булырга тиешлеген яхшы аңлый. Шуңа күрә, олы булуына карамастан, 1934 елда Казан педагогия институтының тел-әдәбият бүлеген тәмамлый.

Язучының «Партизаннар» исемле беренче әсәре 1929 елда Мәскәүдә басылып чыга. Шуннан бирле ул өзлексез иҗат эше белән шөгыльләнеп килә. Шигырьләр, фельетоннар, хикәяләр яза. Бераздан, шигырь язуны ташлап, прозага гына күчә. Хикәяләр, әкиятләр, повестьлар язуга күңел куя. Аның «Гыйльметдин солдат вакыйгасы», «Хәсән солдатның үлеме», «Бала туды», «Үлем эшелоны» һәм башка хикәя китаплары дөньяга чыга. Аннары Идрис зуррак әсәрләргә тотына. Ләкин шуны әйтеп китәргә кирәк, Туктар әсәрләренең санына кызыкмый. Ул, бер булса да, берәгәйле булсын, дигән карашны күз алдында тотып эш итә.

Ул күп еллар Чиләбе шахтерләры арасында яши, аларның тормышын өйрәнеп, «81 нче штольня» исемле повестен яза. Бу — татар шахтерларының катлаулы тормышын якыннан белеп язылган беренче уңышлы әсәр. Күп еллар утырып ул «Ике егет» исемле зур әсәр, роман иҗат итә.

Әсәрдә төп образлар Шәйхи белән Нәдерша. Бу ике егет (егетләрнең берсе авторның үзе дисәк тә хата әйткән булмабыз) гади шахтер балаларыннан үсеп, шул тормышта чыныгып, революция юлларында утны-суны кичеп, менә дигән алдынгы эшче булып җитешкән кешеләр.

Үзе дә шахтерлар арасында яшәгән һәм эшләгәнгә күрә, автор шахтерлар яшәгән әлекке баракларны да, аларның көнкүреш шартларын да яхшы белә. Менә ул баракны ничек тасвир итә: «Шахтерлар казармасы искереп, чалышаеп беткән. Күпне күргән карт казарма төрле яктан куелган терәүләргә таянган да: «Барыбер, бүген булмаса, иртәгә авам»,— дигән шикелле, боегып утыра. Аның кайчан салынганын олы шахтерлар да хәтерләмиләр. Ул үзе болай, тыштан карaганда, буйга салынган ат абзарына охшый. Ә эченә керсәң, борыла алмаслык, ярым караңгы, кысан мунчаны хәтерләтә. Кая карама — ак, соры, яшел, чуар, чәчәкле-гөлле, ямаулы-ямаусыз чаршаулар эленгән. Төрле төстәге тастымаллар, чүпрәк-чапрак шул чаршауларны сырып, чуклап бетергән. Биредә һәрвакыт бөркү, баш әйләндергеч авыр, тончыктыргыч ис».

Ике егет, нинди генә авырлыклар күрсәләр дә, төшенкелеккә бирелмиләр, алда матур, яңа, «буржуйларсыз» тормыш киләчәгенә нык ышаналар. Менә аларның төрмәдә утыргандагы хыяллары:

«Шәйхи белән Нәдерша, рәшәткә аркылы күренгән диңгез култыгының матурлыгына карап, хыялга чумдылар. Мылтык тотып, кылыч күтәреп, шул диңгез буйларын бер итеп йөрер көннәр килеп җитәр микән!..

— Ирекнең матурлыгын күрдеңме, тар төрмә тагын да тарая. Күзләрне дә йозаклый алсалар, бәлки, җиңелрәк булыр иде.

— Алай димә, Нәдерша дус. Матурлыкны күңел күзе белән күрә белгән кеше, барыбер ирекне сагынмый чыдый алмас».

Язучы «Ике егет» романындагы кире типларны, җәмгыять тәгәрмәченә аяк чалып маташучыларны да үзенә хас телдә, ачы, үткен итеп чыбыркылый. Андый типлардан кансыз, рәхимсез, кешелеген югалткан поручик Габделхак Калкамалов, төрмәдәге революционерларның җанына тигән вәхши Мухаморов, Сәлимгәрәй кебек типлар күңелдә тирән җирәну тойгысы тудыралар. «Ике егет» әсәренең теле Туктарга хас җиңел, образлы, халыкчан. Һәр персонажның үзенә генә хас теле бар. Образларга халыкчанлык, мәкальләр, әйтемнәр белән сөйләшү характерлы. Мәсәлән:

«Шәйхи:

— Апрель микән, март микән, гыйшык микән, дәрт микән!

Нәдерша:

— Гыйшык та бар, дәрт тә бар, кавышырга рәт тә бар...»

Идрис ага балаларга «Нәни хикәяләр», «Җир җиләге», «Кечкенә хикәяләр», «Тамчылар», «Батырлыкта — матурлык», «Авыр аяк» һәм башка бик күп әсәрләр бүләк итте. Нәниләргә адресланган хикәяләрен ул гади, аңлаешлы, йөгерек тел белән яза. Бу хикәяләрне укып, кечкенә иптәшләр дөньяның, табигатьнең ямьле, матур якларын күрәләр. Аның бу әсәрләре дә Туктарга хас ягымлы юмор белән сугарылган. Алар балаларга коммунизм төзүчеләр булып хәзерләнергә ярдәм итәләр. Ул әле дә балалар белән элемтә тота. Зеленодольскида балалар белән очраша, хикәяләрен укый. Аның күп кенә хикәяләре уку китапларында урын алганнар. Авторның иң яхшы хикәяләрен 1970 елда нәшрият «Геройство — это здорово» исеме белән рус теленә тәрҗемә итеп бастырып чыгарды. Бу китап рус балаларына да бик ошады. Алар аны бик яратып кабул иттеләр.

Һәр язучының иҗат хәзинәсендә тәрҗемә әсәрләр дә була. Чөнки тәрҗемә әсәрләр язучының телен баеталар, дөньяга карашын киңәйтәләр, каләмен шомарталар. Идрис Туктар Купринның «Ак Пудель», Ликстановның «Малышок», Волошинның «Кузнецк җире», немец язучысы В. Бредельнең «Сазлык солдатлары» кебек әсәрләрен татар укучыларына тәрҗемә итеп җиткерде.

Идрис ага күп еллардан бирле Зеленодольск эшчеләре арасында яши. Анда күп тиражлы газетада эшләде. Үзенең сөйгән эше — китапханәдә дә эш алып барды. Эшчә яшьләрдән торган әдәбият түгәрәге белән җитәкчелек итте. Хәзер инде ул пенсиядә — ял да итә, яза да...

Әнә шулай, тормышның ачысын-төчесен татыган олы язучы, партия члены, мәгариф эшчесе Идрис ага Туктарга бүген 75 яшь тулды. Нишлисең, тормыш бит ул! Картаясы килмәсә дә, картаясың, битне буразналар баса, кара бөдрә чәчләргә кырау төшә. Ләкин ул әле һаман да күтәренке рухлы хикәяләр, мәзәкләр яза. Без Идрис аганы моннан соң да бүгенге кебек тормыш сөюче, картаймас Туктар итеп күрәсебез килә һәм без аның шулай буласына ышанабыз.

Газиз Мөхәммәтшин

# ҖЫЕЛЫШ



Барыгыз да килеп беттегезме, иптәшләр? — диде управдом.— Җыелышны ачарга мөмкинме?

— Мөмкин. Ярый,— диде халык.

Бу әле биш катлы, йөз квартирлы яңа йортта яшәүчеләрнең беренче җыелышлары иде. Ишекләрдә кичәдән үк белдерү эленеп торганлыктан, көн тәртибен дә беләләр: тавышка каршы көрәш мәсьәләсе.

Управдом тамагын кырып алды. Ләкин шул чагында шыгырдап ишек ачылды һәм берәү керде.

— Гафу итегез! — диде управдом.— Мин әле күбегезнең исем-фамилиясен, төс-кыяфәтен бик үк аера алмыйм. Шуңа күрә үзегезнең кайсы квартирдан икәнегезне әйтеп сөйләшсәгез иде, иптәшләр!

— Мин кырыгынчы фатирда яшим. Соңгарак калырга туры килде, ачуланмагыз инде! — диде яңа кергән ханым.

Управдом тавышның, шау-шуның нерв системасына ясаган кире йогынтысы, аларга каршы көрәш чаралары турында, мисаллар китерә-китерә, кызыклы гына доклад ясады.

Фикер алышуларга күчкәч, сүзне беренче булып уникенче квартирда яшәүче элекке журналист, хәзерге пенсионер Якуб Иделский алды. Ул үзенең чыгышын: «...ләкин бездә, җәмәгать, кызганычка каршы, тавышның ифрат та зарарлы икәнлеген аңлап бетермәүче иптәшләр дә бар әле. Мисал өчен, сиксән беренче квартир малае минем тәрәзә каршымда көне-төне мотоциклын пырылдата. Кырык ел эшләгәннән соң ял итәргә хаклымы мин? Хаклы! Ә ул моны аңларга теләми. Җәмгыятькә зарарлы андый бәндәләрне хурлык белән тамгаларга кирәк!» — дип тәмамлады.

Аңа каршы сиксән беренче кабынып китте:

— Ә сезнең внучкагыз белер-белмәс көенә төне буе пианино лыркылдата. Башны алып олагасы гына калды бу өйдән,— дип кычкырды.

— Әйе! әйе! — дип аның сүзен җөпләде бер әби.— Җик күрдек инде ул пионинnардан! Йөз фатирның йөзесендә дә көн-төн гармун уйныйлар, пионин, барабан кагалар, торба акырталар, скрипкә чыелдаталар, курай, сыбызгы сызгырталар. Күзләр акая, башлар шешә. Заман ахырларында шушындый шау-шу, гарасат кубар дип әйтә торган иде минем мәрхүмә әбием. Заман ахыры шушыдыр инде, килеп житкәндер, билләһи...

Унөченче квартир хуҗасы да әбинең сүзен куәтләде:

— Шулай, әбекәй, хак, дөрес сүз. Радио, телевизорларны әйтмәдең әле син. Алары тагын! Әллә безнең өйгә җыен чукракларны җыеп керткәннәр инде — шул хәтле акыртмасалар!

— Радиоларын тәрәзә төбенә куеп бөтен урамга мәче концерты бирүчеләр дә әз түгел. Әйтергә кирәк! Тыярга, нәкәниц!

— Сүз белән генә тыңлатырсың аларны. Чалбарларын төшереп... эһем... эһем... каеш белән каезларга кирәк ул разбойникларны! Шуннан керсә керер акыл. И-их, тән җәзаларын ник бетердек микән дип кычкырып җылар көннәребез алда әле, париннар!..

Илленче квартир егете бу тәкъдимгә шунда ук каршы төште:

— Каезларга кулыгыз бик кычытып торса, әнә үз малаегызны каезлагыз, абзыкай, яме! Әйтергә кирәк, сезнең үз этегез дә, яландагы шикелле, бертуктаусыз ләң дә ләң, һау да һау өреп ята.

— Минем этемдә дәхелең булмасын! — дип кырт кисте аучы.— Бөтен Казанда атаклы ау эте икәнен беләсеңме син аның, малай?!. Дүрт медале генә бар! Әнә синең әле менә бер медалең дә юктыр!..

— Атаклы этләр сәгатькә карап, вакытын белеп өрә...

Шул чагында бик кызганыч-моңлы гына итеп ниндидер мәче кычкырып куйды. Җыелыштагылар, эт турындагы бәхәсне онытып, алтмыш җиденче квартир хуҗасын оялтырга тотындылар:

— Гөлҗамал, песиең тагын чыгарга сорый...

— Гел кеше әйткәнне көтәсең. Үзең белмисең...

— Песи асрагач, аның артыннан йөрергә дә иренмәскә кирәк...

— Һә-әй, җик күргән инде аннан,— диде Гөлҗамал, үртәлеп.— Бүтән кайгыгыз булмаса, юк өчен баш ватмагыз, пажалыста...

— Гөлҗамал җиңги дөрес әйтә,— диде шунда карлыкканрак тавышлы бер ир.— Эт, песи кайгысы — кайгымыни! Менә минем кайгы — кайгы-ы!

— Сез, иптәш, кайсы квартирдан? — дип сорады управдом.

— Унтугызынчыдан ла.

— Ә сезнең нинди кайгыгыз бар? Нәрсәдән зарланасыз?

— Кемнән зарланасыз дип сорасагыз, дөресрәк булыр иде. Ундүрттә яшәүче кәҗә сакал Гайфидән зарланам,— дип кызып китте карлыккан тавыш.— Мин бишенче катта торам, ә ул дүртенчедә — нәкъ минем аста. Нәкъ мин ваннага керең яттыммы — кайдан сизә торгандыр — Гайфи дә ваннасына керә дә гопыр-гопыр су агыза башлый. Шуннан,

---

***ДУСЛАРЧА ШАЯРУЛАР***



## *Рафаил Төхфәтуллинга*

**«Гомернең кырык сигез минуты»**
**Кырык сигез көн кебек, һай, озын.**
**«Тамчылар ни сөйли?» —**
**Аңламыйм,**
**«Агымсу» ни көйли? —**
**Тыңламыйм...**
**Тик сине сагынам, «Йолдызым».**

үзегез беләсез, миңа кайнар су килүе туктала. Котыртып, тамчы-тамчы тамчылап кына тора. Кәҗә сакалның юынып бетергәнен көтеп сәгатьләр буе салкын суда дерелдәп утырам. Әнә, ишетәсезме: хәзер дә шыбыр-шыбыр кайнар су агыза, мөртәт. Юри мине мыскыл итә. Салкын тисен, үлсен ди торгандыр.

— Син үзең мөртәт токымы! — диде Гайфи, бер дә курыкмыйча.

— Их, кәҗә сакал, кәҗә сакал, гараж салырга кирпечне кайдан алдың син, ә? Беләбе-ез!..

— Ә син?!.

Управдом йодырыгы белән каты гына итеп стенага сугып алды.

— Ярый, иптәшләр, көн тәртибеннән читкә китмәгез. Безнең җыелыш тавыш һәм аның кешеләргә зарары турында бит... Димәк, иптәшләр...

Аннары ул үзенең йомгаклау сүзендә җыелышның бик файдалы булганлыгын әйтте, бик актив төстә үтүенә канәгатьлек белдерде. Үзенең буш һәм бәләкәй булмәсен күзеннән кичерде дә, юрганын ипләбрәк ябынып:

— Секретарь, сез протоколны әйбәтләп язып бардыгызмы? — дип кычкырды.

Әллә кайдан — аскы каттан бер хатын-кызның матур тавышы ишетелде:

— Яздым. Иртәгә тапшырырмын.

— Ярый, иптәшләр, шушының белән җыелышны ябык дип игълан итәм. Моннан соң безнең өйдә шау-шу бик нык кимер, тынычлык урнашыр дип өметләнәм,— диде управдом, канәгатьлек белән.

Аңа төрле-төрле яклардан — йөз квартирның йөзесеннән дә күнелле генә шаулашып җавап кайтардылар:

— Дөрес, дөрес!.. Әлбәттә, тынычлык урнашачак.

— Без дә өметләнәбез. Өметсез — бер шайтан гына ди!..

Тавышка каршы җыелыш бетте. Шунда ук уннарча пианинолар, скрипкалар, тальян-баяннар уйнарга, төрле торбалар шыңгырдарга, сыбызгы-курайлар сызгырырга, барабаннар кагылырга, телевизорлар кычкырырга, радиолар, магнитофоннар җырларга, бала-чагалар чыелдарга, газ плитәләре чыжылдарга, су краннары шыбырдарга, этләр өрергә, песиләр мыяуларга тотынды. Биш катлы, йөз квартирлы панельный йорт, яу кергән шикелле шаулый-дөрли, дерелди-чайкала, киерелә-сузыла, ыңгыраша башлады.

Управдом йөзен чытып торып утырды. Көрсенеп куйды. Аннан ары колакларына мамык тыгып, юрганын башыннан ук бөркәнеп ятты.



## *Мостафа Ногманга*

Арчада да Мостафа,
Чишмәдә дә Мостафа...
Мостафаның җырларында
Җырланмаган бер авыл да
Калмады бит ичмаса!..



### *Әхмәт Юныска*

Үгет бирә, киңәш бирә:
— Язасың, — ди, — алай нигә?
Алай язма, болай яз, — ди.
Тик, кызганыч, үзе язмый.



### *Рәшит Гәрәйгә*


«Кыр казлары оча җылы якка,
Күз күрмәгән ерак җирләргә...»
Рәшит Гәрәй шигырьләре никтер
Бер урында гына тирбәлә.

РАИЛ эпиграммалары



### *Энҗе Мөэминовага*

Энҗесе әйбәтен әйбәт үз атында.
Тик күренми генә никтер иҗатында.



### *Әбрар Шәмингә*

Аннан алыр, моннан табар.
Тишек-ертык икән — ямар...
Новеллист юк, димәгез сез —
Бу дөньяда Әбрар да бар.

Н. АРСЛАНОВ эпиграммалары
Б. АЛЬМЕНОВ шаржлары

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## СССР ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ V СЪЕЗДЫ

29 июньнән 2 июльгә кадәр Мәскәү Кремленең Зур сараенда СССР Язучыларының V съезды булып узды. Съезд эшендә делегатлар, кунаклар, совет культурасы эшлеклеләре, партия һәм хөкүмәт житәкчеләре, җәмәгатьчелек вәкилләре катнашты.
Съездны Социалистик Хезмәт Герое язучы Н. С. Тихонов ачты. Әдәбиятыбызның бу олы форумына Татарстан язучылары исеменнән делегат булып Зәки Нури, Сибгат Хәким, Гази Кашшаф, Гариф Ахунов, Гариф Гобәй, Геннадий Паушкин, Шәүкәт Галиев, Нәби Дәүли, Равил Фәйзуллиннар катнашты.

Мирсәй Әмир киңәш бирү хокукы белән һәм Гомәр Бәширов, Хәсән Туфан, Ренат Харисов кунак булып бардылар.

Әдәбиятыбызның уңышлары, аның үсеш тенденцияләре турында зур җаваплылык белән сүз алып барган съезд делегатлары соңыннан язучыларның житәкче органнарын сайладылар. СССР Язучылар союзының идарә составына Татарстаннан Зәки Нури һәм Мирсәй Әмирләр сайланды. СССР Язучылар союзы секретарьларының берсе итеп Татарстан язучылар союзы правлениесе председателе, шагыйрь Зәки Нури сайланды.

## ЛАУРЕАТЛАР КИЧӘСЕ

Мәскәүнең әдәбият йортында әдәби премияләр лауреатларының кичәсе булды. Бу кичәдә М. Горький исемендәге әдәби премия лауреаты шагыйрь Сибгат Хәким дә катнашты.

## ТӘРҖЕМӘ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

РСФСР Язучылар союзы секретариатында тәрҗемә советының утырышы уздырылды. Нәшрият работниклары һәм язучылар белән бергә уздырылган бу утырышта милли әдәбиятларны рус теленә тәрҗемә итү мәсьәләләре каралды. Анда татар язучыларыннан Зәки Нури, Гариф Ахунов, Ренат Харисовлар катнашты.

## ЛАЕКЛЫЛАРГА БҮЛӘКЛӘР

СССР Верховный Советы Президиумы Указы белән совет культурасын, әдәбияты һәм сәнгатен үстерүдә ирешкән уңышлары,



СССР язучыларының V съезды. Татар әдипләре немец язучылары белән. («Neues Leben» газетасында басылды.)

хезмәт иләрен коммунистик тәрбияләүдә актив катнашулары һәм бишьеллыкны уңышлы үтәүдә лаеклы өлеш кертканнәре өчен илебезнең әдәбият-сәнгать эшлеклеләренең зур бер төркеме хөкүмәтебезнең югары бүләкләре белән бүләкләнделәр. Шулар арасында татар язучылары Афзал Шамов «Октябрь Революциясе» ордены, Нури Арсланов Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, Зәки Нури «Почет билгесе» ордены белән, София Борисовна Радзиевская «Хезмәттәге Батырлык өчен» медале белән бүләкләнделәр.

* * *

Татар совет әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре өчен һәм илле яшь тулу уңае белән шагыйрь Гамил Афзал Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Почет грамотасы белән бүләкләнде.

* * *

Совет сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен һәм 60 яшь тулу уңае белән РСФСР-ның атказанган сәнгать эшлеклесе, режиссер Шириаздан Сарымсаков ТАССР Верховный Советы Президиумы Почет грамотасы белән бүләкләнде.

## ДИПЛОМАНТЛАР

Бөтенроссия китап сәнгатенең 1971 елда үткәрелгән конкурсына кырык бер нәшрият һәм алты полиграфия предприятиесе катнашты. Конкурска китаплар, альбомнар, плакатлар, репродукцияләр, эстамплар — барлыгы 263 басма эш куелган иде.

Татарстан китап нәшрияты тарафыннан конкурска куелган эшләрдән «Казан фоторәсемнәрдә» альбомы (А. Геринас рәсемнәре, Р. Кутуй тексты, художнигы С. Виноградов, төзүчесе Х. Гобәйдуллин) икенче дәрәҗә диплом алуга иреште. Татарстанның уңышлары, атаклы кешеләре турында язылган «Исәнме, туган җир» дигән очерклар җыентыгы (редакторы В. Белокопытов, художнигы Э. Зарипов) һәм татар телендә чыгарылган «Музыка әлифбасы» исемле музыкаль әлифба кызыксындыру дипломнарына лаек булдылар.

«Исәнме, туган җир» китабы өчен Камил Якуб исемендәге матбугат комбинаты кызыксындыру дипломы алды.

## БАШКАЛА УКУЧЫЛАРЫ БЕЛӘН ОЧРАШУЛАР

СССР Язучыларының V съездында катнашкан делегатлар, Мәскәүнең әдәбият сөючеләре белән очрашып, съездның эше һәм әдәбиятыбыз турында сөйләделәр. Шундый очрашуларның берсе М. Горький исемендәге Үзәк культура һәм ял паркында оештырылган иде. Анда Советлар Союзының барлык әдәбиятларыннан вәкилләр катнашты. Шагыйрь Зәки Нури бу кичәдә татар әдәбияты турында сөйләде һәм шигырьләр укыды.

* * *

Съезд көннәрендә делегатлар Совет Армиясендә хезмәт итүчеләр белән дә очраштылар. Прозаик Гариф Ахунов шул кичәдә катнашып, әдәбиятыбыздагы яңалыклар һәм татар язучыларының халык белән элемтәләре турында сөйләде.

* * *

Татар-башкорт укучылары белән уздырылган әдәби кичә бик җанлы үтте. Анда татар язучыларыннан Гомәр Бәширов, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Зәки Нури, Гариф Ахунов, Ренат Харисовлар, башкорт язучыларыннан Зәйнәп Биишева һәм Габделхак Игебаевлар катнашты. Кичәдә татар-башкорт әдәбиятындагы яңалыклар турында сүз барды, яңа шигырьләр укылды, тыңлаучыларның күп төрле сорауларына җаваплар бирелде.

## ИҢ ЯХШЫ ӘСӘР ӨЧЕН

Авыл хуҗалыгындагы зур борылышларны, авыл хезмәт иләренең яңача тормышын, соңгы елларда үсеп, күтәрелеп чыккан, коллективны зур эшләргә оештыру сәләтенә ия булган, белемле, олы тормыш таләпләре югарылыгында торып хөкем йөртерлек тәҗрибәле яңа кадрларны матур әдәбиятта кинрәк яктырту теләге белән СССР Авыл хуҗалыгы һәм хәзерләүләр министрлыгы коллегиясе һәм авыл хуҗалыгы хезмәт иләре һәм эшчеләре профсоюзының ҮК Президиумы иң яхшы художестволы әсәрләр өчен ябык конкурс игълан итте.

Конкурс 1971 елның 1 июленнән 1972 елның 1 декабрена кадәр дәвам итәчәк.

Конкурска беркайда да басылмаган роман, повесть һәм пьесалар кабул ителә.

Конкурска дигән әсәрләр, машинкада ике данә бастырылып, нинди булса да бер девиз белән җибәрелә, ә икенче бер конвертка авторның исеме, фамилиясе һәм торган урыны хәбәр ителә. Милли телләрдә язылган әсәрләр русчага тәрҗемә ителеп җибәрелә.

Конкурсның нәтиҗәләре 1972 елның 15 декабрендә билгеле булачак һәм газета-журналларда басылып чыгачак.

Конкурста иң яхшы дип табылган әсәрләргә түбәндәге бүләкләр биреләчәк:

## ИҢ ЯХШЫ РОМАН ҺӘМ ПОВЕСТЬ ӨЧЕН

Беренче бүләк — 2000 сум
Ике икенче бүләк — 1500 әр сум
Ике өченче бүләк — 1000 әр сум

## ИҢ ЯХШЫ ПЬЕСА ӨЧЕН

Беренче бүләк — 1000 сум
Ике икенче бүләк — 700 әр сум
Ике өченче бүләк — 500 әр сум.

Конкурска кульязмаларны түбәндәге адрес белән җибәрергә кирәк:
Москва, И-139, Орликов пер., 1/II, МСХ СССР «На конкурс»

## ГЫЙЛЬМИ СОВЕТНЫҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ

1971 елның 14 апрелендә В. И. Ленинның турылыклы шәкерте, күренекле революционер, Әзербәйҗан коммунистларының җитәкчесе һәм әзербәйҗан әдәбияты классигы драматург Нәриман Нәримановның тууына йөз ел тулды.

Шул уңай белән 12 июньдә СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында җәмәгатьчелек катнашы белән Гыйльми советның киңәйтелгән утырышы булып, сәнгать фәннәре кандидаты Хәсән Гобәйдуллинның «Нәриман Нәриманов һәм татар театры» исемле темага ясалган доклады тыңланды. Бу темага карата кызыклы материаллар нигезендә эшләнгән доклад уңай бәя алды.

## КАЗАН ГАЛИМНӘРЕ — ТБИЛИСИДА

Археологларның һәм этнографларның Тбилиси шәһәрендә үткәрелгән 1971 елгы Бөтенсоюз конференциясендә СССР Фәннәр академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре дә катнашты. Тарих фәннәре докторы археолог А. Халиков «Покровка чорында (бронза дәвере) Идел буе», тарих фәннәре кандидаты археолог Р. Фәхретдинов «Болгар шәһәрләрен картографияләү һәм классификацияләү», тарих фәннәре кандидаты этнограф Р. Мөхәмедова «Сергач татарларының киемнәрендә Алтай һәм Себер параллельләре», биология фәннәре кандидаты А. Петренко «Этник культура тарихы процессларын өйрәнүдә остеологик материалның (хайван сөякләренең) роле» дигән докладлар сөйләделәр. Казан археологларының һәм этнографларының чыгышлары белгечләр тарафыннан җылы каршы алынды.

## ТӨМӘНДӘ СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ КӨННӘРЕ

23 июльдән 31 июльгә кадәр Төмән өлкәсендә совет әдәбияты декадасы үткәрелде. Бу зур әдәби бәйрәмдә ун союздаш республикадан, илебезнең кырыклап шәһәреннән илледән артык язучы катнашты. Татарстаннан вәкил булып шагыйрь Әдип Маликов барды.

Совет язучылары Тобольск шәһәрендәге Завальный каберлегендә шагыйрь-декабрист В. Кюхельбекер, атаклы әкиятче-шагыйрь П. Ершов каберләренә чәчәкләр салдылар, кремльдә үткәрелгән зур митингта чыгышлар ясадылар.

Ә. Маликов Татарстан язучылары союзы исеменнән «Конек-Горбунок» (П. Ершов) поэма-әкиятенең татарчага тәрҗемәсен (Мөхәммәт Садри тәрҗемәсе) шәһәр китапханәсенә тапшырды.

Кунаклар, алты группага бүленеп, Төмән өлкәсе буйлап сәяхәт иттеләр, нефтьчеләр, урман кисүчеләр, балыкчылар, тезүчеләр белән очраштылар. Ә. Маликов Татарстаннан Төмән өлкәсенә Себер нефтен ачышырга киткән якташлары янында булды. Ул барлыгы егерме очрашуда катнашты, русча һәм татарча шигырьләрен укыды.

* * *

Июнь ахырында комсомолның Татарстан өлкә комитеты оештырган иҗади яшьләр группасы белән Җәлил премиясе лауреаты шагыйрь Равил Фәйзуллин һәм шагыйрь Рәдиф Гатауллиннар Төмән өлкәсендә булып кайттылар. Алар татар әдәбиятының бүгенге хәле турында сөйләделәр, шигырьләр укыдылар.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Әлмәт районында иң яхшылардан саналган Сөләй авылы культура йортында танылган шагыйрь Г. Афзалның 50 еллык юбилее уңае белән зур әдәби-музыкаль кичә уздырылды. Шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы турында язучыларның Әлмәт бүлеге җитәкчесе шагыйрь Равил Фәйзуллин чыгыш ясады. Юбилярны каләмдәш дусларыннан Р. Төхфәтуллин, Ю. Әминов, Ә. Маликов иптәшләр котлады. Авыл хезмәт ияләре исеменнән шагыйрьне Фрунзе исемендәге колхоз председателе Н. М. Минһаҗов тәбрик итте һәм истәлекле бүләкләр тапшырды. Кичәнең икенче өлешендә район үзешчәннәре тарафыннан концерт куелды. Сәхнәдән юбилярның җырлары, шигырьләре яңгырады.

* * *

Әлмәт бүлеге язучыларына кунакка Бөек Ватан сугышының легендарь герое, беренче «катюшалар» командиры, отставкадагы полковник Бари ага Йосыпов килде. Әлмәт авылында туып, авырлыклар-ятимлекләр күреп үскән гади крестьян улының зур хәрби белгеч, батыр командир булып китә алу тарихы каләм ияләре өчен гыйбрәтле һәм кызык иде. Бари аганың тормыш һәм хезмәт юлы әдәбият-сәнгать дөньясында беркадәр чагылыш тапкан иде инде. Мәшһүр скульптор В. Мухинаның «Полковник Б. Йосыпов» дигән бюсты Мәскәүдә Третьяков галереясында саклана. Язучы Алтайскийның «Подвиг» исемле китабы да Бари аганың сугышчан юлы хакында. Бари ага үзе дә истәлекләр язган. Кульязма китабының исеме — «Картлык та шатлык». Язучылар аңа бу китабын әдәбиләштереп эшләүдә ярдәм итәргә булдылар.

Шул ук утырышта Сирия һәм Ливанда язучылар өчен оештырылган туристлар группасында сәяхәт итеп кайткан шагыйрә С. Сөләймнованың да чыгышы булды. Ул үзенең каләмдәш дусларына гарәп илләре турында сөйләде, сәяхәт тәэсирләре белән уртаклашты.

* * *

Июль башында язучы Р. Төхфәтуллин Серафимовка (Баш. АССР) эшчеләр поселогындагы халыклар дуслыгы клубы чакыруы буенча клубның 10 еллык юбилеена багышланган тантаналы кичәдә катнашты. Мәктәпнең немец теле укытучысы Җамалетдинов инициативасы белән оештырылган бу интернациональ клубның даны еракларга билгеле. Клубның музее да бар һәм ул халыклар дуслыгын чагылдырган экспонатларга бик бай. Юбилей утырышында Р. Төхфәтуллин халык алдында чыгыш ясады һәм клубка Әлмәт язучылары исеменнән автографлар язылган китаплар тапшырды.

* * *

Әлмәт язучыларыннан Г. Афзал, Р. Төхфәтуллин Түбән Камада яшәүче эшче шагыйрь М. Хәбибуллин белән индивидуаль семинар үткәрделәр. Яшь шагыйрьнең җыентык итеп тупланган байтак күләмдәге шигырьләре тикшерелде. Беркадәресе матбугатта басылып чыгарлык дип табылды.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНДА ОЧРАШУ

Татарстан язучылар союзы эше белән якыннан танышу өчен август башларында Казанга СССР язучылар союзы правлениесе секретаре Ю. Н. Верченко килде.

Ю. Н. Верченко Татарстан язучылар союзы правлениесе партбюро членнары һәм «Казан утлары» журналы редакциясе работниклары белән очрашып, аларга СССР язучыларының V съезды нәтиҗәләре турында сөйләде, Татарстан язучылар оешмасындагы проблемалар, яңа бишьеллыкка билгеләнгән планнар белән танышты.

Казанда үткәргән көннәрендә ул шәһәрнең тарихи, истәлекле урыннарында булды, В. И. Ленин, М. Горький музейларын карады, Ленино-Кокушкинода булып кайтты. КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин һәм Татарстан язучылар союзы председателе Зәки Нури белән берлектә Куйбышев исемендәге химия заводы житәкчеләре белән очрашты. Казан киностудиясендә Г. Тукай, М. Җәлил, Татарстан турындагы фильмнарны карады.

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ,
ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ һӘМ
МИНИСТРЛАР СОВЕТЫ ОРГАНЫ

**«СОЦИАЛИСТИК ТАТАРСТАН»**
**ГАЗЕТАСЫНА**

**1972 ЕЛ ӨЧЕН**

**ЯЗЫЛЫГЫЗ!**

«Социалистик Татарстан» газетасына подписка барлык элемтә бүлекләрендә, «Союзпечать» агентлыкларында һәм эш урыннарында кабул ителә.

Татарстаннан читтә яшәүчеләр, «Социалистик Татарстан» газетасына подписка тору урынында кабул ителмәсә, акчаны турыдан-туры түбәндәге адрес белән җибәрә алалар: 420111, Казань, ул. Ленина, 8, Республиканское агентство «Союзпечати», для газеты «Социалистик Татарстан».

«Социалистик Татарстан» газетасы атнага 6 тапкыр чыга.

Язылу бәясе: бер елга — 6 сум, алты айга — 3 сум.

*Хөрмәтле иптәшләр!*

«Казан утлары» журналы редакциясе 1972 елда түбәндәге зур күләмле әсәрләрне бастырып чыгарырга ниятли:

**Мөхәммәт Мәһдиев.** Фронтовиклар. Роман.

**Эдуард Касыймов.** Кош — канаты белән. Роман.

**Шамил Бикчурин.** Каты токым. Роман.

**Мирсәй Әмир.** Балыкчы ялганнары. Повесть.

**Фәнис Яруллин.** Җилкәннәрне җил еккач. Повесть.

**Мөсәгыйть Хәбибуллин.** Шәһәрдә нарат-лар шаулый. Повесть.

**Фәнил Мансуров.** Якты тауда бүз тургайлар. Повесть.

**Нәзир Сәфәров.** Күргән-кичергәннәрем. Повесть.

**Хәниф Хәйруллин.** Таңнар якты булсын. Повесть.

**Рәисә Ишморатова.** Милиция лейтенанты. Повесть.

**Илдар Низамов.** Дәрья күзе. Повесть.

**Мәдинә Маликова.** Адашканга юл кайда? Мажаралы повесть.

**Мәхмүт Хәсәнов.** Кама таңнары. Повесть.

1972 ел өчен «Казан утлары» журналына язылу дәвам итә. Журналга Советлар Союзының барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин. Язылу бәясе:

Бер елга — 6 сум.

Алты айга — 3 сум.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210